
# КАЗАН УТЛАРЫ

10.1996



# 15 ОКТЯБРЬ — ХӘТЕР КӨНЕ



**Казан Кремле биләмәсендә салыначак Кол Шәриф мәчетенең макеты.**

*М. Шакирҗанов фотосы.*

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**10**

**(888)**

**1996**

КАЗАН


## *Бу санда*


ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

С. ПОВАРИСОВ. Яшьлек иртәсе. *Роман* . . . . 3
Ф. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. Яратуым өчен. *Шигырьләр* . . . . 86
К. СӘГАДӘТ. Җан ярам. *Шигырьләр* . . . . 128

ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН

М. ХУҖИН. Әдәбият һәм тормыш чынлыгы . . . 91
К. НАСЫЙРИ. «Кырык бакча»дан . . . . 92
Ш. КАМАЛ. Уяну. *Хикәя* . . . . 97
М. ӘМИР. Мөстәкыйм карт йокысы . . . . 101

МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВКА 50 ЯШЬ

М. ӘГЪЛӘМ. Төрле еллардан. *Шигырьләр* . . . 106

САҖИДӘ СӨЛӘЙМАНОВАНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Л. ИХСАНОВА. Дустымның ун хаты . . . . 115
С. СӨЛӘЙМАНОВА. Шигырьләреннән кайбер үрнәкләр . . . . 120

ӘЗҺӘР ГАБИДИГӘ 70 ЯШЬ

Р. ГАТАШ. Ихласлык — шагыйрьлек тә . . . . 125
Ә. ГАБИДИ. Аккошлар китә. *Шигырьләр* . . . 126

РАФАЭЛЬ СИБАТКА 50 ЯШЬ

ЗӨЛФӘТ. Сер . . . . 132
Р. СИБАТ. Өчтомлыкны укыгач өч сүз . . . . 133

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Р. ФӘТХЕРАХМАНОВ. Тормыштан килгән геройлар . . . . 149

МӘДӘНИЯТЫБЫЗ ТАРИХЫНА

М. ГОСМАНОВ. Тагын бер әдәби ачыш . . . . 159
Р. МӘРДӘНОВ. Гасый җафи Мәүла Колый сүзли, дуслар... . . . . 160
М. Колый. Берекәннәр сыйфаты . . . . 164

МӘДӘНИ МИРАС

Х. МИҢНЕГУЛОВ. Нинди төскә керсә дә, асылы бер . . . . 172
Г. ИСХАКЫЙ. Бугазлар . . . . 175

ХАЛКЫБЫЗНЫҢ КҮҢЕЛ ХӘЗИНӘСЕННӘН

И. СИРМАТОВ. Бер дәфтәр моң . . . . 180

Укучы сүзе . . . . 179
Безнең календарь . . . . 179, 189
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан . . . . 190

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Нәҗип Бакиров**
**Тәлгат Галиуллин**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Булат Солтанбәков**
**Ренат Харис**
**Розалина Шаһиева**
**Харрас Әюпов**

Бeзнең адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары —
49-36-09,
җаваплы сәркатип — 43-56-12,
бухгалтерия — 43-56-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: начало романа С. ПОВАРИСОВА «Утро юности»; стихи М. АГЛЯМОВА, А. ГАБИДИ, Ф. ГИЗЗАТУЛЛИНОЙ, К. САГАДАТ.
«Из сокровищницы татарских рассказов»: рассказы К. НАСЫРИ, Ш. КАМАЛА, М. АМИРА.
«К 70-летию Сажиды Сулеймановой»: статья Л. ИХСАНОВОЙ «Десять писем подруги» и стихи С. СУЛЕЙМАНОВОЙ.
«К 50-летию Рафаэля Сибата»: статья Р. СИБАТА посвящена выходу в свет трехтомника избранных стихов Р. Файзуллина.
«Литературная критика»: статья Р. ФАТХЕРАХМАНОВА «Герои из жизни».
«К истории культуры»: статья М. УСМАНОВА «Еще одно литературное открытие» и Р. МАРДАНОВА «Новые материалы из творческого наследия Мауля Колый», стихи МАУЛЯ КОЛЫЙ.
«Культурное наследие»: статьи Х. МИННЕГУЛОВА «Сущность одна...» и Г. ИСХАКИ «Проливы».
«Богатство народного творчества»: статья И. СИРМАТОВА «Песенник».
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Сююмбикэ» — фоторепродукция с картины художника Василя Ханнанова; писатель Рафкат Карами.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Тәүфикъ Әйди.**
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.

Производствога бирелде 5.09.96 ел. Басарга кул куелды 11.10.96 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 $^1/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 10 544. Заказ Е-447.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1996 ел.

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



**Суфиян Поварисов**

# ЯШЬЛЕК ИРТӘСЕ

РОМАН

*Яшисе, мең, миллион ел яшисе килә...*
*Ләкин моңарчы булган кызганыч тән яшәве*
*белән түгел, башка бер яшәү белән,*
*матур, изге, биек яшәү белән яшисе килә.*
Галимҗан Ибраһимов

## Дүртенче бүлек

### I

Гәүһәр! Аны диңгез төбеннән чумып эзлиләр. Әмма ул анда — диңгез төбендә таудай өеп куелмаган. Аны табу, башка асыл ташлардан аерып алу өчен, бисмилланы мең-миллион кат әйтеп, диңгез төбендә, бер өем чүптән ярма бөртеге эзләгән тавык шикелле, чокчынырга кирәк. Тормышта бәхет-гәүһәр табу һич тә аннан ким түгелдер. Авыррактыр да әле. Бу хакта һәр ата-ана җитди уйлана. Борчыла. Фикер йөртә. Гыйрфан мулла, Хәсәнә абыстай өчен бу көннәр аеруча көчле пошаманлык, нәзер дулкыны эчендә үтте. Ни гаҗәп, мәсьәләнең мөгезеннән тотарга, кылны кырыкка ярырга гадәтләнгән Гыйрфан мулла да соңгы көннәрдә шәванә пәрдәсенә төренеп, берникадәр «бәлтерәп» калды. Аяк астыннан һич көтмәгән бәла-каза, низан-мазар килә дә чыга. Хөрмәтулла мәсьәләсе бөтенләй аяктан екты. Ата-бабаларыбыз чыгарган мәкальләрне дә искә алды ул: «Йөз юл — мең хата». Янә: «Карының белән кар ярып, борының белән боз ярып булса да юлыңны тап»; «Ниятең кәкре булса, юлның турылыгы файда итмәс...»

---

Суфиян ПОВАРИСОВ (1924) — *язучы, галим, филология фәннәре докторы, профессор, 200 дән артык фәнни хезмәт һәм күп кенә әдәби әсәрләр авторы, Башкортстанның атказанган фән эшлеклесе. Уфада яши.*

Әсәр кыскартып басыла. Аның монда кертелмәгән беренче өч бүлеге «Тулпар» (Уфа, 1995. № 1—2) журналында дөнья күрде.

Йөз юлда мең хата булу аныңсы инде аның табигый хәл. Пәйгамбәрләр дә хатасыз яшәмәгән. Бу да аларның дөнья серен аңлап бетермәвеннән килә. Әйтик, шимбә — хәйлә көне. Шуны белми юлга чыккан алты пәйгамбәр (Салих, Нух, Гайса, Муса, Ибраһим, Мөхәммәт галәйһиссәлам) бәхетсезлеккә очраган. Менә бит йөз юлның мең хатасы нинәрсәгә барып бәйләнә. «Борының белән боз ярып булса да тап юлыңны». Менә терәкә! Ай-һай, каты әйтелгән! Ләкин дә юлда ниятең дөрес булсын. Шунсыз сиңа ак җәймә җәймиләр.

Боларны Гыйрфан мулла яхшы белә. Биш бармагы кебек. Әмма ләкин юлга чыкканда көн сайлау мәсьәләсе дә, әгәр арттырып әйтсәк, хатын ярәшү кеби җаваплы эштер. Гыйрфан мулла моны да яхшы аңлый. Җомга мөселманнарның бәйрәм көне. Адәм галәйһиссәлам дөньяга килгән көн бу. Аңа дога кылып, сәҗдәгә китеп, илаһилык эчендә хозурлана торган көн. Мондый чакта юлга чыгу килешеп бетмәс. Пәнҗешәмбе дә яман көн түгел. Аллаһы Тәгаләнең җәннәте вә җәһәннәме шушы көндә барлыкка килгән. Җәннәте — әйбәт, җәһәннәме — шомландыра. Сишәмбе — Кабил Хабелне үтергән көн. Үтереш, суеш — мәңгелек яманлык. Чәршәмбе. Бу көнне Юныс пәйгамбәрне балык йота. Ибраһим пәйгамбәрне Нәмруд ләгыйнь утка сала. Якшәмбе — мөселманнар өчен бәракәтле көн түгел. Һәр көнне Аллаһы Тәгалә үзе яраткан. Шулай да һәр көннең үзенчәлеге бар. Юлга дүшәмбе көнне чыгарга кушалар. Бу көн, имеш, алда башланмаган юлларны искәртә, һәрберсендә булган бәхет-сәгадәттән өлеш чыгара. Бу юллар бәндәләрне киң дөньяга алып чыга. Шунда һәркем үзенә яшәү гәүһәре таба, имеш.

Дүшәмбе көнне чыкты юлга Гыйрфан мулла. Аның уенча, изге юл бу: Аллаһы Тәгалә юлга ак җәймә җәйгән мәл. Сызылып таң атып килә. Аның алсу нурлары бөтен инсаниятне назлый, иркәли, юата, кайгылардан араландырып, үзенчә бер рухи шифа өрә төсле иде. Ләкин дә юлчыны син өмет иткән оҗмах түгел, көтелмәгән тәмуг каршы ала икән. Авылдан чыгып китү белән, әлеге таң алсулыгын кара-кучкыл болыт каплады, әллә нинди салкын җилләр исеп, коточкыч буран купты. Җил әле бер яктан китереп суга, әле икенче яктан китереп бәрә. Ул, гүя, юлчыларның ныклыгын сыный, аз гына йомшаклык күрсәтсә, очырып, җәһәннәмгә алып олактырмак була.

Әле ни арба, ни чана түгел чак. Гыйрфан мулла әлеге теләсә нинди дыңгырдык юлдан үтәрдәй тимер арбасын пар атка җикте. Печәнен, солысын, азык-төлеген — бөтенесен шунда төяде. Дилбегәне башта Шакирҗанга тоттырды: мә, йоклама, оеп барма, аң бул, инде шәләй-вәләй малай түгел, ир корына җитеп килүче, янәсе. Шулай да бераз баргач, дилбегәне үз кулына алды ата кеше. Чөнки, ни генә димә, ат дилбегәнең кем кулында икәнлеген тиз сизә. Дилбегә тимер кулга эләксә, ул колагын каты торгызып, башын күтәрә төшеп, аякларын каты-каты басып атлый. Камыр кулга эләксә, колакларын юешләнгән бияләй урынына салындыра, башы бәлтерәп кыйгая башлый, аяк атлаулары ташкүлчимгә әйләнә. Дөрес, пар атның икесендә ике төрле җәһәтлелек, сизгерлек, тоемлау. Туры бия, «минем өчен Әхмәтдин ни, Мөхәммәтдин ни», дигәндәй, кеше кулы сайлаучан түгел — үз җаена җилдерә бирә. Тимеркүк башка «калыптан»: шәйләмирәк калсаң, холкын бозсаң, чыгымчылый торган гадәте бар хәтта.

Әлбәттә, атның юлда уңганлыгы аны җигә белүгә дә бәйләнгән. Бу җәһәттән Гыйрфан мулла осталыгына җиткән кеше авылда гына түгел, бөтен тирә-якта юктыр әле. Дугасы аның, тәкәббер кеше маңгае кебек, аз гына алга киерелеп торсын. Мәгәр нык торсын. Мең дию пәрие уптым илаһи берьюлы өрсә дә, аслан селкенерлек булмасын. Ерак юлга чыккач, атка бер минут та йомшаклык күрсәтергә ярамый. Кирәк чакта йөгерт. Чаптырып та ал. Тау итәгендә атлат. Ат йөртә белү — ир-егет эше. Ат — ир канаты ул. Шуларны өйрәтә-өйрәтә чәчәнә, сакалына кырау төште инде. Әмма ләкин һаман төрле яклап тәртә арасына кертеп

булмый бу юеш борыннарны. Һич кирәкмәгәнгә дилбегәне әле уңга, әле сулга тарткалыйлар бит. Ни фәтвасын күрәдер шуның. Мондый каткanак, кылдый-былдый юлда тәгәрмәчең эләксә бер дүңгәккә — арбаң авып, әллә кайда тәкмәчләп барып төшүең бар. Менә сиңа мең хатаның берсе.

Дилбегәне үз кулына алырга булды ата кеше. Шакирҗан:

— Әткәй, үзем... син ял ит...— дип караса да, тыңламады.

— На-а-а... Һәй, малкайлар, уңганнар, һайт,— дип калын тавыш белән бер кычкырып, үзенең каты куллы икәнлеген сиздереп алгач, аңладык ниятеңне хуҗа-әфәндем дигәндәй, атлар дәррәү уянып, җай гына юыртып киттеләр.

Галимҗанны ул толып белән төреп утырткан иде. Дөресрәге, моны әнкәсе эшләде.

— Кем... сиңа әйтәм... әйкәем... Галимҗанны берүк саклый күр инде... салкын тимәсен... гелән авыргалап тора бит...— диде.

Шуңа охшаш янә мең төрле вәгазь әйтте. Дөрес, мондый чакта, үгет-нәсихәт тау-тау өелсә, Гыйрфан мулланың ачуы кабара, тәне кызыша, аркасы буйлап кырмыскалар йөгерешкәндәй тоела башлый. Аның бу «кыргыйрак» гадәтен, сүз белән кытыклауны яратмаганын остабикәсе белепме белә инде. Шулай да ул хатын-кызга хас өйрәтү-төпчену хосусиятен, бала өчен ана йөрәгенең ни дәрәҗәдә өзгәләнгән-сызланганлыгын, бөтен илаһи бәхетенең шуларда икәнлеген сиздерми калмый.

Галимҗан, әнисенең сабак урынына кат-кат тугылаган йөрәк сүзләреннән чыкмаска тырышып, толып эчендә майдай «эреп» барды. Пәри туендагыдай уйнаклап-муйнаклап, котырынып искән салкын җилдә дә, кар катыш яуган яңгырда да әллә ни гаме юк иде аның. Үткән хатирәләр давылы эчендә йөзде ул. Давылларда, Алып батырны хәтерләтеп, Хөрмәтулла абзый кайнаша.

Нәҗметдин мәзин келәтенә ябып куйгач, болар өчен аны коткаруның бер авырлыгы да юк иде инде. Чөнки Галимҗан, Апуш, мәзин малае Кәли — балыкка бергә йөрүчеләр. Алар, әйтергә уңайлы булсын дип, исемнәрен дә кыскартып бетерделәр. Габдулла — Апуш, Кәлимулла — Кәли, Галимҗан Галим булып калды. Һәрберсенең икенче кушаматы да бар. Галимҗан — «Чирлечәүкә», Габдулла — «Чуртан», Кәлимулла — «Кикрикүк». «Чуртан» кушаматы Апушка суда оста йөзгәнгә бирелде. Кәли әтәч булып кычкыра белә. Галимҗанныкы — чиргә бәйле.

Күп вакыт алар бер-берсенә әнә шул икенче кушамат белән эндәшергә ярата: моңа берәү дә үпкәләми. Бу — дусларча шаяру. Дуслык, янәсе, вак-төяк кети-метиләрдән өстен тора.

— Сарыгын әллә табабыз, әллә юк, әйдә, Чуртан, Хөрмәттулла абзыйны коткарабыз,— диде Галимҗан балыкчы дустына.

Тегесе җилкәсен кашып алды, аз гына уйланып торды:

— Ә ничек? Йозагы бозау зурлыгы бит...

— Кикрикүккә әйтик: ачкычын урласын...

— Башың тубал кебек синең, Чирлечәүкә...

— Соңыннан макташырбыз. Эшне гамәлгә ашыргач...

Барысы да, майлы табада шуган коймак шикелле, бик җай гына барды. Кикрикүккә ачкычны табу да, инде төн уртасында авыл тәмле йокыга талгач, бозау-йозакка аны ярату да әллә ни кыенга туры килмәде. Җитмәсә, каравылчы Садретдин карт та кайтып киткән. Тукмалып, имгәнеп беткән кеше түгел, бу таш келәтне шайтан үзе дә ватып чыга алмас, дип уйлагандыр инде. Тик бөтен эшне Хөрмәтулла абзый үзе бозды. Башта, билгеле, төн заманында ачып кергәнгә аптырап калды ул. Кем? Ни өчен? Аларга аннан ни кирәк? Дөрес, аның бу кичерешен ачып керүчеләр белми. Чөнки караңгы. Ай яктысы бераз төшсә дә, бер-берсене танырлык түгел.

Алар башта, ни кылырга белмичә, беравык тын торды. Аннан, үзләренең кем икәнлекләрен әйтеп, дуслары исеменнән Галимҗан сөйләде.

Каравылчы картның кайтып китүе, ачкыч табып, ишекне ачулары, котkарырга килүләре турында әйтте.

— Сез хәзер качыгыз, Хөрмәтулла абзый,— диде Галимҗан.

Хөрмәтулла тиз генә җавап бирмәде. Сөйли башлагач, аның көчкәкөчкә тын алуын, авыр хәлдә булуын аңладылар.

— Җук, малайлар, качмыйм, җарамый... Пәчәму?.. Пәтәмуште... җарамый... Мин ул ысволыч карун мәлгун... мөртәт... кара җөрәк... ач күз хәсиснең сарыгын ырламаган... и вчу... Сарык ырларга минем башым тай типмәгән бит... вәт тәк... мин шуны халыкка... урам хөкеме вакытында аңлатып бирергә тиеш... Качсам... сезгә дә сүз килер бит... Белмәй калмаслар... Минем өчен хатыным... балаларым ыстырадайт итәчәк... Качсам... сарыкны дисвителне шул Хәрти урлаган диерләр... «Ат карагы» дигән «дан»нан курыкмыйм мин... Вәт тәк... пәнимәйт нады... Сарык буры даны алганчы... җыгылып үлим... и вчу...

Малайларга аның бу кыланышы бик сәер тоелды. Галимҗан өчен бигрәк тә. Теге вакытта беренче карашка гәрчә начар тәэсир калдырса да, аның эчендә нииндидер асылташ барлыгы аңлашылган иде. Ул асылташ әле менә зурая барды, зурая барды. Тора-бара ул кешелеклелек горурлык бизәге булып балкыды. Әтисенең дә, әнисенең дә: «Кеше күңеле — тирән дәрья» — дигән сүзләре раска туры килә. Тулган айдай балкып торган җәмәгате Мәликә түти дә, акчәчәкне хәтерләткән кызы Мәдинә дә аның күз алдына фәрештә сынлы булып килеп басты.

Мондый очракта Галимҗан үзе нишләр иде икән? Качар идеме? Качмас иде. Бу бит намусыңнан качу була. Үз авылында начарлык калдырып китәсе килми Хөрмәтулла абзыйның. Дөреслек, намус өчен ул йодрыгы белән дә көрәшкән. Хәзер дөреслек өчен үлемгә бара. Чыннан да, тереләй күмеп куюлары бар бит. Мондый хәбәр тирә-як авыллардан килеп кенә тора. Хөрмәтулла абзый шуннан да курыкмыймы?

## II

Икенче көнне Хөрмәтулланы халык хөкеменә алып чыктылар. Хөкем «Алпавыт» урамы уртасында булачак. Төне буе нур сипкән табактай ай, вәхшәтне мин дә күрим дигәндәй, яктыргач та әле зәңгәр күк йөзеннән күзләрен чекрәйтеп карап торды. Ул күзләр көянтә-бидрә күтәреп торган Зөһрә сылуныкы иде төсле. Нурлар, бәлкем, шул саф, садә, моңсу күзләрдән түгелгәндер. Зөһрә ул моңсу сафлыкны Айга җир дөньясыннан алып меңгән бит. Димәк, Ай йөрәге белән Җир йөрәге бер-берсенең сөю-мәхәббәт ялкыннары кайнарлыгын тоеп тибә. Шулай да Айның йөзе бүген боек, борчулы, кайгылы иде. Әллә Зөһрә-Алиһәнең Җир кешеләре язмышы өчен сызлануымы бу? Җир шартлап ярылырдай зур гөнаһлар эшлисез, кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә каршында ни җавап бирерсез, Адәм балалары фани дөньядан мәңгелеккә саф күңел белән килергә тиеш, диме?

Чулпанның да йөзе бүген башка көннәрдәгегә караганда сүренкерәк, моңсурак, хәсрәтлерәк тоелды. Ул таңны уятырга куркыбрак торды, хафаланмады, сабыр итәргә тырышты сыман. Һәркемнең үз йолдызы бар ди бит. Димәк ки, Җир йөрәге белән Ай йөрәге, Кеше йөрәге белән Йолдыз йөрәге эчке нурлар, эчке яшәү җепләре, эчке чылбырлар аша бер-берсенә тоташкан. Кем белә, Чулпан — Хөрмәтулла абзый йолдызыдыр, бәлки. Шул йолдызның йомшак нурлары иркәләве хозурында килгәндер якты дөньяга. Шул кешене үлем көтә. Нахак бәла тактылар. Бу гаделсезлекне, бу фаҗигане, бу коточкыч хәлне күреп тетрәнмәсме таң сылуы Чулпан? Тетрәнер, әлбәттә. Йөрәге ярылыр чиккә җитәр. Нур урынына яшь түгәр. Шулай да чыдар. Ыңгырашканын сиздермәс. Түзәр. Йолдызлар түземле була. Җир-Ана да түземле. Алар фани һәм ахирәт кануннарын белеп яши. Җир-Ана секундына 30 чакрым тизлек белән оча.

Кояш җиле чаганы итәгенә ябышып. Әмма башка планеталарга орынмый. Үз юлы белән җилдерә. Адашмый. Белеп. Аңлап. Әдәплелек саклап.

Кешеләр әдәпсезләнә. Бер-берсен ашый. Ерткычлана. Ай белән Чулпанның йөзе бүген шуңа кайгылы булгандыр. Уттай янып чыккан кояш ул йөзләргә кызгылт нурлар сипте. Хәзер дөньяга мин хуҗа, дигәндәй, колачын җәеп, акрын гына, күккә күтәрелә башлады. Тегеләр шул кызгылт нурлар пәрдәсе артында яшеренеп калды.

Хөрмәтулланы Кояш дилбегә буе чамасы күтәрелгәч алып килделәр. «Алпавыт» урамына. Һәркемнең үз дөньясындагы шәхси мәшәкате саеккан мәл. Иртәнге намаз укылып, чәйләр эчеп алынган. Көтүгә маллар куылган. Хәзер һәр кешенең «менә мине күр», «кичә дә яныма килмәдең», «нигә тотынмыйсың», дигәндәй, кырык җирдә кырылып яткан кырык эше борынын сузып тора. Шуңа чаклы Хөрмәтулла «эшен» тозлап-борычлап, җайлап-майлап, яңадан мәңге баш күтәрмәслек итеп тапталган үлән кебек бастырып куярга кирәк.

Староста Тәхлис, таң күзеннән торып, итәк астыннан ут йөртү сәпәрәйлегенә кереште. Сүзе сыярлык һәркемнең — дус-иш, таныш-белеш, күрше-күлән, кардәш-ыру капкасын какты. Дөрес, утны ул моңа чаклы да әллә кемнәрнең итәген көйдерер дәрәҗәдә йөртте. Аңа сүзен өскә чыгарырга кирәк. Сүзен боз капламасын. Кешеләр арасында адәм мәсхәрәсенә калдырып, яшәү җәймәсе булып җәелгән вазыйфасыннан аны кибәк урынына җилпеп ташламасыннар. «Тереләй күмәргә» дигән карар чыгару өчен өч шаһит булу мотлак. Аларын да тапты. Дөресрәге — яллады. Акча тамызып. Бәхет бакчасы вәгъдә итеп, кул кулны юа, дигәнне аңлатып. Бер ярма бөртегенә алданып, пычак астына кергән аңгыра тавык кебек, Ходаның сынык икмәккә җан сатучы ахмаклары беткәнмени.

Мөбахис мәзин исә староста төрткән хәйлә утына даими рәвештә ялкын өстәп торды.

— Чын ир-егет икәнлегең, пычрак эшләргә каршы көрәшүче илаһи зат булуың, кешелеклелегең менә шушы изге эшне мәртәбәле итеп башкарып чыга алуыңда күренер; Аллаһы Тәгалә алдында йөзең ак, намусың пакь булыр,— дип котыртты.

Тәхлис — хәйлә ялгашыннан бер пот тоз ялаган бәндә. Мөбахис ялкынын тиз генә дөрләтеп җибәрү ягында түгел. Аның да үз туксаны туксан.

— Син шулай дисең дә ул, мәзин абзый, ул бит миңа гына бәйләнмәгән; кара халык — аңгыра сарык, дип сөйләшсәк тә, кара халыкның бөркет күзле, бүре тешле булганнары да бар; бәгъзе берсе бугазыңны чәйнәргә әзер тора,— диде.

Йодрык зурлыгы башын тотып, бераз уйланып торгач, ул янә дәвам итте:

— Үткер тешләләр, үзең беләсең, байлар арасында да чәчеп үстергән кебек. Бар син, якалашып кара Гыйрфан мулла белән, җаныңны суырып алып, уч төбеңә китереп салыр. Теле белән тегермән тарта, акылы белән дөнья кайната, үткерлеге белән кылдан нечкә, кылычтан үткер сират күперен үтә белә. Андыйлар белән чәкәләшү, ай-һай-һай...

Мөбахис мәзин, яктылыктан курыккан ябалак шикелле. Гыйрфан мулланы беркемнән дә мактатасы килми иде. Киресенчә, алтын базыннан чүп эзләгәндәй, аның үзенә дә, гаиләсе һәм балаларына да, җае туры килгән саен, пычрак ату ягын хуп күрде. Әле дә менә аның бакчасына таш атарга тотынды:

— Ходай каршында энә очы зурлыгы да гаебем юк, Тәхлис туган, үзең шаһит: Солтанморатка ямь өстәрдәй менә дигән дөнья тергездем, күпләр миннән өлге ала, тик шушы хакыйкатьне Гыйрфан мулла аңламый, мине адәм рәтле яшәгәнгә битәрли. Дәхи дә үз урынын яулап алуымнан шүрләп йөри. Бәс, шулай булгач, кем әйтер аны кара эчле

түгел дип. Кара эчлелек мөселман бәндәсе өчен ифрат дәрәҗәдә түбән сыйфат ул. Без Гыйрфан кебекләргә Аллаһы Тәгаләнең бәндәләргә биргән миһырбанлыкларын аңлатырга тиешбез. Бу изге эш өчен көрәшү зарурдыр. Әлгаязе билләһи, дөрес эш өчен бер Аллаһуның рәхмәте киңдер.

Адәм баласы Алла исеменнән әнә шундый төрле җаһиллыкка барудан һич тартынмый. Ап-ак сөт өстенә дегет тамызудан курыкмый. Бу мәсьәлә Мөбахис мәзин файдасына хәл ителсә, бөтен Солтанморатның ак күңелле халкы намусына кара тап сарылырга мөмкин. «Солтанморат» сүзе үзе үк тирән мәгънәгә ия. «Солтан» — хөкемдар, патша, газиз дигәнне аңлата. Солтанат патшалык, газизлек, мәһабәтлек, олылык, зурлык дигән төшенчәдә. «Морат» — максат, теләк, теләнгән әйбер, аңлатылырга, билгеләнелергә уйланган нәрсә. Димәк ки, хөкемдарлылык, газизлек, мәһабәтлелек, изгелектә максатыңа ирешү өчен уйланган эшеңне сафлык илә гамәлгә ашыр.

Гыйрфан мулла кебекләр күңелендә шундый уй-хисләр кайнашты. Аңа киңәшкә якыннары, фикердәшләре, дус-ишләре килеп торды. Башкорт Котлызаман да кара кашлы, шомырттай кара күзле, өзелеп китәрдәй нечкә билле, бер басасы урынга биш басып торган дәртле бичәсе Көнсылуын ияртеп килеп җитте. Күрше авыл чувашы Ычтапан да көтмәгәндә пәйда булды. Гыйрфан мулла үзе дә аптырашта калды. Кем ул? Патшамы? Хөкемдармы? Әллә бу чуалган җеп очын ул гына табарга тиешме? Моның өчен берникадәр горурланып та ала. Эчтән генә. Беркемгә дә сиздермичә генә. Аның белән исәпләшәләр икән, димәк ки, ул тишек арба төбеннән төшеп калганнардан түгел. Ә инде Галимҗанның түбәсе күккә тия яза. Әнә кем икән аның әтисе! Халыкны, авылны афәттән, ялганнан, бәладән саклаучы олы җанлы, туры сүзле, миһербанлы кеше икән!

Галимҗан, һәр мөмкинлектән файдаланып, аларның сүзен әрекмән колакларын торгызып тыңларга тырышты. Ул сүзләрне күңеленә, йөрәгенә салып, янә ми күзәнәкләре дулкынында чайкалдырып, шулар аша кешеләргә бәя бирде. Ычтапан картны яхшы белә ул. «Кирфан ыснакум», «Пына син тыңна әле», «Бер пикер килде пашка» кебек сүзләр әйтә-әйтә килеп керә дә, кулларын болгый-болгый сөйләргә тотына. Бу юлы да шулай итте. Исәнлек-саулык сорашып алу белән сүзгә кереште:

— Кирфан мылла... аны... Кәртине... Кәрмәйне... әй лә... Күрмәтулланы... пик якшы пеләм пит мин... Ишек ясап пирде... Кулы алтын прәме... Нәстәяшчи мужик... Шуңа акча пирдем. Ул акчага Әпсәләмдә сарык ите сатып алган... Шул итне пешергәндә... теге күршесе ач күз Кәмәтдин поронына тәмле ис килеп пәрелгән икән... ну пит сарык ырлаган дигән сүз түгел... Ашакач кабырка суйәкләрен ишек алдына чыкарып ташлаган икән... пында кумакай Мүкәпис пәзин сарыкның ни катнашы пар... Ай-яй-яй, ай-яй-яй... Султанморатта пынтай алама кәлнең пулганы юк ите пит әле... Мин Күрмәтуллага азырак күмүшкә дә пиреп йебәргән идем. Әйдә, мин әйтәм, тутыккан табак төбен бер юып алсын... Җәл пит парин...

Ычтапан агай сөйләде дә сөйләде. Шуларның бөтенесен дә урам хөкеме вакытында әйтәчәген белдерде.

Галимҗанның моңа чаклы Ычтапан картка нык игътибар иткәне юк иде. Бүген аның ихлас күңелдән, чын йөрәктән, кеше язмышы өчен кайнар хис белән сөйләвен мөкиббән бирелеп, эчке бер җылы тойгылар белән, һушы китеп тыңлап торды. Үзе бәләкәй генә ул Ычтапан бабай. Мондый кешене «кәтүк» дип йөртәләр. Ябыклыгы кипкән балыкны хәтерләтеп тора. Калак сөякләре дөя үркәче кебек калкып чыккан. Эчкә баткан яңаклары, нуры сүнеп кысылган күзләре, самавыр күрегенә охшап җыерылган тар маңгае...— барысы, һәммәсе ачы, авыр тормыш тамгасы икәнлекне аңлатып тора. Шул карга күтәреп алып китәрлек карт чуваш-

ның эчке дөньясында, күңелендә, йөрәгендә — күпме рухи байлык, кеше язмышы өчен яну-көю, сызлану...

Язгы кояш кебек балкып, җил-җил атлап, көлә-көлә, уйнаклый-уйнаклый, чегән кызларына хас кыюлык һәм җитезлек белән килеп керә торган Көнсылуны Галимҗан яхшы белә. Ә менә ире Котлызаман кыяфәтенә беркайчан да сынаулы караш ташлаганы юк иде. Аның бөтен гәүдәсе карт аюны хәтерләтеп тора. Карашы, гүя, сөзәргә әзерләнгән үгезнеке. Ике бит очы куш йодрыктай бүлтәеп, кабарып тора. Күзләре асылынып төшкән маңгай белән шул «йодрыклар» эченә кереп кысылган. Муены — самавыр юанлыгы. Дөрес, очларын бөтереп ике якка җибәргән (алар карлыгач канатын хәтерләтеп тора) куе кара мыегы йөз шөкатьсезлеген берникадәр күләгәләп тора. Яшь чагында ул ун ел буе өзлексез мәйдан тоткан, имеш. Сабантуйда берәүгә дә бил бирмәгән, ди. Шул батырлыгына, җисмәни көченә, кара мыегына, аюныкыдай гәүдәсенә кызыкканмы булдыклы, алтын куллы, эш сөючән, чибәр Көнсылу тути?

Бу юлы Котлызаман агай үзе генә килде. Әлеге дә баягы шул Хөрмәтулла абзый язмышы турында фикер алышырга, киңәшләшергә, мәслихәтләшергә. Галимҗан, бер почмакка посып, аны да тыңлап торды. Бу инде Ычтапан дәдәй кебекләрнең утызын арт ягына утыртып каезлардай пәһлеван. Галимҗан өчен шунысы сәер тоелды: бервакыт ул Хөрмәтулла абзый белән көч тә сынашкан икән. Мәгәр бирешмәгән Хөрмәтулла абзый. Моны ишетеп, Галимҗанның колаклары, чәчләре үрә торды. Әлбәттә, Хөрмәтулла абзый да услаптай кеше. Ләкин ул — Котлызаман агайның яртысы гына.

Мәсьәлә болай тора икән. Котлызаман агай көрәшүнең бөтен серен нечкәлегән, җаен бәләкәй чакта ук өйрәнеп алган. Ә менә сугышканы булмаган. Сугышта бәгъзе берәү серткыч бүрегә әверелә. Анда төлкегә хас хәйлә дә була. Гәрчә көрәштә әллә күпме еллар мәйдан тотса да, Котлызаман агай, Хөрмәтулла абзый кебек, сабан туе ямен җибәреп сугышучыларны йодрыклап йөрмәс иде. Менә сиңа адәм баласы. Менә сиңа инсаният хәяты. Менә сиңа бәндәнең бәләкәе, зурысы, бәхетлесе, бәхетсезе. Галимҗанның күз алдында әлегә өч сын: күшеккән тавыкка охшап калган Ычтапан дәдәй, аю кыяфәтле Котлызаман агай, маймылга тартым Хөрмәтулла абзый. Авырлыкларны үлчәү өчен бизмәнгә салсаң, беренче урынны — башкорт Котлызаман, икенчене — мишәр Хөрмәтулла, өченчесен чуваш Ычтапан алыр. Ә инде аң-акылларын салсаң бизмәнгә, нинди дер аерымлыклар булса да, өчесенеке дә бертигез тартырга мөмкин. Бу аларның авыр чакта да кешелекле була белүләренә бәйләнгән. Котлызаман агай да бит, нәкъ Ычтапан дәдәй кебек, Хөрмәтулла абзый язмышы өчен сөйләшергә килгән.

— Башкорт мактанырга яратмый, мулла абзый, ундай гәзит миндә лә юк, үзең беләһең, һугышыусыларзы ла енем һаймай; көрәштә майдан тотһам да, мәгәр кешегә үлеп асыуым килгәндә лә тырнак менән сиртмәнем; тик был юлы Хөрмәтулланы терелләй күмергә йөрәүселәргә быуа был кәшәкә йозрогом менән «һыйлайым» әле...

Сөйләшү, фикер алышу, сүз куешу шактый озакка барды. Нәтиҗәсөземтәне һәр очракта Гыйрфан мулла ясады. Ычтапан дәдәй, гәрчә күңеле саф булса да, сөйләгәндә, тел осталыгы җитмәгәнлектән, салулый торган гадәте бар.

— Уйламый әйтелгән бер сүз — аз ашка салынган күп тоз, Ычтапан кордаш, әгәр сөйләсәң, сүзләреңне чамалап чыгарырга тырыш, буталырлык булма,— дип кисәтте аны Гыйрфан мулла.

Котлызаманга да кисәтү ясады:

— Йодрык — берне, акыл — меңне җиңгәнлекне беләсең бит инде, Котлызаман туган, син алай бик әтәчләнмә әле, мондый буталчыклыкта уйлап эш итү хәерлерәк булыр,— диде.

# III

«Алпавыт» урамы уртасына халык умарта күче урынына ябырылды. Карт-коры, бала-чага, бичә-чәчә, кыз-кыркын...— кемнәр генә юк анда. Бәгъзеләрем мулла-мәзин, мөтәвәли-фәлән, хәлле-мәлле кебекләре җомгага, гаеткә барганда, аш-суга йөрешкәндә генә кия торган затлы чапан, казаки, түбәтәй, итек-читек кигәннәре, анда-санда тамак кырыштырып, үзләрен бөркет оясындагы асылташны эләктерә ала торган каһарман ир-егет икәнлекләрен күрсәтергә тырышып, чыш-пыш сөйләшеп йөриләр. Өсләренә укалы чибәр камзул, аякларына болгар читекләре кигән, башларына аллы-гөлле яулык бәйләгән бәйбичәләр төркеме дә агыла. Алар, инде түл җыеп та мәңге гөпләшеп туя алмаган ана үрдәкләрдәй, үзенчә бер горурлык сакларга тырышкан кыяфәт белән, мыгыр-мыгыр сөйләшеп атлыйлар. Ак күлмәк өстеннән кара камзул, аякларына көзгедәй елтырап торган күн итек кигән, бер басасы урынга биш басып торган түбәтәйле кыланчык, көяз, шаян, хәлле егетләр дә төркем-төркем булып масаеп йөри. Алар икенче бер төркемгә — һәрберсе бер чәчкәне хәтерләтеп торган кызлар җыелмасына кырын-кырын карап узалаар. Берсе — ак, икенчесе — кызыл, өченчесе — зәңгәр, дүртенчесе көрән күлмәк кигән бу кызлар ак, кызыл, зәңгәр, көрән чәчәкне төсмерләтә. Ак калфак өстеннән бәйләгән яулыклары да берберсенекенә охшамаган. Һәрберсендә бер чәчкә төсе бар. Алар нидер сөйләшә, серләшә, сүзләрдән бетмәс-төкәнмәс мәзәк тапкандай, егетҗиләнгә, өлкәннәргә сиздермәскә тырышып, җиңелчә генә көлешеп куя. Әлбәттә, әлеге кыланчык егетләргә бу купшы кызлар, йөзләрен усал караштан саклау өчен каплаган яулык читен ачып, анда-санда күз атып алырга да онытмыйлар. Үткеррәк егетләр моны сизеп тә ала. Ул яулык эчендә сөрмәле серле күз, ал яккан бит очы, пешкән чиядәй тулышкан ал иреннәр барлыкны аңлый. Шул гүзәллек эченә кереп чумасы килә аның. Ләкин — ярамый. Өлкәннәр кушмый. Алар — әдәплелек иманын яклаучылар. Егетләрнең йөрәген яндырырга, нәфесләрен тагын да ныграк кымҗыртырга, өмет чаткыларын дөрләтеп-ялкынландырып җибәрергә тырышып, кызлар өзелергә торган нечкә билләрен бөгелдереп-сыгылдырып, аркаларына сузылып яткан калын, нәфис толымнарын чайкалдырып, чулпыларын чыңлатып алырга да онытмыйлар.

Әбиләр чуагының иң матур кояшлы бер көне, әйтерсең, Солтанморатның хәлле кешеләренә бер-берсенә бәйрәмнәрдә генә кия торган иң затлы киемнәрен күрсәтешеп алу өчен бирелгән. Инде җәйге, көзге эшләр, кем әйтмешли, тозлап-борычлап тәмамлап куелган, саламы-печәне ташылып, лапас түбәләренә өелгән, бодае, борчагы, арпасы, солысы, тарысы...— һәммәсе, һәммәсе үзләренә тиешле бурага салынган. Халык, гүя, Хөрмәтулланы терелә́й кабергә күмү өчен түгел, сабан туендагы тамашага җыелгандай, агыла. Дөньяда, әйтерсең, бернинди дә гөнаһ, шомлылык, күз яше түгү, низаг-хәерчелек юк, фәкать, матур киенгән затлы кешеләр гаммәсе тантана итә.

Бодай арасында буталган кырлыктай, гөл-бакчаны ямьсезләгән чүп үләнедәй, матур-чибәр төсләләр тирәсендә алама-солама киемле гавам халкы да кайнаша. Бишмәт киеп, билен тыгызлап буган, аксыл-саргылт сакаллары түшенә төшкән авыру күзле чувашлар да, алача күлмәкыштан кигән башкортлар да, алатыр татарлары да, мишәрләр дә, типтәрләр дә бар. Ертык-мыртык, кырык ямаулы кием кигәннәр үзләре бер тирәдә төркем-төркем булып йөри. Тегендә шау-шу, монда шау-гөр, бер урында чыш-пыш, сөйләшү, икенче җирдә кычкырып-кычкырып, кул болгый-болгый бәхәсләшү китте. Һәркем булачак фаҗигагә карата үзенең хөкемен алдан ук әйтеп куярга ашыга.

Староста Бүксә Тәхлис, хөкемне язып барырга тиешле сәркатип Галинур, Мөбахис мәзин, авылның кайбер куштаннары, бер әчмүхә чәйгә сатылган шаһитлар халык җыенының урта бер җирендә танавын танауга,

колакны колакка куеп гапләшә. Боларның бөтен максаты шул: Хөрмәтулланы тизрәк кара җир куенына тыгу.

Гыйрфан мулла, беркем белән дә әңгәмә-мәңгәмә кылмыйча, хөкемдарлардан әллә ни ерак булмаган бер урында басып торды. Галимҗан әтисе янында булырга тырышты. Хәсәнә абыстай, Хәмдия кендекәй, Көнсылу... тагын да берничә сылу-сылу, чибәр-чибәр киенгән хатын-кыз алардан ерак булмаган урында үзләренчә сөйләшеп тора. Аларның йөзләре боек, күңелләре сүренке, рухлары төшенке иканлек әллә кайдан сизелеп тора. Шулардан ерак түгел бер урында — Хөрмәтулла абзыйның җәмәгате Мәликә түти, кызы Мәдинә. Галимҗан аларга әледән-әле күз сирпеп ала. Мәликә түти дә, кызы Мәдинә дә теге вакыттагыча киенгән. Мәликә түти, кадаклап куйган тораташтай, шул урында катып калган. Мәдинә аның янына басып каткан. Алар кырына берәү дә килми. Алар беркем белән дә сөйләшми. Хәер, аларның сөйләшер хәлләре дә юктыр.

Галимҗан бер нәрсәгә аптырады: «Чуртан» белән «Киккерикүк» кайда икән? Башка малайлар чыж да выж йөреп тора. Ә алар — юк. Әллә һаман сарык эзләп йөриләрме? Нигә бу юлы Галимҗанга әйтмәгәннәр?

Менә бервакыт:

— Киләләр...— дигән каты тавыш яңгырады. Халык дулкыны тынып калды. Өч каравылчы куллары артка каерып бәйләнгән Хөрмәтулланы алып килә иде.

Галимҗанның йөрәге «жу» итеп китте. Теге вакытта, төнлә, гәрчә ишектән аз гына ай яктысы төшсә дә, аның йөзен ул күрмәгән иде. Бу йөзгә хәзер карарлык та түгел. Бит очлары, маңгае, ияге күгәреп-бүлтеп чыгып, кара канга манчылган. Теге вакытта «Алып батыр»ны хәтерләтеп торган пәһлеван хәзер бәләкәйләнеп, кечерәеп өтек күркәгә охшап калган. Аның нык кыйналганлыгын җүләр дә аңларлык. Бетергәннәр кешене. Изгәннәр. Мескен иткәннәр.

Менә аны мәйдан уртасына китереп туктаттылар. Анда — бәләкәй генә өстәл. Өстәл артында вакыйганы язып барырга тиешле сәркәтип Галинур утыра. Аның янында юан мичкә. Кыска буйлы староста Тәхлис шул мичкәгә басып сөйләргә тиеш. Менә ул, әллә күпме кешеләр ярдәмендә, шунда күтәрелде. Аннан, күрәсезме гайрәтемне дигәндәй, халык дулкынына күз йөртеп чыкты; үзенең мәртәбәле кеше икәнлеген аңлатырга тырышып булса кирәк, берникадәр мактану төсе дә сиздереп, байларча, тамак кырып алган булды. Аннан, кулларын болгый-болгый, булган хәлне гавам алдына ачып салды, әмма хөкемне үзе әйтмәде — анысын шаһитларга калдырды: бу аның болганчык суда йөзмәгән балык икәнлеген күрсәтү өчен иде, сүзне ул Хөрмәтулланың күршесе — беренче шаһит Хәмәтдин картка бирде.

Хәмәтдин картның яшереп тәмәке тартуын һәркем белә. Моны гәрчә кешегә сиздермәскә тырышса да, тәмәке төпчегеннән саргаеп каткан тырнакларын, сирәк тешләре, ярылып ергаланган иреннәре, ике-өч адымнан ук аңкып торган сасы исе әйтеп тора. Әлеге көнне Хөрмәтуллалар ягыннан тәмле ит исе килүе турында сөйләде. Үзенең еллар буе ит шулпасы капмавы, Хөрмәтулланың исә кеше сарыгы суеп ләззәтләнүе турында ачыргаланып әйтте. Әмма ул да, хәйләкәр Тәхлис кебек, хөкемен чыгармады. Бу аның куркаклык билгесе иде. Староста бер хәйләкәр төлкенең җиде бүрене сугыштырганын яхшы белә. Хәйлә тозагына эләккән Хәмәтдин карт ерткыч бүре түгел — куркак куян. Аны өркетү — бәрәңге ашау кебек җиңел эш.

— Һәр юлның бер очы, һәр сүзнең бер азагы, сөземтәсе була. Хәмәтдин абзый, ул синең борыныңа тәмле ис алып килгән сарык итенең Мөбахис мәзин сарыгы ите икәнлекне яхшы беләбез, бу хакта сөйләп тору кирәкми инде. Сез хәзер шуны әйтегез: сарык урлаучыга ни җәза бирәбез?

Хәмәтдин карт кырык җирдән тишелгән, бәлшәеп беткән киез эшләпәсен салып, аны, шуның белән киңәшләшеп алгандай, учында кат-кат

йомарлады; аннан, куркудан агарынып каткан йөзен халыктан яшерергә тырышып, башын аска иде, дер-дер калтыранып, җебеп төште. Староста кат-кат әйтеп, аны йокысыннан айнытырга тырышты, әгәр тиешле сүзен ярып салмаса, Хөрмәтулла урынына үзен гаепләячәк белән куркытты. Шуннан соң гына, тотыла-тотлыга, староста алдан өйрәтеп куйганча, моң авырлык белән:

— Мин... ни... шуны әйтәм... Хәртине... Хөрмәтне... терелэй күмәргә... ыххым...

Шундый ук сүзләрне Тәхлис үзе әзерләгән янә ике шаһиттан — сатлык җаннардан әйттерде. Аннан, үзен ныгытма алган солдаттай горур тотып, тәмам җиңгәнен сизеп:

— Шуның белән халык хөкеме тәмам, җәмәгать, өч шаһит раслады, таралырга мөмкин,— диде.

Хөрмәтулла сүзсез генә басып торды. Башкалар да өнсез иде. Әйтерсең, һәммәсе авызына су капкан. Шул суның түгелеп китүеннән курка. Әмма авызлар ачылды. Сулар түгелде. Халык диңгезе кайнашырга тотынды. Әллә күпме сүздәр яңгырады:

— Бу нинди ахмаклык...

— Авылның өч ачыган ялкавы кеше башы ашый...

— Сатылганнар алар...

— Халык хөкеме болай булмый...

Умарта күче урынына бераз гөжләп алгач, мәйдан уртасына Гыйрфан мулла чыгып басты.

— Мин дә бу хөкемгә каршы. Хөрмәтулланың сарык урлавына тамчы да ышанмыйм. Башкалар да сөйләсен. Алар да минем фикерне әйтер,— диде.

Аның сүзләрен башкорт Котлызаман куәтләде:

— Гирфан мулла дөрес әйтә... уның һүззәренә кушылам... Хөкем эше түгел был... Этем эше...

Аның соңгы сүзләреннән җиңелчә генә көлеп тә куйдылар. Чуваш Ычтапан кул күтәргәч, көлү янә көчәеп китте: ни әйтер инде бу «телсез», янәсе. Ул да күп сөйләмәде. Тиешен генә әйтте,

— Пез пер нәмәне аңлап петермәйпес... Кем күргән Күрмәтулланың сарык урлаганын?.. Берәү дә күрмәгән... ул миңа ишек ясады... Шуңа акча пирдем... шул акчага ул сарык итен сатып алган... Мин Кирпан мулла яклы... хөкем дөрес түгел...

Халык дулкыны янә чайкала башлады. Бер-бер артлы төрле сүзләр ыргытырга керештеләр:

— Гыйрфан муллага кушылабыз...

— Хөрмәтулла сарык урламас...

— Мөбахис мәзиннең комсызлыгын беләбез...

Бер үк вакытта мәзин яклылар да күтәрелде:

— Каракны яклау оят...

— Терелэй күмәргә...

— Беләбез Хәртине...

— Ат карагына сарык урлау бәрәңге ашау кебек кенә...

Тавышны Гыйрфан мулла бүлде:

— Туктагыз әле, җәмәгать, суган базары түгел ләбаса бу, шауламагыз, сүзне Хөрмәтулланың үзенә бирик...

Гыйрфан мулланың калын тавышыннан соң йөзләгән күзләр канга манчылган Хөрмәтуллага төбәлде: аның нидер әйтүен көттеләр.

Хөрмәтулла ашыкмады. Күкрәк тутырып бер тын алды да «уф» дип куйды. Халык аның хәле авыр икәнлеген аңлады. Һаман да эндәшмәгәч:

— Әллә телдән калдымы...

— Бәй, шулкадәр тукмалуга...

— Изгәннәр бит...

— Моны күмәсе дә калмаган инде...

— Болай да җан бирү чигенә җиткән...— диештеләр.

Хөрмәтулла янә бер авыр тын алып куйды. Аның күзләре мәзәкләнде. Бөтен тәне калтыранырга тотынды. Һаман эндәшмәгәч:

— Бетте бу...— диде кемдер.
Ләкин ул бетмәгән иде әле. Аның авызы тулы кан. Халык алдында шуны төкерергә кыенсынып торды. Хәзер инде, сүз әйтергә кирәк булгач, аны эчкә йотарга булды. Бусы да бик авырга туры килде. Төкерек йотар рәте дә калмагач, хәленең чыннан да мөшкел икәнлеген аңлады ул. Сөйләргә дип авыз ачса, тамак төбе гыжлады, тик сүзе генә чыкмады. Халык арасында тагын төрле сүз китте:
— Бетте бу...
— Ни сөйли ала инде ул...
— Нигә кирәк аның сөйләве...
Тавышны янә Гыйрфан мулла бүлде. Бу юлы ул «гаепләнүченең» үзенә мөрәҗәгать итте:
— Хөрмәтулла туган, монда синең язмышың хәл ителә. Күрәм — авырсың. Шулай да әйт бер-ике сүз.
Халык шактый озак көткәч, ниһаять, берничә сүз әйтерлек көч тапты ул:
— Мин... сарык ырламыйм... Мине төбәнсетмәгез... Мин ат карагы... ат ырлыйм... «ат карагы» дип хөкем итегез...
Халык шым булды. Күпләрнең күзе акайды хәтта. Кем инде үзенең ат карагы икәнлеген әйтеп торсын, ди. Әллә акылдан язамы югыйсә? Бу сүзләрнең төбендә берәр серле хикмәт бармы? Ә инде Мөбахис мәзин өчен бу җитә калды:
— Менә, җәмәгать, ишеттегезме моның сүзен. Теге вакытта әйтә килдем, әйтә килдем, атымны шушы мөртәт кенә урлау турында әйттем. Сүзем өскә чыктымы? Чыкты. Хәзер аны «ат карагы» дип тә хөкем итәбез...
Баштан ук сүз әйтергә ярсып торган Мәликә:
— Туктагыз!..— дип кычкырып җибәрде.
Ул, чәчрәнләп, мәйдан уртасына чыкмак булды. Кемдер аның беләгеннән тотып алды. Бу «ярамый» дигәнне аңлата иде. Хатын-кызга ир-ат алдында сөйләү гөнаһ, янәсе. Шулай да ул чигенмәде. Бу пычрак гайбәт бөтен нәсел-нәсәп өстенә ябыла бит. Тәмам ярсыган Мәликәне тотып тордылар. Ә ул, ут чәчәрдәй булып, сөйләвен белде:
— Ат ярата ул... Бервакыт төшендә ат урлаган... Шуннан, мәзәк итеп, үзен «ат карагы» дип сөйләп йөри... Кешенең энәсенә дә тигәне юк аның... Әле менә «сарык буры» дигәнгә гарьләнүеннән әйтә... «Ат карагы» данлырак, янәсе... Хөрмәтулла!.. Нигә ялганлыйсың?.. Ат урласаң, болай ярлы яшәмәс идек бит...
Тәмам ярсыган Мәликә, үзенең халык алдында икәнлеген бөтенләй онытып, үксеп-үксеп еларга тотынды. Нәкъ шул вакыт сарык алып килгән дүрт малай күренде. Муенына җеп бәйләгәннәр. Бау — Апуш кулында. Арттагы өчесе сарыкны этекәләп-төрткәләп килә. Сарык, күрәсең, барырга карыша. Алҗыган-йончыгандыр, бәлки. Әллә ят кулларны сөйминеме? Бик мөмкин. Хайванда хәйләкәрлек тә җитәрлек була. Ә малайлар сарыкның «уй-хисе» белән аслан исәпләшми. Өстерәпме өстериләр.
Менә алар, тамаша кылып карап торган халыкны ера-ера, мәйдан уртасына җитте. Апушның үткен күзләре Мөбахис мәзинне эзләп тапты. Тапты да җепнең очын аңа китереп тоттырды.
Бу Мөбахис мәзиннең кара сарыгы иде.

## IV

Галимҗан бу хәлләрнең барын да күңеленнән кат-кат кичереп, барлык вакыйгаларны акыл казанында кайната-кайната, аларны соңыннан үз хис-тойгы бизмәненә салып үлчи-үлчи барды. Иң үкенечлесе шул булды: сарык эзләргә соңгы мәртәбә барганда Апуш аңа

әйтмәгән. Моның ни сере, ни хикмәте, ни яшеренлеге бар икән тагы? Әллә аны чыннан да «чирлечәүкә» дип кимсетәләрме? Көченә, чослыгына, үткерлегенә ышанмыйлармы? Андый-мондый көтелмәгән күңелсез хәл килеп чыкса:

— Кайгырма, балам, бер яманлыкның бер яхшы ягы булмый калмый ул,— дип юата иде әнисе. Шуны уйлап, яманлык чүмәләсе эченнән яхшылык гәүһәре эзләргә тырышты ул. Күп чокчына торгач, тапты: әгәр Апуш белән тагын да сарык эзләп киткән булса, ул мондагы халык диңгезе манзарасын күрми калыр иде. Яхшылык белән яманлык кына түгел, әнисе әйткәнчә, матурлык белән ямьсезлек тә даимән тәңгәл йөриләрдер, күрәсең. Әтисенең көче, гаделлеккә җанын фида кылырга торуы, җиңеп чыгуы, кеше язмышы өчен йөрәк ялкыны белән көрәшүе аның күңелендә мәңге сүрелмәслек горурлык уты кабызды. Тик Хөрмәтулланың кыланышын гына аңлап бетермәде ул. Ни өчен үзен ат карагы итеп күрсәтергә тырыша? Үлем чигендә дә үзсүзле пәһлеван булып калырга телиме? Шуның белән бәндәчелек кодрәте күрсәтәме? Ничек кенә булмасын, Хөрмәтулла абзыйсы аның күңелендә, теге вакыттагы кебек, яхшы тәэсир калдырды.

Мәликә түтинең чәчрәнләп чыгуы, ире язмышы өчен утка керергә әзер торуы, йөрәген өзеп бирердәй итеп сөйләве дә Галимҗанның күңел кузын күпкә дөрләтеп җибәрде. Янында сулыш алырга да куркып торган кызы Мәдинә чын мәгънәсендә Акчәчкә иде бит. Галимҗан аңа да вакыт-вакыт күз сирпеп алырга онытмады. Дөрес, Акчәчкә шиңеп бара төсле. Бу, мөгаен, әтисе кайгысыдыр. Шулай да ул һаман әле, шундый авыр мәлдә дә, усал җилләргә, кыраууларга, көзге салкыннарга бирешми торган дала чәчкәсен хәтерләтә.

Яхшылык белән яманлык, шәфкатьлелек белән шәфкатьсезлек, бәхетлелек белән бәхетсезлек чәкәләште. Маңгайны маңгайга куешып, якалаша-якалаша, элек тә шулай булганмы? Бу күңелсезлек гомер бакый дәвам итәрме?

Вакыйгалар да тиз үзгәрә. Көннәр дә, атналар да, айлар да, еллар да. Ул көнне җылы иде әле. Шуңа күрә халык җәйчә дә, көзчә дә киенгән иде. Яки яшьләр — җиңелчә, картлар — калынча. Икенче көнне болар юлга чыкканда да, сандугачлы алсу таң ук булмаса да, табигать җәйчәрәк тын ала иде әле. Бераз баргач, җәй җилләре кайдадыр сеңде, аны көз җилләре алыштырды; ул гына да түгел, кара-кучкыл болытлар куера, канатына кар катыш яңгыр төягән усал, салкын җилләр котырынып килде. Галимҗан толып эченә чумды.

Атасы толыпны алмаска да тырышкан иде.

— Һи, әнкәсе, әле әбиләр чуагы лабаса,— дип карышкан иде.

— Соң, атасы, юлга чыкканда борынгылар да җәйге чилләдә тунны калдырмаска кушканнар бит,— дип, үз сүзен сүз итте әнисе. Һәм дөрес эшләгән дә.

* * *

Уйлар диңгезендә йөзә-йөзә, Галимҗан, акрынлап, әвен базарына китә башлады. Йокларга теләмәгән иде ул. Гәрчә күз кабаклары авыраюын сизсә дә, бөтен тәненең нинди дә рәхәтлек эчендә оеп баруын тойса да, ул ләззәтлелектә эрергә теләми иде. Шулай да йокы җиңде. Татлы хыяллар толып тышында калды. Толып эчендә ул икенче бер хыялый дөнья дулкынында йөзә башлады. Дулкын. Ниндидер ефәк дулкын. Шул дулкыннар, төреп алып, аны күккә чөйде. Бераздан ул янә җиргә төште. Бакса, җир өстен ниндидер кара дулкын каплады. Ул дулкын Галимҗанга таба да ябырылды. Инде бетәм, үләм, кара дулкын астында калам, дип куркып торганда, имәнеч зур канатлы бер кош очып килеп, аны тагын да күккә күтәреп алып менеп китте. Алып менеп тә китте, бер очлы тау башында калдырып, үзе икенче очлы тау башына

барып кунды. Бәй, бервакыт ул өй дәүмәллеге ак кош кешегә әверелде. Кеше Хөрмәтулла абзый булып чыкты. Хөрмәтулла абзый тора-бара коточкыч зур Алып батырга әверелде. Киеме алтыннан, имеш. Үзе ул мәчет манарасыннан да озын. Башы казан дәүмәллеге. Казанга шул ук зурлыкта алтын такыя кидерелгән. Аягындагы искиткеч зур итекләре дә алтыннан. Бер алтын кош очып килде дә әнә шул алтын такыяга кунды. Бусы аның җәмәгате Мәликә түти булып чыкты. Мәликә түти башына бәләкәйрәк икенче бер алтын кош килеп кунаклады. Монысы — Акчәчкә. бераз торгач, Хөрмәтулла абзый, аларның икесен ике уч төбенә утыртып:

— Курыкмагыз, акыллыларым, кара дулкын өстенә мин ак җәймә җәям; ул ак җәймә бөтен кешегә бәхет китерәчәк,— диде.

Бер өргән иде, чыннан да, кара дулкын өстенә көмештәй елкылдап торган ак җәймә җәелде. Шуннан ниндидер кодрәт белән Галимҗанны да үз янына тартып алды ул. Тартып та алды, «Акчәчкә» белән икесен бергә бастырып та куйды. Шулай итеп, алтыннан киенгән ике пар — ике куш мәхәббәт басып тора хәзер.

— Мин пәйгамбәр, син дә пәйгамбәр, Галимҗан, ә болар — фәрештәләр,— ди Хөрмәтулла абзый.

Бәй, ни гаҗәп, Хөрмәтулла пәйгамбәр, Мәликә фәрештә, Акчәчкә фәрештә бермәл очтылар да киттеләр. Галимҗан берүзе калды. Дөньяны караңгылык каплады. Шул караңгылык эчендә очты да очты Галимҗан. Ул яктылык эзләде. Ә яктылык юк та юк. Оча-оча канатлары сына башлады. Бу аның соңгы сулышы, соңгы минуты, яшәү өчен көрәшенең соңгы секунды иде. Сулыш кысылып, минутлар, секундлар өзелеп, канат челпәрәмә килгәч, ул караңгы базга гөпелдәп килеп төште.

Озак ятты базда Галимҗан. Калкынып иде, аны ниндидер авыр таш белән бастырып куйганнар.

Менә бервакыт ташны кемдер алып ыргытты. Галимҗан аякка басты. Аны коткаручы кеше Хөрмәтулла абзыйсы иде.

Хөрмәтулла бер өргән иде, алсу таң атты. Кинәт әнисенең Галимҗанны пәйгамбәр итеп төшендә күргәне хәтеренә төште. Димәк, бу алсу таң — Галимҗанныкы. Бу — пәйгамбәр таңы!

Уянып китсә, аның толыбы ачылган икән. Йоклаганда тирләгән булса, хәзер салкын җил өрә. Аның янында чикмәнгә төренгән Шакирҗан йоклап ята. Кар катыш яңгыр һаман сибәли дә сибәли. Кәҗән кигән Гыйрфан мулла артка әйләнеп караштыргалаcа да, Галимҗанның хәлен шәйләмәгән иде. Хәзер инде аңлап алып, атларны туктатырга мәҗбүр булды.

— Их, юньсез малай, мин бит сине толыпка төргән идем, нигә ачтың, карачы, күшеккән тавык кебек булгансың бит,— дип тиргәде Галимҗанны әтисе.

— Йоклап киткәнмен бит, әткәй...

— Тыңламыйсың. Киресең. Шуңа чирле чәүкәсең... Мәдрәсәдә синдәйләрне бик яратмыйлар. Ярый ла кеше булалсаң, яхшы укысаң...

* * *

Әтисенең соңгы сүзләре — «ярый ла кеше булалсаң» — дигәне Галимҗанның йөрәгенә ут якты. Ә нинди кеше булырга? Хөрмәтулла абзый кебек кара дулкыннарга ак җәймә җәючеме? Җәя алырмы? Әллә үзен шул кара дулкыннарга ташлап изәрләрме? Аны азат иттеләр. Әмма авыл буйлап имеш-мимеш давылы котырынып йөреде. Имеш, Гыйрфан мулла Ырымбурга киткәч, Хөрмәтулла абзыйның хөкем эшен яңадан караячаклар. Мөбахис мәзин җинеләп кала торганнардан түгел, янәсе. Ул әле киләчәктә, ходай уң кылса, Гыйрфан мулла кебекләр белән гарьше көрсидән торып сөйләшәчәк. Инде ни кирәк? Нахакка Хөрмәтулла абзыйның измәсен изгәннәр, кабыргаларын, кулларын сындырып, канга батырып ташлаганнар. Сарык табылды бит. Хәзер Мөбахис мәзиннең үзен хөкем алдына тезләндерергә кирәк. Ә ул,

Ходайдан курыкмыйча, һаман келәт астыннан өреп яткан эт кебек кылана. Кеше булырга?! Нинди кеше?!

Бу сорауга тәгаен генә җавап бирә алмый иде әле Галимҗан. Хәер, кәбестә шикелле катлы-катлы булган бу мәсьәләнең асылына кем төшеп җиткән инде. Көрәш дигәне әллә үзе шулмы? Кем өчен кирәк ул көрәш? Кеше язмышы өченме? Бөтен дөньядагы кешеләр язмышы өченме? Бу уйлануларның йөрәгенә орлык булып сибелүен Галимҗан аслан аңламый әле. Ул орлыкларның шытып тамырлануын да аңлап бетерми. Унтугызынчы гасырның соңгы айлары. Алар укырга килә. Ырымбурдагы «Хөсәения» мәдрәсәсенә. Нәкъ шушы 1899 елда Гаяз Исхакыйның «Тәгаллемда сәгадәт» исемле әсәре нәшер ителгәнне Галимҗан белми әле. Шушы ук елда Исхакыйның Пушкин әсәре «Капитан кызы»н тәрҗемә иткәнлеге аның әле ике ятып бер төшенә дә керми. Ул тирә-якка даны таралган «Хөсәения» мәдрәсәсенә укырга бара. 1902 елда Гаяз Исхакыйның «Хөсәения» мәдрәсәсенә хокук белеме укытучысы буларак килүен алдан белсә дә, аның әллә ни исе китмәс иде. Чөнки аңа Гаяз Исхакый ни, тегесе ни, монысы ни — барыбер.

Тик Галимҗанга, Шакирҗан абыйсы кебек, Гаяз Исхакый дәресләрен тыңларга насыйп булмаган икән. Шакирҗан абыйсының эшләре һәрвакыт майлы табада шуган коймак кебек шома бара. Ә нигә аңа, Галимҗанга, җил гел кире яктан исеп тора? Әтисе-әнисе әйткәнчә, әллә кешенең уңай сыйфатларын билгели торган холык-фигыльләндә кире яклар булгангамы? Ә ничек бетерергә ул кирелекне? Канга сеңгәнне пычак белән кырып ташлап та булмый, имеш. Ул, самавыр юшкыны шикелле, мәңге шулай каткан килеш торырмы?

Алмадылар Галимҗанны «Хөсәения» мәдрәсәсенә. Безне капчыкта яткырып булмый шул. Сәламәтлеген тикшергәндә Гыйрфан мулла, оятып олтырак итеп булса да, алдашу юлына басты:

— Абыйсы Шакирҗан кебек инде...— Бер чире дә юк...— Белеме дә аллага шөкер...— дигән сүзләрне әйтте.

Нәкъ шул вакыт Галимҗан буылып ютәлләргә тотынды. Ишек төбендә торган бер савытка барып кан төкерде. Юлда әлеге ачылган толыптан өргән җил, күрәсең, аның үзәгенә үткән.

— Мондыйны без кабул итә алмыйбыз,— диде табиб.

Мәдрәсә башлыгы мөдәррис аның сүзләрен раслап куйды.

Гыйрфан мулла сүз көрәштерүнең файдасы юклыкны аңлады. Троицк мәдрәсәсендә үзенең дә шулай рәхимсез кылануын искә төшереп, үкенеп тә куйды. Кешегә аткан таш үзеңә кайтыр, җилгә төкергән төкрегең үзеңә чәчрәр, ди. Бу әллә шуның бер яшерен, серле гыйльләсеме? Син бит, үзенчә, дөреслеккә барам, дип уйлыйсың, кыек юлга кереп киткәнлегеңне сизми дә каласың. Менә хәзер, авыру дип кеше исәбеннән чыгарып, кайда куярга баланы? Кире алып кайтып китәргәме? Бу авырлыкны Хәсәнә күтәрә алмаячак. Мондый очракта «төртергә» кирәклекне белә Гыйрфан мулла. Әмма аның кешелеклелек сыйфаты, ялган юлдан качарга тырышып яшәве, дөреслек иманын тотарга тырышуы «төртү» кебек күңелсез хәл белән һич килешә алмый. Шуңа күрә, язмыштан узмыш юк, дигән канунга буйсынып, Шакирҗанын калдырып, Галимҗанны «Хөсәения» мәдрәсәсеннән алып чыгып китәргә мәҗбүр булды ул. Белә: монда Вәли мулланың кадим мәдрәсәсе бар. Әмма ул җыен калдык-постык, гарип-гораба, наданмаданны кабул итә торган мәдрәсә. «Хөсәения» тау башында арыслан булып горурланса, бу — тау итәгендәге мескен куян. Шунда калдырыргамы баланы? Рухи яктан имгәнеп бетмәсме? Пәйгамбәрдән иблис килеп чыгуы мөмкин. Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың бит. Вәли хәзрәт арбасының төбе тишек, күчәренең черек агачтан икәнлеген яхшы белә ул. Нишлисең, кем әйтмешли, бодай юк икән, арпа чәчәсең. Тик арпаны бодай итеп кенә булмый. Галимҗанны Вәли хәзрәт мәдрәсәсендә калдырып китәргә туры килде.

## V

Ырымбурдагы Вәли мулла мәдрәсәсе ике катлы таш йорттан гыйбарәт иде. Аның беренче каты җирне уеп эшләнгән. Ул берникадәр солдат землянкасын хәтерләтә. Аның диварлары эчтән дә, тыштан да суланып, мүкләнеп беткән. Тәрәзәләре карыш каткан. Идәннәр пычрак. Икенче кат та шуннан әллә ни ерак китә алмаган. Тар гына коридор. Ике якта ике ишек. Һәр ишекне ачып керү белән синең борыныңа күңел болгаткыч сасы ис килеп бәрелә. Килеп керүче аның ишек төбендәге чүп өелмәләреннән чыккан ыс, ләгәндәге болганчык су буы кушылмаларыннан барлыкка килгән ис икәнлеген абайламаска мөмкин. Янә аңа бик сирәк мунча керү аркасында шәкертләр тәненнән, киеменнән чыккан әчкелтем-төчкелтем ис өстәлә. Пычрак идәннән күтәрелгән тузан, шулар белән аралашып, кеше үпкәсе өчен зарарлы һава ясый.

Вәли әфәнде Гыйрфан мулланы ихтирам күрсәтеп каршы алды. Утырып дога кылышкач, ару гына хәер төртте дә Гыйрфан мулла:

— Мөхтәрәм Вәли әфәнде, бала язмышын бер хода вә дә ки сез сауләт[1] остазга тапшырдык инде, ул һич тә мәкаддир[2] булмас; иншаллаһ, йөзебезгә кызыллык китермәс, пәйгамбәрләр зиһене булса да, тыштан таза күренсә дә, сәламәтлеге әлегә бигүк күркәм түгел шул,— диде.

Вәли мулла аның белән тәкъдирән хөрмәт итеп, олылап сөйләште. Галимҗанның сәламәтлеге йомшак икәнлекне искә алып, үткен җил тимәсен өчен, аны тәрәзәдән ераграк торган урта бүлмәгә урнаштырдылар. Бүлмә дигәне тактадан түгел, чүпрәктән эшләнгән. Кияү өчен әзерләнгән чаршау дип әйтергә дә мөмкиндер аны. Чаршау белән әйләндереп алынган һәр «бүлмә»дә икешәр, өчәр, дүртәр шәкерт тора икән. Вәли мулла иҗтиһаты белән Галимҗан ике кешелек бүлмәгә урнаштырылды.

Гыйрфан мулла Вәли әфәндегә бихисап рәхмәтләр әйтеп, аңа янә дә өстәмә хәер төртеп, аның сау-сәламәтлеге, бәхет-сәгадәте өчен даимән дога кылып яшәргә вәгъдә бирде. Дөрес, бу кадим мәдрәсә аның күңелендә, табигый ки, яхшы тәэсир калдырмады. Троицкиныкында пакьлык хөкем сөрә иде. Моны ул, уратып-чолгатып булса да, Вәли мулланың күңеленә кылчык кадамаска тырышып, саклык белән генә сөйләп тә бирде.

Вәли әфәнде Гыйрфан мулланың шактый мәгълүматлы, мөхтәрәм зат икәнлеген нык аңлады. Аның тәнкыйди сүзләрен чырай сытыбрак кабул итсә дә, ыхым-ыхым тамак кырып, һич кирәкмәгәнгә сакалын сыпыргалаштыргалап, чалмасын рәтләштергәләп алып, ачу-фәлән, үпкәсапка белдермәскә тырышты. Улы Галимҗанга даимән күз-колак булып торырга, аны кирәк чакта якларга сүз бирде.

Галимҗан әтисенең ачык күңелле, шактый киң даирәле булуы, кешелеклелек сыйфатлары ошады Вәли әфәндегә. Гыйрфан мулланың данлыклы Троицк мәдрәсәсеннән китеп, авылда җир эшләре, хуҗалык, малчылык белән шөгыльләнүенә хәтта шатланып та куйды. Баксаң, Вәли мулланың үз хыялында да андый омтылыш, һавалану, тәшәббес булмаган түгел икән. Әмма алар, үзе әйтүенчә, иртән төшкән чыкның кояш күтәрелә башлау белән юкка чыгуы төсле булып калган.

Адәм баласы бер ходай ирегендә, язмышы маңгаена тугач та Алла исеменнән язылып куелган. Кыскасы, Вәли әфәндегә Гыйрфан мулла мисалында табигать кочагында яшәү насыйп булмаган.

Алар шулай фикер-фәтва алышып, киләчәктә хатлашып торырга сүз куешып, дусларча аерылыштылар.

---

[1] Сауләт — олылык, көч, гайрәт.

[2] Мәкаддир — кайгы китерүче, аламалык эшләүче, көендерүче.

— Укуда мөмтаз булачагың шөбһәсез, «таш маңгаем», әмма ләкин бәндәчелек өчен ул гына җитми әле, үзеңне шәкертләр арасында да, Вәли мулла, хәлфә, мөдәррис, башка зыялылар алдында да инсафлы тотарга тырыш,— диде атасы хушлашканда.

Галимҗан: «Ярар, әткәй, син дигәнчә булыр, кайгырма, исән-аман кайтып җит», димәкче иде, әмма тамак төбенә ниндидер төер килеп тыгылды. Ул ютәлләргә кереште. Кан төкерде.

Кайткач, Гыйрфан мулла остаз бикәсенә юлда булган мәшәкатьләрне, табигатьнең рәхимсез булуын, мәдрәсәдәге хәл-әхвәлләрне бәйнәбәйнә сөйләп бирде. Тик Шакирҗанның «Хөсәения» мәдрәсәсенә, Ходай кушу буенча, бик җиңел үтеп китүе, Галимҗанның анда эләгә алмавы турында, хәзергә әйтми торуны мәгъкуль күрде. Чөнки остабикәсенең шактый ябыгып, моңсуланып китүен сизде ул. Йөзендә, күз төпләрендә ниндидер аңлаешсыз кайгы күләгәсе. Аңлый: ул Шакирҗан һәм Галимҗан өчен борчылу галәмәте. Шуңа күрә, остаз бикәсен борчымаска теләп, ул вакытлыча алдашу юлына басты: икесен дә «Хөсәения»дә калдыру турында әйтте.

Гыйрфан мулла — алдашырга гадәтләнмәгән зат. Ул гомумән алдаша белми. Әгәр алдарга тырыша икән, бу кара якны каплап, аклыкны өскә чыгару өчен. Ләкин андый чакта да аның алдашканы күз карашыннан, бигүк ышанычлы сөйләмәвеннән, йөзен яшерергә тырышуыннан сизелеп тора. Боларны Хәсәнә абыстай яхшы белә. Бу юлы да аның сөйләүләре нигезендә ниндидер яшеренлек барын сизде ана күңеле. Хәсәнә абыстай кат-кат төпченеп, ныклабрак сөйләп бирүен үтенгәч:

— Соң, Алла колы, әйттем бит инде, икесенә дә бүлмә, «Хөсәения» мәдрәсәсендә калдылар,— диде дә, тотылудан куркып, башын читкә борды.

Зирәк күңелле Хәсәнә абыстай моны барыбер сизми калмады. «Нидер яшерәсең, атасы», дияргә теләгән иде, әйтмәде, юлдан арып кайткан кешене борчыйсы килмәде.

## VI

Галимҗанның күңеле китек иде. Тирә-якта дан тоткан «Хөсәения» мәдрәсәсенә абыйсы Шакирҗанны алдылар. Нечкә иләктән бик шәп үтте. Ә ул, Галимҗан, иләктән үтми калган көрпә. Шакирҗан абыйсы белән бер бүлмәдә торса, әнисе, Нәгыймә апасы биргән йомшак тәрбия, наз, сөелү хисе һаман өзелмәгән булыр иде. Дөрес, әтисенең үтенеп соравы сәбәпле, аны мәдрәсәнең тынчу һавасын инде биш ел сулаган, шәкерт тормышының газапларын күп татып каешланган, озын гына буйлы, какча гәүдәле, ябык йөзле, аксыл чырайлы, карар күзгә үк миһербанлы, шәфкатьле, әдәпле булып күренгән Йосыф исемле бер мәхдүм белән урнаштырдылар. Ул, Йосыф, Вәли хәзрәт әйткәнчә, олыларга да, мәдрәсәгә яңа килгән, Галимҗан кебек йомыркадан бу фани дөньяга күптән түгел генә чыккан чебеш шәкертләргә дә кадер-хөрмәт, ихтирам-илтифат, мөкиббәнлек белән карый. Аның шулай икәнлеген Галимҗан беренче көнне үк белде. Әтисе хушлашып китү белән, боегып калган сүренке йөзле Галимҗанның күңелен күтәрергә, аны шундук берникадәр хыялый-матур хәят манзаралары дөньясына алып китәргә тырышты. Моның өчен кайгы-хәсрәт тарата торган мәзәк, риваять, әкиятләр сөйләп алды, әйберләрен җайлап-җайлап куярга булышып, чәй кайнатып эчерде. Галимҗан кечкенә өстәл өстенә әнисе җибәргән тәмтомнарны чыгарып куйды. Йосыф та саранланмады. Чәйдән соң ныклап танышу китте.

Йосыф Бөре өязенә кергән Илеш авылыннан икән. Илеш үзе — волость үзәге. Ул яклар, Йосыф сөйләвенчә, укырга Казан мәдрәсәләренә китә, имеш, Йосыф нәсел-нәсәб чылбырының унике буынын сөйләде.

Буынның чишмә башы авылга нигез салучы шул иҗтиһадлы, хезмәткәр Илеш бабайдан башлана икән. Йосыфның әтисе Нургали ишанның бер туганы Ырымбурда яши икән. Шуңа күрә Йосыфны шушында укытуны мәслихәт күргән.

Йосыф әтисе, әнисе, туганнары, авылының табигате белән горурланды. Быел җәй — ямьле июль аенда әтисе аны Казан каласына алып барган. Пароход белән. Монысын Йосыф шигъри матур тел, хис-тойгы, йөрәк җылылыгы, күңел кайнарлыгы белән бәян кылды. Менә җырларда җырланган, үзендә сихри гүзәллекне саклаган, ак сулы Агыйдел. Ул, имеш, тыйнак кына, моңсу гына, инсафлы чибәр кыз елмаюын хәтерләтеп ага. Бервакыт ул кара сулы Чулманга барып кушыла. Ак су — кара су. Агалар да агалар. Ләкин кушылып, аралашып китәргә ашыкмыйлар. Ак су. Кара су. Ак су — чибәр кыз. Кара су — баһадир егет. Чибәр кыз назлана, ояла, кыенсына — егет кочагына йомылырга ашыкмый. Баһадир егет кайнар мәхәббәтен аңлата, бу ләззәтле, сәгадәтле, бәхетле минутларны мең-миллион еллар тилмереп көтүе турында әйтә. Аннан соң да әле әдәпле, инсафлы, күркәм табигатьле кыз егет кочагына атылырга бик ашыкмый, сөйкемле елмая-елмая, назлана-назлана ага бирә. Бу сөйкемлелек, бу инсафлылык, бу илаһилык егетне тәмам ярсыта, шашындыра, акылдан язу чигенә җиткерә. Кыз үзенең чибәр, сылу, назлы булуын гына түгел, горур, көчле, каһарман икәнлеген дә әйтә. Аны шулай камил итеп Урал бабай тәрбияләгән. Урал бабай аңа матурлыгын-батырлыгын теләсә кемгә әрәм итмәскә, Урал буйларыннан алган гүзәллекне саклаган хәлдә, гөлләр-чәчәкләр, таулар-урманнар арасыннан нәфислек саклап агарга, Урал даның ерак-еракларга алып барырга кушкан. Аңлый егет кызның уй-хыялын. Аны чын күңелдән гаять олылап һәм хөрмәтләп үзенә кабул кыла, уй-хыялларын гамәлгә ашыру өчен ерак-еракларга, матур-матур илләргә алып барырга вәгъдә бирә. Шуннан гына алар бер-берсенең кочагына мөкиббән керешеп, тәмамән бер җан булып, бер йөрәккә әверелеп ага башлыйлар. Ак су, кара су аралашуыннан икенче сыйфатлы су барлыкка килә.

Бервакыт алар Идел ана кочагына барып сыена. Идел ана аларны Хәзәр диңгезенә җитәкләп алып китә.

Галимҗан моны хискә бирелеп тыңлады. Йосыф хәзер унҗиде яшьтә икән. Димәк ки, Галимҗаннан биш яшькә өлкәнрәк дигән сүз. Үзеннән шунча кечкенәгә һич иренми әллә ниләр сөйләве, Вәли хәзрәт әйткәнчә, аның бик тә миһербанлы, кечелекле икәнлеген күрсәтә.

— Сандугач сайрашып, ат кешнәшеп, адәм баласы гәпләшеп танышa, син дә үзеңнең кайдан, нинди нәселдән, кайсы яктан икәнлегеңне сөйлә инде, Галимҗан, кеше үзеннән яшерсә дә, дустыннан яшерергә тиеш түгел,— диде Йосыф, бар булганын сөйләп бетергәч.

Галимҗанның күңеле Кондызлы күл, Зәңгәр чишмә, Исәнбикә, Түрсәгәле буйлары матурлыгына йөгерде. Андагы гүзәллекне, хозурлыкны, күркәмлекне сөйләп бетереп буламы? Янә шунысы бар: тыңларга яратса да, сөйләргә, Йосыф абыйсы кебек, артык һәвәс түгел ул. Аның күңелендә әле үзе дә аңлатып бирә алмаслык ниндидер давыл купты. Тыштан сиздерергә тырышмаса да, эчтә ул давыл кайный, котыра, үрле-кырлы килә. Ниндидер гүзәллек белән аралашкан давыл ул. Бу давыл-матурлык, бәлки, гүзәл кыз Агыйдел, баһадир егет Чулман мәхәббәте ялкыны тәэсиреннәндер. Ничек кенә булмасын, олы кеше алдында берникадәр тартынып, кыенсынып, сүз белән аны артык бимазаламаска тырышып, булган кадәресен, белгәнен сөйләп бирде; авылның күркәм табигатен, аның кешеләрен Йосыфның күз алдына китереп бастырырга тырышты; нәсел-нәсәбен, җиде буын ата-бабалар чылбырын сүтеп күрсәтергә дә иренмәде.

Бу вакытта Галимҗанның күңелендә ниндидер яшерен шигъри моң, табигать гүзәллегә энҗеләре балкышы, хәяти аһәң чаткылары, кешеләр рухыннан алган садәтлек, тагы да әллә нинди сихри нәрсәләр бар иде

инде. Йосыф абыйсы аны үз авылы, Агыйдел, Чулман матурлыгы хакында сөйләп әсәрләндерде. Йосыф сөйләгәннән соң Галимҗанның әллә кайларда, ерак-ерак илләрдә, ниндидер серле-серле дөньяларда буласы, шул Агыйделнең Чулманга кушылган урыннарын, Идел елгасын, Хәзәр диңгезен, тагын да бик күп җирләрне күрәсе килеп куйды.

Галимҗан, тартынып-кыенсынып кына булса да, үзе дә начар сөйләмәде шикелле. Югыйсә:

— Авылыгызны бер барып күрәм әле, мин дә сиңа үзебезнекен күрсәтермен,— димәс иде Йосыф мәхдүм.

## VII

Кызык икән бу мәдрәсә тормышы. Әле генә бәгъзе берәү үз бүлмәсендә ялгыз сандугач кеби моңаеп утырса, йә булмаса, болар сыман, икәүдән-икәү чәй эчеп сайраша, кичен, шәкертләр җыелгач, шау-гөр, уен-көлке, җыйнаулашып шаярышу башланды. Өлкәнрәк шәкертләрнең Вәли хәзрәткә кышлык өчен утын кисәргә, аннан соң ниндидер баз казышырга, янә башка эшләр башкарырга киткәнлеген ишеткән иде Галимҗан. Әле менә, зур крепость алган солдатлардай горур атлап, иманеч каты тавыш белән шаулашып-гөрләшеп, алар төркеме кайтып керде. Янә тагын әле тегеннән, әле моннан кузгалган шәкертләр гомумияте, төнен сунарга чыккан тычканнар өере кебек, тыз да быз йөрергә керешге. Ни бу? Нинди кайнашу? Әйтерсең, дөньяның асты өскә әйләнә. Йә, хода! Чыр-чу, шау-шу, тавыш-гауга купты. Гүя, кыямәт көне. «Бисмиллаһир-рахманир-рәхим», «ләхәүлә вә лә куәтә», «әлгаззе биллаһи» кебек сүзләргә сүгенү-кычкырынулары да катнашып китә. Хәтта динне, мулланы, мәдрәсә башлыгын тиргәү сүзләре дә яңгырый. Моның ни галәмәт икәнлеген Галимҗан белми әле. Йосыф мәхдүмнән сорар иде — ул кайдадыр чыгып китте. Ә төркем, бал алганда өркетелгән умарта кучедәй, гөж-мөж килеп йөргән белдө. Менә алар боегып, әллә нинди тирән уйларга чумып, үзен-үзе кая куярга белмичә утырган Галимҗан бүлмәсенә кереп тулды. Аларга, янәсе, яңа килгән шәкертнең акыл кылын тартып карау лязим. Берәүсенең кулында шактый дөнья күргән, тузган чикмән. Шул чикмән белән төреп, Галимҗанга аның күтәрелгән җиңеннән карарга куштылар. Шул җиңнән әллә күпме йолдыз күренә, имеш. Галимҗан, карагач, ничә йолдыз күрүе турында әйтергә тиеш. Һәй, бу надан шәкертләр!.. Һәй, бу томаналык!.. Һәй, бу күңел караңгылыгы!.. Мәдрәсәдә инде җиде-сигез ел ми черетеп, газап чигеп, сасы-тынчу һава иснәп, җиңнән карап йолдыз күренмәгәнлекне дә белмиләрме? Белә алар. Яңа килгән шәкертне белми дип уйлыйлар. Андыйлар да бардыр. Әмма ләкин нигә шундый вак-төяк кызык-мызык белән шөгыльләнергә? Яңа килгән шәкертнең зиһенен, аң-акылын, фикер йөретү офыкларын сынау өчен башка мәгънәлерәк «уен» юкмы? Бу хакта Галимҗан белә иде инде. Аны әтисе дә әллә мең кәррә көлә-көлә сөйләгән иде. Чикмәнгә төренгәч, син кемдер тартып торган җиңгә башыңны тыгарга тиеш. Шуннан бер ахмагы йә салкын, йә эссе су кoя. Аннан, чикмәнне ачып ташлап, шырык-шырык, ихахай-михахай, лыхлых көләргә тотыналар. Шулмы егермегә җиткән ир-егетнең ун-унике яшьлек баланы мәсхәрәләп ләззәтләнүе? Шулмы кешенең аң-акылын сынар өчен оештырылган кәмит? Шулмы егетлек күрсәтү сәпәрәйлеге?

Галимҗан бу хакта ләм-мим белмәгән атлы булып, чикмән эченә керде. Әмма җиң эченә башын тыкмады. Тыккан атлы булып: «һәй, шәкертләр, мин инде бик күп йолдызлар күрдем», «Алар бик матурлар», «Барысы да чекрәешеп яналар» кебек җөмләләр әйтте. Комганнан су кою вакыты җиткәнен шәйләгәч, башын җиңнән чыгарып, чикмән эчендә катып калды. Су коелды. Аның тамчысы да тимәде Галимҗанга. Ул шуңа утыра бирде. Ә тегеләр: «бетте бу», «коенды», «эссе су таракан

ясады», «әллә тончыкты инде» кебек сүзләр әйтә-әйтә шырык-шырык көләргә тотындылар. Көлү чикмәнне ачып карагач кына тукталды. Тамчы да су тимәгән Галимҗанны күреп, алар шаккатты. Галимҗан сер бирмәде. Берничә йолдыз исемен әйтеп гаҗәпләндерде:

— Мин Чулпан, Жупитер, Марс, Плутон йолдызларын күрдем,— дип алдашты. Болар хакында аңа урыс теле мөгаллиме Сәет Илһамов сөйләгән иде.

Галимҗанга бәгъзесе күзен чекерәйтеп, бәгъзесе кулын каш өстенә куеп, бәгъзесе коелып төшеп карады. Мәдрәсәгә яңа килгән күпме шәкерт-чебешне коендырдылар. Ә бу судан коры чыккан. Әллә бер-бер сихере бармы бу маңка малайның? Әллә йөзлекләме? Галимҗан шәкертләрнең «Нәрсә ул Жупитер?», «Нәрсә ул Плутон?» дигән сүзләрен ишетеп, шул атамаларны да белмәүләренә аптырады. Шуннан соң аңа төрле сораулар яуды:

— Апаң бармы? Чибәрме?

— «Әлеп» белән «таяк»ның аермасы нидә?

— Мөхәммәт пәйгамбәр кайда, кайчан, ничәнче елда туган?

Беренче сорауга ул бик матур, төпле, шәкертләрнең күңелен җилкендерердәй җавап бирде:

— Нәгыймә исемле апам бар, бик чибәр, сөйкемле, акыллы,— диде.

Өлкән шәкертләр авыз суларын түгеп, күзләрен ялтыратып, дәрт кабынудан үзләрен кая куярга белмичә сулкылдап, чыдаша алмыйча көлешеп куйдылар:

— Уй-буй, аһ-уһ, үтерде бу маңка малай...

— Апасы тәгаен үземә, бераүгә дә түгел...

— Кайнеш, апаң минеке...

Калган ике сорауга Галимҗан алар уйлаганча маңка малай, селәгәй түгел икәнлеген аңлатырлык итеп җавап бирде:

— «Әлеп» белән «таяк» ни икәнен сораган кеше «әлеп»не «таяк»тан аера белмәүче мәхлук, пәйгамбәрнең туган көнен миннән белергә тырышу сезнең өчен түбәнлек,— диде.

Өлкән шәкертләр тораташтай катып калды. Берсенең авызы чалшайды. Икенчесенең күзе кылыйланды. Өченчесенең борыны борылды. Алар алдында торган маңка-шәкертнең буш тубал белән килмәвен аңлау кыен түгел иде. Шуңа күрә сорауны кыскарттылар. Мондый маңка малайга сорау биреп, үзеңнең адәм ыстырамына калуың бар бит әле.

Алар таралышкач, Галимҗан иркен тын алып куйды. Аның ял итәсе, ятып йоклыйсы, шуның белән бөтен болганчык-кара уйлардан арынасы килә иде. Тик барып чыкмады. Күрше бүлмәләрдә кемнеңдер дуңгыз тавышы белән чыелдавы, бәгъзе берсенең карт алаша кешнәгәндәй хахайлавы, бәгъзесенең яшь кәҗәдәй нәзек авазлар белән безелдәве Галимҗанны бөтенләй айнытып, шул мәзәкләр арасына барырга кызыксындырды.

Барса, ни күзе белән күрсен, мендәр сугышы купкан. Бүлмәнең берсендә бәрешәләр-бәрешәләр, орышалар-орышалар да, анда сугышып туйгач, икенчесенә чыгып китәләр. Анда яңа көрәш башлана. Кем-кемне чәпи, кем-кемгә теш кайрый, кемдә-кемнең ачуы бар — белмәссең, шайтан да аңларлык түгел. Зурлар, мендәрнең бер почмагыннан тотып, бәләкәйләрнең башына чатнатып китереп ора. Теге мескен, чатай-ботай килеп, әллә кайда тәкмәчләп барып төшә. Шуннан, гаҗәеп бер кәмит күргән кебек, шаркылдап көлергә тотыналар. Моның ни мәзәге бар икән? Аны Галимҗан һич кенә дә башына сыйдыра алмый. Берара, син дә калҗасыз калма дигәндәй, усалтай бер калын гәүдәлесе Галимҗанга да китереп чәпәде. Кем уйлаган йомшак мендәрне шулай каты тияр дип? Күзләреннән аллы-гөлле утлар чәчрәде Галимҗанның. Идән уртасында орчыктай бөтерелеп торды-торды да, башы әйләнеп, әллә кайда барып сеңде. Бераздан берсе кулыннан тартып торгызган иде, икенчесе янә колак төбенә китереп сылады. Галимҗан тагын да туптай тәгәрәп китте.

Тагын да шаркылдап-мыркылдап, ихахайлап-михахайлап көләргә керештеләр. Әллә нинди казан кыргандагы тутык тавышлар чыга. Кайсысыныкы бүре улаганны хәтерләтә. Бәгъзесенеке — үгез мөгрәве кебек. Аларның бөтенесе уптым илаһи бергә кушылгач, җен-пәриләр чыелдагандай тоела. Җитмәсә берсе, Галимҗанны янә торгызып, «син бая йолдыз санарга ирендеңме», «безне алдап калдыңмы», «хәзер кәҗә маеңны чыгарыйкмы», кебек сүзләр әйтә-әйтә такылдады. Тагын да сугып җибәрергә тешләрен кыҗырайтса, аның мендәрен кайдандыр ялт килеп кергән Йосыф тотып алды. Йосыфка әллә күпме әшәке, нахак сүзләр яуды:

— Әле шул маңка малайны яклыйсыңмы?

— Сатылдыңмы?

— Сумсасы тәмле булдымы?

Тотындылар хәзер Йосыфның үзен түпәләргә. Мендәр белән әле берсе китереп ора, әле икенчесе, әле өченчесе. Шуннан, бер мендәрне алып, Йосыф үзе дә тегеләргә чәпәргә керешә. Араларында Йосыфны яклаучылар да табылды. Тиз генә икегә бүленеп алдылар. Мендәрләр умырылып, ертылып бетте. Каз мамыгы белән идән тулды. Әйтерсең, ап-ак кар йоны. Мамык, пыр тузып, очып та йөри. Гүя, кар бураны купты. Мондагы мендәрләр эштән чыгып беткәч, икенче бүлмәгә күчтеләр. Анда да шул ук хәл. Хәзер инде өлкәннәр бәрешә. Бәләкәйләр тамаша кылып кына йөри.

Башта ул шаяру гына иде шикелле. Әмма уеннан уймак чыкты. Тора-бара бер-берсенә булган ачуларын да чыгара башладылар:

— Син үткән ел җеназа вакытында миңа дигән хәерне чәлдердең, тирес бит...

— Үзеңне бел, азгын җан, сасы Мәрүскә янында иснәнеп йөрисең...

— Хәмер белән шаярганыңны хәзрәткә әйтсәм әле, чучка борын...

— Мин синең кебек тәмәке төпчеге җыеп йөрмим бит әле, эт җан...

Боларны ишетү Галимҗанга бик кыен иде. Ул үз колакларына үзе ышанмый торды хәтта. Абыйсы Шакирҗан мәдрәсәсендә дә — «Хөсәения»дә дә шулай микән? Юктыр. Анда мондый вәхшилек булмас. «Вәли мулла мәдрәсәсе җәһәннәм төбе кебек ул», дигән сүзләрне ишеткән иде шул. Монда башка мәдрәсәгә үтмәгән җыен шәләй-вәләй — ачыган ялкау, чихут-михут, сантый-мантый, сугыш чукмарлары, кибәк башлар гына укый, имеш. Бәгъзе бер елда шәкерт саны җитми дә кала икән әле. Андый очракта Вәли мулланың коты оча. Чөнки, шәкертләр килмәсә, мәдрәсәнең абруе, дәрәҗәсе тагын да түбәнрәк төшә. Аңа бөтенләй ябылып кую куркынычы да яный әле. Шуңа күрә Вәли әфәнде һәр килгән яңа шәкертне илаһи бер күтәренке күңел, ачык йөз, шәфкатьлелек күрсәтеп каршы алырга тырыша.

Мендәр сугышы тынгач, бүлмәләрне җыештыру башланды. Бәгъзе бер бәләкәй шәкерт, мендәрсез калуына ачынып, елап та җибәрә.

Кичен чәй эчкәндә Йосыф мондый хәлнең еш булуы турында сөйләде. Шулай да бу кадәр күңелсезлеккә барып җитмәгәнлекне әйтте. Бу шаяруның кайбер сәбәпләре дә бар икән. Аларның бәгъзесе бу тынчу дөньяда ун ел чамасы кибеп-корып яши икән. Ә менә җәй көне, түл җыйган үрдәк кебек, алар авылда шактый хәлләнеп килгән. Хәзергә әле алар маена чадаша алмый кайнаша. Каннары кызган чагы. Дәртләре ташып тора. Кая барып бәрелергә-сугылырга белми аптырыйлар. 20—25 яшьлек егет йөрәгенә ни кирәген алар аңлый. Әмма кирәге табылмый. Аяк астында аунап ятмый ич ул. Рухи азык, күңел юанычы, яшәү хозурлыгы кирәк боларга.

Шулар хакында берникадәр үзенчә фикер йөреткәч:

— Син бик боек күренәсең, Галимҗан, беренче көнне үк күңелеңне нык төшерделәр, ләкин гел болай булмый ул, укырга тотынсалар, кикрикләре шиңә, бәгъзе берсе кипкән балыкка әверелә, — диде Йосыф.

Бераз уйланып торгач, янә дәвам итте:

— Күңел ачулар да була: җыр, бию, кубыз тарту, курай, сукыр тәкә уеннары... Адәм баласына барысы да кирәк.

Аның шул сүзләрен раслагандай, кайсыдыр бүлмәдә кубыз тарткан тавыш ишетелде. Йосыф янә сөйләп китте:

— Әнә... Әйттем бит... башланды... Алар инде мендәр сугышын оныткандыр. Шәкерт ачу сакламый. Моны шәригать тә кушмый бит. Өч көн саклаган ачу агуга әйләнә. Ә агу кешенең йөрәген кимерә. Ул акрынлап юньсез затка әверелә. Әйдә, Галимҗан, тамашадан калмыйк. Монда сарык тиресе ябынып, үз уйлары белән генә бикләнеп яшәүчеләрне дә бик яратып бетермиләр. Беренче көннән үк барын да күреп-белеп йөрүең хәерле. Яхшысын да, яманын да. Яхшысына — йөрәк капкачыңны ач, яманына — биклә. Кайгырма: Йосыф абзаң янында ким-хур булмассың. Әйдә, Аллага тапшырдык.

Алар бер зур гына бүлмәгә барып керде. Монда шул баягы мендәр белән сугышучылар иде. Тик ул инде, Йосыф әйткәнчә, онытылган, күрәсең. Чандыр гына гәүдәле бер өлкән шәкерт кубызда уйный. Башкалар аңа карап каткан. Тын алырга да куркып торалар. Галимҗан, сиздермәскә тырышып, әле берсенә, әле икенчесенә карап ала. Берсендә ул йөрәк әрнеше барлыкны сизә. Икенчесенең күңеле тулганлыгын аңлый. Өченчесе елап җибәрер чиккә җиткән. Дүртенчесе елмаеп-елмаеп куя. Моң адәм баласын төрле сыйфатка кертә, күрәсең. Галимҗан бу минутта Хөрмәтулла абзыйсы, Мәликә апасы, Мәдинә яшьтәше моңнарын да хәтеренә төшерде. Гүя, шул моңнар белән бу моңнар аралашып китте. Аралашты да Галимҗанның үз йөрәген дә тетрәндерде. Әллә ул моңга тиз бирешүчән йомшак җанмы? Аның шулай икәнлеген башкалар сизмәдеме? Шуны уйлап, ул үзен-үзе нык тотарга тырышты.

Уйнап туктагач, шәкертне кул чабып алкышладылар. Алкышлау шактый көчле булгач:

— Акрын... тышка ишетелмәсен... йә хәзрәт, йә казый килүе мөмкин бит... — диде Йосыф.

Шуннан акрынрак уйнарга, йә тышкы ишекне бикләп куярга, йә чиратлап сакта торырга сүз куештылар. Акрынрак уйнарга кирәк. Ишекне бикләү килешми. Әчтә нинд̆идер «әтлек» булуны аңлаячаклар. Иң яхшысы — ихатада сакта тору. Хәлфәме, хәзрәтме яки башка кемдер күренсә, тиз генә карап әйтергә. Сакчы кую белән Йосыф җитәкчелек итте. Башта ул үзе торып керде. Аннан берәм-берәм башкаларны чыгарды.

Менә бервакыт:

— Нигә Кылычбай бүген курай уйнамый, уйнасын, уйнасын, — дип шаулаша башладылар.

— Бында бит беззең арала кемдер итәк астыннан ут йөрөтә, минең курай уйнаганды хәзрәткә әйтә; Вәли мулла үткән йыл да асыуланды, уйнаганыңды тагы ла бер ишетһәм, бына ошо салмалы башым менән ант итәм, мәзрәсәнән кыуам үзенде, тине.

Сөйләшүе буенча да, төс-битенә карап та Галимҗан аның башкорт егете икәнлеген аңлап алды. Шәкертләр исә янә шау-гөр килде:

— Уйнамаслык булгач, нигә кураеңны алып килдең?

— Кем икән ул әләкче дуңгыз?

— Тотып измәсен изәргә кирәк ул хаинның.

Шуннан соң башкорт ялындырып тормады. Курайда берничә моңлы көй уйнады. Аңа да алкышлап кул чаптылар.

Галимҗанның күңеле күтәрелеп китте. Бу караңгы дөньяны яктыртырга теләүче йолдызлар да бар икән әле. Җиде төн уртасында да алар күңел ачып, кат-кат самавыр чыжлатып, алып килгән күчтәнәч, ризыкнигъмәт белән сыйлаша-сыйлаша, әле берсендә, әле икенчесендә җыйналашып чәй эчтеләр. Аннан соң тагын да уен дәвам итте. Вакыт-вакыт үкенечле сүзләр дә яңгырап ала:

— Их, егетләр, үтә бит яшь гомерләр...

— Ун ел буе мәдрәсә тузаны эчеп...
— Картаеп барабыз... бер җылы кыз кочагы күргән юк бит әле...

## VIII

Шәкертләр таң алдыннан гына тәмле йокыга талды. Галимҗан, мендәренә ятып, әллә кайчан сеңмәкче иде. Ул, башкалар кебек, арып-алҗып килгән генә түгел, шуның өстенә авыру да бит әле. Гәрчә «Хөсәения» мәдрәсәсендә кан түкерсә дә, монда килгәч, авыруы хакында ләм-мим белдермәскә тырышты. «Чирлечәүкә» дигән кушамат авылда чакта да күңеленә кара сөрем койды да торды. Анда ул сөремне туздырып ташлау, аның урынына ак нурлар салу, үзен мөмтаз-маһир күрсәтү, малайлар белән дуслык булдыру мөмкин иде. Мондагы ызгыш әллә ничек. Шайтан үзе дә аңларлык түгел. Аз гына йомшаклык күрсәтсәң, әллә нинди яман атама салып куюлары бар. Аннан соң аны пычак белән дә кырып ташлап булмас.

Үзен ничек кенә нык тотарга, ихтыярлы итеп күрсәтергә, бирешмәскә, җебеп төшмәскә тырышмасын, безне капчыкта саклап булмаган кебек, эчтәгене йөзгә чыгармый калу мөмкин түгелдер, күрәсең. Зирәк табигатьле, үткер күзле, сынап караучан Йосыф мәхдүм:

— Галимҗан, син юлда йончыгансың, ят булмаса, мондагы тамаша бетмәс, сиңа авырып китүдән саклану хәерле,— диде.

Галимҗан аны тыңламады. Кәҗә дә бакчага сәбәпсез керми, дигәндәй, тыңламауның ике сәбәбе бар: беренчесе — селәгәй малай атамасы алудан курку, икенчесе — шәкерт дөньясы эченә беренче көнне үк керергә тырышу.

— Юк, юк, минем әле һич тә йокым килми, йончымадым да, авырмадым да,— диде ул.

Йосыф мәхдүм аның аркасыннан сөеп куйды:

— Ярый, йокы песигә генә моң, алданмыйк аңа, уйныйк, күңел ачыйк бүген; әле сөйләшәсе сүзләр бик күп.

Галимҗан яткач та тиз генә йокыга китә алмады. Уй давылы эчендә миңгерәде ул. «Әгәр бик тә иҗтиһадлы булып, ваемсызлык күрсәтмәсә, тырышып укыса, иншаллаһ, улыңыз янә ун елдан мөдәррис булыр»,— диде Вәли мулла аның әтисенә. Бу сүзләр әүвәл Галимҗанның колак барабаннарын назлап, күңеленә илаһи бер йомшак ләззәт, омтылыш биреп торды. Вәли мулла андый мәдхияви сүзләрне зур ышаныч илә әйткәндер. Ә менә хәзер, таң караңгылыгында үз уйлары-хыяллары белән япа-ялгыз гына калгач, хәзрәт вәгъдә иткән ун ел, әллә нинди җанлы сурәткә кереп, Галимҗанга йодрык төя, теш ыржайта, тел чыгарып күрсәтә кебек. Янә ун ел! Ул вакытта Галимҗан егерме өч яшьтә була. Ә монда унбиш ел укыганнар да бар икән әле. Алар әле мөдәррис тә, мөлла дә түгел. Бу тынчу, сасы, караңгы оядан, кош кеби очып чыгып китеп, әллә кайларда үзенең асыл зат икәнлеген исбатлау бәхетенә ирешкәннәре дә бардыр. Ә бит бу төчкелтем дөньяда унбиш-уналты ел укып, саргаеп, кибеп, корып бетеп тә һаман әле канат ярмаган, очып китә алмаган, туры юлга керү бәхетен күрмәгән бахырлар да бар. Бәгъзе пишкадәмнәрнең дә язмышы аянычлы.

Ни чыгар Галимҗаннан? Ун-унике ел заяга үтмәсме? Чәчкәләр, гөлләр арасында, оҗмах-җәннәттән аз гына да ким булмаган бай, матур, гүзәл табигать кочагында, аның саф һавасында хозурланып, әнисенең йомшак тәрбиясендә назланып-иркәләнеп үскән бәхетле-сәгадәтле бала бит ул. Шул оҗмахтай табигать куенында «чирлечәүкә» булган малай бу тәмугны хәтерләтеп торган дөньяда бетеп, теткәләнеп, сугышып таланган әтәчкә охшап калмасмы? Бик саф кешеләрнең дә гыйффәтен саектыра, имеш, бу аңлаешсыз-томанлы дөнья. Әнә бит ничек үкенәләр, ничек өзгәләнәләр, әйтерсең, аларның артында калган юллар гөнаһлы, күңелсез, караңгы, ә алда упкын көтә.

Шундый буталчык, болганчык, очына чыгу кыен булган уйлар парә-парә кискәләде Галимҗанның йөрәген. Аннан соң үз уйларыннан үзе курка башлады ул. Нигә алтын базыннан чүп эзләп маташа әле? Бу бит куркаклар, адәм баласының ак күңеленнән кер эзләүче шымчы-җасуслар, иҗтиһатсызлар эше. Әтисе: «Йолдыз караңгыда яктырак яна»,— дигән иде берчак. Ул хакта әнисе дә әйткән иде. Ян караңгыда йолдыз булып. Нурыңны башкаларга сип. Ул нурдан дөнья яктырсын. Әтисе гел шулар хакында тугылап торды лабаса. Башына, миенә, бөтен тән күзәнәкләренә, чәч төпләренә сеңсен дигән кебек.

## IX

Галимҗан, Авыргазы елгасының Агыйдел, Чулман, Идел белән кавыша-кавыша Хәзәр диңгезенә барып җиткәнен белгән кебек, башында өлкән мөдәррис Вәли мулла торган унике еллык кадим мәдрәсәнең соңгы чиге нindирәк офыкка барып тоташачагын да аңларга тырышып йөрде. Халыкның: «Акыллы — тыңлар, акылсыз — такылдар»,— дигән әйтемен авылда чакта ук ишеткән иде инде ул. Ул тыңларга ярата. Ә менә сөйләргә беркайчан да атлыгып бармый. Бу табигатен хәзер ул яхшы белә. Тик кеше акылын «тыңлау», «тыңламау» бизмәненә салып үлчәргә ашыкмый. Бу сыйфат аңа ата-ана канынннан киләдер, бәлки. Әткәсе дә, әнкәсе дә шулай бит: кирәген әйтә, буш сүз уйнату белән шөгыльләнми.

Башта Галимҗан яңа килгән шәкертләр арасында үзсүзле буларак танылды. Ярык күргәнгә дә көлгән кыз кебек, һәр мәзәккә авыз ерып, ихахай да михахай, кыхый да михый килеп йөргән җил акыллы бәгъзе шәкертләр тиз арада аңа әллә күпме атамаларны сагыз урынына ябыштыра да башладылар: «бер сүзенә бер бозаулы сыер сораучы», «телен йоткан ябалак», «акайган күз»... тагын да әллә ниләр, әллә нәрсәләр. Шулар арасыннан «акайган күз» дигән кушамат аңа сыланды да куйды. Күрәсең, башкалар ярыша-ярыша, тел чертләтә-чертләтә, уттай кабына-кабына, үзенең осталыгын һәм гайрәтен күрсәтергә теләп бәхәсләшкәндә Галимҗанның чупай ябалагы кебек тын гына, ләм-мим дими, чукаеп утырганы аларга сәер тоеладыр. Фәһемле, акыллы, мәгънәле фикерне колак торгызып, күзен зур ачып тыңлый торган гадәте дә бар. Димәк ки, зур ачылган күз бәгъзе берәүләр өчен акайган күз булып күренә. Акайган күздә акыл юк, дип тә әйтәләр. Әмма Галимҗанның ул «акайган» күзләр нурында нинди акыл барлыкны кети-мети уйлап, үз танау астын күрми йөргән шәкертләр белми шул әле. «Акайган күз», «Ябалак» дигән сүзләрне үзенә әйтә башладылар хәтта.

Ордым-бәрдем була алмавы аны йомшак көпшә итеп тә күрсәтә шикелле. Әмма тиздән аның «йомшак көпшә» түгел, ә бәлки каты имән икәнлеге ачыклана башлады. Хәтта Йосыф моназарә вакытында аны «мысыр күгәрчене» дип атады. Мысыр күгәрченнәренең бер төре энҗе чүпли, имеш. Моның өчен аңа ифрат дәрәҗәдә күп эзләнергә, күп очарга, шул үзенең гәүһәр бөртеген хәтерләтеп торган нәни борыны белән җирне күп актарырга кирәк икән. Бу тырышлык аңа Алла тарафыннан бирелгән, ди. Бәгъзе бер күгәрчен кеше шәфкатенә зар-интизар булып карап яши: бирсә — ашый, бирмәсә — юк. Инсаният өчен аның матурлык-гүзәллек сыйфаты гына бар. Ә бу күгәрченнәрнең тышкы күренеше тегеләрнекенә караганда да сылурак. Әлеге эчтәге энҗе бөртекләре каурыйларында, түшләрендә дә җем-җем килеп тора, имеш. Аларның энҗе чүпләүче күгәрчен икәнлекләрен шуннан беләләр икән. Аллаһы Тәгалә аларны җирдә исраф булып яшеренеп яткан энҗеләрне җыю, аларны халыкка өләшү өчен яраткан.

Моны Йосыфка нindидер бер акыл иясе сөйләгән. Шәкертләр ни өчен Галимҗанны «Мысыр күгәрчене» дип атавы турында төпченгәч, Йосыф аларга барын да бәйнә-бәйнә аңлатып бирде.

Моның сере шактый тирән, яшерен. Мәдрәсәдә унар-уникешәр ел укып та, мең-миллион кәррә сабынлап юсаң да агармый торган карга кебек, аң-акылларын агарта алмаган карт шәкертләр бар. Аларның бәгъзе берсе, гәрчә моны тыштан сиздермәсә дә, үзенең чеп-чи надан икәнлеген яшерергә тырышса да, яшь гомерләренең заяга үткәнлеген аңлап, эчтән генә сыкрап, янып-көеп йөри. Моны аларның җае чыккан саен: «Их, егетләр, үтә бит яшь гомерләр», «Бер кыз кочарга тилмереп яшибез», «Кем чыгар бездән», кебек ачыргаланып әйткән сүзләреннән дә аңлады Галимҗан. Ләкин алар әлеге теге, төлке хәйләсенә алданып, койрыгы бәкедә бозга каткан бүре хәлендә калуларының серен аңлап бетермиләр. Ун ел буе гарәп сүзләрен мәңге чәйнәсәң дә мае чыкмаган чүбек урынына чәйнәп, аларның мәгънәсен белми яшиләр.

Әгәр унике ел тырышып укыса, аның, Галимҗанның, бу мәдрәсәдә мөмтаз мөдәррис булачагы турында әйтте Вәли мулла. Шул сүзләрне ишеткәч, әтисенең йөзе башта кояштай балкып куйды. Аннары ук кояш балкышын тиз генә болыт күләгәсе каплагандай булды. Монысы ни өчендер — аның сәбәбен Галимҗан, кем әйтмешли, төбе-тамыры белән аңлап бетерә алмады. Әтисе вакыт-вакыт Троицк мәдрәсәсендә шактый мәшһүр мөдәррис булуы хакында сөйли иде. Аны ташлап китүенә үкенгән чаклары да була. Китмәсә, имештер, аннан шаккаттырлык гыйлем иясе чыгар иде. Вәли мулла Галимҗанның унике елдан соң тәмамән мөмтаз мөдәррис булачагын әйткәч, әтисенең күк кабагы дәррәү ачылуны аңлау кыен түгел иде: димәк ки, нәсел-нәсәп кояшы киләчәктә дә бөтен тирә-якка нур чәчәчәк әле. Ул нурлар алама-кара болыт эчендә йотылмасын.

Зирәк, сизгер күңелле, мәсьәләнең асылына төшәргә тырышкан Галимҗан аңлый боларның һәммәсен — уку «Шәрке Габдулла»[1]дан башланырга тиеш икән. Бу хакта аның мәгълүматы юк түгел. Кешәнне мәдрәсәсендә дә, гәрчә ачыктан-ачык булмаса да, ул турында колак очына эленеп калырдай гына төшенчә бирделәр. Әтисе дә мең кәррә туглагандыр:

— Менә Ырымбурдагы зур мәдрәсәгә барырсыз, «Шәрхе Габдулла»ны укырга туры килер, аңа чаклы менә боларны, менә шушыларны бел,— дип, гелән генә бер үк нәрсәләрне тәкърарлап торды. Шакирҗан абыйсын да шуңа өйрәтә иде. Аннан соң тора-бара икесенең дә акыл кылларын тартып карый.

Ике ел буе «Шәрхе Габдулла»ны ятлап, аны, кем әйтмешли, су урынына эчкәч, «Нәху»[2]гә төшәргә тиешләр икән. Әтисе аның да кагыйдәләрен ятлата-ятлата тәмам бәгъренә тия иде. Ләкин берәр сүзнең мәгънәсен сораса, әтисе йә җилкәсен кашырга, йә сакалын сыпырырга керешә. Аннан: «Аның сиңа кирәге юк, мәдрәсәдә бу хакта әйтмәячәкләр дә, сорамаячаклар да», дип ачулана иде.

Ничек кенә булмасын, рәхмәт әтисенә: улы өчен зур гыйлемгә юл ярган — ата күрсәткән йолдызга карап атлау горурлык та, рәхәт тә, җиңел дә.

Шуннан соң алар «Әнмүзәҗ»[3]не өйрәнергә тиеш икән. «Мулля җәлял»[4] дигәне дә бар. Монысы моназарә кылганда фикереңне ачык, анык, мәгънәле әйтә белү өчен кирәк. Бусы хакында да Галимҗанның төшенчәсе юк түгел. Әтисе мәдрәсәдә аның буенча шәкертләргә сабак та биргән хәтта. «Сунның тирәнлеген таяк белән, кеше акылын теле-фикере белән үлчиләр»; «Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел»; «Күңеле алама-

---

[1] «Шәрхе Габдулла» — гарәп теле морфологиясенә фарсы телендә аңлатмалар биргән грамматика дәреслеге.

[2] Нәху — синтаксис.

[3] «Әнмүзәҗ» — гарәп грамматикасы.

[4] «Мулля җәлял» — мантыйкның бер төре.

ның теле алама» кебек мәкаль-әйтемнәрне һәр очракта тәкърарлап торырга ярата иде. Шуның белән ул үзенең маһирлыгын, мәгълүматлы, фикерле икәнлеген аңлатырга тырышты, күрәсең. Әнисе турында әйтеп торасы да юк. Үзе бер алиһә ич ул! Сөйләгәндә авызыннан энҗе чәчә. Сүзләре йөрәгеңә, күңелеңә сары май булып ята. Әлеге күгәрченнәр чүпләгән энҗе әллә шундый матур сөйләүчеләрнең сүзеннән коелганмы җиргә?!

Галимҗан үзе хәзергә авызыннан энҗе коючы күгәрчен түгел. Әлегә ул — энҗеләрне үзе җыючы. Һәр мулла, хәлфә, мөдәрриснең сүзен әлеге дә баягы шул зур колакларын торгызып, йөрәгенә үтәрдәй карашлы күзләрен зур ачып, мөкиббән китеп тыңлый. Тик, ни гаҗәп, әлеге күгәрченнәр чүпли торган энҗеләр табылмый.

Солтанморатта Сәет үчител һәр көн үткәрә иде дәресне. Башта үзе сөйләп аңлата. Шуннан укып белергә, аны кабатларга куша. Өйгә эш тә биреп җибәрә. Икенче көнне сорый. Ә монда әллә ничек, бөтенесе дә чуалып беткән җеп кебек. Очы кайдадыр — монысын Ходай үзе генә белә, күрәсең. Мәдрәсәдә җәмгысе алты хәлфә. Алар шәкертләрне бүлеп алды. Галимҗанга озын гына буйлы, кылыч борынлы, ач яңаклы Зарф исемле хәлфә туры килде. Ул беренче дәресне «Шәрхе Габдулла»дан башлады. Озын буйлы булганлыктан, шәкертләр аны «колга» дип атады. Бу атаманы да бирмәсләр иде, бәлки. Анысы аның — ачудан. Чөнки укытуының рәте-чираты юк. Ул кулына озын чыбык тотып керә. Башта, яшен уты уйнагандай, аны берничә кат чыжлатып ала. Бу сезнең өчен, янәсе. Шуннан үзе берни сөйләп тормый. Укырга фәлән биттән фәлән биткә хәтле бирә дә, чыбыгын янә уйнатып, күз белән каш арасында юк була.

Икенче көнне көтсәләр, әллә җир уптымы үзен, эзе дә юк. Кайда йөри? Нигә килми? Шайтан белсен. Озакка сузылган болытлы көзге көннәрдә әллә нидә бер күренгән кояш шикелле, атнасына бер генә килеп киткән чаклары була. Анда да, берәр шәкерт ык-мык итеп торса, яткызып, әлеге чыбыгы белән «сыйларга» тотына.

* * *

Чыбык сыен көннәрдән бер көнне Галимҗан да чак татып карамады. Ул Зарф хәлфә тарафыннан бирелгән кадәресен тиз үзләштерә. Уй казанында җил уйнаган кайбер шәкертләр кебек, мыш-мыш килеп, кашына-кашына, озак-озак күз чекрәйтеп утырмый. Чөнки аның уй казанында әтисе, әнисе салган гыйлем орлыгы бар. Анда әтисе, әнисе ташлаган яхшы уй тоту чаткылары да җитәрлек. Фән-гыйлемнән ул энҗе-гәүһәр бөртекләре генә җыярга тырыша. Бөтенесен уптым-илаһи кочаклап алырга омтыла. Бәгъзе бер шәкерт, хәлфә сорый башласа, бизгәк тоткандай калтыранырга тотына, һәммә рухы, җисмәни көче югалу чигенә җитә. Галимҗан исә, киресенчә, әллә нинди сораулар биреп, хәлфәнең үзен тетрәтә. «Шәрхе Габдулла»да әллә нинди кушымчалар бар. Аларның төрлесе төрле мәгънә аңлата. Бервакыт ул «зар»ның мәгънәсен сорады. Хәлфәнең моңа үлеп ачуы килде.

— «Зар-зар»ның акырып, кычкырып-кычкырып елау икәнлеген өч-дүрт яшьлек бала да белә; синең шуңа да башың җитми, — диде.

Шәкертләр тынып калды. Хәлфә дәвам итте:

— «Зар-интизар»ын да әйтеп бирергә кирәкме?

Галимҗан авызының бер як чите белән генә елмаеп куйды. Аның бу гадәтен хәзер хәлфә дә, шәкертләр дә белә. Сүзсез генә елмаюы гаҗәпләнүне аңлата. Гәрчә Галимҗан аны кешедән каһкаһә көлү нияте белән эшләмәсә дә, башкалар тарафыннан ул шулайрак кабул ителә. «Зар»ның гарәптә тавыш белән елаучыны, иңелдәп, үкереп елаучыны, дәрмансыз, көчсез булуны, зәгыйфьлекне аңлатканны белә ул. Аның «Шәрхе Габдул-

ла»да икенче мәгънәсе бар: «үзе кушылган исем белдергән әйбернең күп була торган урынын белдерүче кушымча («лык», «зар» мәгънәсендә; мәсәлән, гөлзар-чәчәклек».)

Кат-кат төпченә-төпченә шуны сорады Галимҗан.

Хәлфә икеләнеп сүзсез калды.

— Бу кадәресе синә зарури имәс,— дип, бу хосуста үзенең сай йөзгәнлеген сездерде дә чыбыгын чыжлатып алды.

Шулай да Галимҗан чигенмәде. Зарф хәлфәгә җае чыккан саен, һәр форсаттан файдаланып, сорауны яудыра бирде. «Зариф» гарәп телендә ягымлы, нәзакәтле, чибәр, күңелне тартып торырлык итеп сөйләшүче кеше, оста сүзле кеше кебек мәгънәләрне аңлата. Ә нигә бу хәлфә үзен «Зариф» дип түгел, «Зарф» дип йөртә? «Зарф» гарәпчәдә «савыт», «футляр», «конверт», «дәвам», «эч» дигән төшенчәләрдә йөри. Бу сүз «Шәрхе Габдулла»да да бар икән: Зарфе заман (вакыт рәвеше), зарфе мәкян (урын рәвеше).

«Зариф» хәлфәнең рухи халәтенә, эчке хосусиятына аслан туры килми. Чөнки ул ягымлы да, нәзакәтле дә, чибәр дә түгел. Ул, ягымлы сөйләшкән кешеләр кебек, һич тә күңелне тартып тормый. Киресенчә, күңелне кайтаручы, эш пошыручы җәһаләт. Мендәргә җәелеп утыра да тотына әллә ниләр такылдарга. Мондый мәлдә ул, мактана-мактана, үзен пәйгамбәр дәрәҗәсенә күтәрә. Ул, имеш, моназарә вакытында әллә күпме ишан, хәзрәт, муллаларның авызын каплаган оста мантыйкчы. Ә инде Галимҗан кебек гыйлем диңгезендә тирән йөзәргә килүчеләр мантыйк кылын тарткалый башлагач, ул кылның тутык, өзелергә торуы сизелде. Галимҗан — «зариф» белән «зарф» аермасын сорагач, аның төссез соры күзләре песинекедәй елтырады, ач яңагы эчкә тагын да ныграк баткандай тоелды, колгадай озын буе чайкалып куйды. Димәк, әйтә алмый — белми. Бу юлы Галимҗан, башка вакыттагы кебек, авыз чите белән елмаеп кына калмады. Икесенең дә мәгънәсен чатнатып әйтте дә бирде:

— «Зариф» «ягымлы» дигәнне аңлата, «зарф» «савыт» була,— диде.

Бераз торгач янә:

— Буш савыт була,— дип өстәде.

Хәлфә сыны белән катты. Ә шәкертләр, әллә нинди нәзек-тутык тавышлар чыгарып, мәдрәсәнең черек диварын аударыр чиккә җиткереп, шаркылдап көлеп җибәрделәр. Хәлфә дә чыгырыннан тәмам чыкты шикелле. Җенләнгән кеше төсенә кереп, Галимҗанга кизәнеп килде. Галимҗан да кызып китте. Бер мәлдә аңа әллә шайтан көче кердеме? Хәлфәнең чыбыгын ялт тартып алып, ике кулына тотып тезләренә бәрә-бәрә сындырып ыргытты.

Шәкертләр «аһ» итте. Аларның күзләре тоздай булды. Әллә нинди атамалар тагып бетергәннәр иде бит Галимҗанга. Хәзер кемгә тиңләргә инде аны? Арыслангамы? Бөркеткәме?

Мәдрәсә тарихында булган хәл түгел бу. Моны унар ел шушында ми чиләндерүче берәр аю гәүдәле шәкерт эшләсә, бер хәл иде әле. Күрер күзгә әле һич тә ул кадәр каһарманлык сыйфаты сизелмәгән яшь шәкертнең болай кылануы акылга сыйгысыз. Әллә ул тумыштан ук бер диванамы? Андый сәер яклары турында моңа чаклы да уйланмадылар түгел. Өч-дүрт ай эчендә, хәлфә әйткәнне дә көтмичә, әллә кайда керде дә китте. Ике елга дип тәгаенләнгән «Шәрхе Габдулла»ны ерып чыкты. Дәхи дә әллә нинди урыс китаплары ташый. Хәлфә сораганга «аһ» та итмичә чатнатып җавап бирә. Әллә аңа Ходай үзе әйтеп торамы? Берәр сихерле көч гыйлем серләрен колагына өрәме? Шул зур колаклар аша ул тиз генә ми күзәнәкләре дулкынына барып керәме?

Шундыйрак фикер йөртәләр иде. Аның бу сәляхияте күпләрнең башына сыймый хәтта.

— Син бик бәхетле, Галимҗан,— дигән сүзләрне әллә мең кәррә әйткәндер инде бүлмәдәше Йосыф.

Ә менә бу ахмаклыкны ничек аңларга? Барлык бүлмәләрдә шул хакта сүз барды. Бүлмәдәше Йосыф исә әлеге бәхетлелекнең киресен әйтте:

— Суын эчкән коеңа төкергән кебек, үз бәхетеңә аяк чалу бит бу, Галимҗан,— диде.

Бу хәбәр яшен тизлегендә «Хөсәения» мәдрәсәсенә барып җитте. Икенче көнне, иртәнге намаздан соң ук, абыйсы Шакирҗан килеп җитте. Ул бик борчулы, кәефсез, кайгылы иде. Ләкин, кырыс холыклы икәнлеген искә алып, җай гына сөйләшергә тырышты:

— Алай ярамас иде, Галимҗан энем, менә сине хәзер мәдрәсәдән куачаклар; әти-әнине нинди авыр кайгыга салганыңны аңлыйсыңдыр...— диде.

Сөйләшкәндә бүлмәдәше Йосыф та бар иде. Ул сүзсез генә тыңлап торды. Бераздан авыр тынлык урнашты. Аннан янә Шакирҗан телгә килде:

— Вәли мулла алдында да кыен бит әле.

Галимҗан гаҗәпсенеп карады:

— Ә монысы ни өчен тагы?

— Сине бит «Хөсәения»гә алмадылар. Вәли мулла да башта каршы килгән. Тик ул әтинең ялынуы аркасында гына ризалашкан.

— Мин хәзер сәламәт инде, теләсә нинди мәдрәсәгә китәрмен.

Бер-ике айдан Галимҗан чыннан да үзен яхшы сизә башлады. Моңа бик шат иде ул. Шакирҗан исә аның сәбәбен үзенчә ачыклады. Әнисе аны нигәдер артык иркәли иде. Монда ана канаты юк. Шәкерт халкы чирле бәпкә кебек йөрүчеләрне яратмый. Таңда сикереп торырга, салкын су белән тәһарәт алырга, намаз укырга, чиратлап эшләргә, үзеңә ашарга юнәтергә кирәк. Әтисе бер мәртәбә килеп киткән иде инде. Акчаны Шакирҗанда калдырды. Чөнки әткәсе Галимҗанның акча тота белмәгәнен аңлый. Ә Шакирҗан Галимҗанга акчаны азлап-азлап кына тамыза.

Ярый, кем әйтмешли, болары әле аның баш ярылып күз чыгардай галәмәт кайгы түгел. Менә хәлфә чыбыгын сындырып ыргыту кадәресе аслан акылга сыя торган түгел. Бу хакта сүз кузгалгач, Галимҗан абыйсы Шакирҗанга да, бүлмәдәше Йосыфка да:

— Шулай кирәк,— дип кенә куйды.

Бу күңелсез хәлне Зарф хәлфә иң тәүдә мәдрәсәнең эчке тәртибен саклаучы Заһидулла хәзрәткә җиткерде. Заһидулла хәзрәт исә мәдрәсә хуҗасы Вәли муллага йөгерә-атлый китте. Алар өчесе җыйналып, Галимҗанга каты җәза бирү турында озак кына гәпләштеләр.

— Чыбык белән бик каты, тәмам хәлдән тайганчы, телдән язганчы каезларга кирәк,— диде Зарф хәлфә.

— Әйе, шулай мәслихәт булыр,— диде Заһидулла хәзрәт.

Мәдрәсәдән шуннан соң гына куу муафыйк булыр, дигән фикергә килделәр.

Галимҗанның, дини сабаклардан тыш, нииндидер урыс китаплары, «әхлаксызлыкка» өйрәтә торган әллә нәрсәләр укуы, барлык акчасын шуңа сарыф итүе бөтенесенә дә мәгълүм иде инде. Аның бу «ахмаклыгы» да боларны уттан курыккан бүре хәленә куя башлаган иде. Чүп өстенә чүмәлә, дигәндәй, инде бу кыланышы кара сөрем булып капланды болай да тирә-якка яманаты чыккан мәдрәсә өстенә. Чүпне вакытында утамасаң, иген басуын да каплап китә, гөлбакчаларны да харап итә. Вакытында котылмасаң мондый тыйнаксызлардан, мәдрәсәң эчендә ике аяклы шайтаннарның мыжылдап үрчүен көт тә тор. Әле мәдрәсәгә борыны гына кергән. Әмма шәкерт борыны түгел бу. Пычрактан ризык-нигъмәт эзләгән дуңгыз борыны.

Февраль урталары иде бу. Март аенда уку тәмамланачак. Шуңа күрә, икенче елга килмәсен өчен, сүзне җеп урынына сузып маташуның аслан файдасы юк; мәдрәсәнең эчке низамына яраклы рәвештә, моннан

канатын сындырып чыгарып җибәрү хәерле булыр. Мондый динсез, әхлаксыз, ашаган табагына төкерүчеләрне асрап, Аллаһы тәгалә каршында үзең гөнаһлы булып калуың бар. Ходай сакласын! Ходай сакласын!

Шулай да алар бер «адәмчелек» күрсәтмәк булды. Югары сыйныфта булса, менә бүген үк җилперләр иде. Аның үзен генә чыгарып җибәрү куркыныч. Авыллары шактый ерак. Әтисе килеп алсын. Моның өчен Гыйрфан муллага хат язарга булдылар. Бу «мөкатдәс» эшне Вәли мулла үз җилкәсенә алды. Хатны ул болай артык тузынып язмады. Үзен инсафлы, Алла каршында гөнаһсыз, әдәпле итеп күрсәтергә тырышты. Менә ул:

«Бисмиллаһир-рәхманир-рәхим! Әссәламегаләйкүм вә рәхмәтуллаһы вә бәрәкәтүһ! Сезки гыйззәтле вә хөрмәтле булып торгучы Гыйрфан әфәнде! Үзеңә вә хәләл җефетеңә күпдин-күп сәламнәр күндерәм. Сәлам соңра сезләр өчен бигүк күңелле булмаган хәл турында хәбәр кылырга мәҗбүрмен. Мәгълүм ки, улыңыз Галимҗан йомшак вә чирле бала иде. Шул сәбәпдин аны «Хөсәения»гә дә алмадылар. Бән үзем, сезнең мулла икәнлеңегезне, мәдрәсәдә мөдәррис булуыңызны да искә алып, сезнең белән дусларча мөгамәләгә кереп, авыр булса да, ихтирам-хөрмәт йөзеннән, улыңызны алып калырга җөрьәт иттем. Сез улыңыз Галимҗанны мактаган идеңез, чынлыкта исә киресенчә килеп чыкты. Бу һич кенә дә муасигъ[1] түгелдер. Мәдрәсәнең низам-интизам кадәресе дә аның өчен, гүяки, бер файдасыз нәрсәдер. Хәтта ки, Зарф хәлфә белән якалашу чигенә барып җитте. Ул гайре табигый мавыгу колы. Тыелган эшләр белән мәшгуль. Илтифатлылыкның ни икәнлеге аның уенда да юктыр. Бунын шулай булуы безем өчен би нишан.[2] Алла сакласын инде. Шуңа күрә безләр,—мәдрәсәнең хәзрәте Заһидулла, хәлфәсе Зарф җәнаплары, дәхи дә башка гыйлем ияләре берләшеп фикер алышкач, моназарә кылгач, улыңыз Галимҗанны мәдрәсәдән азат итәргә дигән карарга килдек. Иншаллаһ, безләрнең бу карары аның киләчәк язмышы өчен илаһи бер сабак булыр. Башка урында андый хилафлык кыйлмас. Алла үз канаты астына алсын инде. Чирне вакытында кисеп ташлау хәерле. Шулай итмәгән хәлдә, Ходай Тәгалә каршында сез дә, без дә бихисап гөнаһлы булып калыр идек. Аларны үз иманына берләшеп кайтару безем иң мөкатдәс максатымыздыр. Улыңыз әлегә ипкә килерлек имәс. Вәләкин, яшен искә алып, аны әле бүгендин үк мәдрәсәдән чыгарып җибәрү ягында түгелмез. Шулай эшләсәк, безнең тарафтан бәндәчелексез күрсәтелмеш булыр иде. Шуңа күрә, улыңызны үзеңез килеп алыңыз!»

## X

Хатны алгач, Гыйрфан мулланың оҗмах-җәннәткә тиң өй эче капылт тәмугка әйләнгәндәй булды. Ата кешенең куллары хатны укыганда ук дер калтырап торды. Бөтен тәне-вөҗүде камырдай йомшап, күзләре чекрәеп, колаклары тонып калды. Түбәгә кемдер чукмар белән китереп тондыргандай тоелды. Илаһым! Бар икән күрәчәкләре. Ни гөнаһлары бар икән аның Аллаһы Тәгалә каршында? Инсаниятчелек дигәндә кем аның илаһи ак намусына кара тап төшерә алыр икән? Әй менә балалар төшерә. Шакирҗаны мәмәй авыз булды. Ни караган шунда? Нигә энесе янына даими килеп йөрмәгән? Нигә күзәтмәгән? Нигә үгетләмәгән яхшы якка? Һәр нәмәрсәкәйне бозыла башлаганчы карау мотлак. Бозыла башладымы, шул төшен кис тә ыргыт,

[1] Муасигъ—башка сыйдыра торган.
[2] Би нишан—билгесез.

кис тә ыргыт. Ник ул мәмәй авыз шулай итмәгән? Нигә энесенең һәр ертык урынын ямый бармаган? Селәгәй. Кибәк баш. Буш җилек. Уф! Егыл да үл. Җир тишегенә кер. Чәнчелеп кит. Гарьлеге ни тора моның. Дус бар, дошман бар, туган-кардәш бар. Алар ни әйтер? Җин сызганып көн-төн эшли, чукынырдай булып дөнья көтә, артына ут капса да биш вакыт намазын калдырмый, вәгазь сөйли, үгет-нәсыйхәт кыла, ә менә бер маңкасына көче җитми, диннән язган, иманын саткан, шуңа күрә мәдрәсәдән куганнар, диярләр, илаһым! Баланың тездә чакта сөйдерүе, тездән төшкәч көйдерүе шушы икән. Көйдерә болар. Йөрәгеңне яндыра. Күңелеңне өтә. Менә сиңа таш маңгай. Менә сиңа пәйгамбәр. Менә сиңа нәсел орлыгыннан шытып үсеп чыккан ботаклы-яфраклы агачны һаман үстерү, яшелләндерү, күркәм сыйфатта тоту. Үстерде, ди. Тот капчыгыңны. Үстерми болар. Корыталар. Алар бүгенге көн кояшы белән яши. Үз корсагы кояшы кыйммәт аңа. Аның өчен нәсел кояшы, халык кояшы, ил кояшы сукыр бер тиен дә тормый. Күктәге кояш менә бүген сүнсә дә, гамьнәре юк. Әллә-лә-лә-ләл. Әллә-лә-лә-ләл. Уф! Илаһым! Бердәнбер ышанычы иде бит. Бердәнбер.

Хатны ул, үзе дә сизмәстән, учында йомарлады. Остабикәсе ни дип әйтергә дә белми аптырап тик торды. Мулласының акайган күзләрен, күзге яфрактай дерелдәп торган иреннәрен, җыерылган маңгаен күреп, яман хәбәр килгәнлекне аңлау кыен түгел иде. Ул һаман шулай элеккечә тыныч, салкын канлы булырга, шул салкынлык белән иренең утын сүндерергә тырышты:

— Мулла, син бөтенләй бетеп калдың; аңлыйм, яхшы мәктүп түгел, шулай да Ходайдан сабырлык сора, үзеңне кулга ал. Аллаһы Тәгалә авыр кайгыларга да бирешмәскә кушкан бит...— дип, янә дә шуларга охшаш күпме җылы сүзләр әйтеп юатмакчы булды.

Ләкин ул баллы-майлы, җылы-кайнар, ялкынлы сүзләр мулласының таштай каткан йөрәген эретерлек түгел иде. Киресенчә, бу мәлдә алар ачуын гына кабартты, җенен генә кузгатты:

— Мә, укы,— диде дә Гыйрфан мулла, хатны остабикәсенең битенә бәрде.

Аның лөгатькә сыймаслык бу кыланышы «баланы син генә боздың» дип әйтү билгесе иде. Моны эшләгәч, үзен кая куярга урын тапмыйча җенләнеп-котырынып, тышка чыгып китте.

Хәсәнә абыстай бер мизгелгә ни кылырга да белми аптырап тик торды. Мулласы артыннан чыгаргамы? Һаман шулай:

— Атасы, бу кадәр сабырсызланма әле, ходай кушмаган эш булмас, тынычлана күрче, балаларга кайгылы йөз күрсәтү килешми,— кебек сүзләрне әйтә-әйтә, тәкърарлый-тәкърарлый, юатыргамы? Бәгъзе берчак аңа да килми бит әле ул — кулын гына селтәп җибәрә: кит, янәсе, мыегымны чуалтып йөрмә.

Шундый уйларны кичереп, үзен кулга алгач, идәндә йомарланып яткан кәгазьгә күзе төште. Аның эчендә нинди дәһшәт, давыл, өермә бардыр кебек тоелды. Шул дәһшәт аның йөзенә ут йомгагы булып томырылды.

Кәгазьне абыстай курка-курка гына алды кулына. Аны өстәлгә җәеп, әйбәтләп, укырлык дәрәҗәгә җиткәнче, төзәтте. Укып чыккач, никадәр генә йомшап китмәскә тырышмасын, ходайдан сабырлык сорап изаланмасын, күз яшьләре аның ихтыярына буйсынмады.

Әле иртә иде. Балалар эчке бүлмәдә йоклый иде. Ярый, рәхәтләнеп, йөрәктәге кайгы утын түккәнче, күңелен тәмам бушатканчы елаганын күрмәделәр. Тик ул ялгышкан икән. Кызы Нәгыймә, һәрвакыттагыча песи кебек йомшак кына басып, башкаларны уятмас өчен авыр тын да алмыйча, бу якка чыккан икән.

— Әнкәй, әнкәй, ни булды, нигә елыйсың?

— Еламыйм, кызым, менә, күземә чүп кергәнне.

— Юк, юк, әнкәй, яшерәсең. Әллә эти рәнҗеттеме?

— Иртәнге сәгатьтә нинди рәнҗетү булсын.

Хәсәнә абыстай, кызына күрсәтмәс өчен, елаудан шешенгән күзләрен яулык чите белән каплап, тышка чыкты. Ә менә хатны алырга онытткан. Өстәл өстендә калдырган. Аны укып чыккач, барын да аңлады Нәгыймә. Әнисе кебек, әлбәттә, буылып-буылып еламады, «аһ» итмәде. Башта бу мәсьәләгә битараф кеше кебегрәк кыланды. Шулай да бу усал хәбәр аның да йөрәген таштай катырды. Әтисе хәзер яраланган арыслан кебек кыланачак. Әнисе, мескен, кайгы утында яначак. Өй эчендәге низаг зилзиләдән ким булмас. Бу зилләткә әтисе түзә алмас.

Менә әнисе бераздан әйләнеп тә керде. Ул инде күз яшьләрен ныклап сөрткән. Бая яулык эченнән чыгып торган чәчләре дә күренми хәзер. Шулай да ул һаман да әле кызына туры карамаска тырышты. Нәгыймә:

— Әнкәй, әнкәй бик борчылма инде, Галимҗанның табигатен беләсең бит, ул барыбер үзенчә эшли,— дигәч, ана йөрәге дерт итеп китте.

— Нигә алай дисең әле, кызым, ни булган...— дип барын да яшерергә тырышты. Кызының кулындагы хатын күргәч кенә мәсьәләне аңлап алды. Нәгыймә үзенчә аз гына үпкә белдерергә дә онытмады:

— Әнкәй, нигә мондый хәлләрне миннән яшерәсең әле, бала түгелмен дә инде хәзер,— диде.

Әйе шул: нигә кайгыны да, шатлыкны да уртаклашып яшәгән кызына бу авыр хәлне белдермәскә тырыша соң әле ул? Җитмәсә, Нәгыймә менә-менә канатланырга торган гүзәл кош ла инде. Хәсәнә абыстайның бианасы 12 бала тәрбияләп үстерү белән горурланган. Шуларның берсе — аның ире Гыйрфан мулла.

Шул көнне үк Гыйрфан мулла юлга чыгарга — Ырымбурга барырга әзерләнә башлады. Шул көнне үк хәләл җефете Хәсәнә абыстай түшәккә ятты. Башы чатнап ярылырдай булып сызлый. Вакыт-вакыт күз аллары караңгылана. Керфек очларында да хәтта гер ташыдай ниндидер авыр нәрсә асылынып торгандай тоела. Ара-тирә аягын нык кына көзән җыера. Тамак төбенә әллә нинди имәнеч зур төер килеп тыгылгандай була.

Шулай да төшкә чаклы аны сиздермәскә тырышып йөрде. Өйлә намазын укыганда намазлыкка тәгәрәп китүен абайламый да калды. Аны ястыкка алып салдылар.

Гыйрфан мулла ике ут арасында калды. Бер ут — остаз бикәсе. Икенче ут — Ырымбур. Кайсы утны сүндерергә башта? Әлбәттә, монысын. Бу утны сүндерми торып юлга чыгарга ярамый. Ә нишләп шулай, ваба чиренә эләккән кешедәй, капыл-кинәт тәгәрәп китте соң әле ул? Галимҗан кайгысы шулай иттеме? Юк, ул гына түгел иде. Андый кайгыларга аслан бирешми иде бит ул. Киресенчә, аның үзен авыр кайгылардан аралап яшәргә тырышты. Бер-бер күңелсез хәл килеп чыкса, гелән генә борчылмаска кушты. Юк, аңа гына түгел, кыен мәлләрдә күрше-күлән, кардәш-ыруг, дус-иш...— һәммәсенә, сүз шифасы таба алды, назлы карашларын бүләк итте, йөрәк-бавырына үтеп керде. Юк, әле менә Галимҗан кайгысы гына екмады аны аяктан. Иренең юньсезлеге яткызды түшәккә. Йомарланган хатны тот та аның йөзенә бәр, имеш. Бу инде — илтифатсызлыкның илтифатсызлыгы. Бу инде — әдәпсезлек. Бу инде — шәфкатьсезлекнең шәфкатьсезлеге. Бу — бәяләп бетергесез ахмаклык, юләрлек, түбәнлек. Шундый фәрештә күңелле остазбикә бит әле ул. Кырт-мырт итеп торган, кылдый-былдый йөргән, синең бер сүзең өчен авызыңа мең берәгәйле сүз каплаган зәһәрле хатын булса, әллә-лә-ләл, бәрер идең битенә болай. Бәрсәң дә, ул синең ипи шүрлегеңә табагач белән китереп сылар иде. Матурлык-изгелек фәрештәсенең ак-нурлы йөзенә кара-пычрак кул белән кизәнгән иблис кебек булды бу. Шул гарьлеккә чыдый алмый ауды ул киселгән агач урынына.

Алтыдагы — алтмышта, дигәне шушымы? Нишләтергә бу холык-кылыкны? Әйтәләр ләбаса: «Акылыңа акыл куш, ачуыңа сабыр куш», «Ачу — акыл дошманы», «Ачу алдан йөри, акыл арттан йөри». Тагын да

әлләниндиләрс бар әле аның. Әтисе дә, картәтисе дә әйтә иде. Борынгылар сүзе дип. Алтын бәрабәренә торырдай ул акыллы сүзләр бер колагыннан кереп икенчесеннән чыгып китеп торганмы? Миенә барып җитмәгәнме?

Нишләргә хәзер? Барып гафу сораргамы? Ул, әлбәттә, кичерәчәк. Әмма ләкин аннан ни файда? Ичмасам, шартлап ярылырдай итеп бер авыр сүз әйтсен иде. Бу ахмак күңелгә бер тукмак булыр иде.

Шундый утлы уйлар өермәсе эчендә бөтерелеп йөрде Гыйрфан мулла.

Хәсәнә абыстай исә капыл тәгәрәп китү сәбәбен аннан эзләп бимазаланмады. Ир хакы — тәңре хакы. Әле әнә бәгъзе бер ир хатынын изеп ташлый. Шулай да түзә, йөрәк канын эчкә йота, күгәргән битен, сынган кабыргасын кешегә сиздермәскә тырышып йөри. Сорасалар, «егылдым» дип җаваплый. «Ир хакы — тәңре хакы»,— дигәнне ул яхшы аңлый. Ә шулай да: «Хатын хакы ни икән?» — дигән сөаль дә борчый аны. Шул сөальгә «изге» җавап булып томырылдымы йөзенә әлеге кәгазь йомарлагы? Ул, әлбәттә, нык гарьләнде, түбәнсенде, чыдый алмас хәлгә җитте. шул изде шикелле аны. Шул екты. Шул җәнчеде.

Менә бервакыт мулласы аның янына килде. Салкын кулы белән кайнар маңгаена кагылды. Сизә: кулы дерелдәп тора. Димәк, ул борчыла. Кылган ахмаклыгы өчен үкенә. Сызлана.

Менә ул сүз башлый:

— Йә, остабикә, ачуланышмыйк инде, кичер мин юньсезне, гаеп тәртәсе икебезнең дә йөрәккә килеп төртеләдер. Галимҗанның болай тәүфикъсыз булуында икебез дә гаепледер.

Гыйрфан мулла нык дулкынлана иде. Сөйләгәндә аның калтыранып-калтыранып алуын, сүз таба алмый интегүен сизде Хәсәнә абыстай. Акрын, салмак, йомшак тавыш белән сорап куйды:

— Юлга әзерсеңме?

— Анысы аның качмас иде лә ул. Менә син бит әле... Чирле кешене нишләп ташлап китим...

— Юк, юк, атасы, аңа карама, Нәгыймәнең уңганлыгын беләсең... бүген үк чык юлга...

— Бүген соң инде, остабикә, иртәгә иртүк кузгалырмын, дүшәмбе көн юлга чыксаң, фәрештәләр ак җәймә җәя, имеш.

— Галимҗанга бик каты авыр сүз әйтмә инде, мулла, андыйны яратмый ул, үзең беләсең; һәркемдә бер кире сыйфат булмый калмыйдыр шул инде.

— Ярый, анасы, фатихаңда бул инде, каты рәнҗеттем, үпкәләмә берүк...

## XI

Гыйрфан мулла эшне иң әүвәл мәдрәсә хуҗасы Вәли мулладан башламак булды. Атын аның капкасы төбенә үк китереп туктатып, шундагы бер баганага бәйләп куйды да, тамак кыра-кыра эчкә узды. Ишек шакыгач, башына кызыл фәс кигән уникс яшьләр чамасы бер малай килеп чыкты. Гыйрфан мулла аның йомышчы икәнлеген аңлап алды.

— Вәлиулла галиҗәнаплары өйдәме, улым? — дип сорады ул.

— Өйдә,— дип җавап бирде малай.

— Керергә рөхсәт сорасаңчы. Мин ерактан килдем. Галимҗан мәхдүмнең әтисе булам.

Малай ялт өйгә кереп китте бераздан әйләнеп тә чыкты.

— Вәлиулла галиҗәнаплары сезне көтә,— диде дә янә юк булды ул.

Шуннан Гыйрфан мулла, арбасы янына янә әйләнеп килеп, аннан ике тозлаган каз, бер савыт кәрәзле бал, тагын да вак-төяк күчтәнәчләрен алып, өй эченә юнәлде. Вәли мулла түр башында тәсбих тартып утыра иде. Ул болай ару гына мөлаем күренә. Түгәрәкләнеп торган кара сакалы

килешле генә. Башындагы Бохара дуплысы да кызарып торган бит очларына ямь өсти кебек. Биш билле кара камзулы «менә мин нинди зыялы әфәндене затлыйм» дип мактана шикелле.

— Әссәламегаләйкем! — дип, үзенчә бер түбәнчелек, әмма ләкин гаҗәп олылау, зур мөхтәрәмлек белән сәлам бирде Гыйрфан мулла.

— Вәгаләйкемәссәлам! — дип, тамак кырып, үзен гарьше көрсидә утырган илаһи зат хәлендә күрсәтергә теләп, эре кыяфәт белән каршылады аны Вәли мулла.

Башта сүзләр әллә ни берекмәде. «Әйе», «ә», «җәме», «җә» кебегрәк файдасыз, салкын, кыенсынып сөйләшү дәвам итте. Гыйрфан мулла алып килгән күчтәнәчләрен аның алдына тезеп куйгач кына, тегесенең һавалы йөзе бераз ачыла төште: шунда гына ул тәсбихен куеп, ерактан килгән кешегә илтифатлылык тиешлеген аңлады. Шулай да эре кыяфәтен тиз генә вакларга ашыкмыйча, үзен әллә кемгә куеп, шөһрәт вә мөхтәрәмлелек югалмасын дигәндәй, һаман әле ачылып китәргә ашыкмады. Гыйрфан мулла аның хуш мәҗлесе булмавына беренче күрешкәндә дә сиземләгән иде. Ә хәзер инде, улы шундый хәлгә төшкәч, аның тәкәбберлеге янә мең кәррә артачагы мәгълүм хәл. Бу аның сүз башлавыннан ук сизелде.

— Ху-у-у-ш, Гыйрфан әфәнде, ни йомыш? — дип сорады ул, улы Галимҗан турында ләм-мим хәбәрдар булмагандай бер пошамансызлык белән. Әйтерсең, булган хәлләр аның өчен әһәмиятсез бер вакыйга иде.

Гыйрфан мулла үзен бик түбәнчелекле тотарга тырышты. Биредә сырт кабартуның хәләл җефет алдында кәпәренү түгел икәнлекне аңлый иде ул.

— Сезнең хат буенча килдем, Вәлиулла галиҗәнаплары, шул инде: әлеге дә баягы углым Галимҗан хакында, — диде ул, итәгатьлелекне сакларга тырышып, юаш, басынкы тавыш белән.

Сөйләшү шактый озакка сузылды. Вәли әфәнде Гыйрфан мулланы бетереп тә ташламады, күккә күтәреп мактамады да: шулай да, сүзләренә караганда, аның тел төбе Галимҗанның гаиләдә яхшы тәрбия алмавына барып төртелә иде. Имештер, Галимҗан гәрчә тәрбияле нәселдән булса да, алама эшләр белән мәшгуль.

Шуннан сөйләшү, акрын гына аккан агымсу үз юлын тапкан кебек, чыбык мәсьәләсенә барып төртелде. Галимҗанның Зарф хәлфә чыбыгын сындырып ыргытуы, Вәли мулла уйлавынча, көфернең Мөхәммәт пәйгамбәргә таяк белән кизәнүе кебек икән. Мондый әшәкелек мәдрәсә хәятендә моңача әле булмаган. Аның «тәрбиясез» улы Галимҗан мәдрәсәдән шуның өчен куыла. Бетте китте. Вәссәлам.

— Мондый нәүгъларны[1] безем мәдрәсәдә тоту нәмәхрам[2] шул, Гыйрфан әфәнде, — дип сүзен тәмамлады ул.

Шулай да Гыйрфан мулла язгы кардай эреп төшмәде, куркак куяндай кирегә бөкләргә дә ашыкмады. Әйдә, чәнчелеп китсен аның башбирмәс «ташмаңгае», укыйсы килми икән, кайтсын, сабан сөрсен, тырма тырмасын, иген чәчсен, иген урсын, печән чапсын; Ходайга шөкер, анда эш җитәрлек. Муеннан. Тик көрәш мәйданында бил сындырган йомшак җан кебек, болай җиңелеп кайтып китүе кыен бит әле. Вәли мулла аны наданга чыгарды. Бала тәрбияли белмәгән бер мәмәй авызга чыгарды. Бу хурлыкны күтәреп кайтып китсенме ул Солтанморатка? Юк инде. Булмый. Ул бит әле теләсә кем түгел. Троицк мәдрәсәсендә баш мөдәррис булган абруйлы шәхес.

Гыйрфан мулла шуларны янә бер мәртәбә искәртеп үтүне мәгъкуль күрде. Шуннан килеп, улы Шакирҗанның өй матчасындагы чыбыкны сындырып ташлавы турында да әйтте. Чыбыктан үчител Сәетнең баш тартуын да искә алды. Чыбык белән «тәрбияләүнең» гүзәл нәтиҗә бирмәячәген ярып салды.

---

[1] Нәүгъ — төр, спорт.
[2] Нәмәхрам — гөнаһ.

Аларны, билгеле, салкын кан белән, ашыкмыйча, сабырлык белән, аңлатырга тырышты. Акрын-акрын, уйлап-уйлап, җиңү дәрте белән сөйләште. Вәли мулланың уй казанында фикер сыек булганлыкны аңлады ул. Ахмакны һәр очракта акыллы сүз белән җиңеп булмаячакны да белә. Шулай да монда ордым-бәрдем белән эш итү дә бик читен. Кинәт күз алдына остабикәсенең битенә кәгазь йомарлыгы белән бәрү ахмаклыгы килеп басты. Галимҗанны бөтенләйгә алып кайтса, мәдрәсәдән мәңгелеккә мәхрүм итсә, аның күзенә ничек карар да, ялварулы карашларына ни җавап бирер? Телең булмаса, күзеңне әллә кайчан карга чукыр иде, шул бала язмышын хәл итер рәтең дә юк икән, дип сыкранырга мөмкин. Боларны ул, әлбәттә, әйтмәячәк. Әнә шул әйтмәве үтерә бәгъзе бер вакыт.

Йомшак, әдәпле, мөкиббән сөйләшкән саен Вәли мулланың һавалана баруын, борын чөюен, очынуын аңлады ул. Шуңа күрә бүртеп торган кызгылт бит очларына салкын җил истерүне мәгъкуль күрде.

— Мәдрәсәгез бик йончу, безнең авылда мондый бинага малны да япмыйлар, низам-интизам юк, Вәлиулла әфәнде, мин шикаять кылам, буны аслан да янау ысулы дип кабул итмәгез,— диде ул.

Гыйрфан мулла аның нәкъ авырткан җиренә китереп басты. Ул инде әллә күпме ел шул шикаять дигәннәреннән куркып яши. «Кадим мәдрәсә» дигән «даны» бар. Аңа килергә ашкынып тормыйлар хәзер. Менә шушындый Гыйрфан кебек гайрәтле, гаярь ирләр җыйнаулашып шикаять кыла башласа, мәдрәсәң, кем әйтмешли, карга оясы урынына туздырылырга мөмкин. Шуны уйлап, баштук каты итеп торткан сүз тезгенен акрынлап-акрынлап бушата барырга уйлады ул.

— Хи-хи-хи, хи-хи-хи... усаллык белән алдырмак буласың инде алайса, хәерле булсын. Алла ярдәм итсен үзеңә, мин синдәй кыю кемсәләрне бик якын күрәм, яратам ук,— диде.

Сөйләшә-сөйләшә, фикерләшә-фикерләшә, уйлаша-уйлаша, уртага салынган авыр мәсьәлә Гыйрфан мулла файдасына хәл ителде. Галимҗанны мәдрәсәдә калдырырга булдылар.

— Үзең килү бик муафыйк булды, алып кайтып кит, икенче сыйныфка китереп куярсың, Аллаһы боерса; тик шундый шарт белән инде, Гыйрфан әфәнде: бундан булай андый ахмаклыклар, нәҗес эшләр кыйлмасын,— диде Вәли мулла.

* * *

Март азаклары иде инде. Бәгъзе бер урын кардан тәмам әрчелеп беткән. Алалы-тиләле җирләр дә бар. Койма төпләрендә кояш күзеннән мәхрүм булган кар өемнәре дә күренгәли. Алар инде бозга әверелгән. Өсләрендә пычрак-чачрак, ләпек-чәпек, алама-солама,— тагы да әллә нинди нәҗес әйберләр дөнья ямьсезләп тора. Ә инде урам уртасындагы юллар хәзер тап-такыр. Аз гына җил иссә, тузан күтәрелергә тора хәтта. Әмма яз кояшының йомшак, җылы, шифалы нурлары һәр кемсәне, һәр тарафны, һәр тереклекне илаһи бер олы, сөйкемле мөкиббәнлек белән иркәли. Фанилыкта әле менә:, әйтерсең, һичнинди яман эшләр кылынмый. Гүя, һәммәсе ал да гөл.

Юк, гөнаһ шомлыгы, барысы да алай түгел икән шул. Түгел. Түгел. Мең кат түгел. Вәли әфәнденең салкын мөнәсәбәте Гыйрфан мулланың кәефен нык кырды. Әгәренки аңа, Гыйрфан мулланың өенә, моңача һич таныш булмаган бер адәм заты (юлчы) мохтаҗлык илә килеп керсә, буш кул белән чыгарып җибәрер идемени? Юк, җибәрмәс иде. Аслан җибәрмәс иде. Ә бу җаһил диндар ерак юлдан йончып килгән Алла бәндәсенең авызын да чылата алмады — бер чынаяк чәй дә куймады. Күңел өчен генә булса да: «Самавыр куйыйк, Гыйрфан әфәнде»,— дисен иде. Ә ул, Гыйрфан: «Юк, Вәли әфенде, мәшәкатьләнмәгез, эчкән чаклар булыр

әле»,— дияр иде. Санга сукмаслык әллә нинди бер тиле түгел бит ул. Троицкинең данлыклы мәдрәсәсендә баш мөдәррислек эше кылган шәхес. Кирәк кычкырып уку булсын, кирәк тәфсирне — Коръән тәрҗемәсен аңлау булсын, ул бит зиһенлелек күрсәткән диндар. Әллә аңламыйммы ул җаһил Вәли мулла мантыйгының менә хәзер таралып төшәргә торган шыгырдык арба хәлендә икәнлеген? Илаһым! Кеше белән кеше аермасы — җир белән күк аермасы, дип юкка әйтмиләр икән. Үлемнән оят көчле, дигәне дә бар. Ояла белми икән бу җаһил.

Шундый уйлар давылы борчыды Гыйрфан мулланы. Вәли мулла капкасы төбеннән киткәч, башта ул атын үз иркенә куйды. Аннан, ашыгырга кирәклекне уйлап, юырта башлады. Вәли мулланың гамьсез күркә кебек кабарынып утыруы исенә төшсә, дилбегәсен ачу белән каты гына тартып, чаптырып та ала. Бу вакытта тимер арбаның тәгәрмәчләре, шаңгыр-шоңгыр өзек тавышлар чыгарып, артта куе тузан болыты сузып калдыра. Аңа хәзер җәһәт кенә «Хөсәения» мәдрәсәсенә барып җитәргә кирәк. Аннан Шакирҗанны алып, Галимҗан янына ашыгу мәслихәт булыр. Шәһәрне чыккач, беренче авылда атны ял иттерерләр, кичегеп китсә, шунда кунып калулары да ихтимал.

Шакирҗан янында артык озак мәшәкатьләнмәде ата кеше. Кереп табу белән тиз генә әйберләрен җыярга кушты да җәтрәк Галимҗан янына ашыгырга кирәклекне әйтте.

— Әткәй, чәй эчеп алыйк,— дисә дә Шакирҗан, гәрчә тамагы нык кипкән булса да, чәйләп утыруны ул бу мәлдә мәгъкуль күрмәде.

— Галимҗанда бергәләп эчәрбез, Алла боерса, арбада әнкәгез җибәргән сый-нигъмәт тә бар, әйдә, улым, җәһәт кылан,— дип ашыктырды.

Мәдрәсәдән күпләр киткән иде инде. Якын авыллардан булганнары үзләре җәяүли. Бәгъзе берләре, югары сыйныфтагылар, төрле завод-фабрикаларга, шахталарга, алтын приискыларына эшкә китә — киләсе ел уку өчен акча кирәк. Икенчеләре казакълар арасына юл тота. Язын-җәен анда мөгаллимлек кылып, бераз адәм рәтенә кереп, азрак көрәеп, кесәсен хәлләндереп кайта. Шакирҗан да дәртсенгән иде. Сәбәпсез сәгать тә йөрми, дигәндәй, ике сәбәп аның җилән итәгеннән тартып туктатты. Беренчесе — атадан рөхсәт алынмаган; икенчесе — Галимҗан бәласе.

Бу хакта, ашыга-ашыга әйберләрен җыештырганда, мәдрәсәнең менә бүгенге хәлен аз гына булса да күз алдына китереп бастырыйм дигәндәй, әтисенә җайлап-җайлап әйтеп бирде Шакирҗан. Әткәсе аларны юньләп тыңламады да.

— Һи... нигә кирәк сиңа әллә кая китү, әллә өйдә эш беткәнме? — дип кенә куйды.

Галимҗан өчен әтисе нык ачуланыр дип курыккан иде Шакирҗан. Шуны уйлап, әтисен төрле-төрле сүзләр белән әвәрә кылырга тырышты. Ни дисәң дә, әле шәкертләр китеп бетмәгән. Тыз да быз чабып йөргәннәре дә, йокымсырап утырганнары да, чәй эчү белән мәшгуль булганнары да бар. Әтисенең кызу канлы икәнлеген белә Шакирҗан. Галимҗан өчен менә хәзер үк, шул тыз да быз йөргән шәкертләр туктап тыңлар дәрәҗәгә җиткереп, сүгә башлар кебек тоелган иде. Шулай килеп чыкмасын өчен, янә бер яңалык әйтеп ташлады,

— Әткәй, монда Гаяз Исхакый дигән бер бик мәгълүматлы мөдәррис киләчәк икән, ул китаплар да, әдәби әсәрләр дә яза, имеш,— диде.

Әткәсе өчен бу яңалык та ике чабатаның бер кием булганы сымак кына тоелды. Галимҗанны карамаган, күзәтеп тормаган өчен Шакирҗанның колагын менә хәзер үк борырга иде аның нияте, әмма ләкин тыелды: кеше йортында авыздагы кара канны да төкерергә ярамаганны белә ич ул.

Әйберләрне җәһәт-җәһәт чыгарып бетереп, арбага төягәч:

— Әткәй, син юлда арыгансыңдыр, кая, атны үзем тотыйм,— дисә дә, ата кеше ризалашмады.

— Җәтрәк менеп утыруыңны бел, теләсә кемгә баш бирә торган байтал бардыр шул миндә,— диде коры гына.

Шакирҗан сизә: әткәсенең кырт-мырт килеп торуы, утка баскан кебек кылануы, дөньяга сыймастай булып чабалануы Галимҗан өчен. Ә инде үзен, һаман шул элеккечә, җиде кат күк түбәсенә куеп, балаларына кимсетеп карый: «теләсә кемгә баш бирә торган байтал шул миндә», имеш. Үтерде ул бу сүзләре белән Шакирҗанын. Егетлек дәрәҗәсен челпәрәмә китерде. «Әткәй, нигә әле син мине шул кадәр түбәнсетәсең?» дияр иде, ярамый: ата кеше сүз кайтарганны яратмый.

Хәер, аны әйтергә форсат та юк. Әтисе, дилбегәне тоту белән, аны шактый нык кагып, байталга җәһәтлелек кирәклекне аңлатты. Байтал, колакларын торгызып, шундук ут кебек томырылды. Әйтерсең, сабантуйдагы чабыш мәле. Әтисенең эчендә җил-давыл, өермә барлыкны аңлады Шакирҗан. Бер сүз әйтсәң, әтисе шартлап ярылып, ул давыл-өермә ябырылыр кеби тоелды. Әллә кансыз дамы аның әтисе?

Юк, алай ук түгел. Бердән, Галимҗан өчен үлеп ачуы килсә, икенчедән, берникадәр кызганып та куйды әле Шакирҗан улын: кипкән, корыган, яңак сөякләре калкып чыккан — менә ни дәрәҗәгә төшерә бу мәдрәсә хәяте адәм баласын.

Менә Су урамы белән Татар тыкрыгы чаты. Менә Вәли мулланың Кадим мәдрәсәсе.

— Тыр-р-р...

Байталны ат бәйли торган махсус баганага бәйләп куйдылар. Гыйрфан мулланың теге вакытта да укып киткән сүзләргә күзе төште; ул таш диварны уеп язылган: «Каедкый ятән вакуфи фиәлсудебни палата. 1872 сәнә»[1].

— Әйдә, чәй эчеп, тамак ялгап алыйк та, аннан кайтыр якка тәвәккәлләрбез, караңгы төшкәнче якындагы берәр авылга барып баш төртеп алырга кирәк булыр,— диде дә ата кеше, ризык-ашамлык төйнәлгән төенчекне күтәреп, капка аша үтте. Шакирҗан аннан калмаска тырышты.

Ихатага кергәч, аларны әллә нинди нәҗес чүп өемнәре каршы алды. Гыйрфан мулла шуларны күреп, чыраен сытты, маңгаен җыерып, тәмам гаҗиз булып калды. Күз алдына әле генә борчак чүмәләседәй кукраеп утырган Вәли мулланы китерде. Бу чүп өемнәре дә әнә шул борчак чүмәләседәй җәелеп утырган Вәли мулланы хәтерләтте. Ул өемдә ниләр генә юк: иске чабата, күгәреп-череп каткан җирәнгеч чүпрәк-чапрак, сасыган бәрәңге кабыклары, тагын да әллә ниләр, әллә нәмәкәйләр... Алардан ниндидер сыек-зәңгәр бу-төтен күтәрелә. Әллә көя, әллә яна — шайтан да белерлек түгел. Шулардан тирә-якка косасыны китерә торган тәмсез, әчкелтем-төчкелтем, сасы ис таралган. Илаһым! Боларны күреп, адәм йөзе генә түгел, кояш йөзе кызарырлык бит. Кит инде. Кит! Ничек җаннары түзә? Ничек йөрәкләре әрнеми? Ничек ертылмыйлар боларны күреп? Гарьләнеп үләрлек бит, валлаһи! Ислам дине адәм балаларының рухи хәяте дә, тышкы дөньясы да, күңел халәте дә саф вә пакь булуны таләп итә. Бу пычрак өемнәр якты дөньяга, инсаниятнең ак йөзенә, хәтта ки гарьше көрсинең үзенә кара сөрем җибәреп тора лабаса. Гыйрфан мулла да мөдәррис булды бит. Тазалык-сәламәтлек нигезе, дигән иманга тугрылыклы булдылар. Ихата кардан әрчелү белән, бөтен чүп-чарны түгеп, тирә-якны ялт иттерәләр иде. Мәдрәсә эчендә тәмле исләр генә аңкып торыр иде. Ун-уникe ел шушы чүп-чар арасында чиләнгән мескенләп адәм рәтле нинди диндар, зыялы бәндә чыксын, ди, дөнья күзенә. Бу бит кешедән, якты дөньядан, милләтеңнән, хәтта ки Аллаңнан көлү дигән сүз. Ялкаулыкка йөз тоткан бәндәнең шайтан алдында калтырап

[1] Вакуф шартлары судебная палатада саклана. 1872 ел.

торган шүрәле кеби булуын аңламыймы болар? Зур гөнаһ бу. Гарьлек. Нәҗеслек.

Инде беренче каты җиргә сеңгән таш мәдрәсәсен күр. Ташка үлчим. Таш араларына яшькелт мүк, күгәргән мәшкә, тагында әллә ниләр сыланган. Сытык йөзле туксан яшьлек картны хәтерләтеп тора.

Шакирҗан әтисенең кешегә үтә җитди, таләпчән, сынау күзе белән караганлыгын яхшы белә; шулай да аның бер дә юкка гаеп такмаганлыгын да аңлый. Әле менә чыраен сытып, кашын җыерып, күңелсезләнеп карап торуы тикмәгә генә түгел: мондагы чүп өемнәре аның саруын кайната. Бу күренеш Шакирҗанның үзен дә гаҗәпләндерде. «Хөсәения»дә мәдрәсәнең эчен, тышын тазартып таралыштылар бит. Нигә монда ашыкмыйлар? Матур яз мондый пычраклык белән килешми ич. Гыйрфан мулла:

— Тфү!... Эт бәйләсәң дә торырлык түгел бит монда,— диде дә атлап китте.

Шакирҗан аннан калмаска тырышты. Күпме генә ачуы килсә дә, фикерен «эт» сүзенә бәйләп аңлатуны көтмәгән иде ул. Ничек кенә булмасын, әтисе хәзер үзен һич кенә дә яраланган коточкыч җанвардан ким тотмый. Аны Галимҗан язмышы шулай тотнаклылык чылбырыннан ычкындырганлыкны, җенләнү дәрәҗәсенә җиткергәнлекне аңлый ул. Хәзер Шакирҗанның бөтен курыкканы шул: килеп керү белән кеше арасында Галимҗанны сугып җибәрмәсә ярар иде. Кан кызганда җан да кыза, диләр бит. Җаны кызган бәндә аны-моны уйламый, ни кылганын да белми.

Йөзенә, тән күзәнәкләренә, бөтен вөҗүденә әллә нинди нәҗес нәмәкәйләр үскән туксан яшьлек картның эчке дөньясы да саф-пакь түгел икән. Килеп керү белән аларны шундый ук чүп өемнәре, сасыган сулы ләгән, шалкан чәчәрдәй пычрак идән, тегендә-монда аунап яткан каткан киемнәр, комганнар, чүмечләр каршы алды.

Гыйрфан мулла хәзер боларга игътибар итмәскә тырышты. Хәтта башына шундый уй килде: саф күңелле, ачык йөзле, пакь вә ак куллы остазбикәсе пешергән ризыкларны бу пычрак җирдә ашап утыру гөнаһ булыр. Иң муафыйклысы шул: Галимҗанны алырга да тизрәк «таярга» моннан. Чәй эчәр урын бетмәс әле. Ходай җан биргәнгә юнь биргән. Бу — хакыйкать. Хакыйкатькә, кем әйтмешли, хөкем юк.

Ул, кызу-кызу атлап, Галимҗан бүлмәсенә үтте. Ләкин анда Галимҗан юк иде. Утыз яшьләр чамалы бер кемсә басып тора. Аның ни хәлдә икәнлеген аңлау кыен түгел иде. Бүлмәләрне тикшереп, караштырып йөридер. Әле монда да шәкертләр китеп бетмәгән. Күрше бүлмәләрдә көлешкән, бәхәсләшкән тавышлар да ишетелә. Галимҗан да, бәлки, шулар арасында буталып йөридер. Озын буйлы, ач яңаклы, соргылт күзле бу кемсә Зарф хәлфә иде. Алар арасында шундыйрак сөйләшү булып алды:

— Сез хәлфә буласыз шикелле?

— Әйе, Зарф хәлфә булам.

— Минем улым Галимҗан кая китте икән?

— Улыгыз Галимҗан юк инде.

— Ничек «Юк инде»?

— «Юк» нәрсә «юк» була. Мантыйк...

— Ул сезнең чыбыкны сындырган икән?

— Күрәм, сез аның атасы буласыгыз?

— Әйе, атасы.

— Галимҗан юк инде. Кабатлап әйтәм.

— Аңлыйм, сез миңа ачулы. Шулай да Галимҗан?..

— Галимҗан качты.

— Качты?

— Әйе. Качты. Җирдә дә юк, күктә дә...

## Бишенче бүлек

*Килә шатлык булып бу доньяга бала,*
*Ботен җиһан аны соенеп каршы ала;*
*Ярты гомерен бирә һәр балага ана,*
*Нигә бала аны кайгыларга сала?*

Ана зары

### I

Ярсу йөрәкле чибәр кыздай елмаеп-көлеп, алсу таңнарын балкыта-балкыта, юмарт мул кояш нурлары белән бөтен тирә-якны иркәләп-сөеп, сүнгән йөрәкләрдә яшәү дәрте кабыза-кабыза, менә тагын да яз килде. Басу-кырлар өстенә ап-ак йомшак мамыктай түшәлгән карлар эреп, аның сулары җир-ананың йөрәгә-бавырына шифа булып сеңде. Урамнарда шаулап аккан гөрләвекләр җылы яз күкрәгеннән кайнап чыккан мең төрле шау, көй-моң яңгыратып торды. Аларга сыерчыклар, сандугачлар моңы килеп кушыла да үзенчә бер гаҗәеп нида-симфония хасил итә. Ләйсән яңгыр явып, кояшның җылы нурлары белән парланып-иркәләнеп иркен тын алгач, җир сабый бала кебек шатланып-куанып калды. Аны, гүя оҗмахтагы кәүсәр суы белән юдылар.

«Язның бер көне ел туйдыра», «Яз йоклаган — ризык тапмаган», «Бер бөртек бодайда крестьянның бер пот тире бар», кебек мәкальләрне әйтә-әйтә, авыл халкы, билен бишкә буып дигәндәй, кырга-басуга ашыкты.

Мондый чакта Гыйрфан мулланың йөрәге чабышка әзерләгән Тулпарныкыннан ким ярсымый. Сабаны, тырмасы, чәчү тубалы — бөтен кирәк-ярагы әзерләнеп куелган була. Җитмәсә, аны әле кырыкмаса-кырык якка тарткалап мазасызлыйлар. Берсе чәчү орлыгы сорый, икенчесе — сабан, өченчесе — ат, дүртенчесе — тырма. Тормыш бит борының белән боз ярып, тешеңне кысып, уртыңны чәйнәп булса да алга барырга куша. Түбә сайгагына төкереп ятып, песи шикелле көне-төне йокы симертеп яшәп буламы? Итәгенә ут төртсәң дә ыжламый бәгъзе берсе. Ишәкне алтынга урасаң да ишәк булып калган кебек, кабыргасын очлы без белән төткәләсәң дә, ялкау ялкау булып кала, илаһым! Бу нинди мәнсезлек? Бу ниткән иҗтиһадсызлык? Кайчан күзе ачылыр безнең игенченең? Кайчан яшәргә өйрәнер?.. Хәят түгел бу! Яшәү түгел бу! Йокымсырау. Мәлҗү. Мәмрәү. Гарьлек. Дөньяны шулай матурлап буламы? Ни калдырабыз киләчәк буынга? Балаларга? Оныкларга? Бездә, караңгыда гөл үстереп буламы? Булмый. Баз кебек өйдә тончыккан баладан ни фәтва көтмәк кирәк? Кырмыскалар көн-төн хәрәкәттә. Бал кортлары. Кошлар. Ходай Тәгалә һәрберсенә эшләп ашарга куша.

Җитмәсә, «Гыйрфан мулланың җире яхшы», «Аңа Ходай Тәгалә үзе ярдәмгә килә», «Аның авызы бәхетле», кебек сүзләр канат җәеп таралган авылда. Бәхет, әйтерсең, борчак чүмәләсе, алдыңа китерәләр дә өяләр. Һи, тот капчыгыңны. Өйделәр, ди.

Гыйрфан мулла үз җирләрен дүрт төргә бүлеп карый. Беренчесе — кара туфрак. Икенчесе — каралыгы уңа башлаган. Өченчесе — катнаш. Дүртенчесе — уңдырышсыз кызгылт балчык. Шул түбән сыйфатлы урыннарда да күпереп торган бодай үстерә ул хәзер. Һәр кишәрлек җир тиешле тирәнлеккә сөрүне таләп итә. Сабанны шуңа яраклаштырып көйләргә кирәк. Мәсьәләне ул гына да хәл итми әле. Җирең гәрчә яхшы сөрелгән, менә дигән итеп тырмалган булса да, елы әйбәт кенә килсә дә, орлыгың гәрәбәне хәтерләтеп тормаса, күзен бура төбеңнең ыңгырашканын көт тә тор. «Ашлаган җир аш бирә!» дип бик борыңгы ата-бабаларыбыз да әйткән. Тирес белән сыйлап, тукландырып торырга

кирәк җирне. Менә бит гыйлләсе кайда?.. Эшнең әмәлен, гамәлен белү мотлак. Иген игү бөек бер сәнгать ул. Тирән сер, илаһи бөеклек. Аны әле иң әүвәл акылыңда, уй казаныңда, йөрәгеңдә, күңелеңдә, хис-тойгыңда үстерәсең. Бик борынгы заманнарда ук әйткән бит бер алтын баш:

Ирләр зарлана җирләр яман дип,
Җирләр зарлана ирләр надан дип,—

дигән.

Менәтерәк! Каты әйткән бит. Чатнатып. Надан башка нишләп җир буйсынсын, ди. Атабыз Адәмне, анабыз Хаваны яраткан җир бит ул. 930 ел яшәгән атабыз Адәм галәйһиссәләм. Әллә аңа җиңел булганмы? Эшне тырышып эшлә, дөнья явызлыгын вакытында нык тешлә, дигән сүзләрне әтисе дә, картәтие дә даими рәвештә тугылап тора иде. Авызлык җитми күпләргә. Авызлык. Авызлыклап алгач, чыбыркыларга да кирәктер әле.

Мисалга әллә кая китәсе түгел. Әнә Хәмәтдин карт. Басуы янәшәдә. Бәрҗеттәй елкылдап торган кап-кара җир. Ни сөрүе, ни чәчүе, ни тырмавы, ни утавының рәте юк. Мыскыл итә җирне. Көлә җирдән. Каһкаһә белән көлә. Аннан алаптай авызын ерып, черегән тешләрен ыржайтып, эчкә баткан нурсыз соры күзләрен тоздай итеп карап тора-тора да синең игенеңә: «Ходай тәгалә ашлыкны да кешесенә карап кына бирә»,— дип үрсәләнә. Җитмәсә, оятын олтырак итеп, чәчү орлыгы сорап килгән. «Монысы соңгысы, башка вакытта мазасызламам. Мөбәхис мәзингә бара алмыйм бит мин, ул комсыздан кышын кар сорап та алып булмый»,— дип юмакайлана. Шул җитте бит Хөрмәтулла башына. Шул Хәмәтдин җаһил җитте. Имеш, борынына ит исе килеп бәрелгән. Хөрмәтулла Мөбахис мәзиннең сарыгын суеп ашаган. Шул әләкләмәсә, Хөрмәтулла тукмалмый иде. Шул кыйналудан соң мантымады бит Хөрмәтулла. Кан коса икән. Үлем түшәгенә яткан, ди. Шуларны уйлап, куып кына чыгарасы иде дә бит ул Хәмәтдин дигән хәсисне. Юк, булмый. Әлеге: «Таш белән атканга аш белән ат»,— дигән борынгылар сүзе канга сеңгән. Аңларлар, дисең. Балалары ач калмасын, дисең. Өлге-үрнәк алсыннар, дисең. Юк. Юк булгач — юк. Зилзилә гарасаты белән дә кузгата торган түгел. Мүкләнгән таш. Тутыккан тимер.

Әллә нинди акыллы башлар әйткән сүзләрне әлеге гамәл дәфтәренә язып та куйган иде бит: «Яхшы игенче — кешелек хәятенең беренче игелек иясе»; «Игенче — бөек кеше»; «Ипи валчыгы ат башы кадәр алтыннан да авыррак»; «Икмәк — тормыш ул, ана кебек»...

Троицк мәдрәсәсеннән хәлфәлекне ташлап кайтуы да шуның өчен бит инде: иген игү сәнгатен үзләштерү... Быелгы яз да шул хис-тойгылар давылы эчендә үтте. Биш вакыт намаз. Йокысыз төннәр. Борчулы көннәр. Җирнең җылы куенына гәрәбәдәй орлыкларны салып калдыру өчен җан ату. Ходайга шөкер, бөтенесе дә ал да гөл булды шикелле. Инде чәчүләр бетте. Матур гына итеп, яңгырлар явып үтте. Җир суга туенды. Ел яхшы килер кебек. Алда — сабан туе. Ат чабыштыру.

Тик... нигә бу «бәхет» дигән илаһилыкның бер як чите гелән генә китек була? Шул китекне, кем әйтмешли, уртыңны чәйни-чәйни, тешләреңне алагаем кыса-кыса, йөрәк бәгыреңне мең кәррә әрнетеп, ямап куясың. «Инде булды» дип, күк кабагың ачылып, үткән эшкә тәһарәт алып, дога кыла-кыла салават әйтеп амин тотасың, әмма янә дә алданган буласың: бәхет казаныңның дәхи дә икенче бер урыны тишелгән булып чыга — тагын да ямарга кирәк. Галимҗанның — киләчәктә нәсел-нәсеб тамырыннан алтын кәүсә-багана утыртырга тиешле «ташмаңгаеның» капыл — кара җир упкандай юк булуы бәхет казанының тишелүе генә түгел, шартлап ярылуы күңелсез хәл. Уф, ни гөнаһлары бар икән? Нигә Ходай бу тиклем рәнҗетә аны? Әгәр кирәк булса, булдыра алса,— ачуың килмәсә әйтмәс идең,— коры җәйдә кеше игененә яңгыр булып явар иде; яки яңгырлар шәйсез күпкә китсә, бинһая зур канатлы сәмруг кошка

әверелеп, күктәге болытларны таратып йөрер иде, вә дәхи дә күзгә төртсәң дә күренмәслек караңгы төннәрдә Кош юлында илаһи бер нур-тәҗәлла булып, кәрван юлын яктыртып торыр иде. «Яраткан бәндәсен Ходай төрлечә сыный»,— дигәне дә бар. Әллә шуның бер галәмәтеме бу?

Хәлбуки, бу кичерешләрне, йөрәк януларны, бәгырь телгәләнүне остазбикәсенә сиздермәскә тырышты ул. Чөнки аз гына караш катылыгын йомшартсаң, теле белән чеметкәләргә тотына. «Холыксыз ир тормыш ямен ала, хатыны йөрәгенә яра сала»,— дип ычкындырды беркөн. Дөрес, аны ул аңа төбәп түгел, икенче бер холыксыз иргә карата әйтте. Шулай да тел төбенең үзенә барганлыгын аңлады мулла абзый. Әйтсен анысы. Моңа бер тарлык та юк. Ирләр хатын-кызның лачкылдатып сагыз чәйнәвенә түгел, акыллы сүзенә мохтаҗ. Адәм иткән дә хатын, әрәм иткән дә хатын, дигәне дә бар. Шулай да беркөн Нәгыймәне күзләргә килгән Бәгәнәш авылы мулласын остабикәсенең ошатмавы аның күңеленә берникадәр кырпак кар төшерде. Ике арада кырач җиле — сырт җиле исеп алды. Остазбикәсенең әйтүенчә, юньле адәми зат булса, ул Бәгәнәш мулласы Хафиз хәзрәт утыз бишкә җиткәнче өйләнми йөрмәс иде. Имештер, тыштан күзгә бәрелеп тормаса да, аның эчке хосусиятында кылдый-былдый, кәкре-бөкре, кытыршы-мытыршы яклары бардыр. Булса соң? Адәм баласының берсе дә хатадан хали түгел. Берәүне дә корычтан коеп куймаганнар. Иң әүвәл аның кешелекле булуы лазым. Монысы — йөрәк иманы. Калганнары — шул иманны яктыртучы нурлы йолдызлар. Хафиз муллада ул иман бар. Монысы бер булдымы? Бер булды. Соңгы вакытта муллаларның әлеге каһәр төшкән «зәмзәм суы» белән авыз пычратулары шәйләнә башлады. Хафиз муллада андый гадәт аслан юк. Ике булдымы? Ике булды.

Битендә азрак шадрасы бар икән, аңа карап кына кешене түбәнсетергә ярыймы соң? Шадра йөрәк яндыра, диләр ич. Яндырыр әле. Бардыр эчендә яндыра торган галәмәте. Әллә Мөхәммәт пәйгамбәрдән соң килгән Әбүбәкер, Гомәр, Госман, Гали кебек хәлифәләрнең «китек» ягы булмаганмы? Булган. Тормыш һәммәсен дә акрынлап төзәтә-ямый бара.

Остазбикәсенең йөзендә ык-мык итү чаткылары сизелгәч, ым кагып, тышка алып чыгып китте ул булачак кияуне. Абзарга барып, кул кысыштылар да куйдылар. Шуның белән вәссәләм. Бетте китте. Бу җитди мәсьәлә соңгы ноктасына җитте. Нәгыймәгә кияүне ныклап күрсәтмәделәр дә: кәҗәләве бар — соңгы вакытта кызлар «мәхәббәт» дип авыз суы түгә башлады. Әнисе дә хәтта бер арада үз гамәл дәфтәренең бер сәхифәсенә язганын укып күрсәтте: «Мәхәббәт бик нәзберек үсемлек сыман, әгәр аны һаман күз яшьләре белән сугарсаң, беркайчан да озак яши алмый». Кем сүзләредер — монысы ата кеше өчен караңгы. Шундый мәгънәле, матур, күркәм сүзләрне остазбикәсенең язып куя торган гадәте бар. Хәер, аның үз теленнән дә гәүһәр тама. Җыр чыгара. Шигырьләр яза. Вакыт-вакыт моң дәрьясында йөзә. Үз сүзләредер бәлки.

Бу сүзләрне дә башта үз йөрәгенә алды ата кеше. Хәтта ачыктан-ачык әйтте:

— Тормыш булгач, табак-савыт шалтырамый тормый, анасы, күз яшьләре дә чыккалый, әмма безнең «гыйшык-мыйшык» дигәнебез һич тә син уйлаганча түгел лә инде,— диде ул.

Абыстай мәсьәләне ныклабрак аңлатып бирде:

— Син барысын да үз күңел сандыгыңа гына җыя барма әле, атасы, без яратышып кавыштык. Аллага шөкер, моңа бер Ходай үзе шаһит. Мин бу сүзләрне Нәгыймә язмышы өчен борчылып әйтәм. Үзенә мәгълүм ич: ул да минем кебек нечкә күңелле, йомшак табигатьле, артык итагатьле...

— Хатын-кызга каты күңеллелек әллә килешәме? Әмирҗан, әнә, хатынын ни өчен изә? Каты телле булганга. Әле кичә генә аяк-кулларын сындырып бетергән.

— Әмирҗан үзе кем соң? «Чупай ябалагы» дигән даны бар. Теле каты булса да, хатыны Оркыяның күңеле йомшак аның. Шуны аңлыймы соң ул чупай ябалагы?

Ничек кенә булмасын, туй кебек зур мәшәкать тә шаулап-гөрләп, җилләнеп-давылланып, тирә-якка дан чәчеп үтеп китте. Гореф-гадәттәгечә, кода-кодагыйлашу, ике яктан да кунаклашу, атлар, сыерлар, тәкәләр сую — берсе дә калмады. Кардәш-ыру, туган-тумача, дус-иш, күрше-күлән сыйланып рәхәтләнде. Башкорт дуслар Котлызаман, Көнсылу, чуваш дуслар Әптерәй, Кәтринә, тагы да әллә кемнәр, әллә кемнәр туй шатлыгы кичерде. Хәзер инде Нәгыймә мулла куенында, рәхәт яшәсеннәр. Бәхетле булсыннар. Ходай олы мәхәббәт бирсен.

## II

Көннәрдән бер көнне Галимҗан кайтып керде. Берүзе генә түгел, бүлмәдәше Йосыф мәхдүм белән. Кичкә таба иде бу. Кояш, бөтен дөньяны яз сулышы белән хозурларга-сөендерергә теләгәндәй, гүя, баесам, шифалы нурларымнан мәхрүм булырсыз дип, күк читенә — офыкка ашыкмый гына хәрәкәт итә. Хәер, аның хәрәкәте дә аслан сизелми. Ул, әйтерсең, туктап калып, һәркемне күзли, сынаулы күз карашлары белән аңа мөкиббән китеп карап тора: дус булыйк, дөньяны бергәләп ямьлик, ди. Кояш дөрес уйлый: Якты йөз-чырай белән караса, кешеләр күңеле аяз-күтәренке була: болыт белән капланса, адәм баласының йөрәгендә кара йомгак хасил була, шунлыктан ул боегып кала.

Кояш бүген берәүне дә боектырмаска тырышты. Аның көләч йөзен каплардай болытның әсәре дә булмады. Гыйрфан мулланың зур-зур тәрәзәләреннән тәмиз-пөхтә өй эченә үтеп кергән кояш нурлары да, гүя, һәр гаилә әгъзасына яшәү хозурлыгы, күңел илаһилыгы, бәхет-сәгадәт гәүһәрләре өләшә иде. Галимҗанның суга төшкән балтадай юк булу кайгысы һәрберсенең җилкәсенә кара көйгән тау булып өелсә дә. Һаман шулай беркилеш тамарыз-йөрәк сызлануы белән яшәү мөмкин түгел иде.

Газапны ходай башта тауга биргән — күтәрә алмаган: биле сыгылып, чүккән, җиргә убылган урынында су хасил булган: әгәр бу дәвам итсә, дөньяны су басар иде. Шуннан кайгыны Аллаһы Тәгалә адәм баласына биргән. Күтәрә адәм баласы. Чыдый. Түзә. Бөгелми. Дөньяның рәхәтеннән михнәтне күбрәк, дигәне дә бар. Шул хакта уйланды Гыйрфан мулла. Аннан соң һәр килгән кайгы өчен утка бастырылган шайтан урынына үрсәләнүне шәригать тә мактамый бит әле. Бу — кешелеклегенне, яшәү сәләхиятеңне тәмам сыйрфиян югалту дигән сүз. Ахыр чиктә ул адәм баласын гөнаһ сазлыгына өстери. Дәхи дә иманга хилафлык китерә. Аллаһы Тәгалә каршында булган саф-сыйрыф вөҗданыңа кара күләгә төшерә. Остазбикәсенә дә «баланы син бозды», «иркәлек һәркемне ирәйтә», «Иркә бала итәк ерта» кебек төшенчәләрне аңлата торган бозлы караш ташлаудан тукталырга тырышты. Вакыт-вакыт эчтән кара көйсә дә, тыштан ялтырауны максат итте. Гаилә башлыгы күңелендәге кара төернең хәләл җефетенә дә балалар күңеленә күчү хакыйкатен белә иде ул. Күчте дә инде. Остазбикәсенең бөтен хәяткә, табигатькә, инсаниятькә сөеп карый торган күз карашлары мәзәкләнеп-зәгыйфьләнеп калды. Көләч йөзенә хәсрәт пәрдәсе тартылды. Сөйләшкәндә матур иреннәре вакыт-вакыт көзге яфрак шикелле дерелдәп тора. Кипте. Ябыкты. Корыды. Хәзер инде ул, әйтерсең, балык сеңере. Әлбәттә, аның да эчтәге утны тышка чыгармаска, йотарга, йөрәгендә калдырырга тырышуы сизелеп тора. Ул гына да түгел, ул бит әле сине дә кайгыга баш имәскә, арыш боламыгыдай мәлҗемәскә, йөрәк януын кешегә сиздермәскә өнди. Чын мәгънәсендә алиһә инде! Хатын-Алла!!!

Шундый хисләр дулкыны эчендә тибрәнеп йөрде ул бүген. Бу дулкынхисләр көне буе баш очында елмаеп, адәм балаларына сәҗдә кылып

торучы кояш нурлары дулкыны белән аралашып, аның күңел дөньясына яктылык хозурлыгы өстәде. Нәгыймәнең шушы бүгенге яз кояшы кебек балкып килеп керүе өй эчендә капыл-кинәт икенче бер кояшның пәйдә булуын хәтерләтте. Дөрес, әле ул үзе генә килгән. Мулласының шөгыле бар икән. Шуңа килә алмаган. Әйткән Нәгыймә моңа: «Ак калфагымны алырга онытканмын, дигән, иртәгә ашка шуны киеп барырмын дигән идем, дигән, ерак ара түгел бит, байталыңны җигик тә, дигән, тиз генә барып киликче, дигән, әткәй-әнкәйне мәшәкатьләп, чәй-фәлән дә эчеп тормабыз, дигән. Әйткән моңа мулласы: «Мине бит, дигән, бер бабайга ясин чыгарга чакырдылар, дигән, тарантаска байталны җигәм дә, дигән, теге син ошаткан терекөмештәй тере кучерны утыртып, дигән, юлыгызга ак җаймә җәеп, дигән, озатып калам, дигән».

Килеп керү белән Нәгыймә, ашыга-ашыга, шул хакта сайрап салды да кучер малайның әле аты белән капка төбендә калуын әйтте. Ата-ана моңа ифрат шат иде. Ир кеше хатынын ялгыз килеш бер җиргә дә җибәрми. Имеш, шәригать кушмый. Аннан соң, арбаның төбе юк, бәндәнең кеме юк, дигәндәй, ялгыз йөри торган хатын турындагы берәүнең гайбәте бик тиз урам авызына күчә. Бозык авызлар «ул хатын фәлән дә төгән», «ирле ирдәүкә», «иргә баш бирә торган түгел» кебек гайбәтне, чүбек чәйнәп май чыкмаганлыкны белсәләр дә, мәңге өзелмәс сагыз урынына чыртлатып чәйни бирәләр. Бу — хатын-кызга ышанмау бәласе. Хәләл җефетеңне арыш капчыгына тыгып, авазын чабата киндерәсе белән алагаем кысып бәйләп яшәтергә тырышу кәсафәте.

Гыйрфан мулла, ходай үзе шаһит, нинди генә житешмәгән-килмәгән яклары булмасын, җир алиһәләрен алай читлектә яшәтү кебек күңелсез хәл белән килешә алмый. Хәсәнә абыстай да ата кешенең бу күркәм сыйфатлары өчен мең-мең шөкранә итеп яши. Кияүләре Хафиз мулланың да ахмак күңелле ирләр арбасына утыра торган зат булмау табигате аларның күңелләрен җиде кат күккә күтәреп җибәрде. Әлбәттә, ата-ана Нәгыймәгә бу хакта әйтмәде. Артык сүз — аркага аркан, дигәндәй, бу хакта гәп кузгату баш әйләндерү генә булыр иде. Нәгыймәнең елмаеп-көлеп килеп керүе, әти-әнисен кочаклап алуы, Габделхәкимне кысып-кысып сөюе, күз карашларының ягымлылыгы, ап-ак йөзенең шатлык тойгылары бөркеп торуы...— барысы, һәммәсе аның тарантаска утырып түгел, бәхет арбасына утырып йөрүе турында сөйли иде.

Бөтен гаилә шундый шатлыклы хис-тойгылар дулкыны эчендә сәгадәтле минутлар кичергән мәлдә Галимҗанның ниндидер тәти егет белән бергә кайтып керүе янә бер кояшның балкуы кебек тоелды.

Килеп кергәч тә, иң әүвәл, Йосыф мәхдүм йомшак, моңлы тавышы белән «Әссәламегаләйкем!» диде. Гыйрфан мулла күрешү шатлыгын йөзенә ул кадәр чыгармаска тырышып, ата горурлыгын саклаган хәлдә, җиңелчә генә тамак кырып, «Вәгаләйкемәссәлам!»не әйтте. Аннан соң, тораташтай катып, сүзсез генә, бер-берсенә карашып калдылар. Галимҗанның эчен курку шайтаны тырный иде: әтисенең котырган үгездәй ташланып, йә сугып җибәрүе, йә тел камчысы белән теткәләве бар — кеше алдында бу һич тә килешә торган эш түгел. Шулай да Галимҗан, булачак давыл-гарасат алдында нык торырга кирәклекне аңлап, каушап-җебеп калмады, йөзенә шүрләү-курку галәмәтенең мыскылын да чыгармаска тырышты. Әткәсенең йомшак җилекле кешене, мәмәй авызны, куян йөрәклеләрне яратмавын белә ич ул. Мескен белән киңәшмә, дигән сүзләре дә хәтерендә.

Дөрес, сөзешергә әзерләнгән үгезләрдәй карашып тору озакка бармады. Киметеп әйтсәк, чыпчык канат каккан вакыт та үтмәгәндер. Авыр тынлык, эссе кояш нурында тиз таралган сыек болыттай, «ә» дигәнче юк булды. Ул болытны таратучы Ана-Алиһә иде.

— И балам!.. Галимҗан!..— дип, шул йөрәк канына манчылып чыккан ике сүз аша күңел яраларын, әрнү-өзгәләнүләрен аңлатып, улын килеп кочаклагач, бер-берсенең күз карашларын бәйләп торган авырлык

жебе кинәт кенә үткер кылыч белән тураклап ташлангандай булды. Галимҗанны сабый чагындагыдай кысып-кысып сөеп, бит очларыннан чүт-чүт үбеп алгач, ананың күзләре яшькә тыгылды. Елап җибәрмәскә бөтен көче белән тырышты ул: чит кеше алдында, бала каршында ярамый, килешми. Шулай да башкалар исәнлек-саулык сорашып күрешкәндә, аның сабыр ихтыярына һич буйсынмыйча, йөрәк итен ярып чыгып керфек очына эленгән әрсез гәүһәр күз яшен яулык чите белән тиз генә сөртеп алырга онытмады ул.

Бу авыр очрашу ата кешене дә нык тетрәндерде: ни эшләргә, шаңлап җибәрергәме, кем әйтмешли, эттән алып эткә салып сүгәргәме? Ярамый. Ни өчен? Беренчедән, чит кеше бар; икенчедән, бу күрешү әнкәсенең йөрәген шартлатырга мөмкин; өченчедән, балалар алдында килешми; дүртенчедән, «ташмаңгайга» сугып, үз йодрыгының челпәрәмә килүе ихтимал. Соңыннан сайрашырлар, барысы да ачыкланыр. Ә хәзергә илтифатлылык саклау хәерле булыр.

— Ни хәл, улым, исән-аман гына йөреп кайттыңмы?— дип килеп күреште ул, эчтә котырынган ачу өермәсен тышка чыгармаска тырышып. Кыскасы, хәзергә ике арада бернинди шайтан тавы булмаганлыкны аңлатуны мәслихәт күрде. Шулай да күрешкәндә, күзенең бер як чите белән генә булса да, эчендә боз барлыкны сиздерми калмады. Яраткан атлы булып аркасыннан сыйпаганда да, элекке кебек, аталык хисе җылылыгы тоелмады. Моның күңел өчен генә икәнлеген юләр дә аңларлык.

Галимҗан зур җәнҗал-буран көткән иде. Хәзерге буранның дәррәүфәүрән купмавы, тиз арада кадер кичәсе көнендәгедәй тынычлык урынлашуы аның күңелен күтәреп җибәрде. Гаилә җылылыгын хәзергә тышкы яктан гына булса да күрсәтеп тору Йосыф абыйсы алдында аеруча кирәк иде. Шундый авыр минутларны үткәреп җибәргәч, ул күзләре белән ашардай булып карап торган Нәгыймә апасы белән барып күреште. Аннан энесе Габделхәкимне барып сөйде. Йосыф мәхдүмне дә һәммәсе белән күрештереп чыкты. Шуннан соң Хәсәнә абыстай:

— Син юкта бик изге эшләр дә булып алды, Галимҗан улым, Нәгыймә апаңны Бәгәнәш мулласына бирдек; бик затлы нәсел мәгәр, үзебез кебек тамырлы кешеләр,— дигәч, өй эчендә янә шатлык хисе канат җәйде.

Хәзер инде бер-берсенә булган карашлары язгы җылы агымны хәтерләтә иде. Инде табын әзерләп, күгәрчендәй гөрләшә-гөрләшә, кичке ашка чаклы җыйнаулашып чәйләп аласы гына калды.

— Нәгыймә кызым, син ашыкма әле, табын әзерләш...— дип, Хәсәнә абыстай, элеккечә яшь кызлар кебек җиңел хәрәкәтләнеп, үзенең хәзергә чыгып торуын белдерде. Галимҗан белән кунакка берәр бүлмәдә ял итеп торырга кушты. Ләкин Нәгыймә кайтып китәргә кирәклекне әйтте:

— Мин, әнкәй, аңа икенде намазына кайтып җитәргә вәгъдә биргән идем, юл кешесенең юлда булуы хәерле, чәйләп тормыйбыз инде, ерак ара түгел бит, йә үзегезне чакырырбыз, йә үзебез килеп җитәрбез, җизнәсенең Галимҗанны күрәсе бик килә,— диде.

— Кучерың ач түгелме?

— Түгел, әнкәй, түгел, кайткач сыйлармын әле...

* * *

Хәсәнә абыстай өстәл әзерләү мәшәкатенә күмелде. Нәгыймә хушлашып чыгып китте. Аңа Галимҗан да иярде.

Галимҗан өчен Нәгыймә «апа» гына түгел, «сердәш» тә, дус та иде. Хәер, башка гаиләләрдә дә ир бала белән кыз бала күбрәк дуслашучан. Бәлки, табигатьтәге шушы яшерен серлелек чаткылары алар йөрәгенә дә тәэсир иткәндер. Шакирҗан абыйсы белән тарткалашкач, сүзгә килгән, хәтта якалашкан чаклары да була. Ә инде Нәгыймә апасы белән аның арасында беркайчан да сырт җиле исмәде. Нәгыймә апасы—

энисе табигатьле. Берэр сер сөйләсәң, аны йөрәге белән кабул итә. Ачуланырга тиеш булганда да төсен бозмый, авыр сүз әйтми, үзен зурга куеп масаймый. Теге вакытта Мәдинә белән булган хәлне дә бәйнә-бәйнә сөйләп биргән иде. Аның җырын, моңын мактады, үзен «Акчәчкә» дип атавын әйтте. Бу яңалык Нәгыймә өчен көтелмәгән хәл иде. Шуңа күрә ул аңа һич тә битараф калмады. Уйланып торды-торды да:

— Синең борыныңа ис керә башлаган, кара аны, малай, сак бул, уйлап эш ит, андый нәрсә белән уйнамыйлар,— диде.

Галимҗанның шаярта торган гадәте дә бар. Бу юлы да уйнап-көлеп җавап бирде:

— Акчәчәкне ярату язык түгел, минем күзем шайтан таягына төшмәгән бит әле.

Әле дә менә, чыгу белән, шаярып сөйләшүгә күчте:

— Син, Нәгыймә түткәй, тагын да матурланып киткәнсең, җизнинең кочагы бик кайнармы әллә?

— И хәчтрүш, тапкан сүз, әллә кайда йөреп, бозылып кайткан. Кайда булдың?

— Анысын аңламассың. Башка вакытта сөйләрмен.

— Күрдеңме әнкәйне? Кипкән таяк булып калды бит. Синең кайгың шулай итте аны. Әткәйнең сакалын кара. Син агартып бетердең аны. Җитмәсә, шаярып маташа. Әле синең зур киләчәгең алда. Укыйсың, кеше буласың бар. Шуны бел: ата-ананы рәнҗетеп, ата-ана фатихасы алмаган бала бәхетле булмый ул.

— Син телә бәхетне.

— Чыбыкларга кирәк сине. Колагыңны борырга...

Нәгыймә капкага таба китте. Чөнки әйләнеп кенә чыгасы булгач, атны алар ихатага да кертеп тормаган иде.

Галимҗан апасыннан калмады. Үз өйләренә якынлашканда ук ул капка төбендә җигүле ат һәм ун-уникe яшьләр чамалы кучер малайны күргән иде. Димәк, ат аларныкы булып чыкты.

Ян капкадан чыккач, Нәгыймә тарантаска менеп утырды. Кучер малайның дилбегәне кагуы булды, ат җил җитезлеге белән кайтыр якка очты. Артта чаң-тузан болыты күтәрелде. Галимҗан алар күздән юк булганчы карап торды.

## III

Чәй табынында сүз ул кадәр куермады. Хәсәнә абыстай ясап тора — тегеләр эчеп тора. Ата кеше улының Йосыф мәхдүм белән кайтып керүенә шат иде. Чөнки Оренбургта Галимҗанның ниндидер өлкәнрәк шәкерт белән бер бүлмәгә урнаштыруын үтенгәч, Вәли мулла шушы Йосыф шәкертне китереп күрсәткән иде. Йосыф тышкы кыяфәте, җылы-ягымлы күз карашы, матур сөйләшүе, инсафлылыгы белән билгән иде аның күңелен. Мәдрәсәдә уку беткәч, үзләре әйтмәсә дә, Галимҗанның шушы мәхдүмгә ияреп китүе хакында фараз итте ата кеше. Шуңа күрә бер-ике чынаяк чәй эчкәч, Гыйрфан мулла сүзне үзе үк башлады.

— Ху-у-ш, шәкертләр, инде мәдрәсәдән качып китеп, кайдадыр югалып йөрүегез хакында сөйләсәгез иде,— диде.— Мин бит башта Шакирҗан янына бардым, аннан Вәли мулла мәдрәсәсеннән сине алып китүдә иде уем, Галимҗан, әмма ләкин анда сезнең арттан җил генә искән...

Җавапны Галимҗанның үзеннән көткән иде ата кеше. Әмма ул уйлаганча килеп чыкмады. Әллә Галимҗанны авыр хәлдән коткару нияте белән, әллә гаиләдә ызгыш-низаг чыкмасын дип уйлап, бу «бәлане» үз өстенә алырга булды Йосыф мәхдүм.

— Бөтен гаеп миндә, Гыйрфан бабай, Галимҗанны үзебезгә кунакка алып китәргә мин өндәдем,— диде ул.

Ләкин сизгер күңелле, дөреслек яратучы, ялганны җене сөймәгән Гыйрфан мулла мәхдүмнең сүзләре белән килешмәде:

— Син, Йосыф улым, теге вакытта ук белгәнемчә, затлы нәселдән, яхшы ата-ана баласы; бәс, шулай булгач, мантыйкта ялгышма, фикерләреңдә салулама; Галимҗан арбага таккан дегет чиләге түгел бит, ул теләсә-кемгә тагылып йөрергә тиеш түгел, аның әти-әнисе бар, шулар белән киңәшләшмичә, үз белдеге белән каядыр китеп югалырга аның хакы юк. Аның аркасында мин Шакирҗанның да тиресен күп каезладым, остазбикәмне дә аз рәнҗетмәдем.

Шул сүзләрне ишеткәч, өй эчендә авыр тынлык урнашты. Галимҗан әле әнисенә, әле әтисенә карап алды. Бала өчен ата-ананың күпме йокысыз төннәр үткәрүе, әрнүе-сызлануы, башын ташка бәрердәй булып үрсәләнүе турында ишеткәне бар аның. Ата-ана рәнҗетүче андый балаларга аның нәфрәте дә чиксез иде. Мин беркайчан да алай булмам, әткәм-әнкәмне кайгыларга салмам, дип эченнән иман әйткән чаклары күп булды. Тик тормышта һич тә син уйлаганча килеп чыкмый икән. Алла шайтаныннан адәм шайтаны яман, дигәнне ишеткәне бар аның. Әллә ул адәм шайтаны котыруына биреләме? Әллә иң абруйлы Йосыф шәкерт тә «шайтан» булып чыктымы? Алай дисәң, ул гаепле түгел ич. Әлеге мәдрәсәдән куылганын белгәч, кайтып, әти-әнисе, туганнары күзенә күренүнең авырлыгы турында сөйләде ул. Йосыф мәхдүм аның кайгысын үз йөрәгенә алды.

— Алайса, әйдә, Галимҗан, безгә кунакка китик, мин сине Илеш бабай авылы табигате, аның матур күңеле кешеләре белән таныштырырмын, аннан соң Солтанмораткa килеп, сине атаң-анаң кулына тапшырып китәрмен, аңа чаклы үпкә-сапкалары да басылыр,— диде.

Галимҗан шатланып ризалашты. Илеш авылының матурлыгы, Сөн, Агыйдел, Чулман елгаларының гүзәллеге хакында сөйләп, ул Галимҗанның күңелен тәмам ярсыткан иде инде. Галимҗанның шул гүзәллекне күрәсе, шул гүзәллектә иркәләнәсе, шул гүзәллектә хозурланасы килде. Әлбәттә, үз авылының табигате дә оҗмах-җәннәттән ким түгел. Ләкин бит моңача таныш булмаган чит җирләрне күрү — үзе бер яңа дөнья белән ләззәтләнү. Аннан соң Йосыф абыйсы аны пароход белән Казанга алып барачагы, барганда әлеге Агыйдел белән Чулман кушылган урыннарны күрсәтәчәге, аннан Иделгә барып чыгачаклары турында әйтте. Болары да әле аның ул кадәре әһәмиятле түгел. Иң әһәмиятлесе — алар Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыячак. Вәли мулланың Кадим мәдрәсәсе Йосыф мәхдүмне дә канәгатьләндерми икән. Галимҗанның Вәли мәдрәсәсеннән куылуы — зур бәхетсезлек. Менә бит ничек тора эш. Бәхет, кем әйтмешли, үзе үк сандугач урынына уч төбенә килеп кунарга тора.

Бөтен әйткәннәрен җиренә җиткереп үтәде Йосыф абыйсы. Казанда аның әтисе ягыннан танышлары да бар икән. Әтисе белән туганнан туган агасы Габдрахман хәзрәт Казан шәһәрендәге Акмәчеттә эшли икән. Ул боларны «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укытырга вәгъдә бирде. Аларда атна-ун көн кунак булып, Казанның барлык тарихи-истәлекле урыннары белән танышып чыккач, хәтта дарелфенүн залларында да башта куяндай курка-курка, аннан соң әрләндәй әрсезләнә-әрсезләнә, ахырда бөркеттәй канатлана-канатлана йөреп, вакыт-вакыт тәлкедәй иснәнеп, «их, шушындый оҗмах-җәннәт кеби җирдә укырга» дигән татлы хыяллар дулкынында ләззәтләнеп, әмма ул хыялларның кайдадыр җиде кат күк дөньясы артында икәнлеген аңлаган хәлдә, алар пароходка утырып китә, Уфага барып, аннан Солтанмораткa юл тоталар.

Табында чәйне чынаяктан акрын гына чөмерә-чөмерә, тәм-томны һич тә кабаланмый, итәгатьлелек саклаган хәлдә каба-каба, гәпкә ялкын кушмаска тырышып, сүз шәкертләрнең әнә шул сәфәре хакында барды. Сәфәр турында күбрәк Йосыф мәхдүм сөйләде. Әлбәттә, Гыйрфан мулла вакыт-вакыт үзен энә очында утыргандай хис итте, менә-менә ярсып,

кабынып, заңгылдап китү, Галимҗанны дөмбесләп ташлау чигенә житте. Андый чакта аның йөзенә чыккан ут ялкынын Хәсәнә абыстайның сабыр карашы салкыны сүндерә. Кеше алдында үзеңне нык тот, кигәвен тешләгән аттай чәбәләнмә, хәзер генә кымырҗып, пычагымны да кыра алмыйсың, ди аның карашы. Бусы — бер. Икенчесе шул: Йосыф мәхдүм бик килештереп, чама белән, сүзенә су да, корым да кушмыйча, матур итеп, тәмләп, мантыйкны эшкә җигеп сөйли. Сүзе еланны йоклатырлык, үгез котырынуын басарлык, кабарган күркәнең канатларын төшерерлек. Ат дагалаганда бака ботын кыстырмый, дигәндәй, Гыйрфан мулла хәзергә аларның тоткан юлына аягын аркылы салмаска булды. Аның үзенеке үткән инде. Үткән гомер — сүнгән күмер, ди. Ялкынланган. Сүнгән. Беткән. Әйдә, болар ялкынлансын. Алтын — утта, адәм михнәттә сынала, дигәне дә бар. Михнәт күрә-күрә чыныксыннар. Утырган таш шикелле мүкләнүдә ни фәтва? Зынҗырлы аю түгел дә инде алар. Шулай да авыз йомып калмады Гыйрфан мулла. Бу «кыл койрыкларның» кыланыш-кабилияте дөньясы томанында буталып калырга тиешме ул? Юк. Аслан юк. Ул үз фикере тәртәсен теләсә кемнән бордырырга тиешме? Юк. Аслан юк.

— Беркая да китмисез, ашны казанда кайнаттың ни, чүлмәктә кайнаттың ни; кайната белмәсәң, барыбер тәмсез була ул,— диде дә Оренбургта Вәли мулла белән мәсьәләнең мөгезеннән тотып сөйләшүе, аның якасыннан алагаем эләктереп алуы, шуннан куркып, Галимҗанга укуын дәвам итәргә ризалашуы турында әйтте.

Шулай да Гыйрфан мулла тегеләрнең авызын нык томалауны сүз капкачын тәмамән каплауга санамый иде әле. Бу әле аларның уй кылын тартып карау гына. Мондый гадәт әтисендә дә бар иде. Вакыты белән кырт кисә. Дөңгерләнеп ала. Давылда чайкалган агач кебек, боргаланырга-сыргаланырга аслан җаең калмый. Әмма ул һич тә җиде уйлап бер кискән фикер түгел икән. Җелегең катымы? Уй-фикерең тишек иләк түгелме? Баскан җиреңдә салулап китмисеңме? Шуларны сынар өчен «кырт кисә» икән ул. Бала ялганга ышанса, чүбек баш дигән сүз. Хакыйкатьне аңламаса, аңгыра карга була. Ул, күрәсең, кылыңны төрле яклап тартып карап, һәммә сыйфат-кабилиятеңне сынап, сине билгеле бер низам-тәртип калыбына сукмак булган. Ат аунаган җирдә төк кала, ата рухыннан балага йөк кала, ди. Нинди йөк? Матди йөк? Җисмәни йөк? Рухи йөк? Атаның барлык рухы белән вөҗүдеңә сеңешмәсә дә, тән күзәнәкләреңдә, хәтта чәч бөртекләреңдә, күз төпләреңдә яшидер ул. Гыйрфан мулла әле шуларның фәкать берсен — уй голувиятен үстерү үзенчәлеген искә алды. Әйтте. Бетте. Вәссәләм. Хәзер уйлансыннар. Фикерләреңдә нык тора алырлармы? Салуламаслармы? Адәм фәрештә булмас, әрекмән кәбестә булмас, ди. Тыштан кояштай ялтыраса да, Йосыф мәхдүмнең эчендә ни барын кем белгән. Нигә әле бала язмышын чит кеше кулына уптым илаһи тапшырып куярга? Завык-сафа сөрергә ирек куярга? Янә дә әллә нинди зыян-зәхмәт булмасын кем белә?

Чәй табыны шундыйрак сөйләшүләр, шундыйрак фикер йөртүләр, шундыйрак фараз-мараз итүләр кысасындарак үтте. Дөрес, бу әле самаварны кат-кат бушата-бушата, тир сөртеп юешләнгән тастымал-сөлгене мең кәррә сыга-сыга, илаһи бер иркенләп, җәелеп, дөнья мәшәкатьләрен онытып эчә торган чәй түгел иде. Бу әле җиңелчә, юлда тамагы янган ике шәкертнең сусынын кандыру өчен генә әзерләнгән чәй. Аннан соң Гыйрфан мулла «Патша әтәч»не чалды. Бу әтәчтә мең төрле табигать төсе бар: ак, кызыл, яшел, зәңгәр, сары, кара... һәр каурыенда — бер төс. Әйтерсең, Ходай Тәгалә аның бөтен вөҗүденә болын-дала чәчәкләренең һәммә төсен китергән дә буяган-каплаган. Кикригендә дә, гүя, гәүһәр бөртекләре җем-җем итеп тора. Муенына асылынган бармак башы зурлык кечкенә шарчык кебек нәмәстәкәйләр дә энҗе-мәрҗән кеби ялтырый. Аһ, аның горурлыгы! Капралмыйни! Шул мең төрле бизәкләр белән төсләнгән матур башын югары тотып, шундый ук бизәкләр белән чигел-

гән галәмәт киң түшен генеральныкыдай киереп, тавыклар арасында ай-һайлап, үзен төрек солтаныннан мең кәррә өстен куеп, дөньяда мин генә дип тамак кырган патша кыяфәтендә тамак төбеннән әллә нинди эре-эре тавыш чыгарып, дөньяга сыймастай булып йөрүен күрсәң икән. Моның дәрәҗәсенә җитмәсә дә, аңа охшаш әтәчләр ел да булып тора. Әмма бу аларны яшәтми: йә чукып үтерә, йә ихатадан куып чыгара. Шуңа күрә «Патша әтәч» дип аталды ул.

Мондый гали затны мең-мең яшәтергә иде. Әмма ләкин соңгы вакытта артык комсызланып китте. Ихатада иллеләп тавык җырлап йөри. Агы бар, карасы, чуары, саргылты... Аларның да бәгъзе берсе мең төрле чәчәк төсе белән нәкышләнгән. Карап, сөеп туярлык түгел. Шулар арасында ул берүзе генә күкрәк киереп йөрсен, имеш. Тагы бер-ике әтәч булса, нигә, әллә дөнья тармы аның өчен? Ярый, хуш, аның бу кадәр холыксызлыгына, үзен әллә кемнән, хәтта Мөхәммәт пәйгамбәрдән өстен куеп маташуына да риза булып, күз йомып карар идең; бу юньсезлегеннән тыш тагын да әллә нинди ахмаклыклар кыла башлады: тота да күрше тавыклары янына кереп китә. Ярый, керсен, бер күңел ачып чыксын: күрше хакы — таңре хакы, дигәне әтәчкә дә кагыладыр, бәлки. Ләкин бит анда инсафлы гына йөреп, күрше тавыклары матурлыгы белән илаһи бер сокланып, тыныч кына күңел белән кайта белми. Иң әүвәл аларның әтәчләренә ташлана. Үтергәнче чүки, җәнчи, изә. Ике як күршедән дә хәзер әллә нинди колак ишетмәс, җан күтәрмәс, ачулы бәддогалар ява: Гыйрфан мулла, имеш, күрше әтәчләрен кырдыру өчен усал эттән дә яман әтәч тота. Бер юньсез әтәч өчен күршеләр белән низаглашып, якалашып яшәргәме? «Әтәч азса — хуҗа башына, патша азса — халык башына»,— диләр бит. Бисмиллаһир-рәхмәнир-рәхим!.. Хуш, азгын «патша»! Хуш инде! Бәхил бул! Яшең дә шактыйга китте шикелле. Вакытында яшьнәдең. Горур булдың. Һәр нәрсәнең чамасы бар.

«Патша» янында янә бик иркәләнеп, ыспайланып, җырлап йөргән ике симез патшабикәне дә тотып чалды Гыйрфан мулла. Хәсәнә абыстай аларны пешекләү, йоннарын йолку, аш салу эшенә кереште. Эш белән әвәрәләнгән вакыт тиз үтә. Кояш исә гәрчә адәм балаларының аһ-уһ килеп мәшәкатьләнүен күреп торса да, бер генә секундка да аларга артык вакыт бирми, Алланың үзе кебек тугрылыклы булып, куйган максатына ирешү юлыннан бер илле дә читкә тайпылмый — җай гына бара бирә.

Бүген дә ул тәртиплелек иманына тугрылыклы булды. Ут шарына әйләнеп, баерга ярты дилбегә чамасы калгач, бөтен җир йөзенә алсукызгылт нур сибеп, икенде намазы җиткәнлекне искәртте. Кырык эш кырык җирдә кырылып ятса да, аларны хәзергә бер як кырыйга куеп, Гыйрфан мулла остазбикәсе Хәсәнә абыстай белән парлап намаз укыды. Икенче бер бүлмәдә шул ук фарыз эш ике шәкерт тарафыннан да башкарылды. Әлеге ярты дилбегә буе ара, кем әйтмешли, күз белән каш арасы кебек кенә. Кызыл шар түсенә кергән кояш офык читендә сылу кыздай елмаеп торды-торды да, утлы нурларын җир өстенә тагын да мулрак сибеп, таулар артына яшеренде. Менә Ходайның рәхмәте: нәкъ шул вакытта ахшамсафа гөле, нәкъ кояш кызыллыгы кебек итеп, янып торган кызыл чәчәк атты. Бу юлы да аны башта Галимҗан күрде. Күрде дә барысын да гөл янына чакырды. Бу, үзенчә, ниндидер күренмәгән, киләчәк, булачак бәхет балкышы иде.

* * *

Шакирҗан балыкка киткән иде. Нәкъ ахшамсафа гөле чәчкәсе балкышы вакытында елмаеп-көлеп кайтып керүе, үзен кәүсәр күлендә юынып чыккан кешедәй хозур тотуы, күзләренең ниндидер бер җылылык сирпеп торуы бу балкышка яңа төс, илаһилык, күңеллелек өстәгәндәй булды.

Балыктан буш кул белән кайтса, аның сөмсере коелган, маңгае җыерылып, күз бәбкәләре мәзәкләнгән, борыны салынган була. Әле борын салынмаган, киресенчә, тәкәббер кешенеке кебек, күккә чөелгән. Димәк, балыкны күп чәлдергән. Аның юлы уңган яки уңмаган вакытта үзен ничек тотуын Йосыф мәхдүмнән башкалар яхшы белә.

Шакирҗан тышкы кыяфәте белән чын балыкчыга охшап тормый иде. Чөнки ул балыгын, балыкка киеп барган киемнәрен чоланда калдырып, гадәти чалбарын, күлмәген киеп килеп керде. Галимҗан белән Йосыфны күреп, бераз аптырап, бераз гаҗәпләнеп торды ул. Хәзер инде Галимҗанның Вәли мәдрәсәсендә Йосыф шәкерт белән бергә гаип булуын аңлау кыен түгел иде. Мал да ашаган җиренә кайта. Моның гадәте дә шуның шәенчә икән. Тик бу уй-хиснең тамчысын да сиздермәскә тырышты. Әйтерсең, бернинди шухыр-мухыр, кылдый-былдый, кәкре-бөкре эшләр булмаган: болар көндез бал-май белән чәй эчеп калган, ул, Шакирҗан, кунак егете өчен тәмле-тәмле балыклар алып кайтырга китеп барган.

Сокланып, гаҗиз булып карашып тору озакка бармады; «Әссәламегаләйкем», «вәгаләйкемәссәлам» әйтелешеп, күрешеп алынды. Аннан соң, авызларына су капкан кешеләрдәй, янә сүзсез катып калдылар. Авыр тынлык иде бу. Кем ни әйтергә белми тик торды. Тынлык катылыгын ата кеше җимерде:

— Күк кабагың нык ачылган, Шакирҗан улым, димәк ки, Кондызлы күл сиңа бүген артык мәрхәмәтле булган...

— Әйе, әткәй, бу кадәр дә күп эләккәне юк иде, кунакларның ризыгы киң икән...

«Кунак» сүзен ишетү белән, Галимҗанның әрекмән колаклары тырпаеп, төсе берникадәр бозылып куйды. Сүзне «кунак» ягына борып, аларның әлеге вакытта җир упкандай юк булу мәсьәләсе калкып чыгарга мөмкин. Аннан инде китә авыздан саескан очырулар. Шакирҗанның беркатлылыгы да көчле. Һич уйламый-нитми әллә ни әйтеп ташлавы бар. Аның әле берникадәр мактана торган гадәте дә юк түгел. Шуны уйлап, башта сүзне шаянга борды Галимҗан:

— Минем кармакныкына караганда синекенә азрак эләгә иде, Шакирҗан абый, әллә бүген, оясына туры килеп, балыкны сөзеп кенә алдыңмы?

Аның бу сүзләреннән соң бәгъзе берсе көлеп җибәрде, бәгъзе берсе елмаеп куйды. Өй эчендә... җанлылык хасил булды. Шуннан Галимҗан:

— Мин шаярттым гына, безнең Шакирҗан абый балыкның телен белә, шуңа күрә алар аңа күбрәк каба; әйдә, карыйк әле, Кондызлы күл балыклары сагындырды бит, төшләремә керде, әйдә күрик әле үзләрен,— дип, тышка чыгып китте.

Шакирҗан белән Йосыф аңа иярде.

Оялдында кәрзин тулы балыкны күреп, һәммәсе ләззәтле минут кичерде. Ә Шакирҗан исемнәрен әйтергә тотынды:

— Корбан балык... кызыл балык... мыеклы балык... табан балык...Йосыф мәхдүм дә балык төрләрен яхшы белә. Чөнки алар авылы янындагы Сөн елгасында да, тирә-яктагы күлләрдә дә балык, арттырып әйтсәк, мыжлап тора. Шуңа күрә Шакирҗанга сорау бирде ул:

— Әллә сезнең якларда корбан балыгы белән табан балыгы бер үк суда йөзәме?

Шакирҗан ачыклык кертте:

— Юк, алай түгел: табан — күл балыгы, корбан — елганыкы. Без бүген Мөхәмәй белән бик озак йөрдек. Корбанны — елгадан, табанны күлдән тоттык...

* * *

Кичкелекне ашап, ястү намазы укыгач, алар өчесе,— Галимҗан, Йосыф, Шакирҗан,— ишегалдына чыкты. Йа, хода! Нинди матурлык! Кояшның офык читендә калдырган кызыллыгы әле һаман янып тора. Хәзер инде ул кызыллыкта күксел-зәңгәр, сыек-зәңгәр,

алсу-зәңгәр, чия-көрән...— тагы да әллә нинди төсләр, бизәкләр бар. Ахшамсафа гөле чәчкәсе дә шулай бит. Анда ахшам кызыллыгы өстенә әлеге төсләрнең барысы да бөрчек-бөрчек булып сибелгән. Әллә күк белән җирнең сөешүеннән, үбешүеннән хасил булганмы бу могҗиза-чәчкә? Табигатьнең нинди сере бу тагы? Халык шушы серлелекне ничек аңлый икән? Әллә аның йөрәге табигать йөрәге белән бәйлеме? Кендекләре кояш нурларыннан ясалган күренмәс серле тасма белән тоташканмы?

Табигать күренеше белән хозурланганда һәркем әллә күпме хис-тойгылар кичерде. Галимҗан белән Шакирҗан, берсе икенчесен бүлә-бүлә, кунакка ахшамсафа гөле атамасының серен сөйләп бирде. Шуннан һәрберсенең күңел күгендә ахшамсафа гөле чәчкәсе бәхет күбәләге булып талпынгандай тоелды.

Болар чыкканда шәфәкъның кызыллыгы һаман уңа барган төс белән аралашкан зәңгәр кич иде. Акрынлап, назлы кызны сөяргә-иркәләргә иплән-җайлап кына килгән түземле, сабыр-әдәпле егет кебек, бу күксел зәңгәрлеккә төннең кара күз алмасыннан сыек кара нурлар килеп кушыла башлады. Һаваның тәмен һич аерыр хәл юк. Әле кибеп тә бетмәгән язгы җирнең йомшак бу — парына кичке савым вакытында таралган җылы сөт исе сеңеп калган кебек. Дәхи дә шуңа йөзләп морҗалардан чыгып җәелгән төтен исе килеп кушылган. Алар яшь үлән, яшь кычыткан, яшь яфраклар исе-тәме белән аралашкан. Шуларның һәммәсе уптым илаһи бергә кешеләргә фәкать сихәт бирә торган шифа булып кушылган дияр-сең. Җиңел, йомшак, тәмле һава борын очларын кытыклау белән үк син инде үзеңдә искиткеч бер көчле ләззәтлелек тоясың. Сикерәсе, ыргыйсы, йөгерәсе килә. Ә инде зәңгәр күктәге миллионлаган йолдызлар Җирдәге бәндәләрнең илаһи бу матурлык эчендә хозурланып яшәүләреннән көн-ләшәләр кебек.

Һәркемнең сөйләшәсе килә иде. Шакирҗанның бөтен теләге — айлар буе боларның кайда югалып йөрүләрен белү. Бу хакта ул сорамый калмады. Галимҗанның аз сүзле икәнен яхшы белә. Шуңа күрә сорауны күбрәк Йосыфка бирде. Йосыф мәхдүм, һич икеләнмичә, түкми-чәчми дигәндәй, бар булган кадәресен бөртекләп сөйләп бирде. Шулай да берәүнең дә сүз дәрьясына кереп чумасы килми иде. Чөнки монда сүзләргә караганда хисләр өстенлек ала. Табигать күп сөйләргә кушмый. Йомшак куллары белән, шәфкатьле аналар кебек, ул аларны һаман әле назлап-иркәләп тора.

— Юл азабы — гүр газабы, арыгансыздыр, әйдәгез керик, ятыйк, иртәгесе көн безнең кулда, тагы да иркенләп сөйләшербез,— диде дә Шакирҗан, икесенең дә аркасыннан җиңелчә генә назлап куйды.

* * *

Хәсәнә абыстай үзләре өчен урынны беренче каттагы сәкегә җәй-де. Мамык түшәк, мамык ястыкка чумган, «ә» дигәнче тәмле, татлы йокыга кителәр кебек иде. Бу фани дөньяда зур эшләрдә генә түгел, хәтта йокыда да көткәнеңнең киресе килеп чыга. Менә күз йомыла, менә әвен базарына киттем, чәнчелсен-катсын дөнья мәшәкате, төне-көне буе эшләп ватылган тәнеңне ял иттерү өчен бирелгән, дип уйлыйсың да песи йокысы белән изри башлыйсың; нәкъ шул вакытта каһәр төшкән бер юньсез уй баш миеңә чәчрәнләп килеп керә дә бөтене-сен дә челпәрәмә китерә. Бераз тын гына яткач, мулла абзый азрак сайрашып-гәпләшеп алмакчы, Галимҗан турында мең-мең уйлап, таш-тай каткан башын аз гына йомшартмакчы, шуның белән күңел күгендәге кара болытын берникадәр таратмакчы булды. Тора-бара бу уеннан да кире кайтты. Аңа остазбикәсе дә кызганыч иде. Аның да йоклый ал-мавын сизеп ята. Авыр-авыр тын алуы, анда-санда «уф» дип куюы, үрсәләнү-өзгәләнүе болай да талган-алҗыган йөрәккә без белән чәнеч-

кәндәй була. Шуңа күрә эндәшмәскә, аны борчымаска, бала кайгысыннан яраланган җәрәхәтенә тоз сипмәскә тырышты. Бәгъзе бервакыт үз уйларыңа пәрәвез җебенә уралгандай чолганып, эндәшми-нитми, мыштым-пыштым гына, тирән вә киң хыял-хис дөньяңа чумып, фәлән-фәсмәтән итәм дип, тилереп яту хәерле. Кайгысы да, шатлыгы да, уеңның тәмлесе дә, тәмсезе дә үзеңнеке. Кайгы ул — шатлыкка тагылган дегет чиләге. Бәй, кайтты, күңелгә нур сипте, сүнгән йөрәккә җылы өрде, өй эченә җан керде; булды Ходайга шөкер, хәят кояшын каплаган кара пәрдә ертылды, дисең; ләкин һич алай булмаган икән, шатлыкка икенче дегет чиләге килеп тагылды, кояшны янә кара болыт каплады: Казанга китәбез дип хыяллана. Нәселе яман сыердан үле бозау туар, ди. Бер бала да үле тумады анысы. Ә менә туганын саклап булмый. Әнисенең йөрәк җимеше нәфис Нәфисә дә озак яшәмәде. Нәркис гөледәй назлы, матур, сылу иде бит. Атасының уң канаты булырдай Гобәйдулла да, бу авыр фани дөньяны нигәдер хуп күрмичә, оҗмах-җәннәткә ашыкты. Инде бу Ташмаңгай Казанга барып кайнамакчы. Һм, кайнарсың да... пешеп, өтелеп, канатсыз калып миңгерәрсең. Яман чир тиз йога, яман гадәт тиз керә, ди. Яман чире дә бар бит әле үзенең. Яман гадәт артыннан кууы да юк түгел. Әтисен, әнисен кайгы кочагына ташлап, әллә кая китеп олагуы яман гадәт түгелмени? Юк, җибәрмим әллә кая, тыңламаса, чыбыкка, чыбыркыга кире кайтырга туры килә дип, елга буе уйларына буа буды ул.

* * *

Остазбикәсе дә шул хакта уйлап, мең төрле фаразлар дулкынында тибрәлеп ятты. Уйлар, әйтерсең, аның күз алдында санап бетергесез аллы-гөлле күбәләкләр булып оча. Кайсын тотып алырга ул йөз-мең төстәге күбәләкләрнең? Әмма берсе дә керфек очыңа да, уч төбеңә дә килеп кунмый. Шаярталар алар сине. Уйныйлар, үртиләр. Илаһым! Шул күбәләк-уйларның иң зурысы — Галимҗан белән әтисе арасында булачак көрәш уты. Икесе дә чыбыкны тоткан җирдән сындырырга ярата. Галимҗан хәзер Вәли мәдрәсәсенә бармас өчен тешетырнагы белән каршы торачак. Әтисе үз сүзен сүз итү өчен җан атачак. Бу инде — яңа низаг, яңа якалашу, яңа ызгыш. Ә аңа, ана кешегә, кайдадыр барып, берсенә дә күрсәтмичә, балавыз сыгып алырга туры киләчәк.

Уйлар! Уйлар! Очы юк. Кырые юк. Диңгездәй тирән. Дөньядай киң. Әмма йокы да үзенекен итә. Аның кануннары бар. Адәм баласын әдәпкә кертә торган канун. Кешенең яшәеше, сәламәтлеге, рухи вә җисмәни ныклыгы йокыга бәйләнгән. «Сәламәтлекнең иң түре — йокы»,— дигән борынгы ата-бабалар. Тора-бара аларның икесенә дә йокыдан тегелгән ефәк юрган ябылды.

* * *

Балалар өске бүлмәгә җайлашты. Анда — ике караватъ, бер кәнәфидиван. Караватлар ике түр почмакка урнаштырылган. Уртада — язу өстәле. Галимҗан, Габделхәкимне кочаклап, уң як почмактагы караватка ятты. Нәгыймә апасын якын күргән кебек, Габделхәким энесен дә нык ярата ул.

— Шәкерт абый, минем чынаяк тәтиләрем бик күп хәзер, у-у-у, дөнья хәтле, иртәгә күрсәтермен әле менә,— дип, Галимҗанның куенына песи баласыдай йомарланып ятты ул.

— Ярый, акыллым, шулай итәрсең, икәү уйнап та алырбыз әле менә; тик кара аны, тәтиенә кызыгып, чынаякны юри вата күрмә,— дип, энесен кысып кочаклап, бер сөеп тә алды Галимҗан.

Алар, тегеләргә ишеттермәслек итеп, колакны-колакка куешып, чыш-пыш, ык-мык килешеп, аз гына гәпләшеп алдылар. Әмма ул озакка

бармады. Көне буе уйнап-йөгереп, анда-монда чабып, малайлар белән бөтен урамны пыр туздырып йөреп арыган-алҗыган Габделхәкимне йокы тиз басты. Аннан әле яшь бала исе тәме дә китмәгән кебек. Аның керпе чәнечкеседәй тырпаеп торган каты чәч төпләреннән, бөтен тән-вөҗүденнән, тын-сулышыннан тышкы һава исе, яз һавасы исе, кояш нуры исе, җир исе аңкып тора. Ул хуш-исләрнең барысы бергә кушылып, туган җирнең илаһи бер ямен, тәмен, ләззәтен искә төшерә. Аның куенында, әйтерсең, мышный-мышный энесе түгел, болыннардан җыеп ясалган бер зур чәчәк йомарлагы ята. Сагыну тойгыларының никадәр көчле, мөкаттәс, сихерле икәнлеген шушы минутта янә бер тапкыр ныклап аңлады Галимҗан. Әтисен, әнисен, Шакирҗан абыйсын, кендек әбине, Акчәчкәне, кырларны, болыннарны, атларны, сыерларны...— барысын, һәммәсен өзелеп сагынды ул.

Шулар арасыннан иң бөек илаһи бер зат-алиһә калкып чыга. Бу фәрештәнең мамык-ефәктән торган ике канаты бар. Шул канатлар белән кочакласа, син гөнаһсыз сабый-нарасый балага әвереләсең. Йомшыйсың, эрисең, шатлык диңгезенә чумасың. Бөтен кайгы, әрнү, алама як кул белән сыпырып ташлагандай юк була. Йомшак-нәфис куллары белән чәчләреңнән, битеңнән сөйсә, үзеңнең назлы колынга охшаганыңны сизми дә каласың. Күз карашлары җылысы белән иркәләсә, шифалы саба җилләре исеп, алар бөтен тәнеңдә уралып, сеңеп, йөрәгеңә нindидер сихри яшәү оеткысы салынгандай тоела. Бу — ана-фәрештә канатлары. Бу — ана-фәрештә куллары. Бу — ана-фәрештә карашлары.

Тик бу матур, сөйкемле, гүзәл фәрештәнең күркәмлегенә тормыш авырлыгының кара пәрдәсе тартыла башлаган. Күз карашларында моңсулык, уйчанлык, хәсрәт сөресе...— тагы да әллә ниләр сизелә. Яңаклары эчкә баткан. Йөзендә нindидер сары самавыр шәүләсе бар төсле. Юк, тормыш авырлыгы кәсафәте түгел бу. Бала кайгысы авырлыгы шулай киптергән аны. Галимҗан кайгысы. Нәгыймә апасы чатнатып әйтеп китте ләбаса инде. Ул туры сүзле. Кылдай-былдай, ык-мык, килделе-киттеле кылануны аслан белми. «Кемнеңдер сүзе тугры булса, ул кешенең матурлыгы һәм кадере артык булыр»,— ди бит. «Күрдеңме әнкәйне? Кипкән таяк булып калды бит. Синең кайгың шулай итте аны»,— диде. Моны әйткәндә Нәгыймә апасының иреннәре дерелдәп, күзләре мәзәкләнеп, бөтен тәне калтырап куйды. Ананың газизлеге, бөеклеге, илаһилыгы әнә ничек икән. Бу хис-тойгыны Нәгыймә апасы күз сирпеп алган мизгелдә күрсәтә белде. Ә ул, Галимҗан, нигә алай түгел? Әллә кара йөрәклеме ул? Таш бәгырьлеме? Юк, юк, Ходаем сакласын андый бозлы сүзләрдән. Изге күңелле, олы йөрәкле, матур табигатьле, сөйкемле анасын өзелеп-өзелеп сагынды ул. Йөрәгендә анасына карата утлы, кайнар мәхәббәт бар. Ул ут, кайнарлык эчкә сыя торган түгел. Әгәр өреп тышка чыгарсың, боз тауларын эретерлек. Менә шуны ничек белдерергә? Кемгә әйтергә? Ә нигә белдерергә? Нигә әйтергә? Эчтә саклансын. Анага зур мәхәббәт саклаган йөрәк олы йөрәк ул. Анага булган зур мәхәббәт баланы бәхетле итә. Бүген ахшамсафа гөленең чәчәк атуы да, мөгаен, шуның бер хикмәте-хасиятедер әле. Ана белән бала мәхәббәтен нурландыру-бизәкләү өчен чәчәк аткандыр ул ахшамсафа.

Күпме генә әйтмә, әллә нинди тирән, бинһая зур фикерләр йөртмә, ана мәхәббәте баланыкына караганда мең-миллион өлеш зуррактыр ул. Шулай булмаса: «Ана күңеле — балада, бала күңеле — далада»,— димәсләр иде. Һич югында Шакирҗан абыйсына әйтеп китәргә кирәк булган. Баланың бер ахмаклыгы ана йөрәгенә тау дәүмәллеге кара кайгы булып ята икән. Баланың бер кайгысы ананы әллә ничә елга картайта икән. Менә кем икән ул ана! Ананың балага булган мәхәббәтеннән дә бөек мәхәббәт юк ул дөньяда!!! Юк, юк, юк...

Нәгыймә апасы тагын ни диде соң әле? «Әткәйнең сакалын кара. Син агартып бетердең аны»,— диде. Димәк, аның югалу кайгысы ата йөрәгенә дә кара таш булып яткан. Каты бәгырьле кешегә санап йөри иде ул әтисен. Катылык эчендә дә йомшаклык, илаһилык, кешелеклелек була икән ләбаса. Аның хәбәрсез югалуы әтисенең сакалын тагын да ныграк агарткан. Димәк, ул әтисе өчен дә бик-бик кадерле. Йосыф мәхдүмнең әтисе:

— Һәр эшнең ахырын фикерләп һәм уйлап эш кылмаган кешенең башы бәла вә кайгыдан чыкмас,— диде бер сөйләшкәндә. Әллә ул моны аңа, Галимҗанга, төрттереп әйттеме? Йосыф шәкерт Галимҗанның ни өчен алар ягына барып чыгуын бәйнә-бәйнә сөйләп бирде ич. Димәк ки, ул аның бу кыланышын килештереп бетермәгән.

Мең, миллион төрле утлы-давыллы уйлар диңкетте аның башын. Диңкетте. Изде. Мәмрәтте. Шул уй дулкыннары аны урап-чолгап алды. Шул дулкыннар эчендә, бишектәге сабый баладай тибрәнеп, тирән йокыга талды бервакыт.

* * *

Йосыф шәкерт тә уйсыз түгел иде. Илештә аларның да йорт-курасы, мондый зиннәтлене көндез чыра яндырып эзләсәгез дә таба алмассыз дигәндәй, хан сараен хәтерләтеп, әллә кайдан балкып, горур пәһлеванга охшап күренеп тора. Боларныкы да шул сыйфаттарак икән. Артыграктадыр әле. Чөнки Йосыфларныкы бер генә катлы. Ә боларныкы аслы-өсле өй, ягъни ике катлы. Аннан соң аскы өйнең дә, өске өйнең дә тәрәзә кашагаларында, киштәләрендә, төрле-төрле чөйләргә абыстай һәм кызы Нәгыймә чиккән сөлге-тастымаллар, челтәрләп нәкышләп эшләнгән ниндидер япмалар эленеп тора. Мендәр, ястык, түшәк өемнәре дә ал, кызыл, зәңгәр, яшел, сары, тагы да әллә күпме төстәге җепләр белән чигелеп эшләнгән япкычлар белән ябып куелган иде. Стеналарда да төсләрен санап бетергесез җеп белән нәкышләнеп эшләнгән матур-матур, чибәр-чибәр келәмнәр эленеп тора. Идәнгә җәелгәне дә шулай ук зиннәтле, күз явыңны алырлык матур, искитмәле. Аңа абыстай һәм кызы Нәгыймәнең йөрәк кайнарлыгы, күңел уты, хатын-кызда була торган үтә нечкә хис-тойгы ялкыны кушып чигелгәндер. Ул җәйгечкә аяк белән басу да килешми кебек. Гөнаһ булыр төсле. Өй эчендәге нурлылык, төрле гөл чәчәкләреннән килгән хуш-ис, чисталык-тазалык күңелеңне тәмам исертә, әсир итә. Син үзеңне ниндидер матурлык дөньясына килеп эләккәндәй тоясың. Бөтен күңел зәвыгын кушып телеңне йотарлык тәмле аш пешерү, өй эчен ниһаятьсез рәвештә оҗмах-җәннәт кебек итеп тоту, илтифатлылык хатын-кызның иң уңай сыйфаты бит ул. Ананың йөрәк кайнарлыгыннан, җылы күз карашларыннан, матур хис-тойгыларыннан сирпелгән шәфкатьлелек баланы зыялы, күркәм сыйфатлы, бәхетле итә!..

Хәсәнә абыстай күлмәк кенә түгел, хәтта хатын-кызлар читеге дә, чүәк тә тегә икән әле. Галимҗан, җаен туры китереп, аз гына вакыт эчендә аларын да күрсәтеп өлгерде. Димәк, әнисенең алтын куллы булуы белән ул бик нык горурлана.

Бакчадагы шау чәчәккә күмелгән алма, чия, карлыган агачлары, матур булып тезелеп киткән түтәлләр ата кешенең дә, Шакирҗанның да иҗтиһадлылыгы, эш сөючәнлеге, җегәрле икәнлеген сөйләп тора.

Беренче чәйдән соң, икенде белән ахшам арасындарак, Галимҗан аны ат абзарына алып барды:

— Менә монысы туры бия, менә бусы алмачуар,— дип горурланып, берникадәр мактану тойгысы белән сөйләп, атларның ялларын биш бармагы белән тарый-тарый, муеннарыннан кочаклап сөя-сөя, маңгайларыннан үбә-үбә, һич аңлатып бирә алмаслык күңелле хисләр кичерде.

Монда килүенә бик шатланды Йосыф мәхдүм. Күп ил күргән — күпне белгән, ди. Яхшы кеше белән аралашкан — җанына ризык тапкан, ди. Биредә җан ризыгы, рухи байлык, күңел хозурлыгы бар. Әмма хәзергә шул аклыклар өстенә ата белән бала арасында килеп чыккан низаг-үпкәләшүнең кара пәрдәсе ябылган. Әтисе Вәли мулланы Галимҗанны мәдрәсәгә яңадан кабул итәргә күндереп кайткан. Ә болар Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укымакчылар. Әлбәттә, зур тарткалаш, көрәш, күңелсезлекләр булачак. Кем җиңәр? Монысын хәзергә бер Ходай үзе генә белә.

* * *

Шакирҗан да утлы уйлар өермәсе давылында чайкалып ятты. Галимҗан өчен әтисе, үз тиресенә сыя алмаган арыслан шикелле котырынып, аның өстенә йодрыкларын төйнәп ташланды, вакыт-вакыт чәйнәп ыргытырдай ерткычтай кыланып, «у-у-у», «уф-уф» кебек ымлыклар белән аһ итеп, юләр кешедәй тешләрен шакылдатып, әллә нинди түбән сүзләр белән кимсетте:

— Син,— диде,— мәхлук җан иясе, бердәнбер энеңә күз-колак булып тора алмадың, җебегән, арыш боламыгы, черегән көпшә,— диде. Галимҗанның югалу кайгысын тау-тау итеп, аның җилкәсенә алагаем өеп куйды. Кайчак әнисенең ялыну-ялвару сүзләрен дә ишетте ул:

— Атасы, Ходайдан сабырлык сора, бу кадәр кылануларың һич кенә дә яхшылыкка түгел, Шакирҗанның ни гаебе бар монда,— дип юатты аны әнисе.

Ничек кенә булмасын, Шакирҗанга бик кыен иде. Әтисенең холыксызрак, кырыс кеше икәнлеген белсә дә, бу кадәр намус күтәрә алмаслык сүзләр әйтер дип уйламаган иде. Шакирҗан әтисенең эчендә дөрләп янган утның кайнарлыгын да белә: бала югалту ата кеше өчен энә югалту түгел бит. Ләкин Шакирҗан нахак сүзне бик авыр күтәрә. Эшләгән гөнаһ өчен тукмак алудан аслан курыкмый ул. Гаебеңне чатнатып, күзеңә, йөзеңә бәреп әйтсеннәр. Ялган балдай баллы сүзгә караганда әремдәй әче дөрес сүзнең өстенлеген аңлый ич инде ул.

Бусы бер булсын, ди. Икенче кире галәмәте килеп чыкты бит әле, шайтан алгыры, бу четерекле мәсьәләгә бәйләнешле. Үз агаңнан кач та ят-чит кешегә ияр дә кит. Аны абыеңнан өстен күр. Әтисе аны янә әллә ниләр әйтә-әйтә битәрләячәк:

— Туганлык җылысы юк синдә, мәмәйсең, авызың ачык каргасың,— дияччәк.

Уйлап карасаң, чыннан да шулай бит. Нык күзәтсә, һәрвакыт күз уңында тотса, янына еш килеп йөрсә, чын ага була белсә, мондый күңелсез хәл килеп чыкмас иде. Тирәнрәк уйласаң, гаепнең тәртә башы ахыр чиктә аңа килеп төртелә. Намуслы, кешелекле, әдәпле икәнлеген белә ул. Әллә адәм баласын чын шәхес итәрлек шулардан өстен янә бер хикмәт бармы? Остазның да остазы була, диләр бит. Ул остазлык кәбестә шикелле һаман-һаман катлаулана барадыр. Аннан үрмә гөлгә әверелеп өскә, югарыга үрлидер. Аңа инде унҗиде яшь. Кем әйтмешли, яшьлекнең яшел бакчасына алагаем аяк баса, егетлек кодрәтеңне хакыйкый эшләр белән күрсәтә, ташып торган көчеңне исбат итә алырлык чак.

Юк, Галимҗанны Казанга җибәртмәячәк ул. Моңа әтисенең дә, әнисенең дә көче җитмәячәк. Ә менә ул, Шакирҗан, авыр мәсьәләне чишкән кебек, гаиләне бу кыен хәлдән коткарачак. Кеше күңеле җиде кат җир асты кебек тирән булса да, Шакирҗан ул тирәнлеккә чума да белә. Анда адәм бәндәсенең күңел кылы бар. Әнә шул кылны табу, аңа чиртә белү нечкәлеге лязем дер.

Төне буе диярлек Галимҗан күңелендәге шул кыл турында уйлап ятты ул. Йокыга киткәч тә шуның белән саташты: кыл, кыл, кыл...

## IV

Патша әтәч хәзер юк инде. Иң әүвәл ул таңны яңгыратып кычкыра иде. Тавышы үлем йокысы белән йоклаганнарны уятырлык каты, таш йөрәкләрне хисләндерердәй моңлы, барлык тавыкларны дәртләндерерлек көчле була иде. Әйтерсең, бөтен авыл әтәчләренә Патша әтәч кисәтү ясаган: тирә-якта иң бөек Галиҗәнап кикерикүкмен, булыр-булмас тавышыгыз белән миннән алда кычкырып адәм көлдерсәгез, дөнья ямьсезләсәгез, шушы кылычтан үткер томшыкларым белән чукыйм да үтерәм, берегездән дә матур таңның котын җибәрмәячәкмен, дигән. Җәнлек, хайван, кош-кортларның теле бар диләр бит. Аларның «га-га-га-га», «бак-бак-ба», «ку-ку-ку-ку», «мә-ә-ә», «өм-мә-ә-ә» диюләрендә әллә күпме мәгънәле сүзләр бар, имеш. Патша әтәч «ки-ке-ри-күк» дип сөрән сала-сала үзенең «генераллыгын» аңлаткандыр. Көндезге шау-шу, ыгы-зыгы, тавыш-мавыш эчендә аның сөрәне әллә ни сизелмәскә дә мөмкин. Әмма таңда аның тавышы таш яра. Иң башта ул кычкыра. Аны башкалар күтәреп ала. Шулай итеп, әтәчләр моңы-симфониясе башлана. Бүген ул юк инде. Патша әтәч белән сугышасугыша, чүкешә-чүкешә, бер-берсен канатыша-канатыша ак әтәч башлап җибәрде бүген симфонияне. Аның да тавышы болай сөбханалла икән. Үлем йокысына сеңгәннәрне дә сикертеп торгызырлык. Хәер, гәрчә бер генә әтәч тә мазасызлап кычкырмаса да, Чулпанның таңны уятканы, таңның кешеләрне торгызганы һәр игенчегә аягындагы чабатасы, өстендәге киндер күлмәге, башындагы бәлшәйгән эшләпәсе кебек мәгълүм бер хәлдер. Бу вакытта ул барыбер уяна. Аның бит әле аңа төбәп әйтелгән әллә күпме мәгънәле хикмәтләре бар: «Кем кояштан алда тормаган, шул иң уңмаган»; «Ялкауны таң әтәче дә уята алмас»; «Йокыга моң кеше әтәч тавышын сөймәс».

Әлбәттә, тәмле таң йокысыннан үзеңне суырып алу берәүгә дә җиңел түгел. Әмма җиңел-җилпе эзли-эзли, чуртан авызына эләккән чабактай, авырлык авызына барып кабуың да көн кебек ачык. Гыйрфан мулла гаиләсендә бу мәсьәлә таштан койган коймадай кагыйдәләшкән. Иң әүвәл йорт хуҗасы сикереп торды. Аннан хуҗабикә, балалар.

Тиз-тиз, берәм-берәм, аллы-артлы тәһарәт алдылар. Мулла абзый бүген иртәнге намазны мәчеткә барып укыячагын әйтте. Аңа Шакирҗан да, Йосыф та, Галимҗан да иярде. Капкадан чыгу белән Мөбахис мәзиннең иртәнге намазга азан әйткән моңлы тавышы яңгырады. Йосыф мәхдүмнең күңеленә ул бик хуш килде:

— Менә кемдә икән моңның илаһилыгы,— дигәнен сизми дә калды ул.— Мондыйны бөтен Ырымбурдан таба алмассың.

Галимҗан аның бу ак фикеренә кара тамызды:

— Ул моң эчендә кара шәүлә бар, Йосыф абый.

Бу сүзләр Йосыф шәкертне тәмам нәүмиз итте. Сәбәбен сорарга уйлаган иде, намаз алдыннан сүз көрәштерәсе килмәде. Галимҗан бәхәс-моназара ярата. Гәрчә аннан күпкә кече булса да, бәхәстә гел өстен чыгарга тырыша. Бу гадәте хәзер аның канына сеңгән. Хәер, ул һәрвакыт үз фикереңдә нык торып, кешене ышандырып, эзле мантыйк белән сөйләп сүз көрәштерә. Моң эчендә кара шәүлә булуның бер хикмәте бардыр. Бу хакта соңыннан сорар, Галимҗан әйтми калмас.

Иртәнге намаздан соң алар бергә кайтты. Авыл беразга гөж-мөж килеп торды. Башта сыер көтүе китте. Аннары сарыкныкы. Шакирҗан белән Галимҗан да үз малларын капка ачып урамга чыгарды. Бервакыт ишегалдында Галимҗан белән Йосыф мәхдүм икесе генә калды. Шунда Галимҗан әлеге моң эчендәге каралыкның ни икәнлеген, Мөбахис мәзиннең кара сарыгы югалу, шуны Хөрмәтулла дигән кеше урлаган дип аңа нахак бәла тагу, аны үлем чигенә җиткереп тукмау, соңыннан югалган малның табылу хәлләрен бөртекләп сөйләп бирде. Бу күңелсез хәлнең бөтен авылда кара кайгы тудыруын әйтте.

Галимҗан күп сөйләргә яратмый иде. Ә бу юлы, бер ачылып киткәч, аның сүзләре ничектер чишмә суыдай агылып торды. Тик ул сүзләрдә чишмә суы сафлыгы түгел, ә сафлыкны бозучы керлелек бар иде. Бөтен йөрәге белән әрнеп, күңеле тетрәнеп, вакыт-вакыт тешен кыса-кыса, уртын чәйни-чәйни сөйләде дә:

— Менә нинди ялган диндарлар бар, Йосыф абый, Алладан да, хаклыктан да, иманнан да курыкмыйлар, адәм башын ашау алар өчен чебен үтерү урынына да тормый,— диде.

Бу сүзләрдән соң Йосыф мәхдүм алдында Галимҗан дәррәү тау дәүмәллеге үсеп киткәндәй булды. Димәк, аның күңел дөньясында аккара уйлар дулкыны көрәшә. Аклык өскә чыгарга тиеш. Кешелеклелек дигән төшенчә дә сеңгән аның канына. Кан йөрәк аша үтә. Тормыштан алынган кире сыйфатлар ул канны кайната, ярсыта, ургыта. Боларның барысы да Галимҗанның кырыс йөзенә аламалыкка каршы нәфрәт ташкыны булып чыкты. Йосыф шәкертнең шул тукмалган кешене күрәсе килеп куйды хәтта.

— Мөмкин булса, Галимҗан, әллә шул кешене барып күрәбезме?

— Тик әти-әнигә әйтергә ярамый.

— Нигә?

— Каршы килүләре бар. Яманлыкны алар миннән яшерергә тырыша. Алар өчен мин әле һаман йомырка сарысы.

Бераздан аларны Шакирҗан аскы өйгә чәйгә чакырды. Керсәләр — өстәл өстендәге сый-нигъмәтне күреп исләре китте: табада майда йөздерелгән коймак өеме, бер як кырыйдарак чәкчәк, гөбәдия, тагы да әллә ниләр бар...

* * *

Чәйдән соң Галимҗан белән Йосыф мәхдүм матур гына киенеп алдылар: өстә — җилән, башта — түбәтәй, аякта — читек... Шулай киенү вакытына күрә килешеп тора: әле яз белән җәйнең кул кысышкан чагы — көн салкын да, эссе дә түгел, җылымса гына. Кояш та бүген, җәйге чилләдәгечә, бөтен дөньяны көйдерердәй булып, уттай янып чыкмады. Офыктан дилбегә буе чамасы күтәрелгәндә дә аның йөзе салкын канлы кешенекен хәтерләтә иде әле. Әлбәттә, өйлә вакытларында аның чырае кайнар йөрәкле кешенекедәй кайнап торырга мөмкин. Ә хәзергә уртача-таманча һава. Көтү киткәндә күтәрелгән тузаннар инде, аз гына вакыт аралыгы эчендә аерылышу-сагыну хисләре кичереп, аналарын сөеп-яратып яшәгән нарасый балалардай, җир-ана өстенә күптән кабат төшеп түшәлделәр. Әле кибеп тә бетмәгән җир пары исе аңкый. Уйсулыкларда, елга буйларында, Кондызлы күл өстендә ефәктәй аксыл, юка томан өлгереп тора. Алар тиздән җир-ана белән аерылачакларын сизеп моңаялар төсле. Дөрес сизенгәннәр: кояш нурлары аларны үбеп, сөеп-назлап торды-торды да бервакыт үз кочагына-мәнфәгатенә алды.

Ата кеше, Шакирҗанны ияртеп, печәнлекләрне карап кайтырга дип китте. Аннан ары ишегалдында Галимҗан белән Йосыф шәкерт кенә калды. Алар күңелләрне күбәләкләндерә торган иртәнге саф һава, йөрәкләрне җилкендерердәй матурлык, гүзәллек белән илаһи сәҗдә китеп, ләззәтләнеп-хозурланып, инде китәргә дип торганда, өй эченнән мич каршында аш әзерләүдән бит очлары алсуланган Хәсәнә абыстай килеп чыкты да, ай-һай, боларны тагын да югалтмыйм дигән төс күрсәтеп, борчулы тавыш илә:

— Кая барасыз, Галимҗан улым, бик еракка түгелдер бит?— дип сорады.

Галимҗан әнисен тынычландырырга тырышты:

— Без йөрештереп кайтабыз, әнкәй, борчылма, әллә кая китмәбез, Йосыф абыйга авылны күрсәтәсем килә...

— Кунакны бик йончытма, кара аны, ишетсен колагың, әллә кая китеп олакмагыз.

Галимҗан җавапны шаяртыбрак бирде:

— Юк, юк, әнкәй, менә күрерсең, кояш кебек әйләнеп, тиздән кайтып та җитәрбез. Кайнар сумсаларыңны суытмый сакла.

Капкадан чыгып бераз киткәч, аларга Апуш очрады. Ул, балтасы суга төшкән кешедәй, бик кайгылы кыяфәттә, гамьсез генә атлап килә иде. Аның бите, кулы пычранып беткән. Кырык ямаулы киндер күлмәге, киндер ыштаны аның бик ярлы тормыш баласы икәнлеге турында кычкырып сөйләп тора. Галимҗан шушы кергә каткан тәкәббер Апушны да, төрекөмеш Әптерәйне дә, кысык күзле Мөхәммәтне дә, тагы да кара борынлы, үткер карашлы, сандугач телен, төлке хәйләкәрлеген белгән авыл малайларының барысын да, һәммәсен дә сагынып кайтты. Тик әле менә Апуш нигәдер сырт йонын кабартып тора. Галимҗан кулын сузгач, аны кабул итмәде. Үз кара кулы белән шәкерт дустының ак кулын пычратасы килмәде, күрәсең. Сүзләр дә, киселгән икмәк телемедәй, нигәдер берекмәде, таркау, ятышсыз булды. Чөнки Апуш бу мәлдә үзен гөл бакчасындагы шайтан таягы итеп сизде. Башта бит Мөбахис мәзиннең югалган сарыгын бергәләп эзләгәннәр иде. Ә инде соңгы мәртәбәсендә Галимҗанны ияртми генә киткәннәр. Әлеге Чирләчәүкәне йончытмыйк дип уйлаганнардыр, бәлки. Бу хакта да әйтми калмады Галимҗан:

— Дуслыкны боздың, Апуш, теге вакытта сарыкны эзләргә миңа әйтми генә киткән булдыгыз,— диде.

Апуш берничә сүз белән генә җавап бирде:

— Кем тапса да барыбер түгелмени?

— Миңа ул вакытта бик кыен булды.

— Сарык табылуда ни файда? Хөрмәтулла абзыйны нахакка рәнҗеткән өчен Мөбахис мәзингә берни дә булмады. Карга күзен карга чукымый шул. Аны яклаучылар күп.

— Хөрмәтулла абзыйның хәле ничек?

— Ә сез барып карагыз... Ул телдән калган, кан төкерә, ди.

Апуш теш арасыннан чыртлатып бер төкерде дә китеп барды. Болар юлларын дәвам итте.

Галимҗан юлда барын да сөйләп бирде. Хөрмәтулланың гармунда уйнавын, хатыны Мәликә, кызы Мәдинәнең моңлы итеп җырлавын, кыскасы, аларның моң эчендә олы йөрәкле булып яшәүләрен бәян итте. Мәдинәне Акчәчкә дип атавын, әле менә аны күрәсе килүен дә яшермәде.

## V

Хөрмәтулла өенең тышкы күренеше, ихатасы, абзар-курасы башка ярлыларныкыннан артык та, ким дә түгел. Шул ук җимерек читән, картайган капка, күп кайгы кичергән лапас, дөнья авырлыгының коточкыч төс-йөзен чагылдырып торучы балчык өй. Алар, бик мәдәнилек-илтифатлылык саклап, акрын гына ишек шакыдылар. Башта җавап булмады. Шакуны шактый көчәйткәч тә әле эчтән берниндн тавыш ишетелмәде. Галимҗанның башына өч төрле уй килде: беренчесе — өйдә берәү дә юк; икенчесе — авылда, шәһәрдәге кебек, ишек шакып тормыйлар, шуңа күрә бу дөбердәтүне, гәрчә ишетсә дә, Хөрмәтулла абзый аңа игътибар итмәскә мөмкин; өченчесе — Хөрмәтулланың телдән калуы турында әйтте бит Апуш; бәс, шулай булгач, «керегез» дигән сүзне әйтә алмый ич ул. Яшь зурлыгы ягыннан чыгып хөкем йөрткәндә, иҗтиһадлылыкны хәзер Йосыф мәхдүм күрсәтергә тиеш иде. Тик ул кунак кеше, ярамый. Шуңа күрә Галимҗан кыюлыкны үз кулына алырга мәҗбүр булды: ишекне ачып, дәррәү эчкә үтте, Йосыф аңа иярде.

Өй эче Актүбинеке кебегрәк. Шул ук җир идән. Озын кеше сузылып ятса, аягы ишеккә тиеп торырлык кыска сәке. Көн яктылыгын өй эченә

аз гына төшереп торучы карындык тәрәзә. Шулай да өй эчендә пөхтәлек, җыйнаклык, күркәмлелек сизелә. Морҗа — агартылган. Ул Мәликә түтинең ак, көләч йөзен хәтерләтә. Тәрәзә кашагасына элеп куелган чигүле сөлге Мәликә түти белән Мәдинә-Акчәчкәнең моңнарыннан нәкышләнгән диярсең. Мондый хис-тойгы Галимҗанның уй даирәсендә дулкынланды. Ә инде Йосыф мәхдүм күңеле әле ул хисләр дөньясында йөзә алмый иде. Чөнки ул болар хәятен белми. Шулай да Галимҗан аларның нindirәк һава сулап яшәү рәвешен сөйләгән иде инде. Димәк ки, аңа да Хөрмәтулла абзый, Мәликә түти, кызы Мәдинә турында фараз итү мөмкинлеге юк түгел.

Хөрмәтулла, йокыга мәңге моң булган песи шикелле йомарланып, сәкенең уң як почмагында ята иде. Ул, бәлки, йоклаган булгандыр, шуңа күрә шакыганда тавыш бирмәгәндер. Аның баш астында үзенең йодрыгы зурлыгы гына мендәр. Өстенә үзе белән бергә дөньяның мең авырлыгын кичергән ямаулы чикмән ябынган. Ят кешеләр килеп кергәч, бик авырлык белән булса да, ул торып утырды. Сез, тәти егетләр, яктылыктан качкан ярканатлар шикелле, ни эшләп әле мондый караңгы базга килеп кердегез, дигәндәй, гаҗәпләнеп, соры күзләрен чекерәйтеп карап торды. Күзләр дигәннән, аларның инде хәзер сорылыгы да, күрү өчен иң кирәкле-әһәмиятле бер әгъза булуы да сизелми. Чөнки тирәнгә, эчкә баткан-нар. Яңаклар да суырылып эчкә береккән. Башы теге вакыттагы йодрыгы зурлыгында гына калган. Әлеге гер ташыдай мускуллар шиңгән бәләкәй шалканны да хәтерләтми. Шәлпек иреннәр яңгырсыз елда эсселектән корып кипкән яфрак диярсең. Керпе энәләредәй тырпаеп торган каты чәче йодрык зурлыгы калган баш түбәсен авырттырып, кытыклап тора сымак. Кыскасы, ул инде хәзер карга күтәреп китәрлек хәл-әхвәл фаҗигасе дәрәҗәсендә. Бөтен вөҗүдендә шәлпәйгәнлек күләгәсе шәйләнә. Мендәр янында көл салынган ярык чәркә тора. Димәк, Апуш әйткәнчә, кан төкерүе дөрес булып чыга. Шунысы гаҗәп: әлеге ярык чәркәдән әллә ни ерак булмаган урында — кесәгә сыярлык гармуны. Димәк, шуны уйнап, вакыт-вакыт ял ала, күңел күтәрә, җан тәслим кылыр чагын моңы белән берникадәр озайта бара. Ул моңга Мәликә түти дә, Мәдинә-Акчәчкә дә кушыладыр. Шуларның бөтенесе уптым илаһи йөрәк утын, күңел дулкынын, җан сызлануын, нахакка рәнҗетелү газабын бераз басып торадыр.

Ул нидер әйтергә теләде. Теле күпме генә тибрәнсә дә, әлеге кипкән яфракны хәтерләткән иреннәре күпме генә дерелдәсә дә, аның сүзе чыкмады. Бугазына, гүя, кырлы таш утырган. Юк, таш түгел, укмашкан кан төере икән. Көчәнеп-көчәнеп, күкрәгеп тотып, бизгәк газаплаган кеше шикелле дерелдәп торганнан соң гына ул чәркәгә йөрәктән килгән канын төкерде. Төкергәч, чәркәдәге көл порыхлап күтәрелде.

Галимҗан килгәненә үкенеп тә куйды. Йосыф абыйсы алдында аңа бик кыен иде. Аның бит әллә ни уйлавы бар. Хәзер инде капыл гына ташлап чыгып китү дә килешми. Бу кешене санга сукмау була.

Шулай да ул бераздан телгә килде:

— Сез... сез... ни эшләп җөрисез... Сезгә миннән ни кирәк?..— дип сорады авырлык белән.

Җавапны Галимҗан бирде:

— Мин Гыйрфан мулла улы Галимҗан булам. Актүтиләрдә танышкан идек бит. Ә бу — Йосыф мәхдүм. Ырынбурда бергә укыйбыз.

Хөрмәтулла, тамагына балык кылчыгы утырган кешедәй, сүзләрен янә әйтә алмый торды. Бераздан, чәркәсенә тагын да бер лачкылдатып төкергәч, һаман шулай бөтен күкрәге белән авыр тын алды да:

— Җарый... сине аңладым... Җахшы нәселдән... ә бу җегет... әллә тагы да миңа нахак бәла тагарга җөрүчеме?..— дип куйды.— Тагыгыз... мин аннан тамчы да кырыкмаем... Гүпчи... Вәт кәк.. Пәтәмүште... Мин ырлашмаган... Анысын бер ходай үзе белә... Шул... шул... сез... аксөяк-

ләр... ярлы-ябагай өстенә кара пычракны лаканы белән аударсагыз... Алладан куркырга кирәк аз гына...

Бу сүзләрне сакау кеше кебек тотлыга-тотлыга, йөрәк утына чыдый алмыйча, вакыт-вакыт җен суккан кешедәй калтырана-калтырана, күңелендә кайнаган давыллы дулкынын көчкә тыеп, әрнеп-әрнеп сөйләде Хөрмәтулла. Аның җаны елаганны, йөрәге өзелер чиккә җиткәнне таш бәгырьле кеше дә аңларлык. Булып үткән коточкыч афәтне, фаҗигый хәлне, нахак корбанына әверелгән кемгәдер сөйлисе килгәндер, күрәсең. Башта йөрәк тамырларын сыкрандырып, сызландырып килгән кара кайгы каны тамак шешен яра-яра үтсә дә, сүзе бөтенләй чыкмый иде. Ә инде кара кан төере сүзләргә юл ачкач, йөрәк-бавыр, аң-акыл, хис-тойгыга сеңгән кара сөрем кубып, кан артыннан тышка сүз-сөйләмгә әверелеп чыга башлады.

Галимҗан үзе дә кан түкергән кеше. Кан аны «Хөсәения» мәдрәсәсендә хәлфә, мөдәррис, мулла, шәкертләр алдында хур итте. Ул вакытта җир ярылса, җир тишегенә кереп китәр иде ул. Кан аны Оренбургта бөтен тирә-якны дан тоткан шөһрәтле «Хөсәения»дән, Шакирҗан абыйсы белән бер бүлмәдә тору бәхетеннән аерып, җәһаләт Вәли мулланың караңгы базына китереп тыкты. Кан, кан, кан... Аһ, ул каннар!.. Әллә кан Хөрмәтулла агасы белән икесен бер язмышлы итмәкче буламы? Шул кан уртаклыгы алып килдеме әллә аны монда? Тик менә хәзер нишләргә? Ни өчен килгәнлекне ничек әйтергә? Әйтми чыгып китү дә әллә ничек. Бу авыр минутларда Йосыф абыйсы ничек уйлыйдыр — монысы аның өчен әле ул кадәр әһәмиятле түгел. Әһәмиятлесе — Хөрмәтулла агасының күңел кылына дөрес чиртә белү. Аның горур, баш имәс кеше, «ярлы тәкәббер» икәнлеген дә яхшы белә. Хәйләне, икейөзлелекне, боргалануны яратмый. Ташны балта түтәсе белән бер бәрүдә сугып ярырга ярата.

— Без хәлегезне белергә дип килгән идек, Хөрмәтулла абзый,— диде ул, үзенең авыр сулаганын, кыенсынганын белгертмәскә тырышып.

Хөрмәтулла әлеге эчкә баткан песинекедәй соры күзләрен акайтып, маңгаен җыерып, болай да бозылган төсен аңламаслык дәрәҗәдә үзгәртеп, гасабиләнеп карады да чәркәсенә янә бер кан түкереп куйды:

— Хәлме?.. Күреп торасыз бит... Кешене үтерү җиңел, ә менә үлгәнне терелтеп булмый... Тәк бит... Ну... миңа былтыргы күзегез белән карамагыз... Аны гүпчи җаратмыйм... Җәлләмәгез дә... Мин маңка малай түгел... Ивчү... Мондый тукмалган эт көнендә сасып җатучы әллә мин генәме?.. Һи-и-и... алар дөнҗә тулы... Вәт тәк... Ә сез... тәти егетләр... тутый кошлар... укымышлы, башлы кешеләр... Җазыгыз мына шушы хакта... Дөнҗага бер гыйбрәт булсын, хи-хи...

«Языгыз» дигән сүз шәкертләрнең икесен дә тирән уй диңгезенә китереп салды. Чыннан да, кешелеклелек-кешелексезлек, шәфкатьлелек-шәфкатьсезлек, яхшылык-яманлык турында сөйлиләр ич. Киләчәктә яхшылыкның җиңүе турында фәлсәфә саталар. Коръән, дин, укулар да шуңа корылган. Әмма ләкин меңнәр, миллионнар шушылай нахакка рәнҗетелсә, кешелеклелек җиңмәячәк. Матурлык фәрештәләре нур чәчеп йөремәячәк. Хөрмәтулла абзый язарга куша. Шушы минутта меңнәр-миллионнарның рәнҗетелгән, яраланган йөрәге шуны көтеп ятадыр. Һәр яманлыкның йогышлы авыру кебек тиз таралып, дөнья йөзенә кара ягуыннан куркалардыр. Мең-миллион үкчәле итек белән таптап изәсе иде ул яманлыкның башын. Яхшылыкның башы да, гәүдәсе дә мәңгелек бәхет пәйгамбәре булып калсын иде.

Берникадәр авыр тынлыктан соң сүзне бу юлы Йосыф мәхдүм башлады:

— Хөрмәтулла абзый! Мин, сез уйлаганча, бер дә нахак бәла тагарга йөрүче кеше түгелмен. Менә сез язарга кушасыз. Бик һәйбәт фикер. Ләкин бит без сезнең үткәнне белмибез...

Тагын да шактый озакка сузылган авыр тынлык булып алды. Хөрмәтулла теле белән әлеге кипкән иренен ялап куйды, хәлсез куллары

белән керпе энәседәй чәчен сыпырып, нурсыз күзләре белән боларга карап катты.

— Әйе... эчтә кайнаган кайгыны кемгәдер сөйләсәң, йөрәккә җиңел булучан... Пәтәмүште... берәүнең җөрәге икенчесенеке белән бәйле дә була... Аны Ходай шулай җаратканш... Күрәм... Икегез дә болай миһербанлы күренәсегез... Тыңлагыз әле минем гыйбрәтле хәлемне.

* * *

— Безнең әти карт... мәрхүм... авыр туфрагы җиңел булсын... нәсел-нәсепнең унөч буынын белер иде. Вәт кәк. Пәтәмүште борыны озын ерактан сизәр дигәндәй, беләк буе борыны белән мең төрле алтын базын казып, ул алтыннарны чүп-чардан аераера, синең алдыңа таудай өеп куяр иде. Акыл алтыны бу, туганкайлар. Сүз алтыны. Буйга биек үскән кешенең акылы тубыгыннан, дигәнне ишеткәнегез бардыр. Аның буе кыска иде. «Кәтүк» дип җөреттеләр. Әбаш, мин сиңа әйтим, Мөбахис мәзиннең казаныннан гүпчи дә ким булмас. Әнә шул казанда алагаем кайната иде ул акылын. Чәпчим кайнатып бетергәч кенә аны кешегә кашыклап-кашыклап өләшергә тотына. Вәт сөйләр иде. Прәме... авызына карыйсың да катасың. Картәтинең әткәсе Салават батыр чирүендә булган. Әх... ыхым... ни... Салават аны кәпитән итеп куйган. Вәт кәк. Бу ни шуткы, брат, ышту син. Теләсә нинди ахмакка тәтетмиләр аны. Улмы? Җанаралга җиткән булыр иде. Канлы көрәштә шәһит була мәрхүм.

«Канлы» сүзен әйткәч, бугазына таш утырган кешедәй, капыл-кинәт тын алалмас булды Хөрмәтулла. Эчкә баткан соры күзләре мәзәкләнеп китте. Башын артка ташлап, җим көткән кош баласыдай, авызын ачты. Ул, гүя, әллә кешеләрдән, әллә табигатьтән, әллә гарьше көрсидән сүнеп барган гомерен озайтыр өчен тәненә-вөҗүденә, йөрәгенә, эчәк-бавырына ниндидер яшәү шифасы өмет итә иде. Кем тамызыр аны? Бер бөртек гомер җимешен? Корыган тәнгә аз гына яшәү чаткысы бирердәй матдәне? Шул хакта уйланамы Хөрмәтулла? Бу мизгел-секундта, чалт аяз күктән яңгыр өмет иткәндәй, киселеп барган гомерне сипләрлек нәмәстәкәйләр эзләү хыялы аның башында әле аслан юк иде. Әйтәсе килгәннәрне, мөлдерәмә тулы чиләкнең суы түгелүеннән курыккан кебек, тиз генә әйтеп калырга ашыкты ул. Сүзләре дә, майлы табада шуган коймактай, ничектер җай гына агылып торды. Ходай ярдәм итте шикелле бу минутларда. Ә менә, ап-ак сөткә тамган дегет тамчысыдай, тамак төбенә әлеге кан тәере килде дә утырды. Башын күтәреп, аны кире йотарга уйлады ул. Чөнки кеше алдында көлле чәркәгә кан төкереп утыру килешми. Ләкин ул канын йота алмады. Чәчәде. Горык-чорык ютәлләргә кереште. Буылып-буылып ютәлләде. Эчен тота-тота, тәгәрәп китә-китә ютәлләде. Галимҗанның күңеленә: «Бетте Хөрмәтулла абзый, бәхилләшә бу яхшы дөнья белән»,—дигән шомлы уй килде. Йосыф мәхдүмнең дә ак йөзе күгәреп катты.

Шулай да Хөрмәтулла бирешмәде. Әлеге чәркәгә алагаем кан төкерде дә, сүземне дәвам итәргә әзермен, курыкмагыз, мин әле ул тиклем йомшак җан иясе түгелмен, дигән төс күрсәтте. Ул, мөмкин кадәр үзен кулга алырга тырышып, җаным чыгып китмәсен дигәндәй, учын нык йомарлап, тәртелә-тәртелә, тагын да сөйли башлады:

— Ызначит тәк... Зур авызлы адәм сүзчән була, дигәндәй, атай мәрхүмнең борыны гына түгел, авызы да ифрат зур иде. Сүз... перәме... чишмә суы урынына агыла... и вчү... ыххым... Ул әйтер иде... Картәти мәрхүм... тә-ә-к... Әлеге Нәпәлиүн сугышына катнаша... Ул да һәлакәткә тара... Вәт тәк... Кем өчен? Ил өчен!.. Халык өчен... Киләчәк өчен... Ыштубыда мазасызлык булмасын... Виш кәк... Шуннан атай карт үзе дә китә... Касыйм түрә белән бергә сугыша. И... перәме... теге нигә... Әх... тел төбендә генә... каһәр төшкере... Пар... пар... пар... Парижга барып

керәләр... Тәки оялатмыйлар. Париж жыланын Мәскәү жылысында... Пәтәмүште... анда оялап алса... ул бит... Уралга таба да ыслар иде... Шуңа күрә ул жыланнарны үз ояларында дөмектереп кайтканнар...

Әткәй әле ул чакта бик яшь, өйләнмәгән була. Нәпәлиүнне чәнчелдереп кайткач, яраланган арыслландай, ары сугыла, бире бәрелә, башын ташка бәрердәй булып кылана, пәтәмүште жит нады... Өйләнеп алгач та бәхет хитри нәмәкәй койрыгын тоттырмый. Әйтә иде мәрхүм: Эстәрле өязендә, диер иде, пәмиччикләрнең часный ат заводы бар, диер иде, вәт кәк... Кхыи... ыхы-хы... Минзәлә өязендә Әхмәтов дигән пәмиччикнең дә ат заводы булган... Тәкме?.. Тәк... Анда, жан кисәккәйләрем, «башкорт токымы» дигән атлар... Картәтәң, диер иде әткәй, әнә шунда этләнгән... Көн-төн тир түккән, бил бөккән, тез чүккән, диер иде, мәгәр үзенә ат жүнәтү түгел, жүгәнен алырлык та кәликә эшләй алмаган, диер иде. И вчү... кәнис-мәнис-нәкәнис... Ат жанлы булган ул. Ат жараткан. Атның тирен, исен исни торган булган. Ә үзен пәмиччик Әхмәтовның бер усал айгыры тибеп үтергән. Пәрәме... арт аяклары белән маңгаена гына бәргән... И вчү... кәнис-мәнис...

Әйтер иде әткәй: сез укып жөрегән Әринбур губернәсендә алтмыш тугыз алтын базы... әйлә... оныттым... при... при... прискә бар, диер иде... Шуларның утызы, диер иде, часнәй кулда, диер иде... Шуларда этләнгән әткәй... Ат башы зурлыгы алтын табып биргән бер прискә хуҗасына... Ә үзенә шиш... Кәпикә дә тәтемәгән. Шуннан... Киткән бу агач загатовит иткән жиргә... Җагу өчен... өй... йорт салырга да... Көн жак Урал завутларына жылгадан агач озатып торганнар... ыххым... вәт кәк... Анда да рәт булмаган... киткән авылга... котү котәргә... Җитмеш жәшендә дә сыер, сарык, кәҗә артыннан жүгереп жөри әле. Әнә ничек куа дөнҗаны. Әмма куып житә алмый. Хәлсезләнә. Үпкә авыруы эләктерә. Бер котырган үгез сөзеп үтерә моны... Мәрхүмне... Бик шат кеше иде дә бит... Алдарга да жарата иде. Ул бәгъзе берәүнең акылын сынап карау өчен алдаша иде. Ышанмастайны ышандыра. Ә теге чүбек баш жалганга ышанса, олы авызын колагынача жырып, шаркылдап көлеп жибәрер иде. Мәгәр кешенең кәпикәсенә дә тимәде. Харам мал, диер иде, ашказанында тирес корты белән бер, диер иде. Их, әткәй, әткәй!.. Их, әткәй!..

Ул сөйләвеннән тагын да туктап калды. Ата фажигасы күзенә яшь китерде, күрәсең. Әлеге тамак төбенә килеп тыгылган кан төерә кебек, бу да йөрәк канына манчылып чыккан канлы яшьтер, бәлки. Аны ул боларга күрсәтмәскә тырышты. Сөртеп тә алмады. Йә үзеннән-үзе кибәр, йә килгән юлына кире китәр дип уйлагандыр.

Шәкертләрнең икесенә дә кыен иде. Тыңлавы күңелле, билгеле. Ләкин Хөрмәтулла артык интегеп, газапланып, авырлык белән сөйли. Ә үзенең йөрәгендә кайнаган барлык кара кайгыларын, күңел көлләрен, эч-бавырын өзгәләгән әрнү энәләрен...— барын, барын менә шушы мәлдә чыгарып түгәсе килә кебек. Шуларны газаплана-газаплана әйтү өчен кемнеңдер килүен көткәндер ул, бәлки. Аның салкын, нурсыз, әрнүле күз карашлары да хәзер боларны ашыкмаска, ташлап чыгып китмәскә, тыңларга өнди сыман тоела. Бу исә шәкертләрне чыгып китүдән тотып тора. Алар һаман шулай баскан килеш тыңладылар. Сәке читенә утырсаң, Хөрмәтуллага жилкә күрсәтеп тору була. Ә утыргыч-урындык дигәне монда бөтенләй юк. Шуны уйлаптыр, бәлки, ул «кунакларны» утырырга кыстамады да. Хәзер менә чыгып китсәләр, килешеп бетмәстер шикелле. Аннан соң аларның әле Хөрмәтулланың үзе турында бер-ике сүз ишетәселәре килә. Шуны аңлагандай, бераз тын алгач, ул, авыр бер көрсенеп, сүзне үзе үк башлады:

— Минме?.. Картәти, әти карт сукмакларыннан да жөрдем. Күп жөрдем. Завут, шахты, күмер базы...— берсе дә калмады, нәкәнис. Ыһһым... уф... Кхи... Җаратмыйм мин завут, шахты хәжәеннәрен... Көллесе хамнар... алдакчылар... Котү дә котеп карадым... Бу да батмый. Пәчему? Пәтәмүште бер көн бай хатыны сыерымны имгәнсең дип жәбеште... вәт

иблис... Кешенең энәсенә дә тимием мин... Әти карт әйтмешли, йөрәк кимерә торган тирес корты бит ул. Ат ырладым дип җүри әйттем. Әткәй мәрхүм ышандырып алдый иде. Ә миннән булмый. Шабаш. И вчү. Сез минем телдән көләсездер. Шахтыларда, завутларда тел бозылып бетте. Сүз тапмаганда урыччаны кыстырып җиффәрәм. Үземнең җаңы читәнне сыер тизәге белән сылаган кеше кебек икәнлегемне беләм мин. Аңлыйм. Әле мына әллә ниләр сайрап саласы килә. Тик... сандугач теле бездә юк шул инде ул, бәгырькәйләрем.

Аны Йосыф мәхдүм юатты:

— Сез бик мәгънәле сөйлисез, Хөрмәтулла абзый.

Сүзгә Галимҗан да кушылды:

— Әйе. Безгә тыңлау бик күңелле.

Шуның белән аларның сүз җебе өзелде. Бераз тын торгач, өзелгән җепне Хөрмәтулла үзе ялгап җибәрде:

— Күрәм... сез мине җәллисез... Бая әйткәнчә... кирәкми. Нахакка тукмалуымны да җөрәгегезгә авыр алмагыз. Шахтыда Ычтапан бабай әйтер иде: бәхет өчен көрәшергә кирәк, диер иде, былай эт көнендә җәшәү никуды ни гәдитсә, диер иде. Мына... терелеп аякка баскач, Алла боерса, шушы хакта кәнкритнә уйланырга туры килә. Завуткамы, шахтыгамы китермен пожалуй. Рабучи брат арасында күңел ризыгы бар. Аларда чистый душа. Вәт тәк. И вчү... Хәзер бит безнең ише братка бераз ысвобуды бирелде... Аңа, әти картның агасы теге ни заманында... Крепостной права чорында... бер иблис пәмиччиктә этләнгән... Бәйләп куйган эт хөкемендә... Аннан ни шагу... Ни куда... әйтерсең, аны шунда сумала белән җәбештереп куйганнар... Китеп кара... Җә илле камчысы калҗасы, җә смирт... И вчү... Аннан аны... теге нине... тагы оныттым... Ә... Әйе... крипосной праваны үзгәрткәннәр... Теге ни... ничәнче җылда соң әле?.. 1861 җылда үзгәрткәннәр... туис... бетергәннәр... Хәзер без бер пәмиччик корсагын гына калынайтучы әдәми зат түгелбез. Дүрт җагың кыйбла... и вчү...

Хөрмәтулла, сүзләрем сезнең өчен карга борчак чәчү шикелле генәдер дигәндәй, сөйләүдән туктап калды. Инде чыгып китсәгез дә ярый дигәнрәк төс күрсәтте. Шәкертләр моны сизде. Шулай да аның йөзендә әле җибәрмәскә тырышу галәмәте чаткысы да беленде. Тагын да нидер әйтергә теләгәнен аңлау кыен түгел иде. Ул чыннан да шулай булып чыкты. Бер көрсенеп, авыр тын алгач, ул өзелгән сүз чылбырын янә ялгап алып китте:

— Әмма ләкин... дүрт җак кыйбла да... Мең төрле кара язмыш көтә сине... Пәчәмү?.. Пәтәмүште... Кешене чәпчим кеше дип белмиләр... Мына мине эт урынына изеп ташладылар... Мин бит адәм баласы!.. Бер адәм баласын нахакка үтерүнең гөнаһасы... ай-яй-яй... шуны аңламыйлар... Кешене түгел, тычканны да үтерергә җарамый. И вчү... Бер тычканны үтердеңме? Үтердең. Мының белән син миллион тычканны юк иттең. Пәчәмү? Пәтәмүште... унлап тычкан җитмәсә, бер төлке пропал... Унлап төлке җитми икән, арыслан ачтан чәнчеләчәк... Бер арыслан ким булды, ди... мында инде, туганкайларым, үләксә ашаучы мең төрле козгыннар пропал дигән сүз... Җир үләксә белән тулса... Җәшәү чәпчим чери башлый... Шуннанмы?.. Шуннан... ахырзаман җиткәнче үк барлык адәм баласы... мескен ачтан үлә... И вчү... Мынымы?.. Мынымы?.. Мыны, җан кисәкләйләрем, шахтыда чакта Ычтапан дигән бер дәдәй сүләгән иде... Җизен шулай ул... Вәт тәк...

Боларны сөйләп бетергәч, Хөрмәтулла тагын да буылып ютәлләргә кереште. Кан төкерде. Шәкертләр хушлашып чыгып китәргә торганда, Мәликә белән Мәдинә кайтып керде. Икесенең дә кулында нindидер иске япкыч-чүпрәк белән төрелгән зур төенчек иде. Төенчекләр, күрәсең, тартып-сузып, көчләп-көчләп бәйләнгән. Чөнки алар нык бүселеп тора. Япкыч очлары бер-берсенә җитмәгәнлектән, алар чабата киндерәсе белән озайтылган. Бәйләгән урыннардан балтырган яфраклары чыгып тора.

Димәк, алар урманга шуның өчен барган — үлән белән тукланалар. Икесе дә төенчекне сәкегә куйгач, өй эченә яшь үлән исе таралды. Аларның үзләреннән дә урман исе, болын исе, чәчәк исе бергә аралашкан хуш ис аңкып тора иде. Мәдинәнең кулында бәләкәй генә чәчәк бәйләме дә булган икән. Төенчеген сәкегә куйгач, аны әтисе кулына китереп тоттырды. Моның күңел күтәрү өчен икәнлеген аңлау кыен түгел иде. Бу хәрәкәтләр бик тиз — күз ачып күз йомган арада эшләнде. Бер үк вакытта алар бер-берсенә караш сирпешеп алырга да онытмады. Бусы да гаҗәп тиз — «ә» дигәнче кылынды. Мәдинә, чәчәк бәйләмен әтисенә биргәч, болан баласыдай матур хәрәкәт ясап, боларга йөзен күрсәтмәскә тырышкан хәлдә, юк эшне бар итеп дигәндәй, мич алдына барды, кулына әремнән ясалган себерке алып, нидер сыпырыштыргандай итте. Мәликә түти исә ягымлы, сораулы карашлары белән шәкертләргә карап катты: нинди җилләр ташлады, нинди язмышлар китерде сезне, тәти егетләр, бәйләп куйган шайтан да тормастай бу караңгы базга, ди иде аның гаҗәпләнү тойгысы. Бу тойгыны Хөрмәтулла да сизде шикелле:

— Шәкертләр хәлемне белергә килгән, Мәликә җаным, бар икән дөнҗада җакшы кешеләр, шулар өчен генә булса да җәшәрлек, — диде дә әлеге кызы бүләк иткән чәчәк бәйләмен иснәп куйды. Шул мизгелдә аның эчкә баткан күз төпләрендә, яңак чокырларында, керпе энәседәй тырпаеп торган чәч бөртекләрендә киләчәк өчен яшәү өмете чаткылары, адәм балалары күңеле төпкелендә яшеренеп ята торган кешелеклелек гәүһәрләре, хәяти самимилек балкып киткәндәй тоелды. Аның сүзләрен Галимҗан җөпләде:

— Әйе, Мәликә түти, без Хөрмәтулла абзыйның хәлен белергә килгән идек, — дип, Йосыф мәхдүмнең кем икәнлеге, Ырымбурда бергә укулары, бирегә ничек килеп чыгулары турында ашыгып-ашыгып, өстән-өстән, эш кешеләренең вакытын алудан куркып кына сөйләп чыкты.

Хөрмәтулланың хәзер «Хөрмәт», «Хәрти» дигән атамалары гына түгел, «Хөрти» дигәне дә бар. Димәк, «хөрт кеше» була. Әле менә Галимҗан «Хөрмәтулла абзый» дип, матур итеп, авыз тутырып әйткәч, Мәликә түтинең күңеле тулып китте хәтта. Әтисе Гыйрфан мулланың «кара» халыкка «аңгыра сарык» дип карамавын, һәр кемсәне зурлавын, кешеләргә кешеләрчә җылы мөгамәләдә булуын белә ул. Бу хакта аларның матур, җәннәткә тиң, илаһилык балкытып торган дөнья-тормышларында даими кайнашкан кендек әбисе Хәмдия абыстай да әйтеп тора. Шул инде: борынгылар белми әйтмәгән — өзелеп төшкән алма агачыннан ерак тәгәрәми. Оясында ни, очканында шул. Яхшы оядан очкан баланың канаты нык, акылы житү, зиһене зирәк була.

Шулай уйлады да:

— И гөлкәйләрем, и акыллыкайларым, и йөрәккәйләрем, безнең өше «кара» кешене санга санап килүегез, олылавыгыз өчен бетмәс-төкәнмәс рәхмәтләр яусын үзегезгә, Ходай тәгалә юлыгызга ак җаймә җәйсен, авыр укуыгызны җиңел итсен, — диде.

Алар хушлашып чыгып киткәч тә, озак кына матур, ләззәтле, күркәм хис-тойгылар дулкыны тибрәнде Мәликә күңелендә. Әллә ниләр уйлап бетерде ул: бу дөнья, кешеләр күңеле, яшәү рәвеше әллә бик-бик серлеме? Бу серне адәм балалары аңлап бетермиме? Әгәр аңлап бетерсәләр, яшәү тигез, бик күңелле, гаҗәп күркәм булыр иде.

Шәкертләрнең килүе Мәдинәнең дә күңел кылларын кытыклады. Аның өчен бу килү ышанмаслык, бәясез, ниһаятьсез бөек галәмәтлелек иде. Җитмәсә, чыгып киткәндә, Галимҗан «абыйсы» аңа ниндидер утлы, көйдергеч, аңлаешсыз караш та бүләк итте. Никадәр генә күз ташламаска тырышмасын, булдыра алмады Мәдинә. Башкаларга сиздермәскә тырышып, Галимҗанга күз тутырып бер карап алды. Йөрәк төпкеленнән үк килгән кайнар хисләр агымы икесенең дә күз карашлары ялкынында

очрашты. Бер мизгел. Секунд. Бу кайнар мизгел, әйтерсең, тойгылар җебен мәңге чишелмәс мөкатдәс серләр белән төенләде.

* * *

Алардан чыкканда, Кояш төшлек төбәгенә якынлашып килә иде инде. Һәр тараф тын. Моңсу. Ямансу. Дөнья үз йөрәгендә ниндидер тирән сер саклый сыман. Яхшылыкмы ул? Яманлыкмы? Аклыкмы? Каралыкмы? Шәфкатьлелекме? Шәфкатьсезлекме? Кеше боздай караңгы йортта яши. Ә тышта — яктылык. Монда энә очы зурлыгы да кара тап юк кебек. Вакыт-вакыт әтәчләр кычкырып куя. Юк, кычкыру түгел, сайрау бу. Сандугач сайравы. Аннан да артыграктыр әле. Сандугачныкы еракка яңгырамый. Әтәчнеке таш ярырдай була. Юк, ташны түгел, йөрәкне яра ул. Йөрәк күзәнәкләренә әллә нинди ярсыткыч, җилкендергеч, шаштыргыч моң салып, сине бераз тилертеп ала, әллә нинди кайгы-хәсрәтсез якты дөньяга әйди, күңелеңне хозурлык биләве белән били. Әтәч караңгы, яңгырлы, котсыз-шыксыз көннәрдә болай моңлы кычкырмый. Андый чакта ул өнен дә чыгармый әле. Димәк, әтәч моңы дөнья, яшәеш, хәяти моң белән бәйле. Аны көн матурлыгы, кояш нурлары назы, җир белән күкнең бер-берсен хөрмәтләп сөешү мәле-мизгеле шулай сайрата. Мондый көндә эт тавышлары да моңлы була. Алар кемгәдер ачу, нәфрәт белән өрми, кара тормыш авырлыгына әрнеми, хуҗасы өчен мәңге сакта торган тоткынлык язмышына зарланмый, ә фәкать, иркә бала ата-ана алдында шатлыктан бер очынып куйгандай, кояшлы көләч көндә дөнья йөзенә үзенең бер рәхмәтен белдерү җәһәтеннән моңлы өн чыгарып ала. Мондый чакта әтәч моңы, эт моңы, кеше моңы, табигать моңы, тагын да әллә нинди серле моңнар үзенчә бер зур моң йомгагы хасил итә.

Караңгы баздай өй эчендә яшәгән Хөрмәтулла абзый, Мәликә түти, Мәдинә-Акчәчкә кебек мең-миллионнарның да йөрәк моңы табигатьтәге вак һәм зур әйберләр хәрәкәте моңы белән бәйле түгелмени? Ничек кенә бәйле әле. Әгәр Хөрмәтулла абзый шул йодрык зурлыгы гармунын сайратып җибәрсә, Мәликә түти белән Мәдинә-Акчәчкә аңа кушылып җырласа, шул караңгы, бәләкәй өй эче мең өлеш яктырып, зураеп китәр, йөрәкләрне олайта, хозурландыра, ярсыта торган моң белән тулыр иде. Хөрмәтулла абзыйсының гармун моңын, Мәликә тутасының, Мәдинә-Акчәчкәнең җыр-моңын бик-бик тыңлыйсы килгән иде Галимҗанның. Әрнү-сагыш, шатлык-кайгы, яшәү-гомер итү тойгылары белән аралашкан ул илаһи моңны Йосыф агасына да ишеттерәсе иде. Тик Хөрмәтулла абзыйсында хәзер гармун уйнау дәрте ялкыны сүнгән шул инде. Балтырган җыеп кайткан Мәликә түти, Мәдинә-Акчәчкә, гәрчә шат йөзле булып күренергә тырышсалар да, шактый нык арыганнар. Хәер, аларның җыры, моңы турында бәйнә-бәйнә сөйләгән иде инде Галимҗан Йосыф мәхдүмгә. Хәзергә ул шул кешеләрне — моңлы йөрәкләрне күрсәтә алуына да канәгать. Киләчәктә, бәлки, моңнарын тыңларга да насыйп булыр. Өмет итик. Шайтан гына өметсез була бит ул.

Шундый уйлар дулкынында йөзде Галимҗанның күңеле. Алар сүзсез генә атлады. Бүген үк ул Йосыф мәхдүмгә авылның тирә-як табигатен дә күрсәтмәкче иде. Әмма ул фикерләреннән кире кайтты. Иртәгә дә көн бар лабаса. Барын да берьюлы кочакларга тырышып, һәммәсеннән мәхрүм калуың бар. Төшке ашка кайтып җитмәсәләр, аның югалуыннан болай да яраланган ананың йөрәге тагын да ныграк сызлаячак. Моны ул Йосыф агасына да әйтте:

— Мин Зәңгәр Чишмә, Кондызлы күл, Исәнбикә болынын, Яманташны күрсәтермен дигән идем, төшке ашка соңларбыз кебек, — диде.

— Авылның табигате, аның кешеләре белән горурлануыңны беләм, Галимҗан, барын да карарга, күрергә житешербез әле, Алла боерса, ә минә Хөрмәтулла абзый янына алып баруың өчен мең-мең рәхмәт!..

— Нигә?
— Мин бәләкәй генә кешенең олы йөрәген аңладым.
Аның сүзләренә төзәтмә дә кертте Галимҗан:
— Мин кешеләрне бәләкәйгә, зурга аермыйм.
— Анысы шулай, Галимҗан. Бәләкәй төркемгә мин гавам халкын кертәм.
— Гавам халкы зур ул, Йосыф абый!
Йосыф мәхдүм мондый сүз башлавына үкенеп куйды. Галимҗан күп сөйләшергә яратмый. Юк-бар моназарә-бәхәскә катнашмый. Буш сүз турында зур фикер йөртүне далада җил куып йөрүгә тиңли. Бу хосуста аның үзенең дә чатнатып әйтеп куйганы бар. Шәкертләр арасында зур фикер мәһарәте-осталыгы күрсәтергә, сүз мантыйгының чынлыгын ачыкларга, чуалчык мәсьәләләрне анык-дөрес чишәргә кирәк булганда гына барып керә моназарә дулкынына чумучылар уртасына. Ә бу, кеше турында сөйләшү, очсыз-кырыйсыз вакыт таләп итә. Үз фикерендә котырынган давылларда да селкенмәгән таштай торган Галимҗанны хәзер тынычландырырга кирәк иде.
— Әйе, Галимҗан, килешәм синең белән, безнең заманда кешеләрне вакка, зурга бүлү җәһаләтлек-наданлыкның бер күренешедер ул.

* * *

Алар кайтып кергәндә, аскы катта ниндидер бәйрәм тантанасына охшашрак күңеллелек сизелә иде. Күрше-күлән, дус-иш, кардәшыру җыелган. Алар арасында Көнсылу белән Котлызаман да бар. Әптерәй һәм Кәтринә дә шунда кайнаша. Бер якта Әләксәй басып тора. Шакирҗан да, әтиләре Гыйрфан мулла да әйләнеп кайткан басудан.
Шәкертләр икесе бергә «әссәламегаләйкем»не әйттеләр. Аларның тавышлары моңлы, йомшак, ягымлы иде. Җавап урынына шундый ук күркәм тавыш белән «вәгаләйкемәссәлам» әйтелде. Йосыф мәхдүмнең һәммәсенә сөеп, эчке җылылык, миһербанлылык белән каравы, чибәр йөзе, Галимҗанның да шактый үсеп китүе барысының да игътибарын җәлеп итми калмады. Бер мәлгә карашып тору, күз карашлары белән дә исәнләшү булып алды. Шулай да ул озакка бармады. Иң әүвәл Көнсылу тәтелдәргә керешге:
— И Гәлимйән, йән кисәкәйем, куркыттың бит, куркыттың, әсәйең, атайың гына түгел, һинең капылгара шулай югалуы кайгыһыннан без зә ут йотып йөрөнөк, Котлозаман агайыңның да телендә гел һин булдың: ай-һай-һай, бөтә ауыл халкының исе-акылы китте...
Сүзгә Котлызаман да кушылды:
— Эйе, Галимйән туган. Көнһылый еңгән рас әйтә, был кагыны бик ауыр кисерзек, инде Ходай быннан ары башкаһын бирмәһен...
Аның сүзләрен Әптерәй куәтләде:
— Бес тә уштан языр чиккә еттек, Галимьян, телепестә гел син пулдың; әле пына кайтканыңны иштеттек тә парапыс та килеп тә еттек...
Галимҗан Йосыф мәхдүмгә әтисе-әнисенең башкорт, чуваш дуслары булуы, аларның башкарак тел белән сөйләве, килеш-килбәт, буй-сыннары хакында да әйткән иде инде. Шуңа күрә әле менә аларның кем икәнлекләрен аңлатып торуны кирәк тапмады. Ул хәзер бер хакыйкатьне, кем әйтмешли, төбе-тамыры белән аңлады: бу ахмаклыгы ата-анасын, туган-тумачасын гына түгел, барлык дус-ишләрен, аларга теләктәшлек күрсәтеп яшәгән бөтен авыл халкын, тирә-якны зур кайгыга салган. Ата-ананы санга сукмау, бер гөнаһның тамырлары бик ерак китү, аның әллә кемнәр, әллә кемнәр йөрәгенә кара шытым булып керүе, иҗтиһадлылыкны югалту, мин-минлек... искиткеч куркыныч хәл икән.
Галимҗан өй эчендә ертык-мыртык киемле кешеләр дә булганы өчен Йосыф мәхдүм алдында берникадәр кыенсынды да. Чуваш Әптерәй аеруча кылка киемнән иде. Киндер күлмәк, киндер ыштан, озын сары чәч,

сары сакал аны бик котсыз, ямьсез күрсәтә. Бакча карачкысы итеп куйсаң, бер генә кош-корт та якын килмәс иде. Шулай да монын өчен ул артык нык борчылмады. Чөнки Йосыф мәхдүм, бәгъзе бер аксөяк кебек, кешеләргә югарыдан торып карауны ваемсыз зат түгел.

Чыннан да, Йосыф мәхдүмнең башында андый уйның әсәре дә юк иде. Ул үз әтисенең зыялы мулла икәнлеген яхшы белә. Әмма алар ихатасына ертык-мыртык киемле, чабаталы мужиклар бик аяк басмый. Эче караңгының йөзендә нур булмас, ди. Мондагы кешеләрнең йөзендә нур балкып тора. Димәк, эчләре караңгы түгел. Гыйрфан мулла, Хәсәнә абыстай шундыйлар белән дә дус була, адәм балаларының кадерен белә торган зат икән. Бу үзенчәлекләре Галимҗанга күчкән. Шулай булмаса, үлем белән көрәшеп яткан Хөрмәтулла янына алып барыр идеме аны? Алып бару гына түгел, аның язмышын үз йөрәгенә якын ала бит әле ул. Аның өчен сызлана, өзгәләнә, аны үлем авызына вакытсыз китереп тыккан комсыз Мөбахис мәзинне кичерә алмый.

Җыйнаулашып көндезге ашны ашаганда, чә эчкәндә дә бер-берсенә карата булган күркәм мөнәсәбәт, җылы караш, күңеллелек тойгылары сүнмәде-сүрелмәде. Иске кайгыны искә алуы яңаны чокып чыгара, ди. Иске кайгыны берәү дә телгә алмады. Ходай яңасын күрсәтмәсен. Гыйрфан мулла да бу күңелсез хәлне кара йөз күрсәтеп түгел, якты чырай белән капларга тырышты. Хәтта кызык-мәзәк сөйләп, мәҗлесне җанландырырга, килүчеләрнең күңелен күтәрергә омтылды, вакыт-вакыт көлдереп тә алды. Хәзер инде Йосыф мәхдүм алдында Галимҗан әтисенең күңел күге икенче бер сыйфаты белән ачылды — шаян табигатьле дә икән әле үзе. Хәзер инде ул әчтән генә үзен тиргәп тә утырды. Әллә кая алып китеп, әтисен-әнисен, туган-тумачасын, дус-ишләрен авыр кайгыга саласы калмаган. Их, бу тилелек! Их, бу җәһатләтлелек! Их, бу акыл җитмәү бәласы!

## VI

Йосыф мәхдүм Солтанморатта ике атна чамасы кунак булды. Болай озак торырмын дип һич тә уйламаган иде ул. Өч-дүрт көннән дә арттырмаска иде исәбе. Ләкин төрле сәбәп чыкты да торды. Сәбәпсез сәнәк тә урыныннан кузгалмый, агач яфрагы да селкенми, дигәнне дә яхшы белә. Сәбәпкә сылтанып, кеше мазасызлап яшәү һич тә муафыйк эш түгел, ваемсызлык була. Ләкин аны җибәрмәделәр. Ул халыкның: «Кунак — беренче көнне алтын, икенче көнне — көмеш, өченче көнне — бакыр»,— дигән сүзләрне дә әйтеп көлдерде. Яхшы-акыллы кунак кояштай балкып килер, кояштай балкып китәр, кояшны болыт каплаган кебек, аның да йөзенә кара күләгә төшүе ихтимал, кебек сүзләрне дә әйтеп карады. Әмма Гыйрфан мулла да сүз-җавап өчен кеше кесәсенә керә торган зат түгел икән. Ык-мык, кылдай-былдай килмәслек, боргаланыр-сыргаланырга урын калдырмаслык итеп, чатнатып әйтә дә куя.

— Син ашыкма-кабаланма әле, Йосыф улым, «Сабыр төбе — сары алтын, сабыр иткән — морадына җиткән»,— дигәнне ишеткәнең бардыр,— диде ул бер сөйләшкәндә,— сабырсызлык-пырдамсызлыкны Мөхәммәт пәйгамбәр дә яратмаган. Ә инде Ягкуб пәйгамбәр улы Йосыф пәйгамбәр,— монысы үзегезгә дә мәгълүмдер,— артык шашып, чыгырыннан чыгып, мәхәббәт кайнарлыгыннан ярсып барган Зөләйханы әнә ничек юата:

Сабыр берлә эшләгел ошбу эши,
Сабыр берлә эшләнер эшләр башы;
Морадына тиз йитәр сабырлы кеше,
Бу эш эчрә күрекле сабыр кылгыл имди.

Алар бу форсаттан файдаланып, озак-озак гәпләшеп, фикер алышып, бәхәсләшеп ала торган булып киттеләр. Ата-бабаларыбыз болгарлар кем булган? Мәҗүсилек чорында алар ничек яшәгән? Ни өчен күп аллага табынганнар? Ислам динен болгарлар бик соң, унынчы йөздә генә кабул иткәннәрме? Әгәр без болгарлардан килеп чыкканбыз икән, аларның да чал тарихта ерак ата-бабалары булырга тиеш бит. Кемнәр алар? Һуннар, аланнар, сарматлар, хазарлар, кыпчаклар...— тагын да әллә нинди көчле кавем-ыруглар булган. Болар төрки телдә сөйләшкән. Кайда алар хәзер? Нигә комга сеңгән су кебек юк булганнар?

Гыйрфан мулла Троицкида шәкертләргә дин тарихыннан да сабак биргән иде. Аны ыругдаш, кавемдәш, кабиләдәшләренең дә ерак тарихы кызыксындырды. Әмма ләкин, бу галәмнең чиксез-кырыйсыз икәнлеген һич тә күз алдына китерә алмаган кебек, ерак кавемдәшләренең тарихы-тамыры кайдан килгәнлекне аслан ачыклый алмады ул.

— Ни өчен бәгъзе бер кабилә яши, тарих көзгесе була, тантана итә, ә икенчесе тапталган үлән кебек бетеп-череп кала?— дигән сорауга шәкертләр дә төпле җавап бирә алмады.

— Көчле көчсезне җиңә,— диде Йосыф мәхдүм.

Галимҗан да шулайрак әйтте. Әмма ул үз фикерен шаяртулар, чагыштырулар аша аңлатты:

— Вак балык — чуртанга азык; чуртан — акула ризыгы; акула — кит ашказанына майлы аш. Халыклар да шулай: вагын — эресе, эресен — аннан да эрерәге, аннан да эрерәген иң эресе йота. Бу — гайре табигый хәл.

Боларны Йосыф мәхдүм дә белә иде. Шәкертләр арасында бермәл моназарә, бәхәс-фикерләшү вакытында бер алтын башлысы әйтеп салган иде. Тик мәсьәләне алай куертып, тирәнәйтеп сөйләүне ул килештермәде — кеше өендә ярамый, инсафлы булырга кирәк. Ә инде Галимҗанның олылар алдында үзен шулай фикердә зирәк — чос күрсәтүе әтисен дә, әнисен дә гаҗәпкә калдырды. Ни дисәң дә, хосусән Шакирҗан вә Йосыф мәхдүм белән чагыштырып караганда, ул бит әле тай янындагы колын кебек кенә.

...Йосыф мәхдүмне барысы да — Гыйрфан мулла, Хәсәнә абыстай, Шакирҗан, кардәш-ыру, туган-тумача, дус-иш нык яратты. Тиз генә җибәрмәскә тырышуның бер сәбәбе шул иде. Алар өчәүләп — Йосыф мәхдүм, Шакирҗан, Галимҗан даими рәвештә балыкка йөрде. Кондызлы күл, Зәңгәр чишмә буйларында, Исәнбикә болыннарында булу, Түрсәгәле белән Авыргазы елгасы кушылган урыннарны күрү, Солтанморатның искиткеч матур табигате белән ләззәтләнү, хозурлану аларның күңелен илаһиландырып, хис-тойгыларын баетып җибәрде. Мондагы бәгъзе бер чәчәкләрнең озынлыгы, арттырып әйткәндә, кеше буедай булыр. Аларның башы үзе йөз төрле төс белән нәкышләнгән гөл бәйләме. Йосыф мәхдүм көннәрдән бер көнне бу халыкка Ходай тәгаләнең ни өчен мондый оҗмахтай ямьле урын бирүе, ни өчен авылның Солтанморат дип аталуы белән кызыксынды.

Моны аларга Гыйрфан мулла бәян кылды:

— Һәр кавемнең, һәр ыругның, һәр кабиләнең, һәр халыкның чишмә башы була, балалар,— дип сөйләп китте ул, инде яртысы диярлек көмешләнгән, йөзенә гаярьлек-сөйкемлелек, бераз кырыслык биреп торган матур, түгәрәк сакалын сыйпап, горурлык-җитдилек өчен чын көчле ирләрчә тамак кырып.— Бу хосуста без берникадәр гәпләшеп алган идек инде. Хосусан, ата-бабаларыбыз, аларның яшәү рәвеше, иҗтиһадлылыгы, киләр буынга, ягъни дә мәсәлән безгә, ниндирәк эз-яктылык калдырулары хакында. Бәс, шулай булгач, сүзне асла дилбегә буе сузмыйча, кыскача гына әйтәм. Мәгълүм ки, һәр чишмә бу якты дөньяга мең газап-авырлык чигеп, тау-таш күкрәген бәреп чыга. Чишмәнең чыгышы нинди — суыагышы да шундый. Көмештәй ялтырап чыга икән — суы да көмеш. Иштә, безнең Зәңгәр чишмәнеке кеби. Шуңа күрә андый саф чишмәгә

кадер-хөрмәт тә, гавам халкының дикъкате дә, ихтирамы да зур. Аны күз алмасыдай хис кылып саклыйлар. Ә инде чишмә суы көмештәй ялтырап түгел, бакыр төсле булып чыкса, һаман шулай агып торса, бәндәләр аңа чырай сытып карый.

Шуннан мулла абзый, артык җәелеп китмәдемме дигәндәй, остабикәсенә, башкаларга күз сирпеп алды. Ул, мөдәррис-мөгаллим буларак, сүз җилемен һәрвакыт бертөрле тартып торуны яратмый, вакыт-вакыт, җае килеп чыкса, сүз тәменә, аның сәнгатенә әллә ни зыян китермичә, көлдереп тә ала иде. Бу юлы да шулай итте. Әлеге «бәндәләр аңа чырай сытып карый» дигәнгә «кара чырайлы усал хатын йөзенә караган ир-ат кебек» дип куйды. Барысы да шаулашып бер көлешеп алдылар.

Хәсәнә абыстай ансын-алай, монсын-болай итеп, тавык чүпләсә дә бетмәслек үз шөгыленә күмелеп, ихлас күңелдән мөкиббән эшләп йөрсә дә, болар сүз-фәлсәфәсенә дә һич тә игътибарсыз түгел иде. Кулы — эштә, колагы мулласының авызында булды. Барлык мөселман хатын-кызлары кебек, ирләр сүзенә катышырга яратмаса да, бу юлы үз фикерен әйтми булдыра алмады:

— Сиңа әйтәм, атасы, ни эшләп әле олы башың белән шәкертләр алдында шундый мәгънәсез сүз әйтеп утырасың? — диде.

Гыйрфан мулла җилкәсен кашып куйды:

— Ник мәгънәсез булсын?

— Йөзе кара булса да, күңеле актыр, бәлкем, ул хатынның. Актүтинеке кебек. Кемнең эчендә нинди асылташ ятканны кем белә.

Галимҗан түземсезләнә башлады:

— Әткәйне бүлмик әле, әнкәй!

Гыйрфан мулла янә тамак кырып куйды:

— Әйе, бүленгән сүз — өзелгән чылбыр. Аны соңнан ялгау бик кыен була. Хәзер ялгыйбыз, Алла боерса. Әйе, кабатлап әйтәм, һәр кавемнең чишмә башы булган шикелле, һәр авылның да, ягъни мәсәлән, Солтанморатның да чишмә башы, үз тарихы бар. Аллаһу тәгалә бу урыннарга уңдырышлы җир, күркәм табигать, чәчәкле болын, көмеш сулы чишмә, мыжылдап торган балыклы күл, елгалар биргән. Ходайга шөкер, бу яктан бәхетлебез. Авылның исеме дә бик күркәм, мәгънәле, олылыклы. Солтан — гарәп сүзе. Патша, хөкемдар дигәнне аңлата. Солтанат дисәк, мәһабәтлелек, олылык, зурлык кеби төшенчәләр аңлашыла. «Морат» та гарәпнеке. Максат, теләк, теләгән әйбер, аңлатылырга, белдерелергә уйланган нәрсә. Бәс, шулай булгач, сезгә һәммәсе биш бармагыгыз кеби мәгълүм инде. Кыскартып әйтсәк, Солтанморат мәһабәтлеккә, зурлыкка ирешү өчен максат куеп яшәү була. Бу изге максатны аклый алдымы Солтанморат халкы? Аклады. Зәңгәр чишмәнең дә суы әйбәт. Саф. Пакь. Ләкин дә ераграк. Авылга су кертергә кирәкме? Кирәк. Имән торба ясап, авылга кем су кертте? Солтанморат халкы. Чөнки ул иҗтиһадлы, эшчән, батыр йөрәкле.

Аның сүзен янә Галимҗан бүлде:

— Ялкаулары да җитәрлек, әткәй!

— Бармаклар да тигез түгел, улым!

— Ә шулай да?

— Басудагы игенгә дә бәһаны бер ялкау кишәрлегенә карап бирмиләр. Тормыштагы кара якларга гына карап яшәсәң, алтын базыннан чүп эзләүчегә әверелүең бар.

— Ярый, әткәй, хәзер авылның ни өчен Солтанморат дип аталуын, аның кем булуын әйт инде безгә.

— Солтанморатмы? Ул гаярь, йөрәкле, каһарман кеше булган. Бу урынны аңа патша зур көрәштә батырлык күрсәткән өчен биргән. Иле, халкы, Ватаны өчен теләсә нинди утка, суга керүдән аслан курыкмаган. Әмма ләкин авылыбыз халкы бик чобар. Әллә кемнәр, әллә кайлардан килеп җайлашканнар. Шулай бит ул: әле генә Галимҗан әйтмешли, чуртан вак балыкны йоткан кебек, эре дулкыннар вак дулкыннарны

тарткан шикелле, зур авылларга бәләкәй авыллар кучучән, аңа матурлыкны үзе төзи алмаган юка җилкәләр кызыгып караучан...

Бу юлы аны Шакирҗан бүлде:

— Әткәй, авыл халкының чобар булуы нәрсәне аңлата?

Ата кеше иркен тын алып, янә һәрберсенә җәһәт кенә күз сирпеп, монысын аңлату шактый кыен-авыр дигән төс күрсәтеп, бер кавым аптырабрак торганнан соң, тагын да сөйләп китте:

— Ул бит, балалар, әлеге дә баягы тарих вакыйгаларына, бәндәләр язмышына, яшәү рәвешенә бәйләнгән хәл-әхвәл күренешләре. Зур тарих кешеләрнең күңел сәхифәләренә языла бара. Бер акыллы баш әйтмешли, алтын хәрефләр белән. Ул хәрефләрнең күбрәге, дәхи дә күңел иләгеннән үткән иң-иң эреләре, зирәк, зиһенле-акыллы затларның ми күзәнәкләрендә. Бу күзәнәкләрдәге акыл энҗеләре икенче алтын башның ми күзәнәкләренә күчә бара. Аны, Ходайга шөкер, иҗтиһадлы галим кешеләр китапка терки. Теркәлмәгәне, монысы үзегезгә мәгълүм, күңел китабына языла. Ул «чобар» турында, соңнан укып карарсыз, әнә, теге Коръән эченә дә бер кәгазьгә язып салган идем. Сезгә әле ерак буыннардан килгән тарих галәмәтләренең бүгенге көнгәчә бәндәләр күңеле аша килеп җиткәнлеген бәян итәм. Болай, 1691 сәнәдә, ягъни дә мәсәлән, елда бик каты ачлык була. Кайда дисезме? Казан якларында. Идел буенда. Үләннәр корый. Җирләр ярылып кибә. Малга көндез чыра яндырып эзләрлек бер бөртек үлән булмый. Атлар, сыерлар, сарыклар, кәҗәләр тәгәрәп үлә, бәндәләр чебен урынына кырыла...

Гыйрфан мулла, шул урынга җиткәч, тамагына таш утырып, кинәт тыны кысылган кешедәй, сүз чылбырын капыл өзеп куйды. Нигәдер аның киң маңгае җыерылып, әле яшьләрнекедәй гайрәт чәчеп торган күз карашлары моңсуланып калды, йөзендә кайгы-борчылу күләгәсе хасил булды. Моның моннан ике йөз елдан артык элек яшәгән кешеләрнең фаҗигасен, авыр язмышын үз йөрәгенә алу икәнлекне аңлау кыен түгел иде. Хәтта аның берникадәр күңеле тулып китү хәтлесе дә сизелде. Тик ул йомшаклыкка бирелмәде, мәмрәп төшмәде, тиз арада үзен кулга ала белде. Ә тыңлаучылар «хикәят»нең дәвамын түземсезләнеп көтте:

— Шуннан?— дип куйды Галимҗан.

— Шуннан...— дип, янә берникадәр сүзсез торгач, күңеле белән һаман шул ач халыклар гаммәсе арасында йөргән хәлдә, хис-тойгыларны йөгәнләп, салкын канлы булырга тырышып, җай гына сөйләп китте:— Шуннан... Богдан Ирбулат улы Әхмәтов хәләл җефете һәм күп балалары, кардәш-ыру, туган-тумача, таныш-белеш, дус-ишләре белән бай табигатьле, уңдырышлы туфраклы башкортлар җиренә күчәргә булалар. Күчәләр. Ни өчен, ягъни дә мәсәлән, безнең авылда Богдановлар күп? Әнә шуңа күрә. Менә сезгә бер «чобарлык». Инде икенчесе. Бусының тарихы, Ходай үзе шаһит, тагын да ераграк, әллә кайда, әллә кайларда. Уникенче гасыр башында ук әле пол... пол... поляклар һөҗүме була. Хәзер егерменче гасыр башымы? Әйе, егерменче гасыр башы. Димәк ки, сигез гасыр элек була бу хәл. Сигез йөз ел элек. Урыслар белән дә су болгана. Шуннан... Сембер җирендә гомер иткән Алатыр мишәрләре күчмәк була бу якка. Әнә, бай җир кайдагы адәм балаларын үз кочагына тарта. Алатыр мишәрләре бармы Солтанморатта? Бар. Күп. Дәхи дә бер «чобарлык»мы? Дәхи дә бер «чобарлык». Менә бит аның хикмәте кайда? Шуннан... киң күңелле башкорт дуслар үзләре бер урам төзи. Янә бер «чобарлык». Тегеннән-моннан да күп күчеп киләләр Солтанморатка. Менә бит ул ничек. Кояш нуры барлык тереклекне үзенә караткан кебек бу. Безнең нәсел-нәсәпнең җиде буыны, яхшы оя эзләгән сыерчык шикелле, төрле урында җылы оя эзләп йөри. Солтанморатка минем картәти Әхмәтне Бөре өязеннән чакыртып китерәләр. Ул анда ахун булган. Мәдрәсә тоткан. Үзе белән шәкертләрен дә алып килгән.

Сүз һаман әле су буе сузылгач, Гыйрфан мулла, һәрберсенә җиттеме инде дигән караш ташлап, туктарга кирәклекне белдерде. Хәсәнә абы-

стай да, шәкертләр дә бу сөйләшү өчен бик канәгать иделәр. Тел белән әйтмәсәләр дә, күңел балкышлары шуны сиздереп торды.

## VII

Көннәр, бер-бер артлы җепкә тезелгән-теркәлгән гәрәбә кебек, үз җае, шау-шуы, мәшәкате белән үтеп торды. Сабантуйлар гөрләп үтте. Ул көннәрдә Гыйрфан мулла яшь егетләрчә мең кәррә дәртләнеп, шул ук вакытта «Бу тулпар»ының чабышта сынату-сынатмавы турында борчылып, аһ-уһ килеп йөрде. Моның белән ул әллә ничә ел шөгыльләнә инде. Чабышкысы беренче урынны алса, түбәсе күккә тия, үзен гарьше көрсидәге илаһи бер бөек-гали зат итеп тоя, ә инде андый бәхет тәтемәсә, борыны салына, җир тишегенә керер чиккә җитеп гарьләнә, атны да, үзен дә җебегәнлектә гаепләп котырына. Башкорт дусты Котлызаман да ат ярата. Аларның күңел җебен, йөрәк кылларын әнә шул ат мәсьәләсе бәйләде дә. Аю гәүдәле, карап торуга ук әкияттәге Сәетбаттал батырны хәтерләтеп торган Котлызаман көрәштә дан тотты. Шуңа күрә сабантуй мәйданына атын түгел, үзен әзерләде. Әмма ат җене кагылган, атның колын чагында ук басып торышы, күз карашы, боты, бәкәле, башын ничек тотуы буенча үк нинди булачагын эчке сиземләве белән аңлаган башкорт чабышка һич тә битараф булмады. Ул чабыш атлары үстерергә яратты. Туры биясе аңа болан баласыдай матур, үткер күзле, нык бәкәлле колын бүләк иткәч, ул йөгерә-атлый Гыйрфан муллага килде:

— Мулла абзый, һәй, әттәгенәһе. Хозай тәгалә бирергә теләгән колына, сыгарып куйган юлына, дигәндәй, аттан һинең дә, минең дә бәхет бар икән, Туры бейәм бөгән таңда карап туймаслык колын килтерзе бит, «Толпар» дип исем куштым, теге әкияттәге толпар аттан мыскал да кәм булмаясак был, мин уны һиңә сабышка үстерәм,— дип такылдады.

Ике елдан соң аны Котлызаман Гыйрфан мулла кулына үзе китереп тоттырды. Бәясен сорагач, Котлызаманның кашы җимерелде, сөмсере коелды, әлеге бит очларындагы тавык йомыркасын хәтерләтеп торган бүлтәймәләре биеште:

— Һин, мулла абзый, мине түбәнһәтәһең, әллә ниндәй бер ыйылдык, комһоз бәндәгә һанайһың; башкорт әйтмешләй, дуслык малга корылмаган, бүләк өсөн акса алырга мин бит оңкот әзәм түгел,— дип үпкәләде.

Аңлады ул вакытта Гыйрфан мулла башкорт дустының йөрәген. Зур, эчкерсез, илаһи йөрәкне аңлап шатланды.

Атлар дөньясы — үзе бер зур хәят. Ниндиләре генә юк аларның. Әйткәндәй, күктә йолдызлар ничаклы, алар төре шулчаклы. «Тулпар» дигәне әллә шул йолдызларның берәрсеннән җибәрелгән җан иясеме? Булыр да. «Тулпар» — галәм киңлекләрендә очып йөри торган канатлы ат ич ул. Аның хакында әллә күпме риваятьләр йөри. Шуларның берсен Котлызаман мулла абзыйга сөйләп бирде:

— Бына һин тыңла әле, мулла абзый, акыллы тыңлар, дурак һөйләр, ти, әйзә, мин шул элеккесе диуана булып калайым, һин акыллы булып кал.

Гыйрфан мулланың хәтере калды:

— Тукта әле, Котлызаман, әллә кайсы якка борма сүзеңнең тәртә очын, кайчан минем сине диванага санаганым бар. Ә?

— Юк, юк, мулла абзый, былай шаярып кына әйтәм, якын күреп.

— Шулай диләр аны; әйдә, сөйлә, бүлмә.

— Бәй, шулай инде ул, мулла абзый, әйе, бына былай, мин бары тик кешенән ишеткәнемде әйтәм: «Атабыз Әзәм менән һауаны күктән ергә аткас, ер өстөндә кешеләр ишәйеп йәшәй башлагас, күктә тороп калган фәрештәләрзең дә ергә төшкәһө килгән. Улар, хәйлә табып, алланы

алдамаксы булгандар. «Ергә әзәм яраттың, улар унда гөнаһ кылалар, беззе лә ергә төшәр, без уларзы хөкөм итербез»,— тигәндәр. Алла ике фәрештәгә Әзәмгә булган нәфсене биреп, гөнаһ эштәр кылмаска һүз-зәрең алып, береһен казый, икенчеһен мөфтөй итеп, ергә төшәргән. Шунан былар хөкөм итеп йөрәй башлагандар.

Бер мәлде ирле-катынлы берәүзәр казыйга хөкөмгә килгәндәр. Был ирзең катыны шул тиклем һылыу булган, казый ирзе генә хөкөм итеп, зинданга ултыртырга уйлаган, ә һылуы катынды үзенә алмак булган. Мөфтөй зә казый карарын хуплагас, ирзе зинданга ябып куйгандыр былар. Бына хәзер былар катын өсөн талаша башлайзар. Катын да һәтти үк акыллы булган. Быларга шарт куйган: «Беренсе шартым шул: миңә донъялагы иң матур йөзөктә табып бирегез, икенсе шартым — хәзер хәмер эсегез. Кем күп эсә — мин шуныкы,— тигән.

Теге икәү осоп йөрөп, катын һораган йөзөктә табып килтереп, тегенең камыш кеүек бармагына кейзереп куйгандар за кем узарзан хәмер эсергә тотонгандар. Катын боларга ерәнеп карап торган-торган да гәрлегеннән илай башлаган. Быны күреп, ике фәрештә, күктән төшөп, катынды күккә осороп алып киткән. Зөһрә үзенең йөзөгө менән күктә шул көндән бирле балкып тора башлаган. Ана, Зөһрә йондоз калай барлыкка килгән. Ерзе бик һагынган сагында, Зөһрә һылыу Толпарзы үз янына сакыра, ти. Сакыра ла уга эс серзәрен һөйләй, Ергә кайтып уны бер үбеп, көмеш шишмәләрендә битен йыуып ләззәтләнәһе килгәнде әйтә икән. Тыңлай Толпар. «Ә» тигәнсе атландырып, канаттарын йәйеп, кояш нуры тиз-легеннән әллә нисә миллиард артык тизлек менән көнә буйы осоп, киска уны тагы ла үз урынына илтеп куя икән. Бына ниндәй ул Толпар».

Гыйрфан мулла аны исләре китеп, илаһи бер мөкиббәнлек, хис-тойгылар давылы белән тыңлады. Котлызаманның хәләл җефете Көн-сылуның телгә оста, тәтелдәп-чәтрәнләп торуын, вакыт-вакыт сандугач булып сайравын, йөрәкәеңне өзеп ташлардай тирән моң белән җыр-лавын, чылтырап аккан Зәңгәр чишмә тавышлары чыгарып көлүен, талдай нечкә билен чегән кызлары кебек бөгелдерә-сыгылдыра йөрүен белә ул. Уптым алганда, торганы бер болын-дала чәчкәсе инде. Баш-тарак, танышканның тәүге мәлендә, ни эшләп бу болын чәчәге аю гәүдәле, куркыныч кара йөзле, тупас кыяфәтле Котлызаманга барды икән, дип уйлый иде. Котлызаман тыпырдатып бии дә бит әле ул. Биегәндә аяк табаннарыннан ут чәчри кебек. Бу вакытта инде аның аю гәүдәсе бөтергечтәй уйнаклап тора. Ике кулын бөркет канатына ох-шатып, җәеп тә җибәрсә, менә-менә күккә очып китәр сыман. Мондый чакта аның шомырт кара күзләре очкынлана, кара йөзендә ниндидер дәртләндергеч нур уйный, үзе белән бергә әлеге бит очларындагы тавык йомыркасыдай бүлтемнәр дә бии. Бу мизгелдә Гыйрфан мулла аннан аз гына көнләшеп тә куя. Нигә ул да шулай түгел? Нигә өздереп биергә өйрәнмәгән? Аның да яшь чагы булды лабаса. Егет кешегә житмеш төрле һөнәр дә аз, диләр. Бию — шул һөнәрнең берседер әле ул. Әтисе алдашмаска, иҗтиһадлы булырга, хезмәт сөяргә өйрәтте, иман нуры белән яшәргә куштьы. Әмма ләкин даими рәвешкә мөселман халкы өчен бию, кычкырып җырлау, музыка, рәсем сәнгатенең гөнаһ булуы турында әйтеп тора иде. Әнисе дә шул рухта тәрбияләде. Дин кушмый, янәсе. Аллаһу тәгалә тарафыннан тыелган. Мөхәммәт пәйгамбәр бу хакта үзе ничегрәк фикер йөрткә икән? Әлә уйларга вакыт-форсат булмаганмы? Гавам халкы таба лабаса җаен. Уйный. Көлә. Бии. Җырлый. Соңгы тиенено гармун сатып ала. Сигезәр-унар бала үстерә. Ач. Ялангач. Торырга юньле куышы юк. Әмма күңел ача белә. Барлык кайгысына, авырлыгына төкереп яши. Бу яктан да ул вакыт-вакыт алардан көнләшеп куя. Хөр күңелле, кешелекле, гади-садә булганнары өчен.

Ә инде Котлызаманның ат тиңелтен ат бүләк итүе, шундый илаһи йөрәкле, олы җанлы, матур күңелле булуы Гыйрфан мулланы дөнья, яшәеш, кешелеклелек турында тагын да тирәнрәк уйланырга мәҗбүр

итте. Әлбәттә, бүләкне ул бише белән кайтарачак. Бер яхшылыкка биш яхшылык эшләү аның канына сеңгән. Әтисе мәрхүм дә шулай иде. Таш атканга аш белән атарга өйрәтте. Монысы авыр мәсьәлә, билгеле. Бер дуңгызы сине котырган үгез урынына сөзәргә килсен, ә син аның юлына ак җәймә җәеп тор, алаптай ач авызына ризык-нигъмәт сал, имеш. Нишлисең, яхшылык, кешелеклелек җинсен дип яшисең. Моны аңламаган чучкалар да бар. Ә бәгъзе берсе аңлый. Ташына аш бирсәң, бервакыт алдыңа килеп тезләнә. Ә син иркен тын алып куясың: бер дуңгыз бәндәне яман уйлардан коткардым, янәсе.

Котлызаман кебек тышы салкын, эче ялкын, тышы котсыз, эче гәүһәр булган кебекләр күп, билгеле. Ходай бәхетне һәммәсенә өем-өем бирсә, ай-һай ла, шәп булыр иде дә бит. Ләкин, ләкин, ләкин...

Ярый, монысы бер хәл. Хәзергә икенчесе шул: Котлызаман биргән «Тулпар» сабантуйда беренчелекне алды. И аның матурлыгы. Илаһым! Төсе бурлат. Елкылдап тора. Шәфәкъ нуры белән төренгән диярсең. Бармак очы тидерергә дә куркып торырлык. Тигезсәң, әлеге елкылдап торган шомалык, шәфәкъ нуры япмасы бозылыр төсле. Ялы — торганы бер ефәк көлтәсе. Ул әле җем-җем итеп тора. Күз явыңны алырлык. Башы аның, горур егетләрнеке кебек, һәрвакыт югары. Маңгаенда — йолдыз. Әйе, әйе, йолдыз. Әллә Зөһрә йолдыз үземе? Зөһрәне гарьше көрсидән — күк дөньясыннан, Җирне үбәргә алып төшүче Тулпар шушы үземе?

Сабантуйда беренче килгәч, аңа сокланмаган кеше калмады. Матур кыз кебек бит бу, дип кычкырды кемдер. Ә Тулпар, гүя, моны ишетеп, шуны аңлап, башын һаман югары тота, чибәрлеге белән мактанып тора, ярсыганлыгын да сиздерми.

Чабышка аның өстендә Котлызаман улы Хәерзаман барган иде. Бу исә ике гаиләнең дуслыгын мәңге өзелмәс алтын чылбырлар белән бәйләп куйды. Гыйрфан мулла бер кысыр бия, өч сарык чалып, бөтен авылны бәйрәм иттерде. Күрше-күлән, ярлы-ябагай, дус-иш, кардәш-ыру... берсе дә калмады. Һәммәсен сабантуй шатлыгы белән сөендерде. Чөнки бу аныкы гына түгел, бөтен Солтанморат даны иде. Ә инде авыл даны бәләкәй төшенчә түгел. Котлызаманга исә бер сөтле сыерын бүләк итте. Хәерзаманны баштан алып аягына хәтле чем-ясау итеп киендерде.

...Йосыф мәхдүм сабантуйлар үткәч китәргә җыенды. Ләкин әлегә кайда укыячаклары мәсьәләсе төене һаман әле чишелмәгән килеш кала килде. Ул төенне чишәргә Гыйрфан мулла да артык кабаланмады. Ниндидер бер җае чыгар кебек тоелды. Ашыгып ашка пешүдән курыкты. Әлбәттә, Йосыф шәкертнең кылын кат-кат тарткалап карады:

— Йосыф улым, үзең теләсә нишлә, тик мин Галимҗанның әллә кая китеп югалуын һич мәслихәт күрмим бит әле,— диде бер сөйләшкәндә.

Бу минем өчен һич тә катлаулы мәсьәлә түгел дигән кыяфәт күрсәтеп җавап бирде Йосыф:

— Мин аны көчләмим, котыртмыйм да, мулла абзый, үз иркендә...

Хәсәнә абыстай белән икәүдән-икәү генә сөйләшкәндә дә шундыйрак сүзләр әйтте.

Соңгы чиктә Шакирҗан белән киңәшләшеп карарга булды ата кеше:

— Син, Шакирҗан, Галимҗанга ага кеше ләбаса, энеңнең язмышы бер дә борчымыймыни соң, һаман шул элеккечә гамьсез күркә кебек йөри бирәсең,— диде.

Ата кешенең бу сүзләре Шакирҗанның рухын җимерде. Ул бөтенләй икенче төс алды. Берникадәр усаллык галәмәте күрсәтмәк булды. Чөнки «гамьсез күркә» дигән атама гарьләндерде аны. Шул эчтә кайнаганны әйтми калмады:

— Гомер буе мин сезнең өчен «гамьсез күркә», Галимҗан «пәйгамбәр» булды, әткәй, аны артык иркәләп үзсүзле иттегез, болай ук кирәкмәс иде.

— Соң, балам, чирләшкә булды бит, шуңа күрә күбрәк игътибар аңа бирелгәндер инде.

— Мин әнине кызганам. Галимҗан Казанга китсә, ул нык борчылачак. Әни йөрәгеп тоткалый. Авырта шикелле. Безгә сиздермәскә генә тырыша.

— Әниең өчен үрсәләнүең әйбәт. Минем хакта аз гына булса да уйламыйсызмыни?

— Минем өчен икегез дә бер. Ата-ана бала өчен ике канат. Тапшырыгыз Галимҗан эшен үземә. Мин аны алып калалам. Сез уйлаганча, бер дә «гамьсез күркә» түгелмен.

Бу сүзләрне Шакирҗан бик тыныч кына әйтте. Тик ул тынычлык эчендә көчле давыл бар иде шикелле. Ул давыл җиңү көче булып тоелды. Шакирҗан атасы алдында кинәт кенә янә бер карышка үсеп китте.

* * *

Шакирҗан Галимҗан белән үзе генә сөйләште. Әлбәттә, «синең сәламәтлегең начар», «еракка китәргә ярамый», «уку кайда да бер», кебек үгет-нәсихәт бирә торган сүзләр әйтүдән сак булды ул. Галимҗанның холкын белә. Андый сүзләр аны ярсытып кына җибәрәчәк.

Йосыф мәхдүм шигырьләр яза икән. Үзе өчен генә булса да. Киләчәктә шагыйрь булып китә алырмы, юкмы — анысын бер ходай үзе белә. Ләкин шигырь язган кеше барыбер шагыйрь йөрәкле була. Шагыйрь йөрәклелек адәми затны зыялы, матур күңелле, хис-тойгылы итә. Мондый үзенчәлек Галимҗанда да сизелә. Мандолина уйный. Җырлый. Дөрес, ул боларны беркемгә дә сиздермәскә тырыша. Күрәсең, үзенең әле бик оста уйнамаганлыгын, җырламаганлыгын аңлый. Ул бит җиңеп яшәргә ярата. Кешедән түбән буласы килми. Ул табигать матурлыгына исе китеп, илаһи бер соклану, гаҗәпләнү белән карап тора. Кешеләр язмышы өчен борчыла. Китаплар күп укый. Вакыт-вакыт язарга теләге булуны сиздереп куя.

Быел яз Шакирҗан укыган «Хөсәения» мәдрәсәсенә мөдәррис булып бик зур язучы киләчәге турында хәбәр таралды. Кайчан киләчәген төгәен генә әйтүче юк. Мәгәр бик гыйлемле, зыялы, гали зат, имеш. Ә үзенә егерме яшь чамасы гына икән. «Тәгаллемдә[1] сәгадәт», «Кәләпүшче кыз» әсәрләре, «Бай угылы» романы, «Өч хатын берлән тормыш» драмасы язган, ди. Дәхи дә шулар өстенә тагын «Теләнче кыз» романының беренче кисәген тәмамлаган икән.

Шул хакта сөйләп биргәч, Галимҗанның күзләре шардай булды, йөзе яктырып китте, шул ук вакытта уйчанланды да.

— Кем икән соң ул? — дип сорады бераз тын торгач.

— Гаяз Исхакый, диләр.

Галимҗан Каюм Насыйри, Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэтдин Фәхретдин кебек фикер ияләрен, галимнәрне, укымышлыларны яхшы белә. Каюм Насыйриның 1895 елда нәшер ителгән «Әнмүзәҗ» исемле хезмәтендәге кагыйдәләрне ятлый-ятлый башы диңкеп беткән. Гаяз Исхакый хакында да әллә күпме имеш-мимешләр йөрде. Имеш, аның татар Пушкины булыр чамасы бар. Пушкин сүзе Галимҗан йөрәгенә аеруча якын. Үчитель Сәет авылдагы өчьеллык урыс мәктәбен яхшы тәмамлаганы өчен Пушкин әсәрләре белән бүләкләгән иде бит аны. «Пушкин унтугызынчы гасыр урыс әдәбияты пәйгамбәре, ә син, Галимҗан, егерменче гасыр «пәйгамбәре» бул, — дигән иде. Әнә кем алыштыра икән татарда Пушкинны. Гаяз Исхакый дигән бөек зат. Егерме яшендә әллә күпме әсәрләр язып өлгергән. Галимҗан Пушкинның «Капитан кызы» дигән әсәрен әллә ничә кат укып чыкты. Аның теле дә бик сәнгатьле

[1] Тәгаллем — өйрәнү, белем алу, өйрәтелү.

кебек. Эчтәлеге дә кызык, мавыктыргыч. Анавы Пугачевның язмышын белү генә ни тора. Тик... аңлап бетереп булмый. Әлеге Пушкинны алыштырырдай пәйгамбәр Гаяз Исхакыйның шул «Капитанская дочка» дигән әсәрен татарчага тәрҗемә итүеме, итәчәгеме турында да сүз йөрде. Шәкерт колагы күпне ишетә, шәкерт күзе күпне күрә, шәкерт аягы күп йөри. Дөрес, мондый яңалыклар күбрәк дини китаплар белән генә чикләнмичә, качып-посып барып булса да, кибеттән төрле-төрле әсәрләр сатып алып укыган алдынгы, мәгълүматлы, зиһенле шәкертләр авызыннан чыга. Берсе элеп алса, икенчесе селкеп сала, өченчесе дөньяга тарата; шуннан авыздан чыккан хәбәр канатлы кошка әверелә, шәһәр буйлап очып йөри, тәрәзәләрне, ишекләрне ватып кереп, кешеләрнең колаклары аша күңел сандыгына үрмәли.

— Мин сине үз яныма «Хөсәения» мәдрәсәсенә алырмын, Галимҗан, ул Гаяз Исхакый кебек кеше кулында уку безгә бик күңелле булачак,— диде дә озак-озак Ырымбурга китәргә өндәде энесен.

Галимҗан барыбер тиз генә җавап бирмәде. Чөнки аның Йосыф мәхдүмгә биргән вәгъдәсе бар ич. Шулай итеп, ул ике ут арасында калды.

— Ярый, абый, иртәгә әйтермен: кичке акыл — ярты, иртәнге акыл — бөтен, диләр бит,— диде.

* * *

Озак уйланып ятты Галимҗан. Йокыга таң алдыннан гына китте. Һәм гаҗәп уйландыргыч төш күрде. Имештер, Казан белән Ырымбур арасына Салават күпере тартылган. Галимҗан, яланаяк килеш, шуны үтәргә тиеш. Бәй, читенә килеп басса, атлап китим дисә, Салават күпере Сират күперенә әверелә. Ул кылдан нечкә, кылычтан үткер икән. Шуны белеп, Галимҗан кире чигенә. Әй тотына йөгерергә, хәлләре бетә, күзләреннән утлар чәчрәп чыга. Шуннан ул «куркак» дигән тавыш ишетә. Артына әйләнеп караса, күктә бер фәрештә талпына. Шул кычкырган икән. Ул янә тавыш бирә: «И куркак адәм баласы, сиңа бит бу Сират күперен барыбер бер үтәргә туры киләчәк, яшь, гөнаһсыз чагында тәвәккәлләвең мең өлеш яхшырак булачак»,— ди.

«Куркак» дигән сүз Галимҗанның ачуын китерә, җенен кабарта, үрле-кырлы сикертә. Йөгереп-чабып килә дә ул Сират күперенә менеп тә китә. Чыннан да, кылдан нечкә, кылычтан үткер икән. Ләкин, ни гаҗәп, ул бара да бара, кош җиңеллеге белән бара; кылыч аякны кисми дә, канатмый да. Димәк, аның фәрештә әйткәнчә, бернинди гөнаһы юк әле. Аска караса, гаҗәеп матур күренеш: гөлбакча, җимешлек, кәүсәр күле, хур кызлары... «Син, акыллы зат, оҗмах өстеннән үтәсең», дип кычкыра әлеге фәрештә. «Үткәч, оҗмахта, хур кызлары белән бергә яшәрсең». «Миңа оҗмах та, хур кызлары да кирәкми, минем җирдә яшисем килә», дип кычкыра Галимҗан. Шуннан кинәт кылдан нечкә, кылычтан үткер Сират күпере өзелеп китә, Галимҗан оҗмахка оча. Ләкин оҗмах түгел, тәмуг уты булып чыга бу. Яна. Яна. Яна. Әмма күмергә әйләнми Галимҗан. Әллә нинди утлы чүкечләр белән башын төяләр. Утлы кылычлар белән телгәләп бетерәләр. Шулай да ул җисмәни кыяфәтен югалтмый. Мең, миллион, миллиард еллар гына түгел, мәңге-мәңге шулай булачак, диләр аңа. Бервакыт икенче тавыш ишетелә: «Юк, ул мәңге янмаячак, аны җиргә кире кайтарам, ул әле гөнаһсыз». Бу әлеге фәрештә тавышы икән. Фәрештә аны җәһәннәм төбеннән тыны белән тартып чыгара да үз ягына ала, канатларына утыртып, җиргә китереп куя. Бәй, бусы нәрсә инде моның тагы да: фәрештә әлеге Ырымбурга киләчәк яңа хәлфә Гаяз Исхакый булып чыга. Әмма Ырымбур дигәне Казан каласы икән.

Уянгач, озак кына уйланып ятты Галимҗан. Ырымбурга китәм дисә, янә Казанга барып чыккан. Төштә күргәннең киресен эшләргә кирәклеге аңа мәгълүм инде. Ул, димәк, Ырымбурга китәргә тиеш. Юк, төш кенә

аны җиңмәде. Көндез бер уй давылы эченә кереп чумса, шул төшеңә керми калмый. Төш сине әллә нинди кыяфәтләргә кертә. Монда икенче мәсьәләнең мөгезеннән тотарга кирәктер. Әти, әни, абый, тагын да әллә кемнәр... аның Ырымбурга баруын тели. Шакирҗан абыйсының күз карашлары, өндәге сөйләшүе һич кенә дә дикъкатьсез калдырырлык түгел.

— Ата-ананы рәнҗетеп яшәгән бала бәхетле була алмый, Галимҗан энем,— диде ул әчке бер әрнү белән. Бераз тын торгач, янә дәвам итте:

— Ата-ана фатихасы бала өчен Алла биргән кодрәт белән бер, мәңгелек иман ул синең өчен.

Бу сүзләр нык тетрәндерде Галимҗанның күңелен. Нәгыймә апасы да шулайрак әйтте ләбаса. Димәк, апасы да, абыйсы да кеше язмышы турында зур уйлый. Ә ул, җилне кирегә кистерергә маташып, сырт кабартып йөргән була, зиректән тәртә каера. Алай булмыйдыр ул тормышта.

— Җиндең мине, Шакирҗан абый, рәхмәт, син әйткәнчә булыр,— диде ул иртәнчәк.

Шакирҗан абыйсы аны кочаклап сөеп куйды:

— Үзеңә рәхмәт, Галимҗан, әткәй-әнкәй бик шатланыр инде...

* * *

Шатлык бик зур булды: өйгә, ихатага, авылга, дөньяга сыймаслык. Гыйрфан мулла Шакирҗанга элеккечә кырын күз беләнрәк түгел, миһербанлы караш текәп карый башлады. Галимҗанның Казан ягына караган уй тәртәсен Ырымбур уңаена борырга бик ышанып бетми иде әле ул. Ә менә Шакирҗан һич көтмәгәндә капыл каерып борды да ташлады. Хәзер инде ата кеше әчтән генә, берсенә дә сиздермичә, үз уйлары утында янып, сыкранып йөри. Нигә ул моңа кадәр Галимҗанны гарьше көрсигә күтәргән дә, Шакирҗанны тәпи-тәпи генә йөреткән? Нигә бала аерган? Җисмәни вә рухи көчнең иң илаһилысы Шакирҗандадыр, бәлкем. Ул бит әле үзен авылда гади бер мулла, оста игенче, ат чаптыру өчен җан атып йөрүче дип кенә хис итми, Троицк мәдрәсәсендәге хәлфәлек — мөдәррислек һөнәрен дә даими искә алып, укытучы дип тә исәпли иде. Үз баласының әчке халәтен, рухи дөньясын, йөрәк тибешен аңламаган ата ни эшләп чын хәлфә — мөгаллим була алсын, ди?

— Рәхмәт, улым, бер баладан коткардың, көч бар икән үзеңдә, Аллага шөкер, синнән менә дигән мөдәррис — хәлфә чыгачак, Ходай уң кылса,— дип, Шакирҗанны кысып-кысып сөеп куйды ата кеше.

Аның бөтен уй-хисе — балалар үрчетү, бу фани дөньяда ныклы нәсел тамыры, якты эз калдыру. Ә инде Йосыф шәкерт белән махсус үзе сөйләшергә булды ул.

— Син, Йосыф туган, бу хәлгә авырсынма инде, бик ипле, инсафлы, зыялы икәнлегеңне беләм, майлы чүлмәкнең тышыннан билгеле, дигәндәй, төсең-битең үк балкып тора. Казанда урнашып алгач, хат яз, араны өзмик, яхшы кешеләр белән мөнәсәбәткә керү минем гомерлек хыялым ул,— диде.

— Минем Сезгә рәхмәттән башка тагын да әллә нәрсәләр, әллә күпме изге теләкләр әйтәсем килә, мулла абзый, сүз генә таба алмыйм; яшәү өчен монда бик күп фәһем алдым, Сез искиткеч шәфкатьле, ачык күңелле кешеләр, Аллаһы тәгалә барлык кайгы-хәсрәтләрдән араласын, бала бәхетс күрергә язсын,— дип дога кылды Йосыф мәхдүм.

Пар ат җигеп, Йосыфны Уфага хәтле илтеп куйды Гыйрфан мулла. Бер очтан ул Шакирҗанны да, Галимҗанны да алды. Аны Уфа белән Казан арасында йөри торган пароходка утыртып җибәрделәр. Моннан аңа әллә ни ерак түгел. Бөре, Дүртөйле, Исмаил пристаньнарын үткәч, Аю пристане бар. Әнә шунда төшеп калачак Йосыф мәхдүм. Аюдан аның туган авылы Илеш күз күреме җир генә...

## VIII

Жәй күңелле үтте. Зур мәшәкатьләр белән. Печән чабу. Урак уру. Көлтә бәйләү. Ашлык сугу. Башта боларның һәммәсе менә алмастай текә кыя сыман тоелып тора. Әмма ул кыя игенчене хафага салмый. Җиң сызгана да ул, ныгытма алырга әзерләнгән солдаттай, күкрәген киң киереп ташлана кыяга. Бөтенесен уптым илаһи тозлап-борычлап җиренә җиткергәч, яз, җәй көннәрендә такырайган бура төпләрен көзен янә алтын бөртекләр белән тутыргач, игенче иркен тын алып куя: ул үзен әлеге текә кыя түбәсенә менгәндәй хис итә.

Эш каты була, билгеле. Уңган игенче кояшны басуда каршылый. Эшеннән кояш офык артына күмелгәч кенә туктый. Җәйге төн — бер тотам. Төн уртасы җиткәндә дә әле караңгылык куермый. Кара-зәңгәрсу төстә була ул. Төн таңга авышкан мәлдә генә ниндидер караңгы пәрдә тартыла. Тиздән ул да сыеклана. Караңгы чырайлы кешенең кинәт кенә йөзе яктырып киткән кебек. Ул арада таң әтәчләре сайрарга керешә. Ярсый-ярсый, ярыша-ярыша, ут чыкканда чаң каккандай сөрән салалар: җәй йоклаган — кыш ризык тапмаган, дигән кебек.

Шакирҗан белән Галимҗан да баштанаяк эшкә күмелде. Колач җәеп тирли-тирли печән чабу, ямь-яшел печән исен йөрәккә шифа итеп алу, аннан соң иген исләре белән исерү, басуда кунып ятканда төнге зәңгәр һаваны юрган итеп ябынып иркәләнү, таңның алсу нурларында коену...— боларның барысы да аларны җисмәни һәм рухи яктан ныгытты. Әйтерсең, һәрберсенең тәне-вөҗүде таң төсе, көн йөзе, шәфәкъ балкышы, сихерле төн күзе нурларыннан җыелган гәүһәрләр белән нәкышләнеп чыныкты. Ал-ял белми, таңны эңгер-меңгергә, көнне төнгә ялгап, ярсый-ярсый, вакыт-вакыт кара тиргә батып эшләгәндә, Галимҗан нык ябыкты, коры сөяккә калды. Әмма үрмә гөлгә охшап, буе һаман үсте, артты, калыкты. Бу яктан Шакирҗан абыйсын куып җитә язды. Кыр эшләре саегып, иркен тын алгач, әлеге коры сөяккә ит куна башлады. Беләк мускуллары ныгып, катып китте. Каз йомыркасы зурлыгында ук булмаса да, анда ниндидер бүлтәймә калыкты. Йөзенә төс керде. Карашлары җитдиләнде. Ул үзенең чорына җитди якынлашуын, җир күкрәгенә катыкаты басып йөрердәй гайрәте барлыгын сизде. Китәргә ике көн калгач, Галимҗан Кендекәйгә янә хәер илтеп бирде. Ни гаҗәп, анда Мәдинә-Акчәчкә дә бар иде. Галимҗан аңа карамаска, игътибар итмәскә, үзен кулга алырга тырышты. Шулай да вакыт-вакыт, ара-тирә күз сирпеп алырга да онытмады. Хәерен биреп, Кендек әбисенең фатихасын алгач, тиз генә чыгып китмәкче иде ул. Хәмдия абыстай моңа ирек куямы соң. Мең төрле сорау белән күмеп ташлады. Нигә Ырымбурның Вәли мәдрәсәсеннән качкан? Нигә Казанга барган? Үзе белән килгән шәкерт кем ул? Яхшы заттанмы? Нәселе кем? Ат азгыны тайга ияргән кебек, нигә монда ияреп килгән? Тегесе-монысы, анысы-шунысы, фәлән-фәсмәмәтән... Аларның һәммәсенә җентекләп, җитди, төпле җавап бирү дә кыен. Хәер, Актүти боларның барысын да белә инде. Нигә һаман шул бер балык башын чәйнәргә? Олы кешенең шул инде: ялкытырлык, җилегеңә үткәрерлек, каннарыңны кайнатырлык итеп нотык укый. Кендекәй дә шулай итте:

— Мына син акыллы җегет бит, Галимҗан улым, әйе, хәзер җегет дисәм дә җарый, ай-һай-һай, зрә чибәр булып үсеп киткәнсең, хур кызлары күз атырлык... Әмма ләкин ата-ана җылатып, баш бирмәгән мүкләк кәҗә кебек, әллә кайда шылай пыранлап җөрергә җарыймы соң... Җарамый.. Ананың бер фатихасы — мең бала өчен мең иман. Мыннан кире аслан ана фатихасын бозып җөремә... Ишетсен колагың. Мин сиңә икенче ана. Кендек әбисе икенче ана ул. Фатиха алырга килүең өчен рәхмәт, колынчагым. Ходай Тәгалә авыр юлларыңны җиңел итсен, бетмәс-төкәнмәс зиһен, акыл бирсен, теләгем, берүккенәсе, фәрештәнең

амин дигән чагына туры килсен!.. Сине сагалаган шайтаннарның күзе сукрайсын. Мына шылай...

Актүти сөйләде дә сөйләде, теләк чүмәләсен аның алдына тау-тау өйде, фатихасын дөнья зурлыгында бирде. Тыңлый-тыңлый тәмам арып, Галимҗан чыгып китәргә җыенгач, аңа Мәдинә-Акчәчкәне дә ияртте:

— Бар, кызым, бар, Галимҗан абыеңны озатып куй. Икегез бер көнне тусагыз да, ул сиңә абый була. Бу фани дөнҗага әз генә булса да алданрак килде бит.

Тышка чыккач, алар бер-берсенә карап каттылар да калдылар. Акчәчкә! Әйе, акчәчкә кебек матур ул Мәдинә. Ак йөз. Бит очлары кып-кызыл булып янып тора. Аны киндер күлмәге дә, су кызыныкыдай таралып төшкән чәче дә ямьсезли алмый.

— Акчәчкә!..— диде дә аның кулларыннан алды Галимҗан, озак кына сүзсез торгач.

Мәдинәнең төсе үзгәреп, бөтен тәне эсселе-суыклы булып китте.

— Акчәчкә?!. Нинди акчәчкә, Галимҗан абый?— Мәдинә кулларын тартып алды.

Галимҗан шунда ук үзенең каушавын, шуның аркасында ялгыш эндәшүен аңлады.

— Ни... Мәдинә... Мин... Мин... синең белән сөйләшергә телим... Әйдә... берәр җиргә...

Мәдинәне бу сүзләр тәмам гаҗиз итте. Кызның ак йөзенә ниндидер томан сыекчасы тартылды, бит очларындагы кызыллыкка янә кан йөгерде, алсу иреннәре дерелдәп куйды.

— Җарамый, Галимҗан абый, әллә шыны да белмисеңме: син — мулла малае, мин — җарлы кызы; бодайга кырлыкны кушмыйлар,— диде дә, кырт борылып, курыккан сарык бәрәнедәй тып-тып басып, китеп барды.

Галимҗан, кулындагы тәти кошны ычкындырган кешедәй, аның артыннан үкенеп карап торды.

* * *

Өйгә кайтса, ни гаҗәп, артыннан ук Хөрмәтулла бастырып килеп керде. Мал малга җитә, газраил җанга җитә, ди. Үлем белән көрәшә-көрәшә, әллә ничә мәртәбә җан сорап килгән газраилның үзен дөмбәсли-дөмбәсли, йөрәк казанында кайнаган кара канны тәмам түкереп бетереп, ниһаять, аякка басты ул. Ни-нәрсә ярдәм итте? Җәйнең саф һавасымы? Сандугачлар моңыннан алган рухи илаһилыкмы? Ир-егет гаярьлегеме? Ходай аны алты баласы ятим калмасын өчен курчалаган-саклаганмы?

Бу хакта авыл урамнарында төрле-төрле аяклы хәбәр йөрде. Ул хәбәр кешеләрнең йә ишеген, йә тәрәзәсен алагаем ачып кереп, башта колак яфракларына эленде, аннан ми кузәнәкләре дулкыннарында чайкалды, шуннан авызга күчеп, янә урамга чыгы-чыга, бөтен тирә-якка гайбәт ташкыны булып җәелде. Гайбәтчеләрнең авызы — алаптай казан, тешләре — үткер кылыч, сүзләре — җидееллык шөпшә. Алар башта әнә шул аяклы хәбәрне алаптай авыз казанында кайната, үткер кылыч тешләре белән тураклый, шуннан соң ул сүз шөпшәгә әверелеп, гавам халкына тарала.

Хөрмәтулла көчкә-ялалла аякка басып, кешеләрнең үтеп-сүтеп йөрүләрен күзәтү, өзелеп-өзелеп сагынган киң дөньяны күрү теләге белән беренче мәртәбә үзе кебек кәкшәнләп беткән капка төбендәге ташка чыгып утыргач, әлеге гайбәтчеләрнең тел тегермәне ташы дер-дер әйләнә башлады: «И-и-и... шөйлә аякка басты бу иблис»; «Таштан яралгандыр ул мәлгунь»; «Шайтан затыннанмы әллә үзе»; «Ат карагы ике йөрәкле була»... Шуларга охшаш мең төрле фараз-мараз, ялган-йолган, имеш-

мимеш кара канат какты. Болар — адәм баласын чебеш урынына да күрмәгән таш йөрәклеләр.

Аяклы хәбәрнең икенче төрлесе дә булды: «Илаһым, вакыт җитмәгәч, үлми икән бәндә». «Бетеп-беткән иде бит ул»; «Аллаһы Тәгалә балалары бәхете өчен үз канаты астына алгандыр инде»; «Эчкерсез бит ул, рыясыз»; «Бер гөнаһсыз кешене әрәм иттеләр бит», «Әй, бу нахак бәла тагучылар»... Мондыйлар олы, матур йөрәклеләр. Алар күңелендә иман нуры, Алла кодрәтенә ышану, кешелеклелекнең гүзәл сыйфатлары бар. Шул илаһилык тәэсире шифасы белән коендырылгандыр Хөрмәтулла, бәлки. Шулар тартып алгандыр аны миһербансыз үлем тырнагыннан.

Гәрчә аякка басса да, аның хәле мөшкел иде әле. Эсседә әлсерәгән каз бәпкәсен хәтерләтеп торды. Шулай да акрынлап-акрынлап исәйде, көч җыйды, җәй азакларында урамнан элеккечә каты-каты басып китәргә тырышты. Менә килгән бит әле. Ни өчен? Ни хикмәт? Ни кирәк?

— Әссәламегаләйкем! — диде ул килеп керү белән.

— Вәгаләйкемәссәлам! — диде Гыйрфан мулла.

Шуннан озак кына бер-берсенә карашып тордылар. Бу авыр тынлык һәрберсенең күңелен бозландырды. Бозны мулла абзый эретте:

— Ху-уш, Хөрмәтулла, әйдә, үт әле, утыр, нигә болай чит кеше кебек торасың,— диде ул, нык якын итеп, миһербанлы булырга тырышып.

Хөрмәтулла аягындагы чәчкә аткан чабатасына карап алды: мондый аяк киеме белән сезнең зиннәтле келәмегезгә басарга ярамый, дигәнне аңлатты ул. Киндер күлмәк өстеннән кигән кырык ямаулы бишмәте дә, киндер ыштаны да, башындагы тиргә каткан тишекле-мошыклы киез эшләпәсе дә аны бу җәннәт кебек нур чәчеп торган өй эченең түренә үтүдән тыеп тора кебек.

— Жук, мулла абзый, мин үтәргә килмәдем. Ни... ничек әйтим... мына шылай... шылай булды инде...

Ул уңайсызлана иде. Әйтерсең, бүре алдында калтыранган сарык. Моны мулла абзый да, Хәсәнә абыстай да, Шакирҗан да, Галимҗан да сизде. Әмма Хөрмәтулла һаман әле үзен җәтмәгә эләккән балыктай хис итте. Аны авыр хәлдән Хәсәнә абыстай да коткарырга тырышты:

— Син инде, Хөрмәтулла, алты бала атасы, батыр йөрәкле ир-егет, нигә болай коелып төштең, әйдә, үт әле түргә, үт, үт...

Әнисенең сүзен Шакирҗан куәтләп җибәрде:

— Әйе, Хөрмәтулла абзый, болай килешми бит инде, бала-чага кебек...

Тик Галимҗан гына кысташуга катышмады: олылар алдында килешми. Ә Хөрмәтулла һаман каккан казык урынына тора бирде. Бу минутта ул атасыннан нык кыерсытылган төшенке күңелле мескен балага охшый иде. Әлбәттә, гәрчә тешләрен кыса-кыса, уртларын чәйни-чәйни, адәм рәтенә керергә өметләнеп йөрсә дә, аның хәленең мөшкеллеге күзгә бәрелеп тора. Яңаклар эчкә баткан. Очкын чәчеп торган чая күзләр тонган балыкныкыдай төссезләнеп калган. Ямьсез булса да, аның йөзендә ниндидер мәхәббәтлелек, горурлык, җитдилек чаткылары бар иде. Инде хәзер алар да сүнгән. Гәүдәсе дә бәләкәйләнеп калган. Аны, гүя, башыннан аягына хәтле бу авыр дөньяның кайгы кәфене белән урагннар. Ул әле хәтта менә-менә елап җибәрер кебек кыяфәттә тора. Шулай да элекке горурлыгын барыбер югалтмаган икән. Ул тотлыга-тотлыга, авыр тын ала-ала, көч хәл белән шундый сүзләрне әйтте:

— Сез... мулла абзый... Хәсәнә абыстай... Шакирҗан... Галимҗан... жакшы кешеләр... Тик миңа ылай... кызганып карамагыз... Вәт тәк... Мин гүпчи дә жәлке кеше түгел... Иртәгә завутка китәм... и вчү...

Ул тагын да нидер әйтмәкче булган иде, ләкин теле тибрәнде, сүзе чыкмады. Өй эчен янә авыр тынлык басты. Кешеләр телен тынлык җебе бәйләде. Бераздан ул җепне Гыйрфан мулланың сүз кылычы өзгәләп ташлады:

— Әллә юлга акчаң юкмы, Хөрмәтулла? Булмаса, кыенсынма. Алмак бар, бирмәк бар, дигәндәй...

— Жу-у-ук... Мин аның өчен төгәл... Мулла абзый... Фатихагызны алырга килгән ием... Тәк бит... җулга шылай чыгалар...— ул әлеге кырык ямаулы бишмәте кесәсенә тыгылды, калтыранган куллары белән эзләп алып, аннан бакыр акча чыгарды. Бер аңа, бер быларга карап, үтә нык кыенсынып, аны Гыйрфан муллага сузды:

— Хәер китергән идем... мулла абзый... Аз булса да... кабул итеп алчы... Җулга шынсыз чыгарга җарамый... Догада булсагыз икән...

Гыйрфан мулла аны бик кыенсынып алды. Син бит балаларыңның соңгы тиенен алып килгәнсең, нигә болай кыланасың, фатиханы ансыз да бирә алам ич, дияр иде — ярамый. Хәерне кире кагып булмый. Дога кылырга кирәк. Хөрмәтулла, күпме генә кыстасалар да, түргә үтмәде. Шуңа күрә мулла абзый уң яктагы кәнәфи янына ике урындык китереп куйды. Алар икесе шунда парлап утырдылар. Барысы да дога кылды. Гәрчә укый белмәсә дә, Хөрмәтулла үзе дә, килештерергә тырышып, ике кулы бармакларын бер-берсенә якын китереп, өчпочмак шәкеле ясап, укыгандай итеп утырды да, башкалар белән беррәттән, битен сыйпап куйды. Шуның белән эш бетте, фатиха бирелде, инде ак юл, бәхет телисе генә калды шикелле. Мулла абзый китмәскә, берникадәр сабыр итәргә, ныклап сәламәтләнергә кирәклекне әйтергә дә уйлаган иде, ләкин аның буш үгет-нәсихәт, коры вәгазь булачагын аңлады. Хөрмәтулланың холкын белә ул: бер дә юкка борчак чәчкәнне яратмый. Тик шуны гына әйтә алды:

— Иртәгә дүшәмбе, бу көнне сәфәр чыккан кешенең юлы уңмый калмый, без дә Ырымбурга китәргә дәртләнеп торабыз, Алла боерса,— диде.— Әле көннәр дә бик һәйбәт тора. Бозылып киткәнче, ашыгырга туры килер. Бәгъзе бер елда көзге көннең күге елак бала белән бер була — яше чыга да тора.

— Җарар... Мулла абзый... Хәсәнә абыстай... фатихагыз өчен рәхмәт... Җул кешесенең җулда булуы хәерле... шылай диләр бит... Китием инде...— ул урыныннан калкынды.

— Сабыр ит әле, Хөрмәтулла, сабыр төбе сары алтын, диләр бит, алтын үк булмаса да, сиңа бирәсе әйберем бар иде.— Мулла абзый эчке бүлмәгә кереп китте дә бераздан бер төенчек алып чыгып, аны Хөрмәтулла кулына тоттырды. Хөрмәтулла бер төенчеккә, бер Гыйрфан муллага карап, ни дияргә белми, аптырап тик торды.

— Ни... ни... нәмәкәй соң бу, мулла абзый?

— Аз булса да акча...

— Кирәкми... Мин хәер эстәүчеме...

— Исәрләнмә. Биргәннең битенә төкермиләр. Алмасаң — үпкәлим.

— Мулла абзый...

— Йә, йә, котырынма...

— Алайса... бу... мин аны түләрмен... Шахтыга китермен мужыт... Анда зарпулатыны шәп диләр...— ул урыныннан кузгалды. Баядан бирле тын торган Хәсәнә абыстай телгә килде:

— Хөрмәтулла, утыр әле, утыр, мулла абзыең әйтмешли, сабыр ит, хәзер чәй эчәрбез.

— Рәхмәт, абыстай!.. Сездән күргән җакшылыкны мәңге онытачагым жук... Вәт тәк... и вчү... Теге шәкерт белән Галимҗан бездә булдылар бит... Санга санап килүләрен әйт... Мына шындай кешеләр күп булсын иде дөнҗада... Сезнең күбек... Җарай... Китим инде...

— Чәй...

— Җук, җук, абыстай, оялмыенча...

Күпме генә кыстамасыннар, Хөрмәтулланы чәйгә калдыра алмадылар. Мулла абзый, Хәсәнә абыстай аны озата чыкты. Ишек алдында котәргә кушып, икесе дә чоланга кереп киттеләр.

Хөрмәтулла ихатадагы күркә, тавык, үрдәкләрнең көзге кояшлы көнгә сокланып, ләззәтләнеп, рәхәтләнеп горур гына йөрүләренә аптырап

карап торды. Бер күркә кабарынып, гол-гол-гол итеп куйды. Үрдәкләр, башларын югары күтәреп, бак-бак-бак дип бакылдарга тотындылар. Аларның тавышы «тап-тап-тап» дигән кебек. Димәк, ашарга таптыралар. Ачыкканнар. Түшен алагаем киереп, байларның самавыры дәүмәллеге бер әтәч йөри. Аһ, аның горурлыгы. Капралмыни! Иркә, сылу, назлы тавыклар аның тирәсендә кыланчыкланып бөтереләләр.

Менә тегеләр дә чыкты. Хәсәнә абыстайның кулында ниндидер бәләкәй капчык. Ул бүртеп тора. Эчендә нидер бар шикелле. Мулла абзый сул беләгенә бишмәт салган. Икесе дә килеп туктагач, сүзне Хәсәнә абыстай башлады:

— Менә монавында азырак ярма бар иде, ал әле шуны, Хөрмәтулла, бер генә дә авырсынма, ал, ал, ал...

— Абыстай... инде былай да... акча...

— Йә, йә, күп сөйләнмә, синнән аз файда күрмәдек, ул печән чабуларың, ул урак уруларың, ул абзар төзәтүләрең; кулың алтын бит синең...

Хөрмәтулла алмаска тырышып караса да, Хәсәнә абыстай чарага куймады:

— Аз гына тары ярмасы, балаларга ботка пешереп ашатырсыз, сиңа түгел, аларга бирәм, алмый чараң юк,— диде дә кулына тоттырды.

Абыстай әйткәнчә, ул һич тә аз түгел иде. Ярты пот чамасы булыр. Шуны сизде Хөрмәтулланың кулы.

Алар үзара килешкәч, Гыйрфан мулла аңа әлеге сул беләгендәге әйберне бирде:

— Бу — минем бишмәтем, Хөрмәтулла; иштә, сиңа таман булыр, үзеңнеке бик тузган бит; син төсеңне бозма әле, кыенсынма да; кайткач, киеп карарсың...

Моның өчен Хөрмәтулла авыз тутырып рәхмәт әйтергә тиеш иде. Ләкин әйтә алмады. Күңеле тулды шикелле. Әмма мулла абзый белән абыстайга тел рәхмәте кирәкми инде. Йөрәге белән әйткәнлеген алар икесе дә аңлады.

Хөрмәтулланы капкага хәтле озата бардылар. Бәләкәй капкадан чыгарып җибәргәч, алар икесе дә тын калды. Чөнки Хөрмәтулланың атлап китмәве, олы капкага килеп сөялүе сизелде. Алар шунда колак салырга мәҗбүр булды. Ә Хөрмәтулланың мышык-мышык елаганы ишетелде. Ни өчен? Рәнҗетмәделәр ләбаса. Авыр сүз дә әйтмәделәр. Бу елау шатлыктан иде. Вакыт-вакыт шатлык та, кайгы да күздән яшь китерә. Кайгы яше — ачы, шатлык яше төче була. Шатлык яше гәүһәр төсле җемелди. Хөрмәтулла Гыйрфан мулланың капка төбендә гәүһәр яшь калдырып китте. Ул гәүһәрдә — ярлы-ябагайның йөрәк җылысы, күңел кайнарлыгы, бәхет өмет итү чаткысы. Ул гәүһәр җанлы, тере, мөкатдәс. Анда — кеше йөрәге. Кешелеклелек. Мәрхәмәтлелек. Шәфкатьлелек!

## IX

Кояш аязга баеды. Аннан офыкта озак кына кан-кызыл ут балкып торды. Тора-бара ул ут яңа төсләр белән алышынды: шәмәхә-кызыл, алсу-кызыл, күксел-кызыл, караукучкыл-кызыл... Янә бераздан төсләр буталышып, бер-берсенең эченә керешкәч, нәрсә хакындадыр серләштеләр-серләштеләр дә, озак кына кул кысышып торып, төрлесе төрле тарафка таралышты. Шулардан җанлы әйберләргә охшаш әллә нинди шөкелләр оеша-ясала башлады. Бересе аюга охшап тора, икенчесе — әтәчкә, өченчесе — кәҗәгә, дүртенчесе... дүртенчесе...— Тулпарга. Нәкъ аларның Тулпары лабаса бу. Их, атланып алып, көмеш ялларына тотынып, менә хәзер үк Ырымбурга җилдерәсе иде. «Ә» дигәнче барып җитәрләр иде. Бишенчесе... бишенчесе... тукта-тукта... Хас та теге экиятләрдә сөйләнелгән су кызы. Чәчен тарап утыра. Тукта, тукта, Мәдинә-Акчәчкәгә дә охшый түгелме соң бу? Әйе, әйе шул. Шул үзе...

Әнә кайда менеп утырган табигать баласы. Айдагы Зөһрә кыз кебек. Күк белән җир йөрәгенең кешегә күренмәс сихри ефәк җепләр, нурлар белән тоташуы шушымы? Җирдәге тереклек, матурлык, яшәеш сурәтләрен күктә рәсем итеп, Ходай Тәгалә адәм балаларына яңа сыйфатта күрсәтәме? Мәңгелек дөньяда яшәүнең бер манзарасы-күренешеме бу?

Галимҗан аларга исләре китеп карап торды. Менә шушы бәләкәй генә дөньядан — аларның ихатасыннан күпме галәм уч төбендәгедәй күренеп тора. Их, әлеге күктәге Зөһрәне көн дә чишмәдә юынырга, җир битен үбәргә алып төшә торган Тулпарга атланып, ай, йолдызлар илен гизеп кайтасы иде. Мондый хис-тойгы, тирән кичереш, йөрәк ярсуы анда еш була башлады. Бигрәк тә менә шушындый сихри кичләрдә, айлы төннәрдә, алсу таңнарда, моңсу иртәләрдә...

Ата кеше ихатада анысын алай, монысын болай, тегесен тегеләй итеп йөрде. Иртә таңнан сәфәргә чыгу өчен арбаны, камыт-дуганы, атларны — һәммәсен, һәммәсен янә бер мәртәбә караштырып чыкты: өйдә ныгынып чыкмасаң, юлда тиз бушанырсың, диләр бит. Юл азабы — гүр газабы, дигәне дә бар. Кояш, Ходайга шөкер, аязга баеды: иртәгә көн, Алла боерса, яхшы булачак. Пар ат белән җилдерәчәкләр генә. Гүр газабы күрергә насыйп булмасын.

Ата кеше берара авызы белән кош тотарга чамалаган кешедәй күккә карап каткан улына эндәште:

— Галимҗан улым! Кереп ял итәр идең. Иртәгә иртүк юлга бит.

— Хәзер, әткәй, әнә теге Тулпарга аз гына карап торам да...

— Беләм инде, улым, беләм, табигатьнең күзенә керәсең килә.

— Ырымбурда болар юк бит.

— Анда да бар ул, улым, карамыйсыз гынадыр. Табигать йөрәге матур кешеләргә генә ачыла.

Галимҗан әнисен генә матур фикерле, сүз тәмен нык белүче, ихлас күңелле дип уйлый иде. Әтисе дә, гәрчә кырыс холыклырак булса да, күңелендә әллә күпме асылташ саклый икән. Йосыф мәхдүм алдында ул асылташларын аеруча нык балкытты. Әллә нинди риваятьләр, әкиятләр, хәдисләр сөйләп, үзен чын мөдәррис-мөгаллим итеп күрсәтте. Уфада аерылышканда Йосыф мәхдүм бу хакта Галимҗанга дулкынланып әйтте хәтта:

— Минем әти дә зыялы, белемле, итагатьле мулла, ләкин дә синең әтиең кебек бөтен эч серен ачып салмый, безнең белән иркенләп-ачылып сөйләшеп утырмый, риваятьләр дә сөйләми; синең әтиең дә, әниең дә телгә бай, телгә бай кеше фикергә бай була; аларның бу уңай сыйфаты сиңа күчми калмас, Галимҗан, аларны күп тыңла,— диде.

Моны Галимҗан үзе дә сизә. Әтисе дә, әнисе дә вакыт-вакыт бик кыйммәтле, мәгънәле, зур сүзләр әйтеп куя. Әле дә менә ни диде әтисе: «Табигать йөрәге матур кешеләргә генә ачыла»,— диде. Моны бит кайдадыр язып куярлык. Иң яхшысы — күңел дәфтәренә язу. Аннан аны берәү дә күчереп ала алмый. Ул ертылмый да. Аны көчле давыллар да очырып китә алмый. Ә үзе кем соң ул? Матур йөрәклеме? Табигать аңа берәр мәл ачылырмы? Ачылыр, ачылыр, ачылыр. Ул адәм балалары кебек. Кешене сөйсәң генә сине сөяләр. Табигатьне яратсаң гына ул сине ярата. Кешене тукмасаң, ул сине тукмый. Табигатькә йодрык күрсәтсәң, ул синең башыңа утлы чукмар белән тондыра.

Шундый уй-хис давылы эчендә кайнашып керде Галимҗан өй эченә. Билгеле инде: әнисе юлга ризык-күчтәнәч әзерли. Ул шат. Йөгерә-атлый йөри. Мич алдында озак шөгыльләнүдән бит очлары кып-кызыл булып янып тора. Ул, гүя, тагы да әллә күпме яшькә яшәреп киткән. Гаҗәп матур, нәфис, сөйкемле күренә ул. Әгәр менә хәзер ихатага чыкса, рәсеме әлеге теге су кызы янына күчерелер иде. Аның әнисе шул су кызыннан да матуррак булып күренер иде әле.

Шакирҗан абыйсы да үз шөгыле белән мәшгуль. Җыештыра. Бәйли. Төенчекләр ясый.

— Галимжан, син әллә кайда йөрисең, әйберләреңне караштырмыйсың,— диярга дә онытмады ул.

Галимжан шаяртыбрак сөйләште:

— Мин, Шакиржан абый, күктәге матур сурәтләрне күрдем. Менә шуларны тутырып бәйләргә иде синең төенчегеңә.

— Нәрсәләр бар соң анда?

— Барысы да... Табигать балалары да...

— Син хыяллана башладың соңгы вакытта.

— Мине табигать хыяллайдыра.

Зур язучы булу өчен кешеләрне сөяргә, аларның кайгысын да, шатлыгын да үз йөрәгеңә алырга, табигатьнең иркә баласы гына түгел, зур көрәшчесе булырга кирәклекне әле кайдан белсен ди ул. Әмма ләкин аның чаткылары күңеленә, йөрәгенә һаман салына бара. Ул чаткылар әтисе белән пычкы тарткандагы хезмәт моңыннан, гәрчә әле бигүк урынлы булмаса да, Вәли мулла белән чәкәләшүдән, Хөрмәтулла кебек рәнҗетелгән язмышлардан киләдер. Шул очкыннар ялкынга әйләнәчәк бит бервакыт.

## X

Ястүдән соң, башка көннәрдәгечә, юк эшне бар итеп дигәндәй, китап-мазар укып фикерләшмәделәр: сәфәр алды төне тыныч йокы, күтәренке күңел, сәламәт кәеф таләп итте. Юл низамтәртип ярата. Башкалар, бер-берсенә тәмле йокы теләшеп, рәхәтләнеп ятып йокладылар. Тик Хәсәнә абыстай гына ашыкмады. Иртәнгә тәбикмәк изеп куйды, юлга ит кыздырды, сумса, бәлеш пешерергә булды. Ул өйдә каласы кеше. Болар киткәч, күзе бик йомылып мазасызлый, йөрәге ойый башласа, баш терәп алырга мендәрне сатып аласы юк.

Ләкин алсу таңга чаклы йокларга насыйп булмады. Икенче әтәчтән соң, кыямәт көнендә купкан гауга, тавыш-низагка охшап, бөтен авыл гөж килә башлады. Ямьсез итеп, котырынып, ниндидер фаҗига барлыкны искәртеп, чаң кактылар:

— Чоң-чоң-чоң...

Аннан «янгын», «янгын», «янгын», «янабыз», «җәмәгать», «су», «су», «су», «тизрәк», «тизрәк», «тизрәк», «харап булабыз», «бетәбез», кебек ачы тавышлар яңгырады. Махсус кешеләр, халык уянсын өчен, капкаларга күсәкләр белән сугып йөрде. Бер үк вакытта әлеге «янгын», «янгын», «янгын» дигән сүзләрне дә кабатладылар.

Хәсәнә абыстай һаман ятмаган иде әле. Хәер, бу хакта ул уйламады да. Чөнки сәфәрчеләр торганчы тәбикмәкне пешерә башларга кирәк. Бу тавыш, гауганы ул ишетмәскә тырышты. Йоклаучыларның да тынгысызланмавын теләгән иде. Шулай да теләге фәрештәнең «амин» дигән чагына туры килмәде. Иң әүвәл ата кеше сикереп торды. Ул җәһәт киенеп, Шакиржанны, Галимжанны уятты. Алар да күз ачып йомган арада аякка басты. Мондый чакта мәгълүм инде: һәркем бер сулы чиләк алып йөгерергә тиеш. Болар да шуны эшләде.

Капкадан чыгу белән алар — ата кеше, Шакиржан, Галимжан ут чыккан якка йөгерде. Аларга башкалар да кушылды. Дөрләп янган ут күренә. Ә менә кемнеке икәнлеге билгесез. Аларга каршы атка атланган берәү чабып килә иде. Үзе чаба, үзе кычкыра: «янгын», «янгын», «янгын», «тиз булыгыз», «Мөбахис мәзин яна», «Мөбахис мәзин яна!»

Ара шактый ерак иде. Шулай да берәү дә ыңгырашмады, соңгы көчен җыеп, чиләктәге суын түкмичә, йөгерде дә йөгерде.

Алар барып җиткәндә, Мөбахис мәзиннең йорты яртылаш янган иде инде. Ул шундый коточкыч яна, тәмуг уты да бу кадәр булмас. Кешеләр кырмыска урынына кайнаша. Берәүләр су сибә, икенчеләр көрәк белән җир казып ыргыта, өченчеләр, ут читкә китмәсен өчен, озын саплы тимер

ыргак белән янган бүрәнәләрне, такталарны җиргә тартып төшерә. Су менә кайчан күп кирәк. Авыргазы, Түрсәгәде елгалары, Кондызлы күл дә ерак. Кое дигәне урамга берәү генә. Ярый әле иҗтиһадлы Солтанморат халкы үзләре мең бәла белән ясаган имән торбалар аша авылга су китерде. Ләкин көчле янгын вакытында аның суы да шул ташка үлчим кебек кенә икән. Чиләк белән сипкән суны ялкын ялмап алып кына тора. Ул ялкын, әйтерсең, суга сусаган мең башлы дию пәрие теле. Суны аны үлемнән коткару өчен алып киләләр. Шуңа шатланып, рәхәтләнеп, ләззәтләнеп эчеп тик тора ул.

Суны Мөбахис мәзиннең ике ягындагы өйгә дә сибәләр. Чөнки әлеге ялкын теле аларны да ялмап-ялпап ала. Ялкын аларга күчсә, бөтен авылның харап булуы бар. Ходайга шөкер, ул куркыныч булмады. Утырды да янды Мөбахис мәзин дөньясы.

Янгын сүнгәч тә халык җәһәт кенә таралышмады. Мондый вакытта төпченү, сәбәп эзләү, фараз итүләр башлана: кайдан чыккан ялкын, ни өчен, кем гаепле?..

Гыйрфан мулланың имеш-мимеш, фараз-мараз, гаеп-мәеп тыңларга вакыты юк иде. Аның сәфәр чыгасы бар. Шуңа күрә Шакирҗанны, Галимҗанны ияртеп кайтып китте.

* * *

Шатлыкны — кайгы, кайгыны шатлык алыштыра. Авылда янгын булу — фаҗига, күңелсезлек, кара кайгы ул. Утырды да янды Мөбахис мәзин дөньясы. Аның ялкыны бөтен авылны балкытып торды. Шул ялкын-балкышка иш-куш булыйм дигәндәй, кояш та уттай янып-кызарып чыкты. Төне буе мич алдында мәш килгән Хәсәнә абыстайның бит очлары да шул иртәнге кояш кызыллыгы төсле янып тора иде. Аллага шөкер, ул үз вазифасын җиренә җиткереп башкарды: юлга бөтен ризык-нигъмәт әзер — тамакларына аш булсын! Ходай Тәгалә тәннәренә-җаннарына сихәт бирсен. Тик әлеге шатлык белән кайгы аралашуы гына күңелгә көл сипте. Юньләп йоклый да алмадылар. Ничек чыга алалар инде алар шул килеш ерак юлга?

— Сиңа әйтәм, муллакаем, әйкәем, әллә сабыр итәсезме, бүгенгә ял итеп аласызмы, иртәгә чыгар идегез юлга, Ходай биргән көннең барысы да бер лә инде ул,— дип карады.

— Юк, юк, остабикә, һич кенә дә бер түгел, юл башы өчен дүшәмбе көн әйбәт, сишәмбе көн юлга чыгып беркайчан да уңганым булмады; кем әйтмешли, йокы песигә генә моң, үлмәбез әле; күрмисеңмени, көне нинди матур, җәй уртасы диярсең; әйтерсең, Ходай үзе безгә шундыйны бүләк итеп бирде,— дип, тәртәсен үз ягына таба каерды ата кеше. «Бүгенге эшне иртәгә калдырма»; «Тәвәккәл таш яра»; «Уйлаганнан кире кайту — кирәгеңне югалту» дигән мәкаль-әйтемнәрне дә искә алды ул. Үзен болай бик иркен, шат, шаян тотарга тырышты. Юлга чыкканда балтасы суга төшкән кешедәй йөрүне, борын салындыруны, ык-мык килүне гомумән яратмый ул. Юл күтәренке күңеллелекне, хозурлылыкны, егетлелекне ярата. Бу — бер. Икенчедән, өйдә калачак хәләл җефетенең дә матур дога кылып, зур фатиха биреп, хәер-хаһта торуын тели ул; Шакирҗан белән Галимҗан да юлга чыкканда ачык йөзле, күтәренеке күңелле, дәрт-дәрманлы булсыннар.

— Ай-һай ла, көне дә көне, кояшын күр, ничек нур чәчеп килеп чыкты ул, нәкъ пәйгамбәрләр туган таң инде менә,— дип, бергәләшеп ат җиккәндә дәртләнеп, егетләргә җиңеллек күрсәтеп сөйләнеп йөрде.

...1900 ел. Унтугызынчы гасырның кояшы баеды.

Егерменче гасыр кояшы... Нинди кояш булыр ул? Җиһанга нинди нур чәчәр? Ул нурда адәм балалары мәңге-мәңге, гомер-бакый таңнарга, кояшка, айга, йолдызларга карап, тирән сәҗдәгә китеп теләгән бәхет булырмы? Нурлардан бу мәшәкатьле хәяткә, авыр тормышка, кара

көннәргә яктылык сирпелерме? Аның уллары Шакирҗан илә Галимҗан ничек каршылар бу яңа гасырны? Уйлыйлармы бу хакта? Баш ваталармы? Әллә ике ятып бер төшләренә дә кермиме? Бала күңеле — серле урман, ди бит. Эчкерсез кебек тоелсалар да, сиңа иң кирәк булганын әйтеп салмый алар.

Ат җиккәндә дә, утырышып чыгып киткәндә дә, капка төбендә Хәсәнә абыстай яулык очы белән күз яшен сөртеп алганда да шул уйларыннан аерыла алмады ата кеше.

Менә тагы?.. Ни хикмәт?.. Кендек әби нигә чәчәрдәй булып килә?.. Бер-бер күңелсез хәл бармы?.. Инде пар атка тулы куәт биреп, чаптырып китәм дип торганда...

— Тр-р-р... тр-р-р... Малкайлар! — Ярсып торган атларны көч-хәл белән туктатты мулла абзый. Алар бер-берсенә карашып калдылар. Кендек әбинең тыны тәмам куырылган, кобарасы очып, төсе киткән, хәтта сүзен дә әйтә алмый тора.

Мулла абзый түземсезләнеп сорады:

— Ни булды, Хәмдия абыстай, нигә бизгәк тоткан кеше кебек калтыранасың?

Хәмдия абыстай, юлга чыккан кешеләрне хафага салмыйм дип, курку вә калтырану сәбәбен яшерергә тырышты:

— Юк, юк, берни дә булмады, сезне озатып калыйм дип ашыктым, мына шылай йөгерә-атлый килеп, тәмам тончыктым; Аллаһу Тәгалә сезгә олы фатихасында булып, фәрештәләр барыр җулыгызга ак җәймә җәйсен. Амин!

— Фатихаң өчен рәхмәт, Хәмдия абыстай! Әйе, изге сәфәргә чыктык, Аллага шөкер! Рәхмәтле доганда бул! Әмма ләкин нидер яшерәсең. Бу хакта йөзең, күзең, бөтен кыяфәтең сөйләп тора. Әйт: нинди күңелсез хәл булды? Мин юлга синең кайгылы йөзең күләгәсен алып китә алмыйм.

— Әй, һәй, Гыйрфан мулла, мәгәр үткер күзле, зирәк акыллы, сизгер җанлысың да инде; мәйтәм, җул кешесен борчымыйм, Хәсәнә белән генә мәслихәтләшием дигән ием, былай булгач, җәшерә алмыйм инде, жук, жук, жук...

— Сөйлә, Хәмдия абыстай!...

— Хөрмәтулланы тагын да эт урынына тукмап, теге ни... Нәҗметдин мәзин келәтенә ябып куйдылар бит.

— Ни өчен?

— Мөбахис мәзин йортына утны ул төрткән, җәнәсе дә...

— Кем күргән?

— И... һәй, кем күрсен... Кичә, сездән чыккач, шылар йорты җаныннан үтеп киткән. Китсә соң. Адәм баласы җөрмиенче торамы? Теге ни... аның күршесе имансыз җан Хәмәтдин әләкләгән Мөбахис мәзингә: ни дигән, синең дөнҗаңа Хәрти ут төртте, дигән; Ходай шаһит, үз күзләрем белән күрдем, дигән; тотып алырга уйлаган идем, качты мәлгунь, дигән. Шышы хәбәре өчен Мөбахис мәзин аңа бер әчмуха чәй, бер кадак шикәр, ярты пот он вәгъдә иткән. Судта да шыларның тамчысын да калдырмыенча ярып салырсың, дигән Мөбахис мәзин шыл Хәмәтдин хәсискә. И... и... и... җөрәгем җыртыла җазды, җөрәгем. Алар бу җалган җала сазына сине дә батырмакчылар икән...

— Мине?!. Ни өчен?!.

— Кичә Хөрмәтулла сездә булдымы?

— Булды. Моның ни гаебе бар?

— Имештер, Хөрмәтулланы Мөбахис мәзин җортына ут төртергә син котырткансың. Бу ачу теге вакытта сарык өчен мир җыенында Хөрмәтулланы яклаудан ук килә икән. Уф, Алла!.. Ни әйтием...Ниләр генә эшлием... Хөрмәтулла бу авырлыкны күтәрә алмас инде... Күп торса... ике көн торыр...

Бу сүзләрне ишеткәч, барысының да йөрәге шартлар дәрәҗәгә җитте. Дилбегәне Гыйрфан мулла үзе тоткан иде. Ул әле һаман Шакирҗанга да,

Галимҗанга да ышанып бетми: арбага җигелгән пар атны уйнатып кына алып бару җиңел шөгыль түгел. Авыл урамнарын үткәндә яшен уты урынына томырылырга кирәк. Җебегән борын, коры куык, чепи күзләләр шаккатып, исе-акылы китеп, бөгелеп-сыгылып карап калсыннар. Тик... шайтан юлга тагын да киртә тотты. Тфү!.. Хәмдия абыстайның ялварулы карашы барын да аңлатып тора: ул ярдәм сорый.

Гыйрфан мулла артына борылып карады. Галимҗанның күзләре маңгаена менеп, калын иреннәре көзге яфрактай дерелдәп тора. Менә хәзер аның, теге вакыттагыча, арбадан төшеп йөгерүе, Хөрмәтулланы коткару чарасына ташлануы мөмкин. Булдыра аламы-юкмы — ул әле аны уйлап бетерми, куркыныч давылына ташланырга гына тора. Шакирҗанның да кобарасы очкан. Дөрес, ул сабыр табигатьле. Түземле. Юккабарга пыр-пыр, мыр-мыр килеп, шайтан алыштырган нәмәстәкәй шикелле кыланмый. Шулай да барыбер аның йөзенә дә аптырау-гаҗәпләнү, кайгыру-хәсрәтләнү күләгәсе тартылган.

Гыйрфан мулла үзен ике ут арасында калган кешедәй хис итте. Менә хәзер чаптырып китеп барыргамы? Ихатага кире кереп, атларны тугарып ташларга да Хөрмәтулланы үлем базыннан өстерәп чыгару чарасын күрергәме? Монысын да эшләргә мөмкин. Ләкин көч җитәрме?

Барысын да Хәмдия абыстай хәл итте:

— И... Әйтәсем калмаган. Нигә мына шылай җулга чыккан кешене җаман хәбәр белән албыратам инде. Җүнсез мин. Акылсыз. Беркатлы...

Барысы да, авызларына су капкандай, беразга тынып калдылар. Тынлыкны Кендекәй бүлде:

— Җә... мына шылай... аңгыра тавыктай... миңгерәп тормыйк әле... Мин Хәсәнә җаным җанына керәм, ә сез җулыгызда булыгыз...

Гыйрфан мулла җан ачуы белән дилбегәсен тартты. Атлар хуҗа ачуын чыбыркыдан да ныграк-катырак тоеп, пыр туздырып чабып киттеләр. Алар артыннан чаң-тузан болыты күтәрелеп калды.

*Ахыры бар.*



## Флера Гыйззәтуллина

### Яратуым өчен

Озата барам гомер кояшымны,
Күп калмаган инде баерга...
Гашыйкларны таңнар кавыштыра,
Кояш баешлары аера.

Тәрәзәңә төн пәрдәсен япса —
«Кояш чыкмас!» — диеп көрсенмә.
Төсем булып ак челтәрем кала
Тәрәзәләремнең берсендә.

Озата барам гомер кояшымны,
Таң нурына манып канатым.
Бу тормышны шундый яраттым мин,
Яратуым өчен җан аттым.

Озата барам гомер кояшымны,
Ераклаша барам үземнән...
Атылырга җитеп йөрәк кага,
Яшьләр тама — кояш күзеннән.

### Тау өстендә таулар...

Таулар мендем, карурманга кердем:
Ил сәламен зурлап тапшырдым.
Тау өстендә таулар!
Ә йөрәктә
Моң дәрьясы — килер гасырның.

Тау юллары карурманга илтә,
Мәхәббәтем илтә кояшка.
Урман шавы, тирән сөю назы
Урап алган безне, тугач та.

Милләтемнең шунда җан сафлыгы
Яшел яфрак булып сарылган.
Гасырларны тоташтырып торган
Йөрәк сере бит ул карурман.

Карурманнар кичтем, таулар төштем,
Иелеп сулар эчтем чишмәдән.
Чишмә дәрте, халкым мәхәббәте
Саркып тора сагыну-хисләрдән.

## Иелгән таллар талчыга

Иелә дә бөгелә таллар
Замана авыр суласа...
Дөнья канатлы куласа:
Атомнар белән сынаша.

Башларым әйләнеп китә
Башымны исәм — минем дә!
Җир шары әйләнә бары
Аналар исәнлегендә.

Иелә дә бөгелә таллар
Тамырын яшен сукмаса...
Милләтен бәхилләгән ил —
Гөл бакчасына тоташа.

Иелгән таллар талчыга:
Ярсыма, дөнья, ярсыма!
Хәсрәтең йөрәккә суга,
Кояшлы канатлар сына!

* * *

Икебез дә бергә бүген, бергә бүген,
Икебез дә чайкалабыз көймәдә!
Чал дулкынга күзләреңне төбәмә син,
Давылларга серләреңне сөйләмә.

Язмышның утын-давылын
Сугарып йөзә көймә.
Сикереп суларга төшкәндә
Утларга пешмәм димә...

Икебез дә бергә бүген, бергә бүген
Мәхәббәтнең хис-дәрьясын кичәбез.
Ишкәкләрне дулкынга каршы ишәбез,
Йөрәк янса, сикереп суга төшәбез.

Язмышның утын-давылын
Сугарып йөзә көймә.
Сикереп суларга төшкәндә
Утларга пешмәм димә.

Икебез дә бергә бүген, бергә бүген
Давыл куба, уйлар уба тирәнгә.
Мәхәббәтне су төбенә җибәрмә син,
Ятны сөеп мине читкә тибәрмә!

## Кояш чыгып күкләр яктырылса...

Бу җырымны горур лачын иргә,
Кыяларга атап чыгардым.
Кыя ярын кысып кочакларга
Дулкыннары кайта суларның.

Дулкын белән дулкын көрәшкәндә
Лачын йөзен күрә үзенең...
Коллыкка баш бирмәс ир-егетнең
Кыялардан эзлим түземен.

Бу җырымны көчле күкрәүләргә,
Яшеннәргә тагын җырлармын...
Ут чәчрәтеп, күк күкрәтеп килә
Авырлыгы быел елларның.

Яшен белән яшен көрәшкәндә
Ил дошманын таный үзенең...
Коллыкка баш бирмәс батырларның
Яшеннәрдән эзлим түземен.

Бу җырларым назлы ярсу булып
Килер язларыма сарылсын.
Изге ватандашым! Җан дәвасын
Язгы күкрәүләрдән табарсың!

* * *

Иманыбыз ныклы, камил чакта
Эштән баш калкытсак тын алмага...
— Раббем, рәхмәтеңнән ташлама! — дип
Гел ялвара килдек бер аллага.

Хәзер исә баттык гөнаһка без,
Әйтерсең лә йөрәк таштан койган!
Сак-Сок булып үкси,
Иваннардан
Карурманга кереп качкан иман.

Әйе, безнең алла тарафында
Үкенечле югалтулар байтак!
Юл ярабыз кабат иманга без,
Кара төннәр, карурманнар айкап.

Карурманда безне елан чага,
Яшьлегебез ага ярсу бозда.
Кылыч аша үткән чал гасырлар
Тәсбих тартып чыга каршыбызга...

## Яратыр идем мин сине

...Сине очратканга кадәр
Күңелем — агымсуда иде.
Язмыш мине ярдан-ярга
Кага иде, суга иде...

Ниһаять, мин күз төшердем
Син ачкан язмыш фалына.
Һәм күчендем синең янга,
Тәүге мәхәббәт салына.

...Ут булдымы сөюеңнең
Салга төяп китергәне?
Дөрләп яна дулкыннарның
Ярдан-ярга сикергәне.

Тагын бер кат ачыкланды
Язмышның якты бу көне,
Сөюнең сөйкеме — утта!
Төтендә ачы хөкеме!

Мәхәббәт ихтыярымны
Булса күкләргә күтәреп,
Яратыр идем мин сине —
Бары утлардан үткәреп...

## Атыма кем сулар эчерер

Яшим тик хыялым хакына,
Үземне мин күптән оныттым.
Диңгезгә, сәхрәгә юл чыктым:
Бер күлсез чүлләргә юлыктым.
— Сөю! — дип, сусама, җан атма!
Чүл җиле дөрләде яңакта.
Каргышлы мәхәббәт артыннан
Очтым мин канатлы ак атта.
Каргышым чүлләрне туңдырды,
Ак атым сындырды канатын.
Мин бүген хыялым тураклап
Атымның канатын яматтым.
Хыялсыз — сөелмәс, очылмас!
Вакыт та көттермәс, кичегер...
Мәңгелек төннәргә күмелсәм,
Атыма кем сулар эчерер?

## Кардагы кайнарлыклар...

Карларда чагылгангамы,
Аклыкның ачык төсе?..
Мин үзем гомерем буе
Кышларга гашыйк кеше.

Үкенмим язгы ташуда
Акса да гомер утым...
Маясыз — нәселсез калып
Таркалмас минем токым!

Таркалмас... гомер кыям да
Кар калган оя белән...
Кардагы кайнарлыкларны
Мин инде тоя беләм.

Аклы, саваплы сөюгә
Мин инде тала алам:
Карлы ояга үрелеп
Канатлы бала алам!

Һәм көтәм очкын баламның
Канатлар агартканын,
Тормышны минем шикелле
Агартып яратканын.

## Каргыш

Каргышмы бу? Язмышмы бу?
Ни кимерә карындыкны? —
Аккошлардай кагындык та,
Мәхәббәттән арындыкмы?
Аудардыкмы кыш салкынын
Ай-кояшка, йолдызларга?
Чәбәләнә, тая күңел —
Гел бозларда, гел бозларда!
Каргыш төшкән илдән
кучкән —
Сызланулар аяктагы...
Тоеп яшим: Ил йөрәген
Чәнчә шайтан таяклары.
Киләчәккә каргап озата
Илне заман балалары:
Өстерәлеп килә җирдән
Итәкләрнең каралары.
Кара акыл хөкем сөрә
Мәрхәмәтсез оныкларда.
Каргалдык без, баш очында
Күкләр барын оныткан га.

Ашык-пошык серләр сөйләп
Түгелдек тә җиде ятка,
Өметләрне туй түрендә
Бер мизгелгә мандык акка...
Кидек соңра кара күлмәк:
«Кер күтәрер!» — дия-дия...
Белер-белмәс ярыбызны,
Күрер-күрмәс сөя-сөя.
...Дучар иттек мәхәббәтне
Булыр-булмас тигезлеккә...
Шуңа күрә сабыйларга
Имчәк тә юк, имезлек тә...
Тирә-юньдә юк терәк тә
Терәр өчен уй-гамьнәрне...
Әнә шулай баса дөнья
Башын түбән иганнәрне,
«Ятны сөйдем!» — диганнәрне.
Киң даланы, ал хәятне
Әнә шулай иңли каргыш...
Йә, әйтегез, кайсыбыз бар —
Бу каргыштан йолып алмыш?

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ТОРМЫШ ЧЫНЛЫГЫ

РЕДАКЦИЯДӘН. *Күп гасырлы әдәбиятыбыз тарихында хикәя жанрының үз урыны, үз үсеш эволюциясе бар. Бу күренешкә бәя бирү, тарихи-фәнни анализ ясау — галимнәр эше. Без исә әлегә яңа рубрика ачып, мирас хәзинәбездәге хикәяләрне азмы-күпме барлап, үзебезчә иң яхшы дигәннәрен бүгенге укучыга тәкъдим итмәкчебез. Бу гамәлебезнең бер максаты хәзинәбездәге асыл хикәяләр аша халкыбызның чәчмә сурәтләүдәге эстетик казанышларын күрсәтү булса, икенче максат, әлбәттә, хикәя жанрын тагын да җанландырып җибәрү. Һәрхәлдә, шундый өметтә калабыз.*

*Журнал битләрендә «Татар хикәяләре хәзинәсеннән» дигән яңа рубриканы үзе дә хикәяләр остасы булган язучы Мәгъсүм ХУҖИН алып барачак.*

*Шушы уңайдан укучыларыбызга М. Хуҗинның кереш сүзе һәм кайбер хикәяләр тәкъдим ителә.*

Мәгълүм ки, тормышның бер котыбында, һаман көчәеп, игелек балкый, икенчесендә, астыртын ыржаеп, юньсезлек зәһәрләнә. Яхшысын да, начарын да адәм баласы кыла. Уңай котыб тискәресеннән зуррак, чагыштыргысыз зур. Чөнки әйбәт кешеләр начарларыннан күп, шөкер, бик күп. Шул изге җаннарның һәркайсы турында хикәя язасы иде — аларның һәркайсының язмышы-тормышы кимендә бер хикәялек тора лабаса! Әгәр шуңа ирешелсә, юньсезлек һичшиксез бетәр, тормышны игелек кенә бизәр иде...

Хыялмы бу? Хыял! Әмма чынга ашмаслык түгелдер ул. Әдәбиятның хикәягә бай булуы моңа дәлил ич. Һәм татар әдипләре дә хикәяләрне күп яздылар һәм язалар. Хикәя — безнең әдәбиятның әйдәүче төре. Аның осталары ишле.

Фатих Әмирхан һәм Шәриф Камал егерменче гасыр башында ук хикәячеләр булып танылдылар. Әдәбиятыбыз баһадиры Гаяз Исхакый әсәрләре хәзергәчә күңелләрне дулкынландыра. Ибраһим Гази, Мирсәй Әмир, Фатих Хөсни, Әмирхан Еники хикәяләре үзәгендә җанны сөендереп игелек балкый. Укучыга рәхәтлек бирә бу әдипләрнең әсәрләре — хикәянең максаты да шул лабаса.

Әдәбиятыбызга яңа осталар килә тора. Газиз Мөхәммәтшин, Фаил Шәфигуллин, Габделхәй Сабитов иҗатларында хикәягә тугры булдылар. Аларның әсәрләре татар әдәбиятына байлык өстәде. Хәзер Зиннур Хөснияр, Ләис Зөлкарнәй, Ркаил Зәйдулла кебек үзенчәлекле хикәячеләр мәйданга чыкты.

«Казан утлары» журналы, татар прозасы хәзинәсен барлауга өлеш салу һәм, әлбәттә, шушы хәзинәнең хикәя дигән сые белән укучыны сөендерү максатыннан, «Татар хикәяләре хәзинәсеннән» исемендә бүлек ача. Анда басылачак әсәрләр әдәбиятның бу төре гасырлар буена (борынгы риваятьләрдән дә үрнәкләр укырсыз) ничек яшәвен чагылдырырга тиеш. Төрле чорлар хикәясе турында аерымлап сүз бармый, әсәрнең мактауга лаеклы булуы — сәнгатьчә абруе максатның асылы итеп куела. Хикәяләр тормышның, димәк, әдәбиятның да игелек котыбын зурайталармы — беренчел таләп шундый.

Бу очракта хикәяләрне язылу вакыты белән тезеп бару мөмкин булмастыр. Чөнки, беренчедән, әдәби хәзинәбезне барлау әлегә тәмамланмаган, икенчедән, журнал укучылардан алынган тәкъдимнәрнең редакция әзерләгән исемлекне үзгәртүе, тулыландыруы да ихтимал.

Әсәрләр басылганда, һәр автор турында кыскача белешмә биреләчәк, хикәянең язылу вакыты һәм беренче тап-

кыр кайда һәм кайчан чыгуы күрсәтеләчәк.

Журнал бу бүлекне алып баруны, нигездә, миңа тапшырды. Билгеле, мондый зур хезмәтне бер генә кешенең башкарып чыгуы мөмкин түгел. Һәм мин әдипләрнең, әдәбият галимнәренең, редакция хезмәткәрләренең (ахыр чиктә, һәр мәсьәлә алар белән киңәшеп хәл ителәчәк) ярдәм итүләренә өметләнәм. Һәм моңа ышанам.

Мәгъсум ХУҖИН.
*Апрель, 1996 ел.*

# Каюм Насыйри

## «КЫРЫК БАКЧА»дан

### Ахмаклык бәянында

Сакалның зурлыгы акылга мөнафи[1]. Берәү дә бер китапта күрде: «Ахмак кешенең башы кечкенә вә сакалы зур булыр»,— димеш. Тизрәк көзгегә барып карады, күрде — үзенең башы кечкенә, сакалы зур. Уйлап торды да: «Тукта, башны зурайтыр хәл юк, әмма сакалын би әйе вәҗһин[2] кечерәйтергә мөмкин»,— дип, сакалын учлап тотты һәм учыннан арткаsuccessor ут төртте. Сакалы яңа башлады, кулы пеште. Абау, дип кулын тартып алды. Сакалы янып китте. «Бу һәл ахмаклыгымнан икән»,— дип китеп урынына утырды.

Ахмак дигәнебез, безнеңчә, тинтәк диярләр. Ахырын тикшермичә, тәдбирсез эш кылган кеше — ахмактыр.

Ике ахмак юлга чыктылар, сөйләшә баралар. Берсе әйтте: «Мин Алладан сорыйм, миңа күп куйлар бирсә иде, ите белән, йоны белән файдаланыр идем»,— диде. Икенчесе әйтте: «Мин Алладан сорыйм, синең куйларыңны килеп бүре ашаса иде»,— диде. Болар бик кычкырышып киттеләр, янә татуланыштылар. Бара торгач, күрделәр: бер карт бер ишәккә ике кисмәк бал төягән, килә. Болар бардылар, ул картка хәлләрен сөйләделәр. Ул карт: «Тукта, мин сезнең сүзегезгә җавап бирим»,— дип, ишәген туктатты. Тезгенен кулыннан ычкындырды, ишәге, җиргә иелеп, үлән ашарга тотынды. Өстеннән бал кисмәкләре җиргә төште, баллары түгелде. Карт әйтте: «Бимәгънә[3] сүзегез өчен мине туктаттыгыз, ахмак икәнсез. Сезгә ияреп, мин дә ахмак булдым, тәдбирсез эш кылдым, ишәк өстеннән кисмәкләр төшәсен уйламадым»,— диде.

### Зиһенсезлек һәм аңгыралык

Бер кызны кияүгә бирделәр. Кияү кыз катына килде, күрде: кызның кулы камырлы, тырнак төпләре камыр гына. Кияве пакълек ярата торган адәм иде. Бер хәйлә табып: «Абау, эчем»,— дип угалана башлады. Кыз

---

[1] Мөнафи — каршы.
[2] Би әйе вәҗһин — нинди юл белән булса да.
[3] Бимәгънә — мәгънәсез.

һәм хафа булып: «Соң ничек итик, моннан элгәре эчең авыртканы бар идеме, ни дару итә торган идең?» — диде. Кияве әйтте: «Эчем һәр заман авырта торган иде. Эчем авыртканда, әни кулындагы камырны юып эчертсә, төзәлә торган иде»,— диде. Кыз үзенең кулына карады: «Минә кулымда камыр бар икән, алай булса, юып бирим»,— дип бер табакка су салып юды. «Мә, эч»,— дип киявенә бирде. Кияве әйтте: «Әни өч катка чаклы юа торган иде»,— диде. Кыз янә кулын ике кат юып, кул юган суын киявенә бирде. Кияве суны кулына алды да: «Аллага шөкер, инде эчем туктады, мә, бу суны түгеп ташла»,— диде. Кыз ни өчен юдырганын фәһем итә алмады.

Янә бер егет кыз катына барды. Егеткә аш пешереп китерделәр. Кыз барды да иң әүвәл ашны кабып карады. Авызы пеште. Әйтте: «Һай, безнең әни һәркайчан ашны суытып китерә»,— диде. Егет: «Мин дә кабып карыйм»,— дип барыр да, салкын аш капкан кебек алып, күп замангача күңелсез булып йөрде. Кыз ул арада чыгып керде. Егет әйтте: «Тышта һава ничек?» — диде. Кыз әйтте: «Тышта һава авызы пешкән егет кебек»,— диде. Чөнки һава болытлы, томан иде.

## Тапкыр җавап

Ялган булса да, сөаленә күрә җавабын туры китереп, муафыйк җавап бирү тапкырлыктан вә һәм зирәклектәндер.

Бер кеше беркөн балык сатып алды. «Бу балыкны пешерегез»,— дип хатынына бирде, үзе йокларга ятты. Ул йоклагач, җәмәгате балыкны пешерделәр, ашап бетерделәр. Йоклаган вакытта бу кешенең кулын, авызын балык шурпасы белән майладылар. Бу кеше йокысыннан уянды да: «Балыкны пешердегезме, китерегез, ашыйк»,— диде. Әйттеләр: «Сөбханалла, балыкны пешердек, үзең дә ашадың лабаса, оныттыңмы?» — диделәр. «Юк, әле балык ашаганым юк минем»,— диде. «Ышанмасаң, кулыңны иснәп кара»,— диделәр. Кулын иснәп карады, вакыйган, балык исе килә. «Алай икән, дөрес әйтәсез, ләкин мин ашаганымны тоймадым, йокыда идем»,— диде.

Бер патша үзенең якыннарыннан бер кешене бер эш хосусында урыныннан төшерде. Бу кеше бер хәйлә белән эт кебек өрергә, бүре кебек уларга, ишәк кебек бакырырга, ат кебек кешнәргә өйрәнде. Беркөн патша тәхетендә ялгыз утырып торган вакытта, бу кеше, ишек төбенә килеп, эт кебек өрә башлады. Патша әйтте: «Карагыз, эт бар»,— диде. Ул арада бу кеше бүре кебек улый башлады. Патша курыкты, тәхетеннән сикереп төште. Янә ул арада бу кеше ишәк кебек бакыра башлады. Патша тәхетеннән чыгып качты. «Бу ни тавыш икән?» — дип чыктылар. Бу кеше ат кебек кешнәде. Моны тотып, патшага китерделәр. Патша әйтте: «Әй фәлән, сиңа ни булды, тилердеңме?» — диде. Бу кеше әйтте: «Шулай инде, тәкъсир, син минс урынымнан төшергәннән бирле Аллаһ Тәгалә эт сурәтенә кертте, бүре сурәтенә кертте, ишәк сурәтенә кертте, ат сурәтенә кертте. Аллаһ Тәгалә шундый кодрәтле зат икән, әүвәлге сурәтемә кайтырып, әүвәлге хезмәтемә кертсә дә кадирдер»[1],— диде. Аннан соң патша, гафу кылып, аны яңадан әүвәлге хезмәтенә утыртты.

Берәү бер кешедән сорады: «Бал тәмлеме, шикәр тәмлеме?» — диде. Ул кеше әйтте: «Ашап карамыйча, мин аны каян белим? Китерегез, ашап карыйм әүвәл, аннан ары әйтермен»,— диде. Карыны бик ачкан иде. Бер савыт бал белән бер савыт шикәр китерделәр. Кайдан тапса да, үзе икмәк

[1] Кадир — булдыра алырлык, көчле.

табып килде, әле бал каба, әле шикәр каба. Шулай итә торгач, барын да ашап бетерде. «Юк, кайсы тәмле икәнен белә алмадым»,— диде.

Бер кечкенә бала зурлар мәҗлесендә картларга катышып сөйләшкәндә, берәү әйтте: «Син кечкенә сабый бала, зурлар катында сөйләшмә, тик утыр»,— диде. Бу кечкенә бала әйтте: «Мин кечкенә булсам да, Сөләйман һөдһөдннән[1] кечкенә түгел, син дә Сөләйманнан зур түгел. Һөдһөд тә әйтте: «Әхәтте би ма ләм тәхәтте биһи[2] дип»,— диде. Мәҗлес халкы һәммәсе тәхсин кылдылар.

Беркөн бер патша бәгъзе кешеләре белән сәергә чыккан иде. Бер җирдә, кешеләреннән аерылып, ялгыз калды. Шунда бер карт очрады. Ул картка әйтте: «И бабай, син кайдагы?» — диде. Карт: «Мин шул шәһәрдән»,— диде. Патша әйтте: «Бу шәһәрнең хакимнәре ничек?» Карт әйтте: «Хакимнәребез бик кирәкмәгән усал, залим кешеләр»,— диде. Патша әйтте: «Патша хакында ни әйтәсең?» — диде. Карт әйтте: «Шәһәребездә моның кебек кабахәт залим патша булганы юк иде, золымы белән көйдерде шәһәрне»,— диде. Патша әйтте: «Мине таныймсың, мин кем?» — диде. Карт әйтте: «Юк, танымыйм, син кем?» — диде. Патша әйтте: «Бу шәһәрнең патшасы булырмын»,— диде. Карт әйтте: «Мин кем, син мине таныймсың?» Патша әйтте: «Юк, танымыйм, рәгыйят[3] эчендәге халыкны каян танып бетерәсең»,— диде. Карт әйтте: «Мин фәлән угылы фәлән мәҗнүн, көн саен ике мәртәбә шулай юләрләнеп саташып йөримен»,— диде. Патша көлде дә китте.

Берәү күрде: бер кешенең өендә матчасы төшеп бара. «Бу матча төшеп китәр, төзәтеп куй»,— диде. Ул кеше әйтте: «Тимә, тимә, ул тәсбих әйтә[4]»,— диде. Бу кеше әйтте: «Мин куркамын, күңеленә йомшаклык килер дә сәҗдә кылыр[5]»,— диде.

Бер яшь егет бер карт кешене күрде: бөкрәеп акрын гына бара. «Бабай, ни җуйдың?» — диде. Карт әйтте: «Әй балам, яшьлегемне җуйган идем, тапмый барам»,— диде.

Берәү бер заманда: «Шикәр хәрам, шикәр белән чәй эчү дөрес түгел»,— дип фәтва[6] бирде. «Бу кеше хәлалны хәрам дип әйтте, кяфир булды»,— дип, үтерергә хөкем иттеләр. Сәясәт мәйданына китерделәр. Әмир әйтте: «Сабыр итегез, ул сүзеннән кайтмады микән, сорагыз»,— диде. Бу кешедән сорадылар: «Йә, инде шикәр хакында ни әйтәсең?» — диделәр. Бу кеше әйтте: «Шикәр тәмле, тәкъсир»,— диде. Кателдән[7] котылды.

## Соальне хата фәһемләп, хата җавап бирү

Берәү, бер кешенең өендә кунак булып, өй хуҗасы аны озата чыккач, әйтте: «Миңа куна алып кил»,— диде. Бу кеше әйтте: «Аллаһ разый булсын»,— диде. Кунарга кил, дип әйтә дип, хата фәһемләде.

---

[1] Һ о д е һ е д — кош исеме.
[2] Ә х ә т т е б и м а л ә м т ә х е т т е б и һ и — син кардәш булмаган кеше белән мин кардәшмен (син белмәгәнне мин беләм, мәгънәсендә).
[3] Р ә г ы й я т — халык, масса.
[4] Т ә с б и х ә й т ү — Алланы мактау.
[5] С ә җ д ә к ы л у — олылап, йөзтүбән җиргә яту.
[6] Ф ә т в а — дәгъвалы мәсьәләне чишеп җавап бирү.
[7] К а т е л — үлем.

Берәү бер кешедән пычкы сорады: «Миңа пычкы биреп торсана»,— диде. Ул кеше өенә кереп китте дә ышкы алып чыкты һәм бу кешегә тоттырды. Бу кеше әйтте: «Юк, мин пычкы дип әйткән идем»,— диде.

Янә берәү бер кешедән сорады: «Чыршы Габди кайсы авылныкы?» — диде. Ул кеше җавап бирде: «Чыршы Габди Наратлыныкы бугай»,— диде.

Сорасы сүзеңне яхшы уйламыйча, ашыгып сөаль кылырга да тиеш түгел икән.

## Ишанланучылар бәянында

Кадим заманда пәйгамбәрлек дәгъвасы кылучылар булган кебек, ишанлык дәгъвасы кылучылар һәм буладыр. Халык күзенә тәкъвалык күрсәтеп, максутлары мәгыйшәт өчен үзләренә бернәрсә хасил итмәктер.

Бер адәм бернечә ел озак сәфәрдә йөреп кайтты. Ишанлык дәгъвасы кылып, үзенә ишан исемен чыгарды. Бәгъзе ахмаклар моңар иярделәр. Бара торгач, үзенең ахмаклыгы сәбәпле, ишан исеменнән газел кылынып[1], нишан[2] булып калды. «Халык миңа ихлас куйсыннар»,— дип ялган кәрамәтләр изһар кылып[3], төрле хәйләләр белән бәгъзе наданнарны алдаштыргалады. Бервакытны бу ишан үзенең якыннарыннан бер кызга әйтте: «Без фәлән кеше белән кырга йөрергә чыгарбыз, шул вакытта син безгә бер тәлинкә җиләк җыеп, юл өстендә ашлык арасына посып тор. Без узып барганда, ашлык арасыннан тәлинкә белән җиләкне суз, үзең күренмә»,— дип тәнбиһ кылды. Ахыр бу кыз, ишанның әмеренчә, бер мәгълүм көнне бер тәлинкә җиләк җыеп, ашлык арасында торды. Бу ишан үзенең мөриде белән юлдан барганда, күрделәр, ашлык өстендә бер тәлинкә җиләк тора. Ишан: «Бисмиллаһиррахманиррахим Аллаһеммә саллигалә»,— дип җиләкне барып алды. Мөридենә әйтте: «Кил, фәлән, кәрамәт җиләге ашыйк, әммә бу вакыйганы һичкемгә сөйләмә. Бу җиләк безгә Аллаһе Тәгаләдән килде фәрештә аркылы»,— диде. Җиләкне юл читенә утырып ашадылар. Ул затның моннан башка һәм ялган кәрамәтләре бар иде.

## Бай һәм хезмәтче

Берәүнең бер ялкау хезмәтчесе бар иде. Беркөн бу кеше бу хезмәтчене базарга җибәрде. Акча бирде: «Базардан фәлән нәрсә алып кил»,— дип. Малай базарга китте, бик озак торып кайтты. Бай янә икенче йомышка базарга җибәрде, малай төнлә кайтты. Бай кыйнады. Хезмәтчесе әйтте: «Синең ике төрле йомышың бар икән, берьюлы җибәрү кирәк иде»,— дип бай белән төн буе кычкырышты. Бервакытны бу бай авырый башлады. «Бар, табибны алып кил»,— дип шул хезмәтчене табибка җибәрде. Хезмәтче китте, табибны алып килде. Аның белән янә бер кешене ияртеп килде. Бай әйтте: «Нигә бу кешене алып килдең?» — диде. Хезмәтче әйтте: «Фәлән вакыт үзең мине кыйнадың, йомышка барганда, ике йомышны бетереп кил, дидең. Инде менә сиңа табиб, Аллаһ бирсен, шифа тап, үлсәң, менә сиңа кабер казучы, мине икенче мәртәбә йөртмә»,— диде.

---

[1] Газел кылу — чыгарылу, төшерелү.
[2] Нишан — дансыз, дәрәҗәсез.
[3] Изһар кылу — күрсәтү.

## Саранлык

Ләим[1] улдыр — тешен орыр тешенә,
Үзе ймәс[2], дәхи бирмәс кешегә.

Бер бик хәрыйс[3] ләим кеше бар иде. Бөтен гомере буенча хәрыйслык белән ашамыйча-эчмичә күп акча хасил итте. Акчасын барын да алтынга әйләндереп, бер җиргә җир астына күмеп куйды. Аннан соң һәрбер кулына төшкән алтынны шул алтыннар янына илтеп салыр иде. Вә аның акыл вә мөрәүвәт иясе бер угылы бар иде, үсеп буйга җитте. Гыйлем бабыннан өлеш алды. Адәмнәргә катышасы килә, акча юк. Акчасыз фәкыйрьне игътибарга да алмыйлар. Моның эче пошып йөри, атасының акчасы бар, ничек кулга төшерергә кирәк? Беркөнне сагалап торды, атасы кулына төшкән алтынны янә шул баягы алтыннар янына салырга китте. Бу егет, күрер-күрмәс атасының артыннан барып, алтынны кайда куйганын карап торды да, булды, шөкер, дип кайтты. Атасы алтыннарны куеп кайткач, бер капчыкка таш тутырды да шул җиргә барып, алтыннарны ачып алды, алтын урынына ташларны салып, атасы куйган кыяфәттә өстен ябып куйды, бер-бер хөкем булганчы алтыннарны бер урынга да сарыф кылмады. Берничә заманнан соң атасы янә кулына төшкән алтынны куярга шул урынга барды, ачып күрде, алтын урынында таш тулып ята. Хәйран булды, бу кем эшедер, дип уйлап тора. Бак, бәдбәхет угылым эшедер, дип чакырып угылыннан сорады: «Ул фәлән җирдәге алтыннарны син алдыңмы?» — диде. Угылы әйтте: «И мәрхәмәтле атам, мин алу түгел, һаман алтыннарның барын да белгәнем юк»,— диде. Атасы бик тыгызлагач, икърар кылды: «Алдым, әткәй, ләкин мин урынына салып куйдым»,— диде. Атасы әйтте: «Бәли, син урынына салып куйгансың, ләкин таш тутырып куйгансың»,— диде. Угылы әйтте: «И юмарт атам! Алтын кирәк ашамак-эчмәк, икмәк, рәхәтләнмәк өчен. Әмма җир астында ятарга таш та ярый, балчык та ярый, кирпеч тә ярый».

## Хикәят

Беркөн мәшһүр Хатәм Тай гарәп олугларын чакырып олуг зияфәт итде[4]. Шул вакыт бер фәкыйрь яп-ялангач ишектән килеп керде. Хатәм Тай ул фәкыйрьнең кулыннан тотып, мәҗлеснең югарысына мендереп утыртты. Әйтteләр мәҗлестәге кешеләр: «И Хатәм, сән нишләдең?» — диделәр. «Бу эшең килешмәде»,— диделәр. Хатәм җавап бирде: «Сезнең һәрберегезне үзегезнең дәүләтегез югары утыртты, бу ялангач фәкыйрьне мәнем үземнең юмартлыгым шулай югары утыртты»,— диде.

## Хикәят

Беркөн бер базарга бер кол сатмага китерделәр. Күзе сукыр, тәне җәрәхәтле, кулы чулак, һичнәрсә тотарга ярамый һәм (башка) гаепләр анда бар иде. Бер кеше сатып алырга дип карады. Гаепне күреп әйтте: «Сүзләргә теле ничек?» — диде. Әйттеләр: «Моның теле фәсыйх[5], сүзгә бик оста»,— диделәр. Ул кеше: «Алай исә кабул иттем гаепләре берлән»,— дип колны сатып алды.

---

[1] Ләим — саран.
[2] Ймәс — ашамас.
[3] Хәрыйс — ач күз.
[4] Зияфәт итү — кунак итү, мәҗлес кору.
[5] Фәсыйх — матур һәм килешле итеп сөйләү.

## Хикәят

Беркөн бер бик фәкыйрь кеше иске кием берлән бер падишаһның мәҗлесенә килеп керде. Падишаһ ул фәкыйрьнең кермәклегенә бик хафа булып китте, төсе үзгәрде. Мәҗлестәге адәмнәрдән берсе әйтте: «И дәрвиш фәкыйрь, син белмәссең, бу кадәр иске кием берлән падишаһ мәҗлесенә килмәк гаептер». Дәрвиш әйтте: «Иске кием берлән падишаһ мәҗлесенә килмәк гаеп түгелдер. Әмма иске кием берлән падишаһ мәҗлесеннән чыгып китмәк гаептер»,— диде. Бу сүз падишаһка хуш күренеп, ул фәкыйрьгә ингам-ихсан[1] кылды.

### ИСКӘРМӘ

Күренекле мәгърифәтче, галим һәм язучы Каюм Насыйри (1825—1902) күләм ягыннан иң зур әсәре «Фәвакиһел җөләсә фил әдәбият»ны («Әдәбият турындагы мәҗлесләрнең җимеше») 1879 елда яза башлый. Аның беренче кыскартылган вариантын «Кырык бакча» исеме белән 1880 елда илле сигез битле китап итеп чыгара. Китаптагы әсәрләрнең күпчелеге көнчыгыш әдәбиятыннан сайлап тәрҗемә ителсә дә, К. Насыйри «...урыны туры килгән саен үз фикерләрен өсти, үз карашларын белдерә баручы язучы да булып күренә. Автор... шул кечкенә хикәяләре, новеллалары ярдәмендә үз вакытының реаль тормышын, андагы социаль зарарлы күренешләрне тәнкыйть астына ала» дип язды профессор Мөхәммәт Гайнуллин.

«Кырык бакча» 1902 елда 80 битле китап итеп биш мең данәдә кабат басыла. Моннан соң бу әсәрдән өлешләр Каюм Насыйриның 1945, 1953 һәм 1956 елларда чыккан «Сайланма әсәрләр»ендә, 1957 һәм 1968 елларда басылган «Кырык вәзир» исемле китабында, «Егерме дүртенче бакча» дигән җыентыгында (1970) урын ала.

К. Насыйри ике томлыгының икенче томында (1975) «Кырык бакча»дан шулай ук үрнәкләр бар. Андагы искәрмәләрдә өзекләрнең 1953 елгы «Сайланма әсәрләр»дән, ә «Кырык бакча»дан соңгы өч хикәятнең Казан университеты китапханәсендәге кульязмалардан алынуы, боларын китапханә хезмәткәре Д. Абдуллина күчереп тапшыруы әйтелә.

Текст ике томлыкның икенче томыннан алынды, искәрмәләр өчен дә ике томлык төп нигез булды.

## Шәриф Камал

# УЯНУ

Муса ачуланган иде. Ачуыннан күзләре акайган, йөзе ут шикелле яна, дулкынлануыннан сүзен әйтә алмый иде... Барлык көчен җыеп урыныннан сикереп торды, буылган һәм калтыравык тавыш белән:

— Хәерсез! — диде, уң кулы белән Гафифәнең беләгеннән, сулы белән җилкәсеннән кысып, бар куәте белән ишеккә таба тәгәрәтте. Гафифә барып торып ишек янгенә бәрелде.

[1] Ингам-ихсан кылды — бүләкләр биреп, яхшылык итте.

Берничә куркынычлы секунд хәрәкәтсез кичте... Гафифә аркасы белән ишек иягенә сөялгән, йөзе ак киндер кебек булган, иреннәре күгәргән иде. Муса моңар илтифат итмәде.

Гафифә куркынып кулларын йөзенә кадәр күтәргән генә иде.. Мусаның тимер кебек куллары аның изү якасыннан эләктереп муеныннан кысты... Сул кулы белән ишек иягенә тотынган хәлдә, уңысы белән Гафифәнең изүеннән кысып аркасы белән ишеккә бәрде, әмма ишек ачылмады... Муса моңар аптырады: юкса тышкы яктан бастырганнармы икән? Тагын әллә нинди бугаз хәрефләре чыгарып, ачуланган вәхши җанвар кебек мырылданып, икенче мәртәбә бәрде. Бу юлы ишек чалдырап ачылып китте. Артыннан ук тышкы якта, ачы һәм нечкә тавыш белән ыңгырашып илерү ишетелде. Гафифәнең тавышы иде.

Гафифәнең гаебе ни иде?

Муса исерткечкә мөбтәля[1], Гафифә аның бу эшенә разый түгел.

— Эчмә, йә булмаса мине аер...— ди иде.

Ишек ачылганда, Мусаның аягына бер каты нәрсә чылтырап төште, шуны алу белән ул эшнең гадилеген аңлады. Ишек элгече каерылып төшкән иде. Башта үзе ишекне бикләп тә соңыннан ниһаять дәрәҗәдә ачулануы сәбәпле хәтереннән чыккан иде. Ишек элгечен урынына куеп карады, тәмам сынган, эшкә яраклы түгел иде.

Күптән түгел шундый караңгы бер кичтә, шундый ук бер сценадан соң, Муса ишекне эчтән бикләп, Гафифәне ишек төбендә сәгатьтән артык кертмиче инәлткән, аның моңлы һәм елаган тавыш белән инәлүләрен тыңлап зәвыкланган, вәхши хиссиятеннән вәхши шигырь эзләп маташкан иде...

Хәзер дә шулай итәргә күңеленә килде, ләкин элгечне урынына куеп карады да сынганлыгына сөенде...

Бераз уйлап торгач, үзеннән-үзе сораган кебек бик әкрен:

— Каты сугылды микән?—диде.

Ул хәзер инәлтми, елатмый кертергә дә разый булган иде. Хәтта кайтып керүен тели башлады...

Ул өстәл янына килеп утырган иде, сәгать тугызны сукты, ишетмәде, турысы, тыңламый, сизмичә калды...

Өй эче якты түгел, караңгылана бара; кояш иңгәнгә байтак вакыт үткән иде.

Ут алындырды, янә якты түгел иде...

Ул тирләгән иде—камзулын салды. Ишеккә якын кадакка эләргә дип бара иде... тәне чымырдап китте, чәчләре үрә торды, агач кебек катты... Ишек төбендә... бер күз!.. яшьле күз... туп-туры Мусаның күзенә карый... Гафифәнең күзе...

...Камзулны элде, иелеп караса, күз түгел икән—зур гына бер сәдәф төймә Гафифәнең якасыннан өзелеп калган...

Төймәне кулына алды һәм китереп өстәлгә куйды.

Аз гына яктылык биреп торган лампадан башка өстәл өстендә бернәрсә дә юк иде. Өстәл читенә куелган төймәнең ялтырап күренеше аның дикъкатен җәлеп итте...

Күңеленнән: «Югалмасын, үзе килгәч, үзенә бирермен...»—диде һәм өстәл янына утырды. Башын ике кулы арасына алып уйга калды.

Менә Гафифә унбер-унике яшьләрендә, нәзек, гүзәл, сөйкемле бер кызчык... Әнкәсе белән кунакка киләләр, Муса белән уйныйлар, шаяралар, ниһаять, китәләр... Мусага уңайсыз, эче поша, нидән икәнлеген дә белми, әмма аларның китүе бик уңайсыз тоела, тагын күрәсе килә, тагын уйныйсы, тагын шаярасы килә. Сирәк киләләр—ерак торалар. Бик уңайсыз... Бер елдан соң тагын киләләр... Муса мулладан сабак укып кайта, урам капкасыннан, нәфис күбәләк кебек очынып, Гафифә каршы

---

[1] Мөбтәля—дучар булган.

чыга... Мусаның тез буыннары бушый. Көчкә аяк өстендә тора... кулкулга тотынышып өйгә керәләр...

Ниһаять, гыйшык... өйләнү... мәхәббәт... ух! Нихәтле зәвык, нихәтле сәгадәт[1] иде!

Әүвәлге икесе инде үткән... соңгысын гына кайтарып булмасмы икән? Муса кем соң?

Хәзер ул Идел буендагы «С» шәһәрендә бер тегермәндә эшче иде.

Ул кәефле чакларында иптәшләренә үзенең электә бер бай баласы булып та, соңыннан фәкыйрьләнгәнлекләрен, бай вакытларында шәп атларда йөреп, яхшы өйләрдә торганнарын сөйлидер иде. Ләкин аның бу сүзләренә иптәшләре яртылаш кына да чын дип карамыйлар иде. Шулай да аның сөйләгәннәре дөрес булырга да мөмкин, дип күңелләренә килә иде.

Ул хәзер, исереклегеннән шактый айнып, Гафифә кайтып кермәгәнгә борчыла башлады. Гүя кемдер аның колагына: «Ул мәңге киләчәк түгел... аның башын бәреп ваттың! Ул кан эчендә...» — ди иде.

Түшәм буенча, тимер шар тәгәрәп йөргән шикелле, тонык кына гөрелте ишетелә башлады — күк күкри иде. Муса төймәгә карап хәрәкәтсез утыра... Колагын салып азрак тыңлады да тәрәзәгә карады. Тәрәзә пыялалары буланган, тыш якта караңгы иде... Ул күзен алмыйча биш минут кадәр тәрәзәгә карап торды; тәрәзә аркылы ара-тирә яшен шәүләләре чагылып-чагылып китә иде.

Ул сискәнеп уянган кебек урыныннан торды, өстенә кием салып чыгып китте; Гафифәне эзләп китерәчәк иде...

Чыгып кына барганда ни күзе күрсен — тау асты битеннән ике кеше бер адәмне ике яктан култыклап китерәләр.

Алар шәһәрнең читендә иң сәләмә, иң ярлы мәхәлләдә тора иделәр.

Алар тора торган бүлмәнең ике генә тәрәзәсе булып, берсе ишегалдына, икенчесе «Б» урамына карый иде. Ул урамның бер башы Иделгә таба төшә, икенчесе югары, каберлекләргә чыга иде. Кичләрдә бу урамнар, җәһәннәм почмаклары кебек, караңгы була; берничә җирдә фонарьлар яндырылса да, лампаларының кечкенәлеге, пыялаларының корымлы һәм пычраклыгы, ул корымлы пыялаларның да күбесенең ватыклыгы аларның яктырту хасыятьләрен югалта язган; ул җимерек һәм пычрак пыялалар эчендә тетрәп-тетрәп янып торган кызгылт шәүләләрдән яктылык түгел, гүя караңгылык, кайгы, хәсрәт ага иде.

Муса, теге кешеләрнең килеп җитүләрен көтеп, өй ышыгына туктады.

Тәрәзәдән зәгыйфь кенә якты сузылып киткән иде.

Муса тәрәзә янынарак якынлашты... Ул өч карачкыл да яктыга килеп чыктылар...

Муса аптырап калды:

— Гафифә...— диде.

Гафифәнең сул иңбашыннан салынып төшкән чәч толымы әллә нинди пычрак һәм юеш күренде; үзе башын түбән салган иде. Муса аның канга буялганлыгын сизде...

Гафифәне кертеп яткырдылар.

Китерүчеләр бер городовой белән каравылчы иде.

Городовой, өстәл янына утырып, тәмәке яндырды, рәтсез һәм иренеп кенә сөйләнә башлады:

— Ярый әле, дядя Игнат туры килгән... булмаса суга ташлана икән... Якты дөньядан бизгән, юләр, суга ташлана... Менә никадәр ахмаклык... Кайда соң ул болай сугылган? Башыннан кан киткән бит, мескен, тәмам хәлдән тайган... Син, юләр, нишләп хатыныңны карамыйсың? Әллә сугыштыгыз шулай? Дядя Игнат таныды, юкса частька илтә идек. Нәрсә соң болай?.. Һәлак булган бит, мескен...

Муса, элек аптыраныш, болай әлләни мыгырдады, аннан соң бер городовойга, бер Гафифәгә карап:

---

[1] Сәгадәт — бәхет, рәхәтлек.

— Мин белмим... хәзер эзләргә чыккан идем...— диде.

Городовой артык ваклап сорашмады. Ул авызын ачып-ачып исни генә иде.

Городовойның китмәвенә Муса борчыла башлады.

Ни өчен городовой утыра, ни өчен китми? Каравылчы китте, бу һаман утыра... Юкса, ул Мусаны җинаятьче дип белеп тә, юри шаярып кына белмәгән кебек кыланамы әллә? Муса мөмкин кадәр аның белән күз күзгә караудан кача иде; гүя Муса аның күзенә караса, ул кинәт көлеп җибәрә һәм Мусаның күзенә карап: «Ничек хатыныңны изә алдың? Егет! Афәрин!..» — дип мыскыллаячак иде...

Ни өчен ул еш-еш сәгатькә һәм тәрәзәгә карый, кемне көтә икән? Яхшыга түгел бу... Тышта кемнәр булса да булырга кирәк.

Шул арада тышта шаулап яңгыр ява башлады.

Караңгылыктан, әллә кайлардан килеп, эре яңгыр тамчылары бер-бер артлы дөбердәп тәрәзәгә бәреләләр һәм, гүя, килеп Мусаның йөрәгенә кадала иделәр.

— Ярый, хәерле кичләр! — диде городовой.

Муса эндәшмәде.

Городовой чыгып китте, Муса елый иде...

Гафифә арка өстенә яткан, күзләре түшәмгә текәлгән, куркуы һәм җәрәхәтенең әрнүе сәбәпле булса кирәк, ул тешләрен кысып, чыраен сытып ята иде. Баш астындагы ак мендәр өстеннән агып киткән ике юл кан сызыклары лампа яктысында ялтырап күренә иделәр, берсе идәнгә тама, икенчесе урынга, Гафифәнең астына таба китә иде. Ул көчләнеп:

— Муса, якын кил...— диде.

Муса тизләнде һәм аның кулын битенә куйды. Аның сөйкемле куллары салкын иде.

— Гафифә, җаным! Мин бит сине җәберләдем, хаксыз рәнҗеттем, мин залим булдым... бер юлга кич, җаным... гомердә дә болай итмәм,— диде.

Ул инде үксеп-үксеп елый иде. Бите буйлап аккан кайнар күз яшьләре Гафифәнең кулына тама иделәр.

Гафифә бераз вакыт хәрәкәтсез яткач, башын азрак Мусага авыштырды:

— Муса, мин үләм...— диде.

Муса аның маңгаеннан үпте...

Гафифә көчлек белән сүзендә дәвам итеп:

— Сугылып егылгач та... сиңа үпкәләп киткән идем... суга төшмәкче идем... Инде мин үләм... мин сине сөядер идем... Нигә артымнан бармадың, белмәгәнсеңдер шул... Ах, үләм инде, тынычланырсың... кулымны...— диде.

Икенче кулын да Мусага сузды.

Муса үбеп-үбеп җан сулышы белән аның кулларын җылытмакчы була иде. Әмма куллар инде җылынмый иделәр...

Төннең байтак вакыты шулай үтте. Муса, Гафифәнең башындагы җәрәхәткә чүпрәкләр куеп, канын туктатты, ләкин Гафифә инде сөйләшә алмый иде...

Тышта һаман шаулап яңгыр ява, әллә кайлардан тирәнтен гөрләп килеп күк күкри, караңгы тәрәзәләрдә ялт-йолт итеп аклы-күкле утлар чагылып тора иде. Гафифә түшәмнең әллә кай җиренә карап елмайган кебек ирен очларын азрак киерде һәм ике мәртәбә җан сулышын эчкә чикте һәм дә күз кабаклары төшә башлады... керфекләре керфеккә тимичә күзләре ачык калды. Гүяки ул тирән бер фикергә чумды.

Октябрь ае. Кич салкын һәм җил иде.

«С» шәһәренең каберлекләре ай яктысында ялангач һәм хыял диңгезенә чумган сыман күренә иде. Каберлекнең урта бер җирендә бишалты төп картайган имән агачларын көзге кичнең үткен, салкын җиле

иңә, сыга, ыңгыраштыра, артык нык иңгән саен, саргайган, кипкән яфракларыннан берничәшәрне ботаклардан өзеп-өзеп калтырата-калтырата әллә кайларга туздыра иде. Бу вакытта имәннәр генә түгел, гүя башказыклар[1] да чайкала, ыңгыраша иделәр...

Шул каберлекнең түбән бер почмагында өсте үләнсез, яңарак бер кабер бар иде... Башказыгы, кортлар тишкәләгән, кайрысы каергаланган черек бер усак агачыннан гыйбарәт булып, корт ашаган тишекләре белән, каерылган кайрыларында җил сызгырып, әллә нинди тавышлар чыгара иде...

Бу — Гафифәнең кабере иде...

Шушы кечтә каберлекләрдән ике чакрымнар читтә, урман янында, тирәсе биек койма белән коршалган зур бер бинаның бүлмәсендә, стенага бәргәләнеп башы, күзе канга буялган бер егет: «Җибәрегез мине! Ул суга төшә, мин аны коткарам... җибәрегез...» — дип кычкыра иде.

Юләрләр шифаханәсендәге бу егет Муса иде...

*1909*

ИСКӘРМӘ

Шәриф Камал (1884—1942) татар әдәбиятында хикәя осталарының беренчеләреннән булып танылды. Чәчмә әсәрләренең тәүгеләреннән саналучы «Уяну» хикәясе (элегрәк шигырьләре матбугатта чыгуга карамастан, язучы бу әсәрен иҗатының башы итеп саный) «Шура» журналының 1909 елгы уникенче санында басыла. Аннан соң, бик нык төзәтелеп, «Хикәяләр төркеме» (1914) җыентыгына кертелә. Әдипнең 1926, 1929 һәм 1934 елларда чыккан җыентыкларында хикәя тагын шактый үзгәртелә. 1938 елда басылган «Сайланма әсәрләр»ендә, кайбер кечкенә төзәтүләр белән, хикәянең 1914 елгы басмасындагы текст кайтарыла. Хикәя Ш. Камал әсәрләре өч томлыгының 1941 елда чыккан беренче томында бар. Шулай ук язучы өч томлыгының (төзүчеләре Г. Кашшаф һәм И. Нуруллин, Татарстан китап нәшрияты) 1974 елда басылган беренче томы шушы хикәя белән башлана. Текст һәм искәрмәләр шуннан алынды.

## Мирсәй Әмир

# МӨСТӘКЫЙМ КАРТ ЙОКЫСЫ

Мөстәкыйм картны күптән исәптән чыккан кешегә санныйлар иде инде. Дөрес, яшь ягыннан тугызынчы унны куса да, болай күрер күзгә таза иде әле үзе. Вакыты белән зур-зур, авыр-авыр эшләрне җиңел-җиңел генә эшләп ташлый ала һәм ашау ягына килгәндә дә сынатмый торган иде. Тик бер генә нәрсә аяктан ега иде аны: йокысын җиңә алмый иде карт.

Гаҗәп бер йокы булып чыкты ул Мөстәкыйм карт йокысы. Нинди генә вакытта, нинди генә хәлдә йокламый иде ул?

---

[1] Башказык — мишәрчә: кабер өстенә куелган казык.

Тәмле генә итеп сөйләшеп утырганда дисеңме, ләззәтле генә итеп чәй эчеп утырганда дисеңме — әллә каян таяныр әйберен таба, әллә каян сөялер урыны туры килә — эри дә китә.

Өй эчендәгеләр аның бу гадәтенә ияләшеп беткән иде инде. Бервакытны ул тавык суйган чагында йоклап көлкегә калды. Ә тавык суярга еш туры килә иде аңа. «Кулы тәмле» дип, күрше-күлән дә тавыкны аңардан суйдыра иде. Шулай беркөнне шактый ерак күршеләреннән исәпләнгән Хөбби карчык кысыр тавыгын күтәреп килде.

— Тиз генә суеп бирче шушыны, Мөстәкыйм абзый,— диде карчык,— күкәй салмый башлады, рәхмәт төшкере.

— Хәзер эшен бетереп алып керәм мин аның,— диде Мөстәкыйм карт һәм, бер кулына тавыкны, икенче кулына чалгы пәкесен алып, лапас астына кереп китте.

Хөбби карчык, Мөстәкыйм картның үзе белән бергә картайган Марзия карчык белән сөйләшеп, өйдә калды. Марзия самовар да куймакчы иде дә, күршесе чын күңеленнән каршы төште:

— Кирәкмәс, күрше, эшем ашыгыч, зинһар, мәшәкатьләнмә, бик тиз кайтып җитәм, дип кенә чыгып киттем,— диде.

Ләкин бик тиз генә кайтып китә алмады ул. Ике карчык байтак сөйләштеләр. Мөстәкыйм карт һаман тавыкның эшен бетереп алып керми иде. Хөбби карчык сабырсызлана башлады:

— Ай алла, нишләп болай озаклады соң бу Мөстәкыйм абзый, рәхмәт төшкере? — дип берничә тапкыр кабатлап алды.

Картының гадәтен белгән Марзия карчык, борчылып, кулын селкеп куйды:

— Йоклап китте микәнни, ходаем,— диде,— чыгып карыйксана үзен.

Марзия карчыкның сизенүе дөрес булып чыкты: Мөстәкыйм карт, тавыкның канатларын артка каерып, икесен бергә җиргә баскан, томшыгын кысып тоткан килеш, башын тез өстенә салган да йокыга чумган иде.

Икенче бервакытны ул тәһарәт алып утырган чагында, бер аягын юган, икенчесен юмаган хәлдә, болдыр баскычына утырган килеш йоклап, икенде намазының вакытын уздырып җибәрде.

Марзия карчыкның мондый хәлләргә бер дә исе китми, вакытлы-вакытсыз, урынлы-урынсыз йоклаган өчен картын шелтәләп торуны да кирәк тапмый иде. Шулай да бер тиргәде ул аны.

Ул көнне алар өйдә икәү генә калганнар иде. Уллары-киленнәре эштә, ә бала-чага уйнарга чыгып киткән иде. Карт белән карчык аулаклап кына чәй эчәргә ниятләделәр. Карт, бик матурлап кына кисеп, кәрәзле бал алып керде. Ни җитте бал гына да түгел, бала корт балы иде. Карчык икесенә генә җитәрлек итеп, сөт белән күкәйгә генә туглап, сары майда гына йөздереп, төче коймак пешереп алды. Кырыйлары бөдрәләнеп, сап-сары булып кәрәзләнеп пешкән коймаклар иде алар. Үзләреннән-үзләре авызга кереп эрергә генә торалар иде инде. Бүген генә савып утыртылган сөт өсте дә чыгарып куелды. Нечкә билле ак самовар, барлык тишекләреннән пар бөркеп, сызгыра-сызгыра сәке йөзлегенә килеп утырды. Әби болай да яхшы чыгышлы такта чәйне мул гына чеметеп алып ак чәйнеккә салды. Аякларын бөкләп, самовар каршына менеп утырып, чәйнеккә су агызам дигәндә генә, урам тәрәзәсе аша бер малай кычкырып узды:

— Марзия әби! Бәрәңгегезгә Муллагали дуңгызы кергән!

— Каһәр генә суксын инде,— диде карчык,— шул ходай каргаган малны кайсы юньсезе генә авылыбызга аяк бастырды соң! Бер генә тынгы юк бит, илаһым! Чәйне пешерә торчы, карт, хәзер керәм,— дип малайлар җитезлеге белән урыныннан сикереп торды да каргана-каргана чыгып китте.

Баштарак ят булып тоелган колхоз тормышының бөтен якларына күптән ияләшеп, үзләшеп беткән иде инде карчык. Тик татар авылында

дуңгыз терлеге асраучылык белән генә килешеп бетә алмады ул. Ите харам булуы берни түгел инде, теләмәгән кешегә көчләп ашатмыйлар анысы. Менә бәрәңге бакчасын сөрү кебек әшәке гадәте булуы яман мәлгуньнең.

Бакчаның аргы башында бәрәңге төпләрен чүеп җибәрә-җибәрә җир сөрүче ак дуңгызны күргәч, Марзия карчык ярсып кычкырып җибәрергә дип авызын ачкан иде дә, ни дип кычкырырга белмичә, тукталып калды.

— Нәгъләт! Нәгъләт! Сыер булса — «һәш!» дияр идең, сарык булса — «төррә!» дип, эт булса — «чәбә!» дип, кәҗә булса — «кәҗә, ристан!» дип кычкырыр идең. Дуңгыз бит, чучка! Ни дип кычкырасың аңа. Синең татарча әйткәнеңне беләмени ул! Йөгереп бар да билен сындырганчы күсәк белән ор шул!

Билгеле, Марзия карчык карак дуңгызга күсәк белән ора алмады. Дуңгыз, мыскыл иткән кебек, бер урыннан бер урынга күчеп, әбинең ачуын китерде-китерде дә кәкрәеп торган койрыгын болгый-болгый чыгып китте.

Марзия карчык үзалдына сөйләнә-сөйләнә: «Чәйнең тәмен җибәрде, нәгъләт, коймагым суынып беткәндер инде»,— дип зарлана-зарлана, кире өенә кайтты. Өйалды ишеген керүгә үк борынына килеп бәрелгән тәмле чәй исе аның ачуын басып, күңелен тынычландырып, рәхәтләндереп җибәргән иде. Ләкин өй эченә керү белән беренче мәлгә ни дияргә белмичә катып калды. Бөтен идән су белән тулган, ашъяулыктан да, паластан да пар күтәрелә, ә шундый күңелле итеп, гөрләп калган самовар, яшелле-зәңгәрле ис чыгарып, эреп утыра иде.

Мөстәкыйм карт, гадәтенчә, стенага аркасы белән сөялеп утырган хәлдә йокыга киткән булып чыкты. Ничек кенә йоклаган әле: чәйнеккә су агызырга дип, самовар борынын ачкан да, чәйнек тулганны да көтмичә, эреп киткән картлач. Аннан соң инде самоварындагы су агып бетү генә түгел, бөтен коймаклары, баллары белән бергә ашъяулыгың, подносың агып китсә дә гамендә юк аның.

— Илаһым, бар икән бер бетмәс йокы! — дип кычкырып җибәрде Марзия карчык.— Самоварга тыкшынмый торсаң ни булды, ичмасам?!

Мөстәкыйм карт, уянырга теләмәгәндәй, күзен ачмыйча гына җавап бирде:

— Төшне бүлдердең лә, карчык, бик матур төш күрә башлаган идем. Кытай илләрендәге чәй бакчаларында, мин сиңа әйтим...

— Төшең корысын ла, рәхәтләнеп кенә эчәрмен дигән идем иркенләп, бер йокыңа баш була алмадың лабаса. Ничә әйтәм инде мин сиңа, йокың килсә, әнә ястыкка ятып йокла, дип. Әнә бит, синең өчен җәеп куелган ястык бит ул! Бер-ике карыш җиргә күчеп ятарга да иренәсеңмени соң?..

Күзләрен ачып, өй эчендәге хәлне күргәч тә, картның исе китмәде. Үзен аклау йөзеннән һәрвакытта әйтә торган сүзен кабатлады ул.

— Йокы кайда килсә, шунда тәмле була ул, карчык,— диде.— Әйе, йокы кайда килсә, шунда йокла син аны. Ә син, ястык, дисең. Синең ястыгыңа барып җиткәнче ачыла ул йокы. Аннары пушай ят син...

Шулай итеп, Мөстәкыйм картны колхоз өчен күптән исәптән чыккан кешегә саныйлар иде инде. Карт үзе дә, бу хәл белән килешкән булып, зур эшләргә тыгылмый, тик үз йорты тирәсендә, үз җае белән генә кыштырдап йөри бирә иде.

Тыныч илебезгә Гитлер Германиясе юлбасарларча һөҗүм башлап, бөтен халык Ватан сугышына күтәрелгәч, ир уртасы кешеләр фронтка китеп, колхоздагы барлык эш хатын-кызлар һәм картлар белән үсмерләр кулына калгач, Мөстәкыйм карт үзенең исәптән чыккан кеше булып яшәвенә риза булып кала алмады.

— Ике улымны да фронтка озаттым,— диде ул, колхоз идарәсенә килеп,— алар өчен бирәдә кем дә булса эшләргә тиештер бит,— диде.— Мин үзем, болай карт булсам да, йокламаган чагымда бер дә яшьләрдән

ким түгел. Кулымнан килгән хәтлесе булыр, кушыгыз мине берәр эшкә,— диде.

Аны хуплап каршы алдылар. Карт өченче бригадага беркетелде.

Өченче бригаданың башлыгы Фагыйлә исемле бик кайнар характерлы яшь кенә бер хатын иде. Ирләребез кайтканчы шушы бригаданы аяктан екмый алып бара алсам, бу каһәр суккан Гитлер дөмегеп, сугыш беткән көнгә сөреләсе җирләр сөрелгән, чәчеләсе чәчелгән, чабыласы чабылган, урыласы урылган хәлдә ирләребез кулына тапшыра алсам, башкасы кирәкми, ди иде ул һәм, берәүләрне тиргәп, берәүләрне юмалап эшкә куша-куша, хуҗалыкны артка калдырмыйча бара иде. Әмма ярсу йөрәкле хатын иде инде. Юмалау килешә торганрак кешеләрне юмалый башласа, тәмам эретә — балавыз итә иде Фагыйлә. Ә инде яхшылап әйткәнне колакка алмый торганрак кешеләргә кадалса, чыдап кына тор: утка басканнан ким сикертми иде ул андыйларны. Нәтиҗәдә бары да тыңлыйлар иде үзен. Кемнәрне уңай якка сыпырып, кемнең чәчен кирегә ышкырга кирәклекне белә иде шул.

Әмма Мөстәкыйм бабайның көен таба алмыйча аптырап бетте Фагыйлә. Карт бригадага бик күп файда китерде. Ләкин, әлеге дә баягы, йокысын ташлап бетә алмады ул. Эш өсләрендә вакытлы-вакытсыз, урынлы-урынсыз йоклап китеп, Фагыйләнең ачуын китереп бетерде. Ләкин Фагыйлә, бердән, аның олы кеше булуын, икенчедән, кулыннан килгән кадәр намус белән эшләргә тырышуын, бригаданы валюк баулары, тырма, сәнәк кебек коралларга бервакытта да мохтаҗ итмәвен искә алып, аңа каты бәрелмәскә тырышып килде. Берничә тапкыр теле кычытып-кычытып куйса да, түзгән иде. Тик кызу печән өстендә килеп чыккан бер күңелсезлек Фагыйләнең сабырын җуйды.

Өченче бригада хатыннары искиткеч бер дәрт белән ярышып, икенче бригададан уздырырга тырышып печән чапкан вакытта Мөстәкыйм карт аларга ярдәмгә бирелгән иде. Чабучылар ял иткән чакларда, аларның чалгыларын таптый иде ул. Ул таптап биргән чалгылар Гали пәкесе булалар иде инде булуын. Ә менә бервакытны, печән чабу өчен заказ ясатып алынган кебек матур көннәрнең берендә, картыбыз чалгы чүкегән чагында кырын ятып йоклап киткән бит. Чалгылар чүкелеп беткәнче генә черем алырга дип ятып торган хатыннар да уянмаганнар. Җәйнең иң озын көннәрендә бер караңгыдан икенче караңгыга чаклы эшләп йөргән кешеләр бит. Рәтләп йокы эләгәмени аларга бу көннәрдә! Печән өсте! Йоклаганнар да йоклаганнар болар. Алтыннан кадерле вакыт та әрәм үткән, чалгылар да чүкелмәгән. Шуның аркасында ул көнне теге бригадалар чабучылары өченче бригадага караганда норманы бик күп арттырып үтәгәннәр.

Фагыйлә бу хәлгә болай гына түзеп кала алмады. Мөстәкыйм картны кәнсәләргә рәис янына чакыртты. Кич булып, көн караңгыга авышып барган вакыт иде. Үзе өстәл артыннан рәис белән янәшә урын алып, Мөстәкыйм картны каршысына утыртты да тотынды пешерергә, тотынды пешерергә! Чыдап кына тор!

— Болай ук гамьсез булырсың дип уйламаган идем мин сине, Мөстәкыйм бабай! — дип башлап җибәрде ул сүзен.— Карт кеше дип, тырышып йөри дип, моңарчы дәшми килдем. Кәнүшни түбәсен япканда салам алып торган чагында йоклавыңа да сүз әйтмәдем. Тары чәчкән вакытта тагын...

Шулай тезеп китеп, Фагыйлә аның кайчан, кайда йоклаганнарын санарга тотынды. Мөстәкыйм карт каршы сүз әйтмичә: «Ие, ие, кызым, булды бугай шул, картлык күрәсең инде»,— дип, һәр гаебен өстенә алып утыра иде. Фагыйлә аның болай барысын дөресләп утыруын да ошатмады.

— Сугыш вакыты икәнен аңларга теләмисең син. Аңларга теләсәң, бер йокыңа гына баш була алыр идең. Шушындый кызу көндә, шушындый җаваплы эшне тоткарлауга барып житү уен эшмени ул! Ә?!

Бу сүзләр, кәгазьгә язылгач бик көчле яңгырамасалар да, Фагыйлә авызыннан әйтелгән вакытта алар бик каты булып, бәгырьләргә үтәрлек ачы булып чыктылар. Мөстәкыйм карт инде бөтенләй эндәшми башлады. Ул эндәшмәгән саен, Фагыйлә тавышын күтәрә бара иде. Карт аның саен дәшмәгәч, бригадир рәискә борылып сөйли башлады:

— Менә күр инде, Сабир абзый, нишлим мин бу карт белән? Сүз дә бирми бит, ичмасам.

Ул, кинәт Мөстәкыйм картка борылып, тагын да катырак тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Адәм рәтле эшләргә телисеңме, Мөстәкыйм бабай, юкмы? Йә, әйт!

Мөстәкыйм карт җавап бирмәде.

Бригадир тагын нәрсәдер әйтеп кычкырмакчы иде дә, нидер исенә төшкән кебек, кинәт тынып калды. Өстәл артыннан чыгып, аның каршысына ук килеп басты һәм әкрен генә картның йөзенә иелде.

Мөстәкыйм карт рәхәтләнеп йоклап утыра иде.

— Менә, күрдеңме? — дип рәискә борылды бригадир.

Рәис кәефләнеп көлеп җибәрде.

— Ай, мондый бабайларым күбрәк булсачы,— диде ул, көрсенеп, һәм җитди тавыш белән бригадирны кисәтеп куйды.— Мөстәкыйм бабайга тел тидерәсе булма моннан ары. Чыбыркылата торган карт түгел ул. Әйдә, тынычлыгын бозмыйк, йокласын...

Икенче көнне иртән иртүк, җәйге кыска төннең шәфәкъ кызыллыгына ялганган алсу таңы сызылуга, Фагыйлә йортының ян тәрәзәсе төбендә Мөстәкыйм картның көр тавышы яңгырады:

— Фагыйлә кызым, тор инде. Көне бик матур, йоклап ята торган чак түгел! — дип кычкыра иде ул.

*1943*

ИСКӘРМӘ

Татар әдәбиятының олпат шәхесләреннән берсе Мирсәй Әмирнең (1907—1980) бу хикәясе бик тә бәхетле. Ни өчен? Чөнки хикәядә, әдипнең бөтен иҗатына хас булганча, ихласлык, кем әйтмешли, ярылып ята. Язучы дәһшәтле сугыш вакытында да елмаюның-көлүнең файдасы булуын остача тасвир кыла — хикәянең очлануына игътибар итегез. Әйе, Мирсәй абыйның елмаюы-көлүе үзенчә. Һәм үзебезчә! Татарча!

Хикәя беренче тапкыр 1943 елда «Совет әдәбияты» журналының («Казан утлары») 9—10 нчы санында басыла. Язучының күп кенә җыентыкларына кертелә. Соңгырак басмасыннан берсе — «Исеңдәме...» (1972 ел) исемле китабында. Шунысы да язучы осталыгына дәлил — хикәянең беренче басмасы белән соңгысы арасында аерма юк диярлек, берничә сүз төшерелгән. Хикәя язучы өч томлыгының (1966—1967) өченче томыннан (1967) алынды.

## МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВКА 50 ЯШЬ



# Мөдәррис Әгъләмов

## ТӨРЛЕ ЕЛЛАРДАН

### Утлар-көннәр

*Көннәр яна-сүнә тора*
*Утлар сыман,*
*Яна-сүнә: ә мин тагын*
*Юлга чыгам.*

Артта калды Казан, мин менә
Башны куеп тәрәз җегенә,
Карап торам төнге йортларга,
Берән-сәрән янган утларга,

Утлар-көннәр артта калалар,
Күзнең явын алып яналар,
Юл читенә басып, юкәләр,
Артка таба йөгереп үтәләр.

Күз кыса да кача утларым,
Сәфәрендә эше юк аның,
Табигатьнең бар үз мәгънәсе —
Көзге муллык теле һәммәсе.

Ә соң нәрсә җитми кешегә,
Күчәнә дә һаман күчәнә...
Сәфәрнең дә бар үз мәгънәсе,—
Бәхет теле җирнең бәндәсе.

Без бармыйбыз җиргә сер сөйләп,
Әйтерсең лә, бара табигать,—
Табигатьнең без бер кисәге,
Утлар-көннәр...
Гомер исәбе.

*1965*

## Җир башы

*Каз канаты каурый-каурый,*
*Җил каерсын оченме...*
*Җилләргә дә, елларга да*
*Бирмим синең исемне.*

Җирне иңләп яңгыр яуганда,
Төн үткәрдек сары саламда.

Тәгәрәде яшен җир буйлап,
Тып-тын гына яттым җыр уйлап.

Туңуларны, әйе, оныттым...
Сине җанга салып җылыттым.

Җылындыңмы икән, белмәдем,
Сәяхәттә йөргән көннәрнең

Иң яктысы калган шул якта.
Нәрсә уйладың син шул чакта?

Яшен айкап торды җир башын,
Җир башыннан таптым җыр башын...

Синең сөю булып ул яшен
Йөрәгемне телгән, күрәсең.

*1965*

## Юлдашым

*Бу юл кемнеке?*
*Бу җыр кемнеке?*
*Юлыннан атлыйм.*
*Җырын кабатлыйм.*

Толымнары суга чумган,
Чыланадыр тал-чыбык.
Юлга чыксам, иләм суга
Талчыбыктай талчыгып.

Елгаларым изге шул,
Әкияттәге күзге шул.

Кояш көйдергән көннәрдә
Күңел эзли күләгә;
Урманнары юлга чыга
Яндым инде дигәндә.

Урманнарым — пакь чатыр.
Оялмый кунак чакыр.

Ваем юар дип, кайгым бар дип,
Ярты юлда туктама!
Вайларыма дәва булып
Телләремә җыр тама.

Халык җыры — юл башым.
Халык җыры — юлдашым.

*1969*

## Җил дә җил

*Карадыңмы үткән көнгә,*
*Лаекмы син бүгенгегә?*
*Шундый сорау бирә-бирә*
*Яши кем дә егермедә.*

Җил дә җил бүген,
Җил дә җил...
Чаганнар аягүрә.
Тынгысыз җилләр йөрәккә
Иртә дә кич тә керә.
    Йә юллар җыры булып ул,
    Йә толлар җыры булып
    Керә дә
    Гадәти юлдан
    Уйларны китә борып...
...Үткән чорлардан яңгырый,
Ишетелә әллә кайдан.
Яңа буын. Яңа заман.
Яңа көч. Яңа мәйдан.
    Мәңгедән шулай килгәндер
    Кичеп буыннар аша:
    Кешелекнең каршысына
    Давыллар чыгып баса.
...Тынгысыз җилләр йөрәккә
Иртә дә кич тә керә...
Җил дә җил,
Чаганнар түгел,
Заманнар аягүрә.

*1965*

## Үләннәр яшел иде...

*Сойгән онытыламени?*
*Кулмәкләр уңа җилләрдә,*
*Кеше дә уңамени?*

Поездлар үтеп тора,
Йөзне җил тели, йөрәктән
Кайгылар китеп тора.

Барыбер әрни яра,
Хәтерем төннәр буена
Йөрәктә учак яга,

...Үләннәр яшел иде,
Сөюем килде дә миңа,
Җаныңа яшер, диде.

Мин күккә чөйдем аны,
Яшен булып яшьнәде дә...
Күмергә калды бары.

Поездлар китеп бара,
Ә сөю китми, сабый күк
Могҗиза көтеп тора.

*1968*

## Ярсу

Толпар бирегез миңа,
Бирегез көмеш йөгән...
Улмы хыянәт иткән,
Улмы ятларны сөйгән?

Толпар бирегез миңа,
Тамсын мәхәббәт яше.
Өзелсен өзәңгеләр
Үзәгем өзелгәнче.

Толпар бирегез миңа,
Кыйссалар буйлап чабыйм;
Үземнең сөюемә
Тиң булган сөю табыйм.

Толпар бирегез миңа,
Бирегез яхшы ияр...
Өметем, калма миннән,
Син минем белән ияр!

Толпар бирегез миңа,
Бер чабыйк томырылып...
Йөрәктәге кайгылар
Калганчы умырылып.

Толпар бирегез миңа!
Кешеләр,
Ник дәшмисез?
Мәхәббәтемне аңларга
Әллә артык картмы сез,
Әллә артык яшьме сез?!

*1969*

## Язгы киңлек

Шундый бер хис туа бу киңлектән,
Әйтерсең лә, инде менә күптән
Бер яфрак булып йөзгәнбез дә...
Ул җир дигән ярга килеп җиткән —
Кузгалган да ерак чиксезлектән.

Бу дәрьяда ничек югалмаган?
Ничек туктамаган талга ләгеп?
Йөргәнбез күк миллион еллар буе
Елга яры эзләп, бәргәләнеп —
Кайда булган шәрык, кайда гареп?

Аерып булмый офык белән суны,
Офык белән суның чиге беткән.
Әле ярый җиргә юлыкканбыз...
Шундый бер хис туа бу киңлектән,—
Тагы кемнәр килә чиксезлектән?

*1970*

## Уйна, курай

Уйна, курай, үзәкләрне өздер, курай,
Яман уйларым булганда, биздер, курай...
Томырылып чапсын атлар, тынсын ятлар,
Иксез-чиксез, сахраларны гиздер, курай...

Тынып торыр бу хәятнең зилзиләсе...
Өзелсен лә бәгырьләрнең өзеләсе...
Сөрән сала кем ул анда?
Безнең җанга
Ташкын керсен — далаларның җил-җиләсе.

Бездән киткән ярлар үксеп еласыннар,
Мәнсезләр дә бер кычкырып уйласыннар.
Ярты җаным синдә бугай, уйна, курай,
Ятлар арага керергә кыймасыннар...

Синдә җилләр уйнаганнар ярсый-ярсый...
Син җыр башы, табигатькә моңнар башы.
Уйна, курай, үзәкләрне өздер, курай,
Әйтсен гавам: вәт нәгаләт, кыр курасы.

*1971*

## Гомер җыры

Насыйп булган һәммәсе бу гомергә;
Туры килде сүзләрдән җыр үрергә.
Кайсы калды туганчы ук күмергә,
Кайсы калды асылынып телемдә.

Асылынып калды телдә сүзләрем
Дар агачына асылган чәчәндәй...
Мин әйтергә теләмәгән сүзләрнең
Ияләре мыжгыды янәшәмдә.

Булды насыйп бу гомергә һәммәсе,
Түзсә түзә ябай хода бәндәсе.
Үземнеме, чит-ятнымы җәлләсе,
Катты каным, өшеп йөрәк пәрдәсе.

Ни яшем юк, катты каным, чын менә!
Елгада туңган боз кебек ул тынтан...
Ә эчтә моң, илаһи бер хәрәкәт
Боз астындагы су кебек агышта.

Бу гомергә һәммәсе булды насыйп,
Тик булмадык нигездә артык кашык.
Китмәсәк тә җиде күкләргә ашып,
Бәллүр җирдә калдык без туры басып.

*1972*

## Төнге сулар

Ничә күрмим төнге суны —
Төнге сулар гел борчулы...

Аларда бит көн буена
Кем балыкта, кем коена,
Кем ял итә, кем туена.

Ничә төшмим — төнге сулар
Ярга тиеп авыр сулар...

Телем-телем йортлар сына,
Телем-телем утлар сына...
Ул кем әйтә: сулар тына?

Ничә күрмим — төнге сулар
Күкрәгеннән җылы чыгар...

Күтәрелә җылы томан,
Җәйләрдә дә һаман туңам,
Туңа дөнья Тукай сыман.

Төнге сулар, төнге сулар,
Төнге сулар гел моңсулар...

Моңы барның йөрәгеннән
Һәрвакытта җылы чыгар.
Соңга кадәр үзе туңар.

...Ярга тиеп төнге сулар
Кеше кебек авыр сулар...

*1974*

## Күзгә ялвару

Һәм ничә күздән соң
Без тагын бергә,
Бары түң йөгергән
Ялангач җиргә.

И язмыш, тагын бер нәкъ шушы көздә
Сына син безне!
Сына син безне!

Сүзләр үз, күзләр үз —
Нәрсәдер үзгә...
Барыбер булмадык
Бер-беребезгә...
И язмыш, соңгы кат нәкъ шушы көздә
Тыйма син безне!
Тыйма син безне!

Күпме уй-хыяллар
Әйләнгән көлгә,
Калганы без булып
Керәчәк гүргә.
И язмыш, тагын бер нәкъ шушы көздә
Кыйна син безне!
Кыйна син безне!

*1976*

## Күкрәгеңдә аның ике кош...

Мин кайтырмын әле... Ниләр димә,
Үз дигәнчә бара бу тормыш.
Мин кайтырмын... Иркәләүне белә
Синең күкрәгеңдә ике кош.

Иреннәрең кötә янып-көеп,
Ишетермен үпкә сүзләрен.
Борының көтә — Һималайдан биек,
Аннан биек — яна күзләрең.

Адымымны мин бүгенге юлда
Кыйгач кашларыңнан башладым.
Бик әйләнеч булыр кайтуым да,
Әйтеп тора кыйгач кашларың.

Ә барыбер мин кайтырмын әле,
Гомер кичерсәң дә кай якта,
Аякларда дөреслек юк, диләр,
Ялган!
Йөрәк кушканныкы аякта!

Мин кайтырмын. Рәнҗү калдырырдай
Гаепләрем булды минем дә.
Тел сөяксез, ни сөйләмәс, диләр,
Ялган!
Сөеп исергәннең — телендә!

Тормыш шулай,
Синең синең бар ул,
Минем әле тагын минем бар.
Мин кайтырмын. Барыбер йөрәгеңдә
Мин ясаган кара миңең бар.

Кара миңеңминем кара кыз,
Яшь егетләр! Бик сак карагыз,
Күкрәгендә аның ике кош!
...Әнә шулай бара бу тормыш.

*1985*

## Синең кулда каләм...

Үзең!
Үз теләгең белән
Үз тамгаңны киртләгән —
Тукталып калмаска тиеш
Халкың тапшырган каләм!
Үз сукмагың!
Үзең салдың,
Беркем көчләп кертмәгән.
Карасы бетсә, каның бар —
Халкың тапшырган каләм!

Ата-бабаң беркайчан да
Уракка кичекмәгән.
Син дә кырда. Синең кулда
Халкың тапшырган каләм.

Җырны чикләмәгән вакыт,
Ә гомерне чикләгән...
Рәнҗеп туктамасын
Сиңа
Халкың тапшырган каләм!

*1983*

## Мин әйттем...

...Стенага терәп
сорый Кирәк —
тамагы киң аның Кирәкнең...
Рәсәй кешесе дә кеше кебек
бер яшәргә тиеш:
— МИН ӘЙТТЕМ!

...Тыелып торган чишмәләр күп иде,
рәхмәт, Заман,
ачтың, киңәйттең...
Калганнары миннән соңгыларның
Әйтер сүзен көтә:
— МИН ӘЙТТЕМ...

...Бер дә гаҗәп түгел яманлыкка
әйләнүе яхшы ниятнең...
Яманлыкның гына
яхшылыкка
әйләнүе булмас:
— МИН ӘЙТТЕМ!

...Үз яры бар хәтта тал-тирәкнең,
ник булмасын һәрбер йөрәкнең...
Эзләп,
        табып,
                югалтып ла кара —
син дә саргаерсың:
— МИН ӘЙТТЕМ!

...Еламаска өйрәтүең белән
шигырь язарга да өйрәттең...
Рәхмәт, язмыш,
                илгә һәм халыкка
әйтер сүзле иттең:
— МИН ӘЙТТЕМ!

...Тарту безнең нәселдә юк иде,
ә мин, җүләр,
                байтак көйрәттем...
Илне яклап көрәшмәгәннәргә
илне тарту хәрам:
— МИН ӘЙТТЕМ!

*1990*

## Сүз җибәрдем

Сүз җибәрдем... Бәлки, дидем,
Сусаганга әйбәт булыр...
Теле кычытканнарына
Гайбәт булыр.

Сүз җибәрдем... Яхшыларга,
Бәлки, әле яхшы булыр...
Ачылмыйча яткан күңел
Бер ачылыр.

Сүз җибәрдем... Яманнарга
Табылачак анда яман.
Яманлыкны кылганнарга
Шул сүз таман.

Сүз җибәрдем... Мәгънәле сүз.
Ул — шулкадәр кирәк кайчак,
Күлне — балык, илне халык
Болгатачак.

Сүз җибәрдем... Гаебем зур.
Яратмыймын болгатуны.
Күлне — балык,
Илне халык болгатачак,
Мин — ил улы.

*1990*



# ДУСТЫМНЫҢ УН ХАТЫ

Саҗидә
минем якын дустым,
сердәшем иде.
Без аның белән
китаплар бүләк итештек,
хатлар алыштык.
Иң сагындырганы —
ул Казанга килгәч,
күрешеп сөйләшкән
сәгатьләр булды.

Гадәттә ул «Татарстан» кунакханәсендә урын ала иде. Күп вакытын безнең өйдә үткәрде, дисәм дә ялгышмаммдыр. Инде улым да армиядә булганлыктан, өч бүлмәле иркен фатирда үзем генә яшәгән чаклар да бар иде. Иртән мин эшкә китәм. Ә Саҗидәгә тыныч фатирда иркенләп эшләргә бөтен мөмкинлекләр бар. Чыгып яткан китапларының корректураларын укыганы, каләмдәшләренең киңәшләреннән соң кульязмаларын карап утырганы булды. Кирәксә, телефон да өстәл өстендә генә. Редакцияләрнең теләсә кайсына шалтыратырга мөмкин. Язучы дус-ишләр белән дә сөйләшеп алырга була. Саҗидә бит ул Казанга кунак булып, яки юктан вакыт үткәрү өчен генә килми. Ул эшләргә, иҗат итәргә килә Казанга. Ә язучының иҗат оешмаларына йомышы бетеп тормый.

Кич белән кабат очрашкач, төннәр буе сөйләшеп утырган чакларны бик еш искә алам. Сөйләшергә татлы кеше иде Саҗидә. Ул бер вакытта да шәхси тормышында казынырга, эч серең алырга тырышмый. Аның алдында син үзеңнән-үзең ачыласың. Һәм бер вакытта да моңар үкенмисең. Чөнки ул кеше серен ихтирам итә, саклый белә торган кеше иде.

Кайчагында ул бер-ике көнгә югалып тора. Мондый чакта аны язучыларның Аккош күлендәге иҗат йортыннан эзләргә кирәк була. Анда — Хәсән Туфан, анда — Сибгат Хәким, Гомәр Бәширов — шунда... Алар белән бер сөйләшеп утыру үзе бер гомер. Саҗидә укырга дип шигырьләр алып килгән була. Өлкәннәрнең фикерләрен тыңлап, канатланып кайта да, тагын бикләнеп, эшләргә утыра.

Кунак йортындагы бүлмәсендә ул каләмдәш дуслары белән җыелышып утыру өчен кайта. Хөрмәт иткән шагыйрьләре Нури Арслан, Илдар Юзеев, Шәйхи Маннур, Шәүкәт Галиләр хозурында Әлмәттә язып килгән шигырьләрен укый. Кешеләргә шигырьләрен укырга ярата иде Саҗидә. Хис белән, күңелдән укый иде. Әмма үзе бер вакытта да тыңлаучылардан фикерләрен сорап йөдәтмәде. Язганнарының тәэсир көчен ул аларның күзенә карап белә иде булса кирәк.

Иҗатына ышану көче зур иде аңарда. Тәнкыйтьчеләрнең фикерләрен хөрмәт иткән очракта да әсәрләрен яклый ала иде. Чын талант иясе генә каләменнән төшкән һәр сүзенең кадерен шулай беләдер, мөгаен. Саҗидәнең миңа язган хатларында холкының бу ягын ачык чамаларга мөмкин.

Аның мин яраткан тагын бер гадәте бар иде — тормышның вагына-төягенә артык исе китмәде. Бу яктан алар ире булган шагыйрь Әдип Маликов белән нәкъ бертөсле иделәр. Ялга да санаторийларга түгел, иҗат йортларына гына йөрделәр. Яңа әсәр язып кайтсалар, яки күләмлерәк әйберне башлап куйсалар — елның иң әйбәте шул иде алар

**өчен. Сажидә Ялтадагы иҗат йортына барырга ярата иде. Миндә аның шуннан язган берничә хаты саклана.**

**Елга берничә тапкыр күрешеп, очрашып торсак та хат язышуның да хаҗәте чыга иде шул. Мин аларның берничәсен Сезгә дә тәкъдим итәм, хөрмәтле укучылар. Шигъриятә һәм прозада бик әйбәт әсәрләр калдырып, арабыздан иртә киткән моңлы да, тыйнак та һәм, иң кадерлесе, гаять талантлы булган Сажидә Сөләймānованың эчке дөньясын, уй-фикерләрен, борчуларын бераз чамаларсыз дип уйлыйм.**

**Ләбибә ИХСАНОВА.**

Ләбибә!

Мәскәү күгендәге йолдызлар санынча сәлам! Съезд шәп үтте, Сезне СССР язучылары съездына делегат итеп сайладык. Бүген Кремль Сараенда кабул итәләр, шунда барырга җыенабыз. Делегатларга ихтирам зур. Тик минә кунаклар гына бераз читләтелделәр. Ибраһим абый, Әмирхан Еникиләр алдында миңа бик уңайсыз. Аларның гостиницалары да хәтта читтә булды.

8 март көнне бөтен хатын-кыз делегатларга букетлар бүләк иттеләр. Һәм бүген кич Большой театрга тантаналы кичәгә чакыру билетлары тапшырдылар. Менә хатын-кыз булуның әйбәт яклары!

Хәсән абый өчен «День поэзии» һәм Марзияның заказын да, зинһар өчен, син тапшырырсың инде. Бергә генә төреп җибәрербез. Соңлап булса да беренче Яз бәйрәме белән тәбриклибез.

**Сажидә, Әдип** *(хат Сажидә кулы белән язылган — Л. И.)*
*8 март, 65 ел.*

Ләбибә, исәнме!

Мин менә Ялтада ялда. 7 нче августка чаклы биредә булам. Чит җирдә хат аласы килгәнгәме, әллә болай гынамы — сиңа язасы килеп китте.

Синең Ялтада булганың бармы икән, мин беренче тапкыр. Гомумән, диңгез буенда икенче тапкыр. Диңгез искиткеч, чыгасы килми. Яр буенда басар урын юк, шул чаклы халык. Шул чаклы сафлык һәм зәңгәрлек каян килә икән ул диңгезгә дип аптырыйсың.

Ялта — матур гына шәһәр. Хәер, урам тулы төрле төстә, төрле холыклы халык, шуларны күзәтеп, шәһәрнең матурлыгына игътибар итеп тә булмый. Шәһәр ыгы-зыгы эченә кереп югалган. Вывескалар украинча язылган, товарлар Украинаныкы. Кырымга килеп, Украина вывескалары укып йөрү сәер кебек. Эч пошыргыч сәер. Безнең строй һәм оятсыз оккупацияне икесен янәшә куеп булмый әле, күнегелмәгән.

Монда чәчәкләр матур. Безнең якның бүлмә гөлләре урамнарда үсеп утыралар: яран, тамчы гөлләр, зәйтүн гөлләре. Минем нәнәй үстерә торган гөлләр, болын чәчәкләре: йөзьяшәр, ромашка, күгәрчен күзләре бездәгедән бераз эрерәк булып газоннарда үсеп утыралар. Иң көтелмәгәне — газоннарда кеше буе булып, шайтан таяклары энәләрен тырпайтып утыралар. Чәчкә дигәне йодрык зурлык. Бездә генә почет юк икән аңа.

Таныш язучылар очратмадым әле. Үзегездә ни хәлләр? Нәшрият, идарә, журналларда ни яңалыклар бар (минем игътибарга лаеклы)? Үзең кайчан ялга барасың? Ни язасың?

Иптәшләргә сәлам.

Берәр хат язып җибәр әле күңел өчен.

**Сажидә,** *15 июль, 66 ел.*

Ләбибә!

Син молодец, эшләп торасың, язып торасың, әйберләрең чыгып тора. Докладлар да ясыйсың җитмәсә.

Туган якларда булып кайту тәэсиреннән бер әйбер яза башлаган идем, ул торып тора әле, дөнья мәшәкатьләре белән бүленгән иде. Монда килгәч биш

кечкенә шигырь яздым. Бер-икесен сиңа җибәрәм. Укып кара әле, («Кипарислы Кырым». «Дулкыннар», «Тамчы гөл», «Севастополь», «Ялта», «Мәхәббәт фонтаны» дигән шигырьләрен салган иде. Л. И.)

Иҗат йортларында таныш язучылар күренми. Башкортстаннан өч кеше бар, алар да очраклы рәвештә путевка алганнар. Күбесе монда Киев, Харьков, Минскидан, гомумән, хохоллар. Бахчисарай фонтанында булганда экскурсоводларның шовинистлыгына исем китеп кайттым. Шуңа да инде бу тирәләрдә татарларга кырын караш. «Татар националистлары» дип Ай-Петрида партизаннар каберлегендә дә сөйлиләр. Бахчисарайда инде Кырым ханлыгын хурлауга кайтып кала. Бары хан гаремнарында һәм фонтаннар бүлмәсендә генә борынгы дөньяга барып керәсең. (Мин дүрт экскурсиядә булдым.)

Минем стихия — диңгез. Диңгездә бөтен борчулар, бөтен кайгылар онытыла. Син дә, диңгез генә, дөньяда башка берни дә юк. Ләбибә, бер икәү килик әле, сөйләшеп. Язучыга аз гына семья мәшәкатьләреннән арынып тору да кирәктер. Минем ял йортларына, санаторийларга йөргәнем юк. Әдип белән бер Гаграга барган идек. Үзем генә беренче килүем.

Ярый, сау бул, дус-иштәргә сәлам.

*27 июль, 66 ел.*

Исәнме, Ләбибә дускай!

Менә ничек хат яза башладым бит әле мин. Ике көн элек кенә сиңа хат җибәргән идем, әллә нинди ахмаклыклар да язып бетердем бугай, күңелемнең нечкәргән чагына туры килгән, күрәсең.

Шигырьләр дә салган идем, бераз эшләнгәнрәк вариантын тагын җибәрәм. Эшләнеп бетмәгән килеш синең күңелеңдә калмасын, дим. Хәер, эшләнгән килеш тә калмавы мөмкин (күңелдә).

(Элек язган хатында «Севастополь» дигән шигыренең ахырына мондый искәрмә язган иде Сәҗидә: «Соңгы юлларда «юнәлеш алган» яки «кыләчәкнең юлын яктырткан» мәгънәсен әйтергә тырышам, ләкин чыкмый әле. Рифма мәгънәне җиңә. Бишенче шигырем Бахчисарай фонтаны турында. Ләкин шигырем кешене үзем тәэсирләнгән кебек тәэсирләндерә алмас шикелле.»

Бу хатында исә ул шигырьләренең яңа вариантын салган иде Л. И.)

Казан аша самолетка билетлар юк, Мәскәү аша кайтабыз. 8 ендә иртә белән юлга чыгабыз. (Мин туганымның хатыны белән монда).

25 августта «Азат хатын» журналының 40 еллык юбилее икән. Шунда мине дә чакыралар имеш дигән хәбәр ишеттек. Әйбәт булыр иде, Казанга күптән барган юк бит. Җәлил һәм Тукайларның юбилейларына да барып булмады. Ләкин Казанга буш кул белән бару бер дә кызык түгел. Ә яңа әйберләр югырак әле. Бик аз. Кайда булса да тәкъдим итәрлек түгел. 1968 елның планына бер җыентык тәкъдим итәргә исәп. Башлаган бер әйберне бетерәсе бар. Балалар нәшриятына да дүрт шигырьдән торган бер китап бирергә ният бар иде әле, ничек булыр.

Үзеңә уңышлар, тормышыңда иминлек телим. Язучыларга күп сәлам.

**Сәҗидә,** *28 июль, 66 ел.*

R. S. Тагын бер шигырь өстим. Анысын тиз генә яздым, бигайбә.

Исәнме, Ләбибә!

Хатыңны алдым, рәхмәт. Син отпускада ятасың икән әле. Язып буламы? Балалар ни хәлдә?

Без үзебез дә тырышабыз әле (языштырабыз дигән сүз), Әдип бер авыл турында цикл яза. Әйбәт кенә табышлары бар, хәтта көнләшерлек.

«Казан утлары»на яңа ел башында ике дистәдән артык шигырь җибәрдем, Нурый абый адресына. Ул өйдәме икән, юкмы икән, белмим. Шушы айның егерменчеләрс тирәсенә үзем Казанга барып чыгарга да исәпләп торам. Шигырьләрнең кайсын кая урнаштырырга кирәк булыр. Журналга алсалар аның 5—6 сыннан артыгын алмаслар. Гомумән яраса әле.

Бик кызыксынып «Мөдир Сәҗидәне» укыдык. Нурихан молодец. Авыл кешеләрен шул кадәр дә дөрес бирер икән. Шигырьләрдән бу арада әлләни күренмәде.

Съездны без февральдә була дип көтә идек, шулай мартка калдымени? Хәзерге көндә мин тарих турында уйланулар язып маташам. Бик абстракт чыгармы икән инде. Авыр бара. Мондагы иптәшләр һәркайсы үз эшләре белән мәшгуль, күптән җыелып очрашкан юк. Яңа елны да һәркем аерым каршылады, Октябрь юбилеен да. Гамил өйдә генә ята, соңгы вакытта тарихи личностьлар

турында ике легенда язды (берсе Аксак Тимер турында). Рафаэль сез кире кайтарган повестын камилләштерә иде, бәлки бетергәндер инде. Әлмәт театры Сәетнең бер пьесасын алырга вәгъдә иткән, шуны кызулый. Гариф сезнең журнал күптән шаулый торган романы өстендә утыра бугай. Күргәнегезчә, беркем дә вакытын бушка уздырмый.

Эшкә кайчан чыгасың?

Безне сораган-белгәннәргә күп сәлам.

Иҗатыңда уңышлар, һәр төрле шатлыклар теләп Саҗидә.

Әдиптән сәлам.

*11/I—68 ел.*

Саумы, Ләбибә!

Нихәлләрдә яшисез?

Без Кырымнан йөреп кайттык. Коктебель бик ошады, таулары, диңгезе. Казаннан ял көне уздык, журналга кереп булмады. Куна калмадым инде, өйдә малай бар бит, тизрәк аның хәлен беләсе килде. Ул безнең кайтуга кабак боткасы пешереп, мунча ягып куйган. Гомумән, әйбәт яшәгән. Үзен классның комсоргы итеп сайлаганнар.

Мин сиңа теге «Әс-сәләми» буенча сүз катмакчы булам. («Әс-сәләми, Суфият» повесты. Л. И.) Журналда чыкмастай әйбер түгел кебек күренә үземә. Редколлегиядән Сибгат абый укыйм дип калган иде, аңар бирә алдыгызмы? Редколлегиядән (редакция сотрудникларыннан башка) бер-ике кеше укысын иде. Чөнки, дөресме-ялгышмы — редакциядә миңа караш начарланды дигән фикер яши (миндә). 71 елның Октябрь аена тәкъдим ителгән шигырьләр быелның беренче санына чаклы сузылып килде. Шулардан башка бүтән бер әйбер дә чыкмады быел. Ә бит редакторда Яхъя кулыннан үткән хикәя бер ел чамасы ята. Менә шуңа да редколлегия членнары объективрак килмәсләр идеме икән дип уйлавым. Рәнҗүем нахак булса, мин гөнаһлы.

«Әс-сәламдәге» үтмәстәй җирләрне кыскартырга мин әзер. (Эш шунда гына торса, ягъни базарның күберәк булуында.)

Хәзергә шулар.

Равилебез аспирантурага очно урнашкан икән, яңа кандидатура турында идарә фикерен көтәбез.

Изге теләкләр белән: **Саҗидә.**

*25/X—72*

(Хатның соңында сүз Әлмәт бүлегенең җитәкчесе Равил Фәйзуллинның, аспирантурага укырга керү сәбәпле, эштән китүе һәм аның урнына киләсе кешене белү хакында бара. Л. И.)

Саумы, Ләбибә!

Әлмәт якларыннан күп сәлам!

Әлеге дә баягы — мин теге әсәрне һич салып куя алмыйм, уемда шул гына, Р. Мостафинның хаты күзне ачып җибәргәндәй булды, ничек эшләү-төзәтү юллары ачыкланып китте. Ул киңәш иткән «Сад камней» китабын табып (сатуда беткән икән) укып чыктым, үземчә нәтиҗәләр ясадым. Корьәннең русчасын табып, кирәкле җирләрен укыдым. Менә тагын шул «Әс-сәләми...» өстендә уйланып утырам. Сызгалап-язгалап та алам.

Редколлегия членнарына укырга бирү сезнең фикер белән исәпләшмәүдән түгел, редактор бит бөтенләй басмау ягын каера. Кичә бездә Шамил Бикчурин булган иде, аңар да әсәрнең басылырлык түгел икәнлеген исбатлап җибәргән. Әйбер дөнья күрерлекме, түгелме — шул хакта миңа ышаныч кирәк. Идея позицияләре, сәнгатьчә эшләнеше ягыннан бу шул килеш тә төсмерләнергә тиеш. Һәр хәлдә басылыр-басылмаслыгы билгеле булырга тиеш. Әсәрнең сюжет канвасы шулай калыр, йөргәнне-күргәнне дә язмый булмас, уйланулар артыр. Андагы һәм мондагы тормыш турында. Юльязма-очерк белән повесть арасындагы бер жанр булырдыр ул. Гранинның «Сад камней»се шундыерак.

Редколлегия членнары ни әйтер тагын. Үзем, югыйсә, кул кычытканнан түгел, ә укучыга җиткерәсе сүзем булганча язган идем. Чигенергә исәп юк. Миңа бит вак мещанлык һәм аполитичность маркасы ябыштырып маташалар.

3 нче санда тапшырылган хикәя кердеме соң?

Син ялга да китеп барырсың инде. Язган әйбернең язмышы кыл өстендә торгач, минем ял ял булмады.

Сиңа әйбәт ял насыйп булсын!

**Сажидә.**

*1/XII—72 ел.*

(Мисырга сәяхәт кылып кайткач, Сажидә «Әл-сәләми, Суфият» дигән әсәр язып «Казан утлары»на биргән иде. Редакция хезмәткәрләренең әсәрне укып чыккач әйбәт фикерләре авторны ышандырып җиткермәде. Шуның өчен редколлегия әгъзаларының күбәрәгенә укытуыбызны үтенде, хәтта шул әсәр турында сүз бара. Л. И.)

Ләбибә дустым, саумы!

Исән-сау кайтып җиткәнсездер дип өметләнәм. Дөньяның олы вә вак мәшәкатьләрен ташлап, Октябрьнең пыялаланган юлларыннан минем бәйрәмгә килүең өчен тагын бер кат рәхмәт. Сез килмәсәгез, бүтән дуслар килмәсә, ул бөтенләй дә бәйрәм булмас иде. Сезнең белән ул күңелле үтте. Сүзләре купшы төсле булса да, ихлас әйтәм. Баш-күз әйләнгән чак, аерым игътибар күрсәтә алмадым. Минем иҗатка игътибар күрсәтеп торучы журналның ир-егетләренә синең белән күчтәнәч җибәрермен дип әзерләп куйган идем, анысы да онытылган. Китүегезнең вакыты билгеле булса да, китү ашыгыч булды, кәефләнеп алган агай-эне (үзебезнекеләр) кайнашты әйләнәмдә. Ярый, бар да имин узды. Бүген иртән Ш. Бикчурин шалтыратты, рәхмәт әйтә. Андый юбилейны күргәнем юк иде әле, ди. Кунак өендә номерын тапшырмый киткән икән, паспортын да алмаган (гаҗәп, үзәк шәһәрләрдә паспорт кунакның кулыннан алынмый бит), шуны алырга үтенә. Аның өчен борчылып торган идем, кайтып җиткән икән, шөкер. Мәхмүт Х. хатыны белән иде, аның өчен кайгырмадык. Шулай итеп, бәйрәм мәшәкатьләре узып китте. Энҗенең ире дә шалтыратты: шагыйрәбез егылып кулын авырттырган икән, шуңар килә алмаганнар. Гафу үтенде. Сине чакырган сыман ук чакырган идек.

Венерага, әниеңә, гаиләңә күп сәлам. Журнал егетләренә, Зәкигә сәлам һәм рәхмәтләребезне тапшырсана.

**Сажидә.**

*15/X—76 ел.*

(Сүз Сажидәнең 50 еллык юбилее турында бара. Л. И.)

Саумы, Ләбибә!

Яңа ел белән тәбриклим!

Яңа ел яңа куанычлар алып килсен!

Син берәр яры киткәнсеңдер, ялдадыр инде, хатымны кайткач булса да укырсың.

Минем хәлләргә килгәндә, соңгы айларда шифаханә юлларын таптадым. Мондагы хирург мине бик куркытты, операция ясатмасаң 1 яки 2 (күп дигәндә) ел яшисең калган, диде. Дөресен әйтергә кирәк, бик борчылдым. Яшисе килә. Дәваларга салганнар иде, хәлем бик начарланды, туктаусыз коса башладым. Тагын Казанга җибәрергә уйладылар, дәвалауны туктаттылар. Бураннар башланып Казанга бара алмыйчарак тордым, кайбер язу-сызу әйберләрен караштырдым, чәчелеп-сибелеп калмасыннар, дип. Шул көннәрдә Гәрәй килеп китте (Гәрәй Рәхим. Л. И.), повестьны кыскартып... («Гөлбадран» повесты турында сүз. Л. И.)

Инде Казанга билет та алган идем. 19 декабрьдә «Азат хатын»да редколлегия утырышы да икән, катнашырмын дигән идем, дәвалануны туктаткач, хәл ярыйсыга әйләнгән иде. Әлмәткә Казан каласының баш хирургы, фәннәр докторы Розенгарден (фамилиясен дөрес белмим.) киләчәк, аңа күрсәтәбез, беркая да барма, диделәр. Менә бүген аңа күрендем. Гаҗәп тә инде бу хирурглар, фикерләре бер-берсенә бөтенләй капма-каршы. Казан хирургы берни тапмый. Операция кичергән һәр кешедә андый гына төеннәр (уплотнение) була ди. Берниндн операция турында да уйларга кирәкми, ди. Берәр биш елдан тагын очрашырбыз һәм шунда ни кирәклеге турында кабат сөйләшербез, ди. «Сов. Татария»да декабрь аенда чыккан шигырьләрне ошатуын әйтте, хәтта берничә юлын яттан сөйләде. «Без сине сакларга тиеш» дигән була. Ихлас сөйләгән сыман, мин ышандым диярлек. Минем хирург планнарымны җимерде җимерүен, эшкә дә

керәлмәдем. Болгариягә дә кәеф күтәрелмәде, шулай да ахыры хәерле бетүгә сөенәм әле. Киләчәк тагын нәрсә күрсәтер. Венерага күп сәлам.

**Сажидә.**
*19/IX—78*

Саумы, хөрмәтле Ләбибә!
Киләчәк бәйрәм белән котлыйм! Сау-сәламәт рухланып яшә!

Ләбибә, минем повестьны 4 санга күчерергә булгансыз икән, нигә инде? Бер күчә башласа, күчә дә күчә ул. Тагын кемнеңдер съезд алдыннан чыгасы килер, баш редакторга керер, уңай хәл итеп чыгар...

Мин Болгариягә китәргә булдым әле. Мине әле Казанга, әле Әлмәткә йөрттеләр врачлар. Уртак фикерләре юк. Шуннан файдаланып, сәяхәткә чыгып китмәкче булдым. Исеңдәме Вл. Солоухинның «Приговор»ы? Күзгә карап авыруны белә торган карт Болгариядә бит? Аның янына Вл. Солоухин бер язучы хатын белән бара, ул хатын да операция кичергән була. Эх, исемнәре истә калмаган, журналны хәзер генә каян табасың... Болгариядә шул картны эзләп тапмаммы әле...

23 ендә Казанда булабыз, шул ук кичне Мәскәүгә китәбез. «Татарстан» поезды беләндер. 24 ендә поезд белән Болгариягә чыгып китәбез. Изге теләктә кал.

Уңышлар теләп, **Сажидә.**
*21/X—78*

(Бу — Сажиденең соңгы хаты. Сәяхәттән ул күтәренке күңел белән кайткан иде. Ике яшь кешенең мәхәббәте турында күңелемдә бер лирик повесть туып килә, дип тә сөйләде. Ләкин мәрхәмәтсез авыру аның тормышына ерып чыга алмаслык киртә булды. Озакламый ул Казан хастаханәсенә кереп ятты һәм көннән-көн сула барып, мәңгелеккә китеп югалды. Л. И.)

# Сажидә Сөләйманова

## ШИГЫРЬЛӘРЕННӘН КАЙБЕР ҮРНӘКЛӘР

### Сөюмени

Юл йөрүме, тузан кунмаса,
каршы җилләр битең кисмәсә.
Кайнарлыгын көннең тоймасаң,
татлылыгын суның сизмәсәң.

Йөзүмени, киңлек кичкәндә
беләкләрең арып-талмаса.
Аргы якны кочып шатлыктан,
яшь үләнгә башың салмасаң.

Күз яшеңнең саф һәм ачысы
йөрәгеңне уеп төшмәсә,
сөюмени,
бәхет каршына
канатланып күңелең очмаса.

*1958*

* * *

Колачлап иңләдем
Агыйдел суларын.
Әллә син килмәдең,
әллә мин соңладым...

Дулкыннар кагалар
бер ярдан бер ярга.
Безнең дә аралар
охшаган шуларга.

Юлларда җилләрдән
җырларың ишеттем.
Әллә мин ашыктым,
әллә син кичектең...

*1959*

* * *

Киткәннәрнең юллары озын,
көткәннәрнең көннәре озын.
Йөргәннәргә ачыш-табышлар,
көткәннәргә — сагыну, сагышлар.

Сагыш коесыннан су эчим,
сөйгәнемнең юлларын үлчим.
Янадыр ул. Бәлки туңадыр,
эчеп бетералмыйм шуңадыр.

*1970*

* * *

Сынаулар үттең,
сынатма,
сокланыйм, калыйм хәйран,—
буйсындыр мине —
сындырма,
буй-сыным Урал-таудан.

Биклә дә мине үзеңә,
чикләмә сагың белән,—
җыр булып ташып чыгармын,
чыгышым Агыйделдән.

Атмый тор, оча бер лачын,—
ташкыннар, кошлар юлы.
Аккошлар күлләргә кунсын,
син Идел сыман олы.

Буй салам,
дулкын-уй салам,
буйсынам сынмасам да,

Аккошлар юлыдай елым,
күлләрдә кунмасам да.

*1974*

## Кояш бизәге

Мин туганчук яңа йолдыз туган,
женьшень үскән, көмеш табылган.
Миннән башка көзге бер яфракка
кимрәк булыр иде табигать.

Урманнарны ялгыз гына гизсәң,
шул яфракны танып өз әле —
язмыш дәфтәрендә балкып калыр
бөек рәссам кояш бизәге.

*1974*

* * *

Мин Зөһрәсе җырның, ә син Таһир.
Бәет кайда өзелсә дә бәхил.
Сихерләндем күзләреңә багып,
юк та иде шуннан олы бәхет.

Ә ул күзләр җир һәм күк йөзендә,
карый елга-күлләр көзгесеннән.
Йолдыз яна төннәр гөмбәзендә,
Күзләрендә утлар сүнмәсенгә.

Өзелмәсен, тукталмасын вакыт —
гашыйклыгым шул ук, җырым шаһит —
янам-көям җирне-күкне багып,
шуннан артык юк та инде бәхет.

*1977*

## Сабыр канатлары

Сабыр канатларым, сабыр канатларым...
Кулым сузып калдым, чапты пар атларым!
Тик ымсынып калдым, кыенсынып калдым,
сөйгәнемнән гүя нахак талак алдым.

Ыспай кунакларымы, оста каракларымы —
чыбыркылап куды чаптар пар атларны.
Янар инде атлар сугармаган килеш,
төнгелеккә калыр тугармаган килеш...

Йөгерә-атлый китәм җәйләүләргә таба,
җәяүләргә кала, җәяүләргә кала,

сыгылмагыз әле, сабыр канатларым,
бер йотымга сусап, кетәдер атларым.

Ир канаты аттыр, кыз канаты актыр.
Ак канатка атмас, булса ул чын батыр.
Бәлки эзләп тапкан чапкын туры атларны,
тугарылмый чапкан атлар яраткандыр.

Узалмыйдыр атлар тимер авызлыксыз...
Тик ямьлерәк иде дөнья явызлыксыз.
Канга тузсын тезләр, егыла-тора атлармын,
тик сынмасын гына сабыр канатларым.
Сабыр, канатларым.

*1978*

* * *

Җил иркендә сине күрдем,
җилкендем дә илердем.
Хыялдагы сурәтеңә
җан өрдем мин, өн бирдем.

Алиһәләр аһ иттеләр,
тал-тирәкләр яшь түкте.
Кем күпсенде, кем юксынды
күккә ашкан яшьлекне.

Алып очты җил-өермә!
Ераклашты тавышың...
Ак кәгазьгә кара сөрмә
булып төште сагышым.

Алиһәләр аһ ордылар.
Тал-тирәкләр яшь койды.
Таллар — суга, су — дәрьяга,
дәрья ярга ашкынды.

Шул мизгелдә син — сәгадәт.
Сизгер җанга — чын сәнгать!
Ярдан алдым, җырга салдым
сурәтеңне, мәхәббәт.

*1974*

## Төшен — төшкә

Бераүгә дә багышламый гына
үзем өчен язам, җан өчен.
Башта уйлар, җанда көйләр чыңлый,
очын очка кила ялгыйсым.

Җил иркенә чыгып җилгәрәсем
төшен — төшкә, чүбен — кибәккә.
Арыш басуының алкышлары
җанга иңә, тынны киңәйтә.

Башакларның бардыр бер исәбе,
күрәләрме әллә охшашлык? —
Уңыш туе өчен җилгәрелү —
ул, мөгаен, үзе бер шатлык.

Җиргә салган һәрбер бөртек тере,
яшәрерләр кабат язларын.
Башаклар бит алар тормыш өчен,
кеше өчен сала башларын.

Битне сыйпый арыш башаклары,
хатирәләр тынны киңәйтә.
Эш өстендә уйлар җилгәрелә
төше — төшкә, чүбе — кибәккә.

Яшь чакларым, алтын башакларым!..
Сорамадык хәтта кем өчен —
яшьтәшләрем янды яшәү өчен,
яшәү биргән туган җир өчен.

Үзем өчен генә җырлый алмыйм,
арышларым, сезгә багышлыйм.
Урган, чәчкән, яуда калганнарны
онытмасак, җырда ялгышмам.

*1978*



# ИХЛАСЛЫК — ШАГЫЙРЬЛЕК ТӘ...



**Әзһәр Габидине**
**күреп белгәннәр, әлбәттә,**
**аның самими, садә,**
**хәтта беркатлылыкка якын**
**ихлас җанлы булуын**
**сизми калмастыр;**
**әйе, бөтен гомере буенча**
**Әнкәбез-Шигърияткә гашыйк булып,**
**шигырь бакчасында**
**армый-талмый казынган,**
**тынгысыз кеше ул.**

Инде җитмеш яшен тутырган (26 сентябрьдә туган!) Әзһәр ага һаман сабыйларча саф, матур хыяллар, омтылышлар белән яши — мәңгелек бер гашыйк ул, билләһи! Ә гашыйклыкның, ихласлыкның икенче исеме — шул ук Шигърият ләбаса...

Сарман районының Чукмарлы авылында (1926 елда) туган Әзһәр Габидигә дә тормыш үзенең чукмарларынукларын аз тидермәгән югыйсә: әйе, яшүсмер көе сугышка керү, Ерак Көнчыгыш фронтында булу, японнар белән бәрелештә яралану, госпитальләрдә яту... Әмма шунда ир-егет булып чыныккан Әзһәр 1945 елда иң зур шатлыгын да кичерә: «Тревога» исемле фронт газетасы типографиясендә аның «Борылмалы юллардан» исемле шигырьләр китабы басыла. Инде ул китап авторы Әзһәр ага бу сөенечне бүген дә саклап йөртә, сугыштан соң озак еллар туган ягында укытучы булып эшләгәндә дә (ул татар теле һәм әдәбияты, тарих укыта. Шунсы да кызык: алты баласы да укытучы була аның!) ул шагыйрь булып яши. Яза, яза... 60 елларда аның «Без — яз дуслары», «Тапкырҗан табышмаклары» исемле китаплары чыга. Алар — балаларга адресланган. Ә зурлар өчен лирикасы — «Таң сәгате» (1994) китабына тупланган... Гомумән, соңгы елларда Әзһәр ага бик актив яза: газета-журналларда еш басыла. Ул — Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Шагыйрьнең исемен таныткан тагын бер өлкә бар бит әле: аның ихласлыгы каләмдәшләренең әсәрләренә, китапларына язган рецензияләрендә дә чагыла. Казан, Уфа матбугатында аның шундый 250(!) мәкаләсе басылган. Монда да ул — садә, шигырьгә мәңге гашыйк булып кала.

Юбилее белән котлап, без бу санда укучыларыбызга тәкъдим итә торган яңа шигырьләре дә шул хакта сөйли, шиксез, шуны раслый. Афәрин! дибез.

Рәдиф ГАТАШ.

# Әзһәр Габиди

## Аккошлар китә

*Хушлашырга безгә*
*иртәрәк бит әле,*
*иртәрәк бит әле, аккошлар.*
Равил ФӘЙЗУЛЛИН.

Көз житте инде, көз житте,
Аккошлар китә;
Ә күңелдә яшь үләннәр
Борынын төртә.

Көз житте инде, көз житте,
Кыраулар төшә;
Ә күңелдә әле һаман
Җиләкләр пешә.

Көз житте инде, көз житте,
Куера сулар;
Иртәләрен ак томанга
Төренә кырлар.

Бер җилпенеп шул томанны
Өзәсе иде,
Колачны җәеп суында
Йөзәсе иде.

Килми әле чалгыны да
Ялга куясы,
Пешкән шул җиләкләрне дә
Килә җыясы.

Хушлашырга иртәрәк тә...
Китә аккошлар...

Нигә ашыктыра икән
Безне язмышлар?!

## Җитмешенче көз

Җирдә атлый җитмешенче көзем,
Үзе матур, үзе шатлыклы;
Үзе шулай гүзәл булса да ул
Кич-иртәсе, никтер, сагышлы.

Җирдә атлый җитмешенче көзем,
Болытлары җырлы, шау-шулы;
Болыннары шау-шулы булса да,
Толпарлары гүя тышаулы.

Җирдә атлый житмешенче көзем,
Ташкыннары чыңлы, ярсулы;
Ташкыннары ярсулы булса да,
Гөрелтесе уйчан, моңсулы.

Җирдә атлый житмешенче көзем,
Мизгелләре күркәм, шат сынлы;
Юкка-барга сөрән сугып тормый;
Акыл җыйган, сабыр холыклы.

Җирдә атлый житмешенче көзем,
Калсам иде күп эш майтарып;
Җирдән алган бурычларымны да
Булса иде үзенә кайтарып.

## Туктама

Ярсу елга дулый,
Күңел алга ыргый,
Берсе әйтә: «Борыл»,
Икенчесе: «Омтыл».

Курку туктап кала:
«Карышмачы, буйсын»,
Өмет чыга алга:
«Маякларың янсын».

Давыл шаша тәмам,
Төн куера һаман,
Ә мин юлны тотам
Маякларга табан.

Омтылышы булса,
Сүрелмәсә өмет,
Бөтен авырлыкны
Җиңеп чыга егет.

Яшьлек хушлашса да,
Чаларса да чигә,
Йөрәк типкән чакта
Тукталырга нигә?!

## Сакласын иде

Җанга рәхәт бер моң белән
Шаулыйдыр урманнарым,
Әгәр эчләрендә йөрсәм,
Югала арганнарым.

Көмеш көзгедәй җемелди
Елгаларым, күлләрем;
Кояшка карап елмая
Чәчәкләрем, гөлләрем.

Тәмле хуш исен аңкыта
Җиләкле аланнарым,
Алсу гәрәбәдәй балкый
Миләшем, баланнарым.

Алтын дулкындай чайкала
Басуларым, кырларым;
Алтын көшелләре белән
Тулыдыр ындырларым.

Болар Табигать-Ананың
Сокландыгыч күркәм эше,
Аны шул гүзәллек белән
Сакласын иде кеше.

ШИГЪРИЯТ



**Камил Сәгадәт**

### Җан ярам

Көндезләрен шәм яндырып эзлим,
Төннәремдә айга ялварам.
Давыллардан йолып,
Упкыннарга аткан
Мәңге түзәлмәслек җан ярам!

Йөрәгемә якын кеше булып
Бөтен барлыгымны биләдең.
Күк капусын ачып кергән идем,
Айда дигәч, айга менгән идем —
Үзең дәштең, үзең килмәдең.

Ай янында якты йолдыз булып,
Зөһрә йолдыз булып син калсаң,
Хисләремнән ефәк баскыч үреп,
Синең янга мин дә менәр идем
Яннарыңда урын табалсаң.

Көндезләрен — шәм яндырып эзлим,
Төннәремдә айга ялварам,
Давыллардан йолып,
Упкыннарга аткан
Мәңге түзәлмәслек җан ярам.

* * *

Йөрәгемнең юлда арып-талып
Егылганы болай беренче.
Син бит Кояш!

Болыт арасыннан
Тик бер генә кабат күренче.
Елмаюың җанга сихәт бирер,
Елмаюың миңа — сөенче.

Горурлыкта шактый алдырсак та,
Алҗуларым болай — беренче.
Син бит — Кояш!
Болыт арасыннан
Тик бер генә кабат күренче.
Яратуда булмый җиңелүче,
Яратуда булмый
Җиңүче!

* * *

Сөюләр бит бар иде,
Канатлар да пар иде.
Эреде дә юкка чыкты,—
Хәзер ни ямь бар инде?

Атласам да абынам,
Уйланам, гел сагынам
Аклы күлмәкләреңне,
Затлы күлмәкләреңне.

Сагынам күзләреңне,
Төртмәле сүзләреңне.
Хис көлтәсе — чаптар ат,
Теләсәң күпме ярат!

Йолдыз кебек атылдык
Тормыш үзәннәренә.
Җан-йөрәкнең сызлавына
Ничек түзәргә менә?

Инде янә талпынам,
Шул чакларны сагынам.
Күмер түгел,
Көл калмаган
Яшьлекнең учагыннан...

## Халәт

Май кояшы балкышыдыр
Сезнең йөзләр,
Таң нурының чагылышы
Сезнең күзләр.
Көн дә күреп
Шул күзләргә багар идем,
Күңелегезгә сөю уты
Ягар идем.

Тәкәбберлек илә мине
Этәрсәгез
Башка мәңге
Барлыгымны
Сиздермәмен.
Янармын тик эчтән, әмма
Хисләремне
Яңа язлар өчен саклап,
Сүндермәмен.

Бу җыруны язган өчен
Гафу сорыйм,
Язмыйча һич
Түзә алмас
Хәлдәмен мин...
Ходай үзе ярлыкасын,
Күңелем саф,
Сөюемнең тоеп яшим
Ярдәмен мин!

* * *

Талгын күлдәге аккоштай идем,
Җил искән саен күлгә сыендым.
Җәйдән китмәдем. Көзне көтмәдем.
Мәңге яшәргә шулай җыендым.

Җил-давыл булып тузгып килдең дә
Сизми дә калдым — уратып алдың!
Уратып алдың, моңнарга салдың,
Тик нигә үзең бер читтә калдың?

Күлләр дә кипте синең утыңда,
Аккош җан бирде — синең учыңда.
Ә син битараф калдың барсына,
Мондый җәйләрне күңел тарсына.

Җәйдә син хәзер. Көзләр көтмисең,
Мәңге яшәргә шулай җыенып.
Талгын күлдәге аккошлар кебек,
Җил искән саен күлгә сыенып...

* * *

Сезнең якта алсу шәфакъ күрсәм,
Әллә ниләр уйлап сискәнәм.
Яна,
яна,
яна,
яна төсле
Минем йөрәк кебек, бар галәм.

Сезнең якта күксел томан булса,
Моңланасың, димәк. Сизенәм.
Сызлый,
сыкрый,
өзгәләнә күңел,
Онытып булмый икән тиз генә!

Сезнең якта бүген кара болыт,
Яшен кисә, кисә йөрәкне.
Ай, мәхәббәт!
Ай-һай, ялгыз яну
Өзеп карый икән үзәкне.
Биреп карый икән кирәкне!

Сезнең якта алсу шәфакъ күрсәм
Әллә ниләр уйлап сискәнәм.
Яна,
яна,
яна,
яна төсле
Минем йөрәк кебек, бар галәм...



# СЕР



**Гадәт-холкы белән
әйткән һәр сүзе
гаять тә
тәңгәл килә торган кешеләр
әлләни күп очрамый.
Әдип
һәм
шагыйрь
Рафаэль СИБАТ —
менә шундыйларның берсе.**

**Хәер, олысына, кечесенә карата гаять ихлас күңелле бу ир-егетнең күңелендә җәүһәрләр җемелдәшкәнен бер карауда гына сизеп булмый. Иң элек аның күңел тәрәзәсенә күз салырга кирәк...**

**Күрше Киров өлкәсенең Вятские Поляны районына караган Түбән Шөн авылы егете Рафаэль Сибат (ул чакта әле — Хуҗин) белән без Казан дәүләт университетына укырга керер өчен имтиханнар биреп йөргәндә, 1965 елның җәй ахырында танышып, бик тиз дуслашып алдык һәм шуннан бирле иҗади рухташлык безне бер сукмактан әйдәп алып бара.**

**Рафаэль тыелгысыз рәвештә, олы мөгаллиме һәм дусты мәрхүм Мөхәммәт ага Мәһди әйтмешли, тәмам арып, кулыннан каләме төшкәнче яза торган зат. Гадәттә, ул язганын кабат кайтып, төзәтеп тә маташмый — вакыты юк, аның хыялы яңа әсәр эчендә үрсәләнә...**

**Шушы арада ул бихисап шигырьләр, эссеистикага хас нәфис зәвыклы язмалар язып өлгерде. Җиде ел буена Малмыж районының «Дуслык» исемле гәзитендә эшләү дәверендә генә дә татарның иң кызыклы шагыйрьләре, әдипләре хакында француз Моруа эсселарын хәтерләткән язмаларын дөньяга туктаусыз чыгара килә. Мәсәлән, М. Мәһдиев, Р. Гатауллин, М. Әгъләмов, Зөлфәт һәм башкалар иҗаты хакындагы аның уйланулы язмаларын тәнкыйть мәкаләсе дип әйтергә һич тә күңел тартмый. Болар — үзләренчә бер әдәби әсәрләр. Бу юлы да «Казан утлары» журналының Рафаэль Сибатка 50 яшь тулуга багышланган сәхифәсенә Равил Фәйзуллинның өч томлык әсәрләре чыгу уңаеннан үзенең чор һәм поэзия хакындагы күләмле эссе-уйлануларын тәкъдим итте ул.**

**«Казан утлары»нда моңарчы аның «Ике гашыйк һәм җыр тыңлаучы ат» (исеменә генә дә сокланырлык!), «Текә күтәрелеш» исемле зур әсәрләре чыкты.**

**«Казан» журналында чыккан «Югалтулар табышы» повесте инде роман булып килә — аның икенче кисәге «Идел» журналында чыгачак. Рафаэль әле генә «Казан утлары»на «Исабәт» исемле романын китерде. Һәм — йөзләгән ихлас шигырьләр...**

**Рафаэль Сибатның шигъри талпынышы — сүзнең барлыкка килгән чорындагы саф хисен кайтарырга омтылу.**

**Рафаэль үзе һәм үзенең иҗади мохите, мәсләге хакында журналыбызның баш мөхәрриренә язган хатында болай дип тә куйган:**

**«Авылда яшәп иҗат итү бер яктан бик рәхәт: монда — Табигать, монда — Иркенлек! Ләкин... Әдәби мохит юк, аралашырдай кешеләр юк. Язганнарыңа профаннарча бәя бирүчеләр очрый анысы. Кайчак шуңысы рәнҗетә, хәтта җәберсенеп тә куясың: «Нигә язып интегәм соң мин!?» Шигырь китабы алып, Поэзия Сараена кулын юмыйча, аягын сөртмичә генә керергә азапланучы, үзләрен шигъри җанлы дип санаучы салкын йөрәклеләр өчен Шигърият Ишеге төбенә:**

— Шагыйрьләрнең горур вә яралы Җанына тимәгез!

— Аларның Нечкә Күңеленә кагылмагыз!!

— Илаһи Утлы Рухларын сүндерә күрмәгез!!! — дигән кисәтү-белдерүләр эләр идем.

Нишләрсең! Дөнья бу...

Тукай әйтмешли: «Халкыбыз шул бик надан...»

Шуңа мин әкәм-төкәм кебек биклә-небрәк яшим. Әлеге дә баягы Даһиебыз язган шәехнең биш «ю»сына кермәгән өч «ю» миндә дә бар:

— Калеб. Китап. Каләм.»

Бу — үзе бер иман шарты. Һәм Рафаэль өчен генә түгел. Намусны изә торган заманда яшибез. Ә чын поэзия шундый иманга табынганда гына исән калачак.

...1968 елда олуг остазыбыз Нури Арслан яшь иҗат көчләре хакында радиодан сөйләде. Ул Рәдиф Гаташ, Равил Фәйзуллиннардан соң үзенчә бер яңа дулкын кузгалуын әйтте. Һәм исемнәрен санады: М. Әгъләмов, Х. Әюп, Э. Мостафин, шушы юлларны язган бәндәгез Зөлфәт һәм, әлбәттә, Рафаэль Сибат.

Алтмыш җиденче елларда Урал таууларында без Рафаэль белән икәүләп чибәр кызларны томан эченә алып китеп, сөю аркасында тукмала язып йөргән идек. Ә ул кызлар — шигърият — һаман томан эчендә...

Бер уйласаң, мәхәббәт, сөю, шигърият хакына кыйналу да килешеп тора бит!..

Сәер хәл, әлбәттә: Сибатка — 50 яшь! Хәер, асыл талантның яше сан белән билгеләнми. Чын шигърият — сер. Ул һаман да — томанда...

ЗӨЛФӘТ.

## Рафаэль Сибат

# ӨЧТОМЛЫКНЫ УКЫГАЧ ӨЧ СҮЗ

(РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИННЫҢ ӨЧТОМЛЫГЫН УКЫГАЧ ТУГАН УЙЛАНУЛАР.)

I

### Тәүсүз

Дөньяда бер тылсымлы Хисеият Иле бар. Ул — Поэзия. Аның могҗизалы сер-сихерен, бәлки, күпләр аң белән аңлап та, хәтта... сизеп-тоемлап та бетермәскә мөмкиннәр. Ләкин Кеше Күңеле күбрәк Җан белән кабул итүгә корылган бит. Шуңа бу Хисеият Иленә, тылсымлы дөньяга килгәннәр аны тиз генә ташлап китә алмыйлар һәм шушы дөньяны тудырган кешеләргә — Шагыйрьләргә — эчтән генә рәхмәтле калалар...

Шулай! Рәхмәтне кычкырып йөрмиләр, ә дога кылган кебек тып-тын калып, җанның сәҗдәдә чагында әйтәләр. Һәм шунысын да өстәргә кирәк: шагыйрьләргә чыннан да дога кылырлык иң — алар Җирдә яшәгән чакта ук үзләренең Җан-Рухлары белән Күк Инсаннары рәвешендә, Югары Рух иләре булдырак та иҗат итәләр. Шунсыз илаһи чын Поэзия дә юк! Шагыйрьләр һәрвакыт Югарыдан торып сүз йөртәләр. Хәтта иң түбән хәлләрдә калганда да. Яшь-яшь кенә килеш чахоткадан үлеп барганда да... Палач балтасы астына башын салганда да... Нахакка туган җиреннән сөрелеп, шигырьләре белән япа-ялгыз калганда да...

Чын шагыйрьләр — патша булсалар да, хәтта кол булсалар да — үз сүзләрен барыбер әйтәләр. Үз язмышына өстән карап, илләр-халыклар турында уйлап...

Монда хикмәт — нәрсә турында әйтүдә. Әмма иң мөһиме: шагыйрьгә нәрсә турында әйтү генә җитми, ә «ничек!» — әйтү дә кирәк.

# Уртасүз

## 1. «Шигъри бомба»

**1965** ел...

Татар поэзиясенә «бомба» ташланды!

Һәм — ул бомба шартлады. Тавыш-тынсыз гына... Аның тавышы соңыннан берничә еллап яңгырап торачак. Шигъри бәхәсләрдә...

Хикмәт нәрсәдә?

Бу «бомба» дигәнебез әлегә беркемгә дә диярлек ныклы билгеле булмаган яшь шагыйрь Равил Фәйзуллинның ирекле шигырьләре иде. Ирекле!! Шәп сүз бу, билләһи! Тик ирекнең ни икәнен оныткангамы — бу «ирекле»ләр кемнәргәдер ошамады...

Әнә бит «Казан утлары» (ул вакытта «Совет әдәбияты») журналында басылган шиг... Чү! — хәтта шигырьләре дә түгел, хис-фикер «нюанслары» каләм әһелләре, тәнкыйтьчеләр арасында каршылыклы уйлар давылы тудырды.

Нюанслар...

Шигърияtьнең үзе кебек үк матур, нечкә, челтәрле сүз. Мәгънәсе дә төгәл билгесез, шуңамы серле. Ә әйтелеше? Бу сүзне ишетүгә үк әллә нинди уй-хисләргә коенасың. Өстеңдә Ниагара шарлавыгымени...

Поэзиябезнең Тукай кебек бөекләре Рухы гафу итсен, мин үзем яшьтән үк, хәтта малайчактан «шигырь кыштырдаткан» кеше буларак, шагыйрьләрдән Равил Фәйзуллинга турыдан-туры нярэп яздым. Ул үзенең «Нюанслар иле» белән үзенә әсир итте.

Фәйзуллинның «Нюанслар иле»нә нярэп язган дистәләрчә шигырьләрдән мин берничәсен бүген дә хәтерлим әле:

Борынгы истәлек-чиркәүдә
каргалар бик моңлы җыр суза...

* * *

Җир тәнен тракторлар ерта...
Алабута елый...

Ни нәрсә ул Равил Фәйзуллинның нюанслар иле?

Әдәбият сөючеләргә япон танка һәм хайкулары таныштыр. Танка 31 иҗекле 5 юллык булса, хайку 17 иҗекле 3 юллык, танкага 1000—1300 еллар булып, хайку чагыштырмача яшь, аны XVII гасырда бөек Басё (1644—1694) башлаган диләр, ә XVIII гасырда икенче бөек япон шагыйре Есе Бусон (1716—1783) тагы да камилләштергән. Бүген Японияда күбрәк хайку белән язалар, ул танкадан да кыскарак ич! Ә Хиппон халкы кечкенә — кыска әйберләр иҗат итеп озын-озак яшәргә ярата. Әнә бүген дә алар шагыйрә Мати Тавараның хайкуларын ябырылып укыйлар. Ә бит 1200—1300 еллар элек аларда «нагаута» — озын җырлар булган.

Инде танка һәм хайкуларга килсәк, алар — кеше күңеленең эчке халәтен аңлатып язган шигъри нәсерләр. Аларда күбрәк ике күренеш янәшә бергә китерелеп «үбештерелә». Нәкъ менә кыз белән егет кебек. Нәрсә туа бу «үбешү»дән? Гадәттәгечә, 4 килокалорий янамы? Әллә киресенчә өстәлә генәме? Алар берберсеннән этеләләрме янсә, киресенчә, тартылалармы?

Боларны тою шигырь укучының үз эше — ул әлеге энҗеләрне эмоция белән кабул итә бит, чөнки танка һәм хайкулар үзләре үк эмоция кыйпылчыклары ич, Җан-Рухның эчтән генә, сизелер-сизелмәс кенә дертсенеп куюы.

Менә шушы типтагы, ягъни фикер янсә хиснең «Көйне белегез» («Угадай мелодию») телетапшыруындагы кебек, өч-дүрт нота белән генә бирелеп, калганын укучы үзе эзләргә тиеш булган «нюанслар»ын татар поэзиясенә 22 яшьлек Равил Фәйзуллин алып килде һәм — моның белән зур «шартлау» ясады. Болар — безгә таныш булмаган татар танкалары (шулкадәрле дә танклары дип ычкындырасы, ялгышасы килми, әлеге хәрби машинаны җенем сөйми!) һәм татар хайкулары иде. Ләкин...

Болар япон шигырьләрен кабатлау түгел. Кабатлап әйтәм: киресенчә, халык иҗатының үзеген тәшкил иткән кыска формаларына «кайту».

Алар — кыска шигырьләр яки, Фәйзуллинча әйтсәк: «Нюанслар иле...»

Күркәм сүз! 22 яшьлек шагыйрьгә шушы тәгъбирне тапкан вә татар шигъриятенә кертеп җибәргән өчен дә рәхмәт әйтергә була. Нюанс дигән француз сүзенең фикер-хистә сизелер-сизелмәс кенә күчешләр, төсләр чайпалышы, аһәң сирпелеше икәнен тирән тойган хәлдә ул аның Иленә үк кереп киткән.

Нюанслар — тормыш вә яшәешнең, тереклек итүнең атом кисәкчәләредәй нәп-нәни мизгелләре алар. Фәйзуллин адәм күзенә орынмаган бу мизгелләрне менә ничек тотып алган:

### Хәтер

Яз җитүгә
беренче булып
таудагы кабер ачыла.

### Омтылыш

Йолдыз атылды.

Сабый бала форточкадан
кулын сузды.

### Көзге яңгыр

Торналар китеп бара.

Кош канатлары орынгач,
болытларның күңеле тулды.

### Үҗәтлек

Кырмыска, саламны сөйрәп,
түмгәгенең очына менде.
Кояшка тәки якынайды!

### Натюрморт

Тәлинкәдә — Кояш.
Тастымалда — икмәк.
Телем күзләренә нур тулган.

### Тулай торакта

Кызлар күптән йоклый.
Кефир шешәсендә гөлләр
Таңны көтә.

Татар поэзиясендә завод суккан кирпечләрне хәтерләткән бертөсле шакмак шигырьләрдән соң (озын-озын шигырьләрдән соң!?) болар шул «кирпеч»ләр өеме арасына барып төшкән «бомба» булды. Бу яшьлекнең дуамаллыгы, үзен яңача күрсәтүе вә танытуы да иде:

— Менә без болай да яза алабыз!!!

Хәер, төп мәсьәлә анда да түгел. Монда бер генә сорау куярга мөмкин:

— Әлеге «Нюанслар иле» белән яшь шагыйрь ни булса да әйткәнме?

— Әйткән! Үзенчә, яңача әйткән...

## 2. Тәнме, җанмы?..

Менә шул мисалга китерелгән өчъюллыкларны үзгә итеп язылган, Фәйзуллинча язылганнарын — язучылар, шагыйрьләр, тәнкыйтьчеләр һәм укучыларның бер өлеше танымаска, шигырь итеп санамаска тырыштылар. Боларны монолит кирпеч-шакмак, сакал-мыеклы шигырьләр язу өчен теркәп куйган уй-фикерләр, башка килгән беренче, икенче яисә өченче җөмләләр,

тагы да икенчеләтебрәк әйтсәк, поэтик чимал санадылар. Икенче бер төркем аларны «ак шигырь», «ирекле шигырь» санап, шулай яшәргә мөстәкыйльлекләре барын күтәреп чыкты. Әйе, ирекле ил мөстәкыйль булган кебек, ирекле шигырь дә чит тәрәкләрсез дә мөстәкыйль! Әлеге поэтик энҗеләр шигырьнең сакалмыексыз чагы, гүя алар сабый, чиста, пакь, садә килеш дөньяга килгәннәр дә, шул рәвешчә бөек рәссамның киндерендә мәңгелек нарасый булып калганнар.

Күпләр моны татар шигыре традицияләрен бозып, яшь шагыйрьнең үз шигъри архитектурасын эзләүе итеп кабул иттеләр. Ягъни мәсәлән, форма эзләү, поэзиянең шәкли ягы.

Татар шигъриятендә ритмик сындырулар аша яңа форма эзләүне гасыр башында Сәгыйть Рәмиев күтәреп җибәрде. Һади Такташ, Хәсән Туфаннар аны дәвам итте. Соңарак ул Әнвәр Давыдовта да нык сизелде. Ритмик «аксатулар» шигырьне ат урынына уйнаткан бөек Тукайда да очрый ич.

Ләкин ни генә димә, форма эзләүнең бомба шартлаганына тиңе бары Равил Фәйзуллинда гына булды дисәк, дөреслеккә һич тә хилафлык кылмабыз.

Каян килгән ул аңа?

Әлбәттә, яңача язасы килүдән, яшьлек кайнарлыгыннан, шигырьнең тын юлына утырган тузанны очыртасы килүдән. Чөнки яшьлек ул — тән, ә картлык — җан. Икенчеләп әйтсәк, тән — шул форма инде, ә җан — эчтәлек, формага салынган Рух кичерешләре. Шигырь бит Җан-Рухның бөтенлеге белән елмаюы яисә үксүе.

Яшьлек тән матурлыгына омтыла, аның да үзенчә иң кызыклы моделен эзли, шәхси вариантларны барлап карый. Ләкин... Бу модель Җан-Рух квинтэссенциясе белән тутырылмаса, әлеге форма үлек, ул көлке, кызганыч һәм мескен. Шуңа: «Тәнме беренчел, әллә Җанмы?» — дигәндә, материалистлар яисә идеалистлар кебек бер кырыйдан икенчесенә фанатикларча сукыр ташланмый гына Галәм, Космос, Аллаһы, Яшәешнең хозур-кодрәтен тоеп:

— Икесе дә! — дип җавап бирү хакыйкатькә хыянәт итү булмас. Чөнки әлеге хакыйкать һәрвакытта диярлек кайдадыр бер урта җирдәрәк тора: уңда да түгел, сулда да — «йолдызларга күмелгән» кеше йөрәге сыман — уртадарак.

Талантлы шагыйрь Равил Фәйзуллин да иҗатының башлангыч чорында ук «Җан бөеклеген», шигырьнең шәхси ягы белән мавыкканда да аның эчке энергиясе, йөрәк тибеше турында онытмаган. Үз җаны-иманы турында да гомер буе кайгырткан ул:

Бу җанда ни калды?
Иманым сау калды!

Ул хәтта тауларның да җанын эзли:

Тауларның да җаннары бар,
Кыяларның — йөрәге.

Әйе, шәп шигырь язар өчен Зур Җан, Сау Җан, Иманлы Җан кирәк, чөнки шигырь — Җанның кыйпылчыгы ул! Шуңамы Фәйзуллинның иң-иң кыска шигырьләре — беръюллыкларыннан да фикер җегәре, тетрәнүләр дулкыны, кичерешләр апогеесе, теге яки бу күренешкә карата фәйләсуфларча бәяләмә һәм рәсемишарәләр тоясың вә күрәсең. Ә алардагы оригинальлек?! Үзеңчә әйтү!

## Сөюсез ел

Елады кан Елан елында.

* * *

Үл генә — күбәер дусларың...

* * *

Бәхетнең тәхете юк, имеш.

* * *

Тынлык ул — иң бөек илаһи музыка.

* * *

Җирдә ятмый, кайда ятсын яхшылык!..

* * *

Каберләрнең фәкать туган елы...

* * *

Еллар юка чакта — уй биек.

Кемгә ничектер, бер караганда, салкын акыл белән хиссез генә язылган тәгъбирләргә охшасалар да, мин аларда эчке энергия — Җан җылысы тоям. Юк, болар уй-хиссез генә туган юллар түгел!

## 3. Җан җылысы

Фәйзуллин тудырган поэтик дөньяга килсәк, аның яктылыгына таң каласың. Хәтта шигырьдә үлемне күрсәтүе дә гаҗәп бер оптимистик рухта:

«Бүтән инде
Мәңге картаймам мин...»
*(Дәүәнисе сүзләре)*

Билләһи, менә ул сезгә поэзия оҗмахы кайда! Монда исләрдән туган хисләр, бетмәс-төкәнмәс яшәү дәрте. Бу шагыйрь, җыр язу янсә җырлау гына әле ул җыр түгел, ә гомерлек җыр — җирдә яшәү үзе дип фараз кылучылардан һәм, бу уен гоманлап кына калмыйча, Тән-Җан-Рух субстанциясен шушы позициядән чыгып аңлаучылардан. Аның иҗат критерийларының берсе нәкъ менә шунда чагыла да. Кеше буларак та, шагыйрь буларак та ул тоташкан, шигырьдә бер төрле сандугачтай сайрап, тормышта карга булып каркылдап йөрми. Аның әйткәне, киресенчә, тормышны күзәтүләреннән, үз кичерешләреннән, уй-фикерне балалатулардан туган җанлы сүзләр тасмасы.

Тормыш нинди — ул шуны үз Җаны аша лакмус кәгазедәй уздыра — шагыйрьнең шигырьләре дә шундый. Ләкин... һәр шигырьгә Олы җаннан зур җылы өрелгән. Шулай ук Фәйзуллин үз шигырьләрендә тормышның чагылышын да (копиясен) күрсәтми. Әгәр болай дисәк, бу фикер артык беркатлы, мескен, хәтта көлкеле булыр иде. Гомумән, нигә әле безгә ул тормыш копиясе? Шагыйрьнең вазифасы ул түгел бит, ул кешеләргә (поэзия сөючеләргә) җан җылысы өрергә тиеш. Моның өчен ул үзендә көч — Илаһи Көч тоярга тиеш:

Көч бир СИН миңа, мәдәт бир!
И, АЛЛАМ — Бөек Хуҗам!
...Ник тыныч түгел бу күңел,
ник тыныч түгел бу җан?

Әйе, шагыйрь көчле, аның Җаны җылы, күңеле тынычсыз булырга тиеш. Суык Җанлы шагыйрь поэзиягә килсә — ул бит диверсант, кара йөзенә акбүз япкан икейөзле мәхлук. Инде иллене узса да, шагыйрь һаман җан суыклыгыннан, җан туңудан курка.

Менә аның соңгы елларда гына язылган дүртьюллыгы:

Син мине бүтән каргама!
Каргасаң — җаным туңа.
Каргышыңнан үзеңдә дә
яңа борчулар туа.
*(1995 ел, май)*

Әнә! Җылы майда да Фәйзуллин Җан Җылысын кайгырта. Туңмасын Җаны!

## 4. Ислərдəн туган хислəр

Вакыт-вакыт акыл шигырьлəре өстенлек итсə дə, Равил Фəйзуллин — хискə бай шагыйрь! Кайвакыт бу хислəр чамасызланып, аны күмеп тə китə кебек. Ничек һəм каян туа алар? Уйлавымча, иң беренче — табигатькə бик якын торуыннан. Табигать — сафлык, садəлек, чисталык, матурлык ул. Иң хəерлесе: Табигать — алдамый! Бөек Гете əйтмешли: «Табигать һəрвакыт хак. Ялгышлар, буталулар — кешелəрдəн». Ə бит тормышта паралогизмнар күпме?! Юк, алар хис тудыра алмый, тудырса да, ул нəфрəт дип атала. Якты хислəргə килгəндə, алар чəчəклəрдəн туа, урман-елга буйларында туа. Матур хислəр «таз эчендəге орчык малай»ны күрүдəн дə барлыкка килə. Алар ана елмаюыннан, сабый карашыннан, кайгы-сагыштан, бəхет-шатлыктан да туа. Ул матур-гүзəл, зифа гəүдəле, ерык авызлы кер чайкаучы кызларны күргəч тə туарга мөмкин:

Кер чайкыйлар кызлар,  
Тезлəрендə — Кояш!

Күзлəрендə — яз!  
Ярым ачык күкрəклəре  
оялган күк бераз...

Ə менə «кыр казы исе»ннəн туган хис ниндидер илаһи, ул Күккə үк тоташкан сыман:

Бардыр... Бəлки, кемнəрнеңдер  
кабер казыйсы килə  
Бу чакта ничек үлим соң —  
кыр казы исе килə!

Шагыйрьнең иң-иң көчле-куе, тыгыз, дəртле хискə өртелгəн шигырьлəре мəхəббəт турында:

Мин сине ничек яраттым!

Ничек шəп əйтелгəн!! Юк, шушы бер юлга сыйган дүрт сүз, сигез иҗек, унике аваздан соң башка берни дə əйтергə кирəкми! Монда инде əйтелгəн. Бу сөю турындагы барлык сүзлəрнең квинтэссенциясе. Татарча табылган иң шəп, иң кыска əйтелеше. Хəтта башка варианты юк та кебек. Монда тирəн хис тə, югары пафос та, җан сыктавы да, кичерешлəр аһəңе дə, ташны эретерлек моң-сагыш та бар.

Фəйзуллинда мəхəббəт шулкадəр бөек көч, шулкадəрле дə Югары Хис, хəтта «Вакыт кодрəте» дə аңа тəэсир итмəскə мөмкин.

Бар нəрсə үзгəрə...  
Вакытның кодрəте!  
Күңелдə шул килеш  
Синең яшь сурəтең.

Əйе!

Мəхəббəт мəңге яшь кала, шуның кебек аның турында язучы Шагыйрь дə күңеле белəн мəңге яшь! Шуңамы ул гомере буе йөрəгеннəн ак күгəрченнəр — сөю-хис кошлары очыра.

## 5. Поэтик сер

Тəүсүздə үк əйтеп үткəн идек инде, поэзия — могҗизалы сер-сихер ул. Чынлап та, ул үзенең серлелеген, Күккə тоташканлыгын югалтса, реалистик акыл, прагматлык — романтик рух, бал кəрəзедəй куе хис белəн өртелмəсə, ниндидер сихер-магия өстəлмəсə — бу инде сер түгел, ə билгеле бер күренешне механик тасвирлап чыгу яисə уй-фикерне хиссез-төссез генə хəбəр итү. Ə бит уй эчендə уйлар, фикер эчендə фикерлəр бар. Хис йөрəгендə хислəр ята. Менə поэтик серлелек каян килə!

Рус шагыйрьләре Гумилев, Мандельштам, Пастернак — поэтик сер ияләре.
Дөнья әдәбиятына күз салсак, символик серлелек Метерлинкта бик көчле. Кайвакыт аның символлар урманын ырып-ерып чыгып та булмый. Һәм, нигәдер, ерып чыгасың да килми. Ә шигъри тәэсирне сизәсең, тоясың бит! «Иностранная литература»да Сен-Жон Перс шигырьләрен укыган бар иде. Ә менә аның «Ориентирлар» поэмасын радиодан ишеткәч, хәйран калдым — менә сер илә бөеклеккә төренгән әсәр! Ә «Кошлар» поэмасы? Табигать турындагы шигырьләре?? Боларга да поэтик сер, күккә тоташканлык, Космик Хисләр хас.
Дөрес, шигырь — ребус, кроссворд, Нурихан Фәттах язганча, «башваткыч» яисә табышмак та булмаска тиеш — болары да салкын акылга исәпләнгән ич! Хәтта фантасмагорияләр дә поэтик сер тудырмаска мөмкин, ләкин шигырьдә серлелек югала икән, аның тәэсир көче бермә-бер кими, аның кызыклыгы, илаһилыгы югала. Поэтик сер шигырь укучыны эзләнүгә этәрә, уйларга чумдыра. Туны астыннан күлмәге күренгән кешене исереккә саныйлар, сүзләре артыннан фикерләре ачык ярылып яткан баналь шигырьләр дә чишенгән салмышка охшыйлар. Мондыйлар безнең ярты мең ел коллыкта ачылган татар йөрәкле шагыйрьләргә дә хас. Шәрә йөрәк бу, салкын җилләргә, зәмһәрир суыкларга, ярсулы давылларга каршы куелган йөрәк. Изелүне, мескенлекне мөмкинлектән уннарча, йөзләрчә артык күтәргән йөрәк... Шуңамы, ул яшеренергә теләми, сер томаннары артына качарга җыенмый — күбрәк турысын әйтә. Әмма...
Татар шигъриятенә поэтик сер хас түгел дияргә җыенабыз икән — бик нык ялгышырбыз.
27 яшендә шигъри даһилыкка ирешкән Тукай иҗаты поэтик сер түгелмени?! Европа галимнәреннән алда Җирнең Кояш тирәсендә әйләнүен әйткән Сәйф Сараи сүзләре сер-сихер түгелме әллә?! Ә Колгали, Котб, Мөхәммәдьяр, Дәрдмәнд иҗатлары? Җәлилнең «Моабит дәфтәре»ндәге героик лирикасы...
Поэтик сер Фәйзуллин иҗатына да хас нәрсә. Хәтта аның кайбер шигырьләрен бераз сәерсенеп тә укыйсың:
— Тукта, тукта! Туктале!! Ни әйтергә теләгән моның белән шагыйрь?
Кабат укыйсың — нидер тоемлана кебек. Әйе, тоемлана башлый, әмма...
Барыбер шигырь ачылып бетми. Ачылса да, хәйләкәр дипломат кебек, контекста үзе өчен генә яңа мәгънә калдыра. Ул катлаулана, кәбестә кебек каткатлана, шуның белән кат-кат укуга этәрә. Әнә шул «йозаклы» — бикләнгән шигырьләр нәрсәседер белән тарталар да. Аңа ачкыч эзлисең, ул, иң мөһиме тәэсир итә, кызыксыну тудыра, аңыңа барып җитмәсә дә, җаныңа үтеп керә. Тик шулай да, шагыйрьнең бар шигырьләре дә бикле-ябык түгелләр, киресенчә, күбрәк ачык, төгәл-үткен фикерле. Ә инде аның иҗатында поэтик серне күрсәтү өчен конкрет мисаллар эзлибез икән, уйлавымча, шактый ук кыен хәлгә калырбыз. Чөнкиме? Чөнки поэтик сер дигән нәрсә аерым бер шигырьгә генә түгел, ә теге яки бу шагыйрьнең тулы бер иҗатына хас күренеш ул. Моңа аның язу стиле дә, «әдәбият кухнясы» да, хиссият байлыгы да, фикерләү рәвеше дә, яшеренлелеге дә һәм хәтта — үзе һәм башкалар тарафыннан тудырылган имиджы да керә. Инде бик тә скептик адәм: чыннан да:
— Ә шулай да, әйдә, төгәен бер мисал сыйфатында шигырь юлларын китер әле! — дисә, менә ул! Дөресе, менә алар; бер түгел ике шигырьннән:

* * *

Сагышымны сиңа илтер, —
диңгездә Ай юлы.

* * *

Соңгы аваз, карлыгач кебек,
киңлеккә күтәрелмәс.
Урманнар айкап йөрмәс.
Кояшка сәлам илтергә
Җиде кат күккә менмәс.

Ботактагы соңгы алмадай,
ычкынып да иреннән,
тәгәрәп кире кайтыр ул
күтәрелгән җиренә.
*(1964, март)*

Бер яктан монда бар да ачык кебек:

«Сагышны Сиңа илтүче диңгездәге Ай юлы» метофора, образлы әйтү. Ә нигә диңгездәге Ай юлы? Сагышлы булгангамы? Ә нигә җирдәге түгел, диңгездәге Ай юлы? Ачык күренгәнгәме? Диңгез үзе мәхәббәт образы түгелме? Сораулар, сораулар... Хәер, нигә әле алар?! Иң шәбе — әйбәт әйтелгән бит! Янсә менә «Соңгы аваз...»да бары ачык кебек:

— Соңгы аваз — соңгы сулыш ул...
— Ә аннан соң?
— Ә аннан ни булачагын беркем дә белми...
— Серме?
— Сер...

Әйе, бу урында поэтик сер дә бар...

## 6. Элитарлык

Шагыйрьнең тагы бер үзенчәлегенә игътибар итик: Фәйзуллин бер үк вакытта гомумкабул һәм элитар шигырьләр дә яза ала. Гомумкабулны һәркемгә аңлаешлы дип санасак, элитарлыкка килгәндә, болары, образлы әйткәндә, аристократик шигырьләр. Алар иң югары зәвыклы укучы, аерым бер элита өчен языла. Элитарлыкны поэтик сер белән бутарга ярамый, чөнки поэтик сер күпләр тарафыннан кабул кылынып, хәтта аңлашылмаган сурәттә дә җанга якын ителеп, ә гади генә элитар шигырьләр, ниндидер аңлашылмаучанлык тудырып, чит-ят күренергә мөмкиннәр. Ә болай алар бербересенә бик нык бәйләнгәннәр, поэтик серлелеген югалтса, элитар шигырьләр туа алмый, алар бит иң нечкә тоемга, иң сизгер күңелгә, иң югары зәвыкка чамалап языла. Аларны тудыру өчен сүзләр дә бик сайланып кына алына. Монда тупаслык янсә колакка ятышсыз сүзләр гафу ителми.

Элитарлык XIX йөз рус әдәбиятыннан Тютчев, Майков, Фетта ачык сизелә. Ул Блок та да бар. Бервакытны иң беренче Нобель премиясе лауреаты француз шагыйре Сюлли-Прюдом иҗаты белән танышырга туры килде. Табигать, сөю турында югары пафоста, элитар рухта язылган әсәрләр. Бүләкне, фараз кылуымча, аңа шул элитарлык өчен биргәннәр булса кирәк. Талант бит Нобельлек үк түгел! Менә шуннан соң уйга да чумасың:

— Ә шулай да, элитарлык, тарлык булмаса да, поэзия пигы түгел әле ул!

Чын шигырьне шагыйрь элитар булсын әле дип язып утырмый, ә йөрәгендә тудыра. Менә мондыйракларны:

Ай — вакланган дулкыннарда
ватылган бәхет сыман.
Ә синең тын күзләреңә
Ай тулы килеш сыйган.

Йөзә ул киң диңгездәге
ялгыз ак җилкән кебек,—
керфекләрең офыгына
бер кереп китәр кебек.

Аннан кабат чыгар төсле
чисталык диңгезенә.
якынлашыр да Ай-җилкән
Мине дә алыр менә...

*(1964, март)*

Әлеге шигырьне укыгач, уйга бат инде:

— Элитар шигырьме бу?
— Әйе!
— Ә гади, гомумкабул шигырь түгелмени??
— Әйе шул, бик күпләргә аңлаешлы мәхәббәт шигыре дә бу. Бары образ өстенә образ гына өелгән, метафора көчле, рәсем-ишарәләр берсе-берсе артыннан...

Менә шуңа искәртик: элитарлык мәсьәләсе шактый ук четрекле: аңа поэтик сер дә сыя, гомумаңлаешлы гади-ачык шигырь дә сыя. Элитарлыкка иң хисчән күңел дә сыйган, тирән акыл таләбе дә сыйган. Шуңамы поэтик сер, элитарлык кебек критерийларны аерым бер чикләр белән төгәл билгеләү дә, бәлки, тәгаен мөмкин түгелдер, алар бит Җанның шигырьне янсә тулы бер иҗатны үзенә сеңдерүе аша гына шактый ук ачык тоемланалар.

Ә Фәйзуллинга килгәндә, ул, чыннан да, халыкчан да, элитар да шагыйрь...

Әдәбият гыйлеме күрсәткән сукмаклардан килеп, ул, өйрәткән критерий, категория, термин, атама, бәя-билгеләр белән эш итсәк, Фәйзуллин иҗатын күз алдына китерү, ачыклау вә аерып кую өчен, стиль үзенчәлекләреннән аңа гына хас булганнарына дикъкать бирү өчен без нинди сүзләр куллана алыр идек? Гәрчә һәр аерым сүз-термин, категория-атама астында дистәләрчә битләрдә язарлык мәгънә-аңлатма ятса да, язмабыз бик-бик озынга китәр дип, бу урында без аларны механик рәвештә кабатлап чыгарга гына булдык, чөнки алар да азмы-күпме ачыклык кертәчәкләр дигән өмет бар.

Фәйзуллин стиленә нәрсә хас дигәндә, аның шигърияте гаять тә образлы! Хәер, шигырь образсыз гына була ала микән? Образ тудыруда аңа метафора, метанимия, ассоциатив чагыштырулар, символлар, перифразалар нык ярдәм итә. Ул фикер-сентицияләр, антитезалар, афоризмнар, төрттерү-кинаялар белән яратып эш итә. Рәсем-ишарәләр дә күп анда.

Тормышта кискен борылышлар, көтелмәгән хәлләр еш булган кебек, Фәйзуллин иҗаты да перепитияләр белән тулы. Прозаик үз героен экстремаль хәлләргә куеп карап, аның карашларын, бигрәк тә персонажның характерын төгәл вә анык ачарга омтылса, шагыйрь үз хисләрен «экстремаль»дә сыный. Бу бигрәк тә мәхәббәт шигырьләрендә сизелә. Аерылу, тирән сагыш, вәгъдәсезлек, хыянәт моментлары шундый. Бу шигырьләр соң дәрәҗәдә экспрессив:

Шау яфраклы имән идем.
Син китергән хәсрәттән
чыпчык кунмас
шәрә ботак калдым.
Күңелем катты
чакматаштай.
Кабынырга
теләк, көч тә юк...

*(1995, май)*

Бу, бәлки, мәхәббәт турындагы шигырь дә түгелдер. Бары зур-олы хәсрәтнең чагылышы гынадыр. Ләкин ул экстремаль халәттә туган экспрессив шигырь. Гомумән, Фәйзуллин гомере буе шигъри экстазда яши, шуңамы күп иҗат итә. Шигъри куәс аның җанына бөти-амулет булып асылган... Гел «экс»ка аксый торгач, тагы бер «экс»лы сүзне өстик инде. Дөресе, өстәргә туры килә, чөнки әлеге сүз дә шагыйрьнең иҗат стилен, эш методын күпмедер ачарга ярдәм итә. Миңа калса, Фәйзуллин күп кенә шигырьләрен экспромт белән яза.

Ритмны сыгылмалы итү өчен эчке рифмалар кертә: «Елады кан елан елында», «салларга салып», җил-җилкән». Иҗат методына килсәк, бу шигырьдә реализм-рационализм шактый нык чагылыш тапкан, әмма романтик рух вә сенсуализм да үзен сиздерә, экспрессионизм мотивлары да очраштыргалый. Ләкин ул — күбрәк прагматик.

Фәйзуллин шигырьләрендә фигыльләрне аз куллана, аларда — күренешләрнең исемнәре яисә аларга үзенчә исем бирү һәм халәт атамалары.

Кайвакытта ул билгеле фикерләрне дә кабатлый. Ләкин бу плагиат түгел, ә әдәби параллелизмнарны реминисценцияләү. Чөнки алар — Фәйзуллинча!

Аның иҗатына хас тагы бер як бар — ул шигырь техникасы. Поэтик каркасны Фәйзуллин бик тә үзенчә корырга ярата: беренче юлда, әйтик, өч иҗек, икенчесендә — биш, ә өченчесендә яисә дүртенчесендә җиде, сигез, хәттә тугыз, ун да булырга мөмкин. Әле анда шигырь юлларын бер җөмлә итеп язу да бар; шуңа хис эмоциясе, уй-фикере беткәнче ул беренче юлны баш хәреф белән башлый да калганнарын вак хәреф аша дәвам итә. Фикере булганнар гына моңа бара ала.

Шагыйрьнең детальләр остасы икәне дә ачык сизелә. Прозада бу эшкә мәрхүм Мөхәммәт Мәһдиев бик тә маһир иде, ә поэзиядә Равил Фәйзуллин:

Атылып төшкән һәр йолдыз
җыелып бара йөрәк төбендә

Кайвакыт шагыйрьдә оккультизм тойгылары да сизәргә мөмкин. Әйе, һәркем кебек, ул да күпмедер дәрәҗәдә оккультист — кешенең яшерен көчләренә ышана, хәтта... Космик Көчләргә дә ышана кебек. Алайса каян тусын мондый серле шигырьләр:

Җан очты Күк бушлыгына.
Кабыгы калды Җирдә
кабер-түмгәк булып.

* * *

Тау убылып, үзән-чокыр булды.
Түбән биеклекләр эзләп микән —
Йолдызлар төштеләр коеңырга
шаулап узган яңгырдан соң.

* * *

Яңадан туармын кирәксә!

Инде хәзер төрле-төрле «экс»лардан качып, «изм»нардан арынып, шәхсән үзем фаразлавымча, Фәйзуллин иҗатына иң хас нәрсәне әйтик. Бу — фәлсәфилек. Юк, фәйләсуфларга хас фәлсәфилек түгел, ә шагыйрьләр фәлсәфилеге: җылы хыялый, кешечел һәм күпмедер кыргый да. Кешедә, гомумән, кыргыйлык көчле. Хәтта кыргый хайваннарныкыннан да көчле.

Шагыйрь никадәр генә реалист булмасын, аның Рух утында Гаҗәби вә Серле Дөнья яктырткан, Җан көрсиләрендә әкияткә ышану да утыра. Ул хәтта «җир хыялы — коммунизм»га да ышанып алырга мөмкин. «Әкият»кә ышанмаган кеше — тимер йөрәкле ул, ә андыйлар җылы, якты, хыялый шигырь яза алмый. Гомумән, һәр кешедә, бигрәк тә нечкә күңелле, ышанучан, һәрбер нур яктысына йөрәге ачык шагыйрьләрдә гомер буе фикер каршылыклары да яшәргә мөмкин.

— Әйбәтме бу?

— Һәрхәлдә, начарга түгел! Хакыйкать бит бәхәстә, фикер каршылыкларында туа.

— Кешелек ничә төрле «хакыйкать»не узды инде!?

— Инсаннарга, гомумән, Хакыйкатьне төгәл белү бирелмәгән. Кешелек өчен андый мөмкинлек юк һәм аның булмавы дөрес тә, чөнки һәр бәндә Хакыйкатьне белсә:

— «Мин Алла!» дип дөньяга шәрран ярыр һәм Галәм кызыксыз бер төстә калыр иде.

— Ә нигә кеше хакыйкать эзли соң?

— Безгә чикле гомер бирелгән, шул чикле яшәүдә адәм баласы бер чиктән икенчесенә сикергәләп, үзе өчен бөек Канун, Илаһи Көч, Космик Кодрәт эзли, шул рәвешчә ул гасабилана-гасабилана Хакыйкатьне эзләп табарга, Сер-Сихергә ия булырга омтыла. Моны мәңгелеккә омтылу һәм кызыксыну да тудыра.

— Хакыйкатьне табу мөмкинлеге дә булмагач, ни кала соң кешеләргә?

— Матур вә яхшы яшәү! Бу мөмкинлек тулысынча аның кулында...

— Ә үлем?

— Матур яшәгәннәр матур үлә дә белә. Кара әле Фәйзуллинга, ул ничек ди бит:

Кошлар оча-оча югала...

Тагы да конкретрак:

Кеше булып кала алсак,
шул җитә.
Шул җитә...— ди.

Шулай да... Шагыйрьләргә Хакыйкать турында сүз әйтү мөмкинлеге бирелгән, ә фәйләсуф күпме генә тырышса да, Чын Хакны әйтә алмаячак! Әнә ич:

Пәйгамбәрләр —
ничек кирәк таба —
шулай иңдерәләр вәхине!

Кеше Акылы бервакытта да Галәмне, Космик Рухны, Аллаһыны ача алмаячак, ул моның өчен артык акылсыз, ә менә Шагыйрь җаны Яхшылык вә Матурлык аша, үз кичерешләре аркылы, Күккә тартылуы белән Хакыйкатькә һәрвакытта күпмедер якын тора. Аны тоемлый.

Шуңамы Шагыйрь мәңге фәлсәфи сәфәрдә.

Инде язганыбыз буенча каләм белән шактый атлый торгач, Шагыйрь-Фәйзуллиннан Кеше-Фәйзуллинга да тәртелик әле. Беразга гына булса да...

Гадәттә, шагыйрьне шәхестән, ә шәхесне шагыйрьдән аерып куючылар да бар:

— Зур шагыйрь бит, олы талант, нигә аның кешелек сыйфатлары: ялганчы булуы, вәгъдәсезлеге, куркаклыгы, комсызлыгы...

Монда ялгышның шактый тирәндә ятуын искәртеп, бер нәрсәгә аерым игътибарны юнәлтергә кирәктер — Кеше буларак югалып барган инсан, шагыйрь буларак та шиңәчәк. Һичъюгы, ул иҗади үсми, бер урында таптана, ягъни мәсәлән үз-үзен кабатлый башлый. Хәер, французлардан карак Франсус Вийон, гомосексуалист Жан Жене иҗаты моның киресен раслый. Зинаида Гиппиус та женси тыйнаксыз хатын булган ич. Ә талантлары? Ә шигырь вә проза әсәрләре?!

Равил Фәйзуллинны мин якыннан беләм дип әйтә алмыйм, әмма берничә очрашуда ук аның шагыйрьлеге һәм шәхесе бер-берсеннән аерылмавын аңладым. Аларда идентиклык сизелә. Иң әүвәле ул — ихлас инсан: җырда язганын җирдә эшли! Борынгы фәйләсуф Биент әйтмешли, Фәйзуллин да:

— «Бар булганымны үземдә йөртәм» — дип әйтә ала. Хәер, ул үзе дә пилигрим кебек дөнья гизеп — үзен күп йөртте... Суфи шагыйрьмени...

Һәр зур шагыйрьнең, легендар ук булмаса да, үз имиджы булырга тиеш. Дөрес, ул моны үзе генә тудырмый, аны дус-ишләре, иптәшләре, шигърият сөючеләр барлыкка китерә. Билгеле бер аксиома бар:

— Һәр шагыйрь — күпмедер сәерҗан ул! (русчасы — «чудак»).

Сәерҗанлык Фәйзуллинда да шактый нык сизелә. Көтелмәгән эшләр эшләп ташлау, кинәт кенә туган үзгәрешләр, хиснең акылны акылча утыртуы — шагыйрьләр өчен хас нәрсәләр. Әле монда Шагыйрьнең Шәхесне вакыт-вакыт йөгәнләп-авызлыклап алуы да бар. Ләкин бу юләрлек түгел. Юләрләр — Җир шары өстендәге тере мәетләр алар.

Равил Фәйзуллин фамилиядәше врач һәм галим Искәндәр Фәйзуллинга ияреп бер ара ерак араларга йөзеп карады. Әйтик, 10 чакрымга. Чемпион вә рекордсмен Искәндәр кебек йөзәрләп километрны узмаса да, 10 чакрым җәяү атларга да куркып торабыз хәзер. Безгә тагы ул араны йөзү?! Ул фамилиядәшенә багышлап шигырь дә язды. Күркәм шигырь.

Мәҗлестәшләре, гаптәшләре белән утырганда — андагы киң күңеллелек, сүз саен диярлек афоризмнар. Юк, боларны ул якланып яисә үзенең акылын, эрудициясен күрсәтү өчен эшләми вә әйтми, ә пыскый башлаган мәҗлескә нәни генә йомры-кызу, ут-ялкын төртергә тырыша. Шуңамы, хикмәти сүз һәм каламбурларны коеп кына утыра.

Ишеткәнемчә вә белгәнемчә генә түгел, ә күргәнемчә дә Фәйзуллин, һәр татар кешесенә хас булганча, мунча ярата. Ул, гомумән, Су Кешесе бугай. Әнә бит «Мунчада» шигырендә:

Ләүкә — тәхет! — ди.

Ә «Саулык шигырендә:

Бар бит — гәүһәр, энҗе бөртеге дип,  
Канын, җанын аямаучылар.  
Җитәме алар ләүкә түшәменнән  
Сау тәнемә тамган тамчыга!

Иң зур матурлыкны да шулай күрә: мунчада эре-эре тирләр («көмеш тирләр»!) агызып чабынучы ир. Ә аның «Мунча яга апалар» шигыре нинди җылылык белән коендырылган. Юк, хәтта мунча кайнарлыгы белән. Ләкин бу кайнарлык бик эчкә яшеренгән. Мунча чабыну кайнарлыгы бу. Ә даһиларның чабынырга яратучылар арасында күбрәк булуын әйтәләр. Хакмы-юкмы? — белмим... Даһилык үзе үк бик катлаулы мәсьәлә...

Бервакыт авылда очрашкач, аның мунчадан чыгып килүе, гәрчә бик каты-каты авыру булсам да, миңа ифрат нык тәэсир итте: Биленә шадра сөлге бәйләгән, гәүдә таза, басып торыш — горур!

Гүя Фәйзуллин мунча чабынмаган, ә бер үзе Берлинны алган!

Валлаһи, дим:

— Рим патрициемени!
— Пәйгамбәрмени!!!
Шул халәт-күренешне, тойгы-сурәтне күргәннән соң, мин аңа карата шаяру катыш шигырьгә охшаш бер нәрсә дә әвәләгән идем.

**Мунча кунагы**

Фәйзуллин чыкты
Парлы мунчадан
Пәйгамбәр сыман.
Яши бу Шагыйрь
Бәйрәмнәр сыман.
Язганнары да
Хәйраннар сыман —
Ә ни рәвешле
Һәр шигъри юлга
Моң-сагыш сыккан?
Үзеннән әле

Фәйләсуф чыккан —
Фәйзуллин чыккан!!
Болар өстенә
«Ташына менеп»
Чабынып чыккан.
Ак-зур сөлгесен
Патриций кебек
Ябынып чыккан.
Язачак шигырен
Сагынып чыккан.
Шигыре кош күк
Кагынып чыккан...

Сәламәт булуга ул нык игътибар бирә, әмма аны ипохондрик дип атап булмас иде. Кем ничек уйлыйдыр, миңа калса: шагыйрь, җан чисталыгы белән беррәттән, тән чисталыгы өчен дә җан ата. Чиста тәндә — чиста җан, чиста җанга — чиста тән!
Аннан соң...
Уйлавымча, ул һәрвакыт алда чабыначак мунчасын һәм язачак шигырен сагынып яши булса кирәк.
Мин моны матур сүзләр өчен әйтмәдем.
Һәрхәлдә, миңа шулай тоела...

## 9. Вакыт иләге һәм Ил-Тел.

Сезнең аяз төнне миллион-миллиардлаган йолдызлар белән тулган биниһая биек, тишек зәңгәрле, серле-дәһшәтле Күккә караганыгыз бардыр.
Менә йолдыз атыла... Менә тагы берсе... Хак тәгалә Күкне иләк итеп шулай йолдызлар или:
— Болары сүнгәннәр...— ди дә... Йолдызлар коела...
— Нигә сүнгәннәр?
— Чөнки алар инде янмый. Алар күптән сүнгәннәр. Йолдызлар да үлә икән...
«Вакыт кына мәңге тантанада»,— ди Фәйзуллин.
Яшәештә Вакыт әнә үз иләгенә салып кеше гомерен или. Көннәр, айлар, еллар коела гына. Һәр тәүлек саен иләктә синең көн-комнарың кимүгә бара. Ни чара?! Әнә бит шагыйрь ничек ди:

Тик онытмаска:
Мине туфрак җибәрде
Кояш астына —
сынамакка...

«Вакыт», гомумән, аның яраткан сүзе. Менә бит 15 яшендә үк әйтелгәне:

Алай үтелгән вакыт...
Болай үтелгән вакыт...

Яшәп үтелгән вакыт,
яшьнәп үтелгән вакыт —
бүтәннәр бәхете өчен
сарыф ителгән вакыт!

Күрәсең, әдәбиятта Фәйзуллинның неофит-өйрәнчек чагы бик аз гына булгандыр. Вакыт дигәндә, менә тагын да бәгырьне өзеп әйткәне:

Яшәү — кыска. Ажагандай.
Үтә гомер цейтнотта!
Бөтен өмет, бөтен ышаныч —
Үзем өчен үзем генә белгән
Вакыт эчендәге Вакытта!

Ләкин...

«Вакыт эчендәге Вакыт» та бетәчәк ич. Шулай булгач, нишләргә? Ил өчен эшләргә! Ил-Тел өчен янарга!!! Бу — мәңгелекнең кеше өчен бирелгән чын-төп юлы...

Халык идеаллары — синең идеалларың булсын. Үз ирегең һәм Халык иреге өчен көрәшү — хак юл (үз Иреге булмаган җан Халык Иреге өчен көрәшә алмый)

Кеше ирекле...
Яланаяк
салкын, юеш ташта торамы ул,
үлән-чәчәк өстендәме,
Һавадамы,
судамы,
җир куенындамы —
Ул ирекле.

Хәятыма тигән
шул зур бәхет өчен
көрәшергә бөек хакым бар.

Бу шигырь 23 яшьлек шагыйрь тарафыннан Казанда 1966 елның 10 августында ук язылган. Әйе, көрәшергә! Фәйзуллинга квиетизм бөтенләй ят нәрсә. Шуңа 1968 елда ук ул:

«Көрәшчеләр кирәк!» — дип оран сала. Гүя 90 нчы еллардагы бәйсезлек, ирек-азатлык өчен бәйгегә алдан ук әзерләнергә чакыра. «Көрәш» — аның яраткан сүзе. Чөнки кул кушырып кына утырганнарга берни дә бирмиләр. Бирсәләр дә — аның өчен хәер алучы мәчет карты булу кирәк. Әнә бит:

...Бар ул тук-шат яшәүчеләр
илсез-телсез калып та.

Шигъри телең булып ник дәшмәскә ди?!

Телең бар килеш
шым тору авыр.

Кешеләрне җан йокысыннан уятырга кирәк! Дөрес, илсез-телсез калган маңкортлар шигырь укымый. Бигрәк тә татар шигырен.

...Каргалар шигырь укыса,
Күгәрчен булыр иде.

Әйе шул!

Күпләребезне коллык хисе куркыткан гына түгел, мескенләндереп читләргә яраклаштырган һәм горурлыгыбызны югалтыр хәлдә исерткән дә. Фәйзуллин русофоб түгел («урыска рәнҗеп туелган»), Ил-Тел югалуын Рәсәй политикасыннан ары ул татарларның үзләреннән дә күрә. Алар характерындагы тискәре яклардан.

Күктән — белепме, көлепме? —
Ярым Ай карап тора.
Гүя әйтә: бу кавемгә
айну да ярап тора.

Ярым Ай — Ислам символы. Мөселманлык эчкечелек белән рәттән атлый алмый. Ләкин ярым Ай — ярты гына ай, тулы түгел. Халыкның бәйсезлеге дә тулы түгел ич! Ул «тарихи махмыр»да. Ә «айну»? Айну ул айлану, тулы айлы — тулы тормышлы, чын ирекле булу. Бик шәп образ, киная-ишарә бу. Бары тоя белергә генә кирәк.

Вакыт иләге...
Ил-Тел бөтенлеге...
Яшәештә, халыкларның үзара мөнәсәбәтләрендә Бәйсез Ил, Биксез Телнең генә туган халкың гомеренә бетмәс-төкәнмәс еллар-гасырлар китерәчәген шагыйрьләр — нечкә җаннар, тел сакчылары — ныграк аңлый шул. Тукай, Дәрдемәндләр кебек...

Ил корабын җил сөрә...— дип...

«И туган тел...» — дип...

Фәйзуллинча:

Дәүләт диген Сабантуй...— дип...

## 10. Халык хәтере.

Үсмерчак дәфтәренә әле 15 яшьләрендә үк:

Шагыйрь булып, китабыңны тотып.
кайтсаң иде туган ягыңа! —

дип язган Равил Фәйзуллин 35 еллык иҗат чорында татар вә рус телләрендә 33 китап чыгарды инде. Һәр елга бер китап диярлек ич бу! Әнә, Гөлзадә Бәйрәмова язганча, шагыйрьнең 3 томлыгына 1600 ләп шигыре, 3 поэмасы кергән. Шигырь юллары саны якынча — 24000. Ә йөзләгән мәкаләләре, очерклары, эссеистик язмалары?! Аның иҗаты турында гына 300-ләп тәнкыйть мәкаләсе басылган. Балалар өчен дә күп язды ул. Аңа кыскалык хас, ул японнарча иҗат итәргә ярата, ләкин без шагыйрь эпик пландагы зур күләмле әсәрләр өстендә эшли алмый дибез икән, шактый ук хаталанырбыз, чөнки «Гадиләргә гимн», «Керәшчеләр» поэмалары нәкъ киресен раслый. Ә инде иң көчле дәлил кирәк дисәк, пролог, эпилог һәм 15 бүлектән торган «Сәйдәш» поэма-силуэтын атый алабыз. «Сәйдәш» — шагыйрьнең киң колачка ия булуына ишарә генә түгел, ә фактик гәүдәләнеш ул.

Хак сүз — шагыйрь 1600 шигыре белән түгел, ә 16 шигыре белән дә кешелек хәтерендә калырга мөмкин. Әйтик, мондыйраклары белән: «Менә без дә үсеп җиттек, әни!», «Кыр казы исе килә», «Язгы дәрт белән өздерә...», «Болгарда төн», «Аккошлар», «Әй, мәхәббәт», «Нишләр идем, әгәр дә мин...», «Саубуллашу», «Көн уртасында килгән уй...», «Шаһзадә дә түгел, галим зат та...», «Дошман — сигез, без тугыз», «Бөтен өмет», «Август», «Кояш баю»...

— Уналтымы?!

— Ә «Атлар, атлар»? Ә башкалары? Алар бит ятим вә рәнҗүле күзләре белән карап: «Ә мин? — диләр? Ә без?? — диләр. Мин син санаганнардан ким мени? Без — мескен мени??

— Тагы санаийк алайса: «Сөлге», «Умырзая», «Яраттым», «Чыныгу», «Си минор», «Иясез шатлык», «Тордым басып Кама ярында», «Таныйм да, танымыйм да» һәм...

Йә, җитәр!

Мин дә «һәм башкалар» диярга теләдем ич!

Тормышта безне әнә шул «һәм башкалар» еш кына коткара да инде. «Һәм башкалар» исемлегенә кергәннәр генә нәүмизләнеп торалар. Алар хезмәте вә иҗаты, вакытлар узуга, төссезләнеп, тоныкланып кала, кайвакыт юкка ук чыга...

— «Һәм башкалар» рәтендә калмас өчен иҗатчыга нишләргә соң?

— Халык хәтерендә калырга!

— Өстә аталган шигырьләре беләнме?

— Әйе.

— Алар гына җитмәсә?

— Үзенең фәлсәфи акылы белән! Безнең татарда чын мәгънәсендәге фәйләсуфлар аз.

Аек акыллы, шактый мәгърифәтле милләт булсак та. Сократ, Аристотель, Платон, Спиноза, Гегель, Бердяевлар тусын өчен горур һәм бәйсез халык булу кирәк. Коллыкка төшкән милләтнең гамәле бер — буйсыну, эчендәге яшерен уе — бу коллыктан ничек котылу? Ул Космос, Яшәеш, Кешелек турында зурдан

уйлый алмый. Аның өчен аң-белем, зыялылык, интеллектуальлек һәм Җан-Рух эзләнүләре өстенә әле Ирек һәм Иркенлек тә кирәк. Философ — даладагы йөгәнсез аргамак ул, тышауланган боек бахбай түгел, эш аты түгел. Татар күбрәк эш аты, алаша... Мәрҗәниләр, Риза Фәхретдиновлар сирәк...

Әмма зур фәйләсуфлары булмаган халыкның да бөек шагыйрьләре булырга мөмкин. Татар халкы да шундый: Кол Гали, Сәйфи Сараи, Мөхәммәдъяр, Акмулла, Дәрдмәнд, Тукай, Туфан, Фәйзуллин — фәлсәфи шагыйрьләр. Фәлсәфилек урта гасырлардагы суфи шагыйрьләрдә дә нык сизелә. Алар — дала аргамагы...

Хәзергеләрдән фәлсәфилек — Равил Фәйзуллинда... Кемгә ничектер, шушы ягы белән ул миңа якын да. Уй-акылы көчле анда, тирәнлек бар анда. Бүгенге татар шигъриятендә ул — иң көчле фәлсәфи шагыйрьдер, мөгаен. Шул ук вакытта бик нечкә лирик та:

> Башны салларга салып,
> Китәсе иде агып —
> дәшәр иде әле дулкыннар
> бер шагыйрь җанны танып.

Монда: бер гомер, сагыну халәте, тетрәндергеч канәгатьсезлек, гаҗәеп моң, ирләрчә сагыш...

Мондый юллар Халык Күңелендә калачак.

Инде бер сорауга күчик:

— Язучыларның төп вазифасы нидә?

— Хәтер булуда.

— Нинди хәтер?

— Халык Хәтере!!!

Чын Шагыйрь Халык Хәтере булырга тиеш. Ул үткән ялгышларны искә төшерсен һәм киләчәк афәтне искәртсен. Матурлык вә яхшылыкка өндәсен.

Әнә шундыйлар гына Халык Хәтерендә калачак. Халык Хәтере була алганнар гына...

Һәрхәлдә, Фәйзуллин шулар рәтендәдер, дим.

## III

## Ахырсүз

Соңгы сүзгә җитүгә, алдан искәртеп куйыйк: бу язма тәнкыйть мәкаләсе түгел, ә эссе-уйланулар, шагыйрьнең өчтомлыгын укыгач туган кайбер уй-фикерләр, аларның да аерым фрагментлар рәвешендәрәк чагылышы гына. Киләчәктә Фәйзуллин иҗаты турында аерым тикшеренүләр күп булыр әле. Ул үзе дә:

> Сүзләремнең чын бәясе
> алыныр көн алда әле! —

диеп тәмамлый өчтомлыгын.

Тагын...

Язганнары хәйран гына һәм шактый күп җыелса да, алдарак әйткәнемчә, ул «шигъри экстаз»да яши. Әнә бит шагыйрь ничек ди:

### Туктармы?..

> Җил — исүеннән туктармы,
> җилкән корганга карап?
> Чирәм — үсүдән туктармы,
> очын кыргалга карап?
> Су — хәрәкәттән туктармы,
> буып куйганга карап?
> Адәм — көрәштән туктармы,
> иреген тыйганга карап?
>
> *(1983, январь)*

Моңа:

Шагыйрь — язудан туктармы,
еллар үткәнгә карап?
Шигырь — яшәүдән туктармы,
Шагыйрь киткәнгә карап? —

дип тә өстәргә була.

Әйе...

Фәйзуллин үз сүзен әйтте!

Әмма дөнья киң, гомер учагы һаман да дөрләп яна.


Аның әйтәчәкләре алда әле. Бәлки, тагын да камилрәк сүзләре, шигъри эзләнүләренең иң отышлылары. Соңгы елларда татар поэзиясе традицияләренә дә тагын нык якынайды ул, ләкин шәкли якны да һич онытмый. «Булма такмакчы!» — аның иҗади кредоларыннан берсе булса кирәк.

Киләчәктә Шигърият бакчасында Шагыйрьнең чәчәк атачак Яңа Гөлләре бар:

ялкын гөле, алтын гөле;
акын гөле, акыл гөле;
гавәм гөле, галәм гөле...

Арыслан йолдызлыгы астында туган Равил Фәйзуллин — бүгенге татар поэзиясе арысланнарының берсе. Бирсен Алла — киләчәктә дә бу арысланлыгын югалтмасын! Әйтте — тагы да әйтсен!..

*1996 ел. (15 март — 15 апрель.)*
*Түбән Шон.*



# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

## Рәшит Фәтхерахманов

# ТОРМЫШТАН КИЛГӘН ГЕРОЙЛАР

### (МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ ӨЧТОМЛЫГЫ ЧЫГУ УҢАЕННАН)

Иҗат серләре... «Иҗат процессының асылына төшенеп, аны өйрәнеп буламыни?» — дип шик белдерер кайберәүләр бу турыда сүз чыкканда. Чынлап та, рухи дөнья лаборатор анализга бирелми торган өлкәләрнең берсе булып санала. Әдәби образның туу, роман-повестьларның барлыкка килү процессын бөтен тулылыгы белән күзәтеп, бу процессны канунлаштырып, билгеле бер эзлеклелеккә салып өйрәнеп бетерү мөмкин эш түгел. Тик шулай да «язучының остаханәсе» дигән сүз, «иҗат лабораториясе» дигән төшенчә, иҗат психологиясе турында галимнәрнең хезмәтләре, язучыларның иҗат процессы турында мәкаләләре, истәлекләре бар. Тагын хөрмәтле язучыбыз мәрхүм Мөхәммәт абый Мәһдиевнең: «Килер бер вакыт, Тукайча әйткәндә, һәр әсәрнең ничек язылуы, һәр әдипнең ничек яшәве турында бездә дә язарлар әле», — дигән сагышлы моң белән өретелгән җөмләсе бар. *(М. Мәһдиев «Ачы тәҗрибә». Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1993, 298 бит).* Димәк, язучы остаханәсе бөтенләй үк тикшеренүгә бирелми дип әйтә алмыйбыз икән. Алай гына да түгел: язучы иҗатын аңлауда, аның нечкәлекләренә төшенүдә иҗат лабораториясенә кереп өйрәнү һәрвакытта да нык ярдәм итә, тикшеренүләре зуррак нәтиҗәләргә китерә ала.

Татар әләбият белемендә, Нил Юзиевның «Хәзерге татар поэтикасы» исемле саллы хезмәтен, И. Башированың «Җидегән чишмә моңы» китабын исәпкә алганда да, әлеге мәсьәлә аз өйрәнелгән өлкәләрнең берсе булып кала бирә. Бигрәк тә татар прозаикларының иҗат лабораториясен өйрәнү проблемасы — күтәрелмәгән чирәм хәлендә. Ә бит һәрбер танылган язучы иҗаты шушы юнәлештәге өйрәнүләрне сорый. Чөнки һәр талант — кабатланмас бер дөнья, һәрбер әдәби җәүһәрнең туусы зур вакыйга, әдәби мохиттә тирән эз калдыра торган күренеш.

Бу җәһәттән караганда, танылган язучы Мөхәммәт Мәһдиевнең иҗат лабораториясе иҗатының үзе төсле үк бик үзенчәлекле, башкаларныкыннан аерылып тора торган бик күп кызыклы якларга, өлешләргә ия. Укучыга «Кеше китә — җыры кала», «Фронтовиклар», «Ут чәчәге» һәм башка шуның кебек җәүһәрләрне биргән, шигъриятле мемуар жанрында безгә кыйммәтле истәлекләр калдырган Мөхәммәт Мәһдиев феномены 70—80 нче еллар әдәбияты күгендә якты йолдыз булып балкысын өчен, әлбәттә, язучы шәхесенең бай рухи дөньяга, уникаль психологик сәләтләргә ия булуы кирәк булган. Озак еллар буе язучының иҗат лабораториясен өйрәнү дәверендә мин моның чынлап та шулай икәнлегенә төшендем.

Әдәби иҗат хыялга никадәр генә бай булмасын, аның нигезе, чишмә башы — реаль тормышта. Язылачак әсәрләренең оеткысы язучы күңеленә балачактан башлап салына, тормыш тәҗрибәсе, күзәтүләр белән баетыла, тормыштан алган тәэсирләр, тетрәнүләр аның рухи дөньясын формалаштыралар, индивидуаль-психологик үзенчәлекләр белән кушылып әдипнең индивидуаль стилен барлыкка китерәләр. Геннар аша тапшырыла торган информациядән — язучы талантыннан — башка иҗатчы шәхесенең барлык яклары да тышкы тирәлек тәэсирендә формалаша.

«Бөтен хикмәт — балачакта. Балачакта нинди юнәлеш бирелсә — кеше гомере буе шуны эзли, үзе дә аңламастан, шуңа омтыла икән. Мин педагогика фәненең иң әһәмиятле бер законын олыгайган саен тирәнрәк аңлый барам. Кешене формалаштыруда өч шарт бар, ди ул фән. Болар нәселдән килгән сыйфатлар, тирәлек һәм тәрбия. Зур ачыш бу! Кеше гомерендә, кеше биографиясендә әнә шул өч шарт даими рәвештә катнаша, гомеренең төрле мизгелләрендә шул шартларның әле берсе, әле икенчесе калкып чыга»,— дип яза язучылык хезмәте турындагы «Мәшәкатьле һөнәр» исемле мәкаләсендә М. Мәһдиев. *(«Идел» альманахы, 1984, 78 бит).*

Язучының иҗат лабораториясе дә еракта, әнә шул балачактан алган тәрбия һәм тәэсирләрдән башлап формалаша. Тикмәгә генә әтисе Сөнгать абзыйның, туганнан туган абыйсы Фәрит Сафинның ничек итеп матур әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләүләрен ягымлы җылылык белән искә алмый язучы. Язучы күңелендә озак еллар буена сакланып килгән, язасы килү теләгенең (әдәби әсәр язарга иң беренче этәргечнең дип аңлыйк) башы да әнә шул әдәбиятка булган мәхәббәткә барып тоташа торгандыр, мөгаен. «Гомер буе язасы килде» — дип искә алган иде Мөхәммәт абый әңгәмә вакытында, үзенең беренче әсәрләрен утыз сигез яшендә генә яза башлавын күз алдында тотып.

Еллар буе тупланган тәҗрибә, эчке тетрәнүләр, шуларның күңел дөньясында бертуктаусыз эшкәртелүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән әсәрләрнең кайсын гына алып карасак та, язучы тормышыннан аларның нигезен, әдәби образларның табигыйлегенә тәэсир иткән нинди дә булса бер вакыйга табарбыз. Язучы үзе дә иҗатының кайсы ягына кагылышлы сорау бирсәң дә, һәрбер үзенчәлекнең тормыштан килүен ассызыкларга ярата иде. Язучы иҗатының үзенчәлекле яклары: аның әсәрләренең тирән сагышка, моңга ия булуы, шул моңның нечкә юмор белән үрелеп баруы. Моң белән юморның синтезыннан торган, татар әдәбиятында «Мөхәммәт Мәһдиев стиле» дип исеме чыккан бу үзенчәлекнең чыганагын да әдип үзе тормыштан күрә, балачактан ук алынган тәэсирләргә китереп бәйли. Язучы белән «Татарстан яшьләре» уздырган бер әңгәмәдән өзек карап үтик.

«Сагыш. Мин моны соңыннан гына аңладым: романга *(сүз «Фронтовиклар» романы турында бара — Р. Ф.)* ул минем балачактан килеп кергән. Авылда солдат хатларын мин яза, мин укып бирә идем... Кайбер солдат үз хатын йөрәк өзгеч җыр белән тәмамлый, аны укыганда хатыннар елыйлар. Солдаткалар төннәр утырып хат язганда яшертен, иң нечкә әйберләрне дә яздыралар иде (шуңа да алар хатларны олылардан яздырмаганнар). Сагышның нәрсә икәнен мин әнә шул чакта белдем.

— Ә юмор?

— Аның башы — әтидән. Өйдә шаян сүзне яраталар иде. Мәзәкләр язылган календарь битләренең 20 нче еллардан ук җыелып килгән тупланмасы миндә әле дә саклана. Менә дигән юмор мәктәбен флотта үттем». *(«Иң әйбәт ял — иҗат», «Татарстан яшьләре», 1975 ел, 1 ноябрь).*

1986 елның мартында ул вакыттагы 10 нчы интернат-мәктәп укучылары белән очрашу барышында иҗатындагы юморның чыганагы турында сорау бирелгәч, автор гаиләсендә юмор яратулары, һәр көнне кичен булып узган кызыклы хәлләр турында сөйләшеп алулары турында әйткән иде. Күрәбез, стиленең үзенчәлеген билгеләүдә мөһим роль уйнаган нәрсәләр авторга тормыш тәҗрибәсе аша килә.

Әдәби әсәр нинди генә темага, кем тарафыннан гына язылмасын, иҗат процессының башында иң әүвәл язучының тормышны күзәтүләре ята. Язучы иҗатының аерылгысыз өлеше булган хыял да әнә шул күзәтүләргә нигезләнә. Художник талантының үзенчәлекле элементы булган күзәтүчәнлек, талант никадәр зуррак булса, шулкадәр үткенрәк, кабатланмасрак була бара. Тормышның гаҗәп катлаулы, вакыты белән бик эчпошыргыч, вакыты белән тирән фаҗигале яисә үтә көлкеле вакыйгалары эченнән бер-берсен кабатламас меңләгән төрле йөзләр, характерлар арасыннан иң кирәкле детальне, иң төсле буяуларны, иң дөрес сызыкларны, вакыйгаларны тотып алып әдәби образ, сокландыргыч портрет, динамик сюжет дәрәҗәсенә күтәрү өчен бай фантазия белән бергә дөньяга үзенчә генә һәм художник күзләре белән карый белү дә кирәк. Тормыш детальләрен җентекләп күзәтә белү сәләте, аларны әдәби әсәрләрдә урынлы итеп куллана белү осталыгы, булачак персонажның эчке дөньясына кадәр үтеп керерлек күзәтүчәнлек психологик анализ остасы Мөхәммәт Мәһдиевнең иҗат лабораториясенә хас нәрсә. Тормыштагы һәр вакыйга, һәр күренеш язучының рухи дөньясын баета, тулыландыра, вакыты җиткәч яңа роман яки повестьның языла

башлавына этәргеч булып хезмәт итә. Прозаик иҗатындагы портретлар төрлелеге, табигать күренешләренең вак нюансларына кадәр тотып алынган үзенчәлекле тасвиры, безне чолгап алган тирәлектән килеп кергән авазлар, исләр, төсләр гаммасының муллыгы, теленең аһәңлелеге, милли колоритны бирә белү сәләте, тагын башка бик күп үзенчәлекләр — болар барысы да М. Мәһдиев талантының гаҗәп дәрәҗәдә күзәтүчән булуы хакында сөйли. Язучыда тормышны күзәтү осталыгының зурлыгы турында аны якыннан белгән кешеләр дә әйтә, әдәби тәнкыйть тә вакытында аңарда бу талантның нык үсканлеген таныган иде. Әңгәмә вакытында әдип үзе дә, тормыш материалына бик игътибарлы булуын раслап, менә болай дигән иде:

«Кешеләр төрлечә булалар. Менә берәүләр үзләренең төсе-бите, кыяфәте, характеры белән аерылып торалар. Менә болар әдәбият өчен иң уңай материал инде. Уртакул кешеләр була. Әдәбиятка алар да кирәк, әлбәттә. Һәм бик төссез кешеләр була. Алар да шул үзләренең төссезлеге белән әдәби герой булып кереп китәләр.

Язар өчен иң уңай образ, әлбәттә, тискәре образ. А. Н. Толстой әйткән, тискәре образ үзеннән-үзе бәреп, нахальный рәвештә әдәбиятка кереп тора, дигән. Ә менә уңай образны тудыру бик кыен, дигән. Мин моны үземнең практикамда белдем. Толстойның сүзләрен белмидер идем әле. Берничә әсәр язганнан соң гына Толстойның шул сүзләренә очрадым. Чыннан да, кайсы гына әсәрне алып карама, минем үземнең әсәрдән, иң җете төсле, буяулы, чәчрәп тора торган персонажлар — алар тискәре яки ярым тискәре геройлар, персонажлар. Ә уңай геройны эшләве, чыннан да, бик кыен.

Ә болай мин геройларны тормыштан алам. Газета-журналлардан алмыйм. Алардан алып яза алмыйм. Миңа үзем күргән кеше кирәк. Үзем күргән. Минем аның белән таныш ук та булмавым мөмкин. Вокзалда очравы мөмкин, поездда очравы мөмкин, каядыр кибет чиратында күрергә мөмкин мин аны. Ләкин үзем күрмәгән геройны тудыра алмыйм. Һәрбер геройның, һәрбер персонажның нигезендә, әлбәттә, үзем күргән конкрет бер шәхес» *(язучы белән әңгәмәдән, 1991 ел, 1 август)*.

Язучы күзәтүчәнлегенең ни дәрәҗәдә зур, карашының никадәрле үткен булуын, тормышның вак детальләренә кадәр үтеп кереп, аларны анализлау куәтенең ни хәтле көчле икәнен раслаучы мисалларны әдип иҗатыннан күпләп табарга, аларга сокланырга, тормышка игътибарлы караш ташларга Мәһдиевтән өйрәнергә кирәк.

Тормыш фактларын чын мәгънәсендә язучы һәм галим күзлегеннән карап өйрәнә белгән сирәк шәхесләрнең берсе ул. Без бер генә мисалны карап үтик. Һәркайсыбызның тәрәзә төбенә килеп кунган, җимлектән ит чүпләгән песнәкне күргәнебез бар. Шул турыда язарга кушсалар, кыска гына бер җөмләдән арттыра алучылар бик сирәк булыр, язылган җөмләбездән дә шаккатырлык берни дә тапмаслар. Хәзер инде шул күренешне художник һәм психолог күзләре белән күзәткән язучыдан бер өзек карап үтик:

«Берничә көн күзәтүләрдән соң мин песнәкнең ашау-эчү, үзара мөнәсәбәт мәсьәләләре бөтен бер системага корылып, аерым кагыйдәләргә корылганына төшендем.

Иң беренчесе шул — песнәкләр бу азыкны үзләренә махсус куйганны белеп алгач, хуҗага ихтирам йөзеннән пәрдә ачылгач кына, хуҗаны күргәч кенә тәрәзә янына очып килаләр икән. Без — карак түгел, без — намуслы, димәкчеләр.

Икенчесе — боларның кагыйдәсе буенча өч тапкыр чукыгач карап аласы: форточкадан мәче сикермәсен, күрше балконда ябалак сагалап тормасын. Шуңа күрә тәрәзә каләендагы тавыш монда бер ритм тудыра: тек-тек-тек, тек-тек-тек. Әнә шулай дүрт яки биш цикл (алты түгел) текелдәп алганда вахтага алмаш килеп төшә...

...Тагын бер сыйфат: һич тә беткәнче ашыйсы түгел, ә иртәнге аш вакытында бер кат тамак ялгап алгач, туктыйсы. Көндез, көн авышкач, тагын бер тапкыр шундый «визит». Кичке якта, гадәттә, алар күренми». *(М. Мәһдиев «Бәхилләшү», 435 бит. Татарстан китап нәшрияты, 1990)*.

Тормыш фактларын эзлекле рәвештә күзәтергә өйрәнгән язучы (орнитолог түгел) «Бәхилләшү» повестеның бишенче бүлегендә безгә кошлар турында әллә никадәр мәгълүматны популяр, әдәби формада тапшыра, гомумиләштерүләр ясый, нәтиҗәләр чыгара. Кыска гына бер өзектән дә без язучы күзәтүчәнлегенең тормышның һәр тарафына үтеп кергәнлеген, авторның эзләнүчән, кызыксынучан

шәхес икәнлеген күрә алабыз. М. Мәһдиев прозасында әдәби детальнең күче турында сөйлибез, язабыз икән, аның башы әнә шул күзәтүчәнлеккә барып тоташа торгандыр, мөгаен.

Язучы — кешеләргә, аларның портретларына, холык-фигыльләренә, тышкы тирәлеккә, телгә гаять дәрәҗәдә игътибарлы. Язучы теленең байлыгы турында сүз алып барабыз икән, ул байлыкның күктән төшмәгәнлеген, төпле өйрәнүләр, җентекле тикшеренүләр, сүзләрнең яңгырашына, аларның мәгънәсенә, төсмерләренә игътибарлылык, башка әдипләрнең телен күзәтү, җирле сөйләмнең аһәңен, үзенчәлекләрен тою нәтиҗәсендә авторның рухи дөньясында барлыкка килүен танырга тиешбез. Берничә тапкыр студентлар белән фольклор экспедициясенә чыгып, халык авыз иҗатын туплау, фольклорны фән буларак университетта укыту, сугышка кадәрге һәм сугыш чоры татар авылында җырланган җырларны хәтерләү, ул чор кешеләренең сөйләмен онытмау — язучы теленең йөзен билгеләүдә әһәмиятле роль уйнаучы факторлар. Язучының җырларны әдәби әсәрдә куллануы да бик үзенчәлекле. Мәһдиевтә җырлар әдәби әсәр тукымасына үзләренең эчтәлеге, мәгънәсе, сүзләре белән генә түгел, ничек башкарылуы, реаль шәхес тарафыннан ничек итеп җырлануы, геройның ул вакыттагы үз-үзен тотышы, авазларның әйтелү-яңгырау үзенчәлекләре белән килеп керәләр. Автор җырларның башкарылуы турында сөйләгәндә, аларны укучы колагында да яңгыраарлык дәрәҗәдә максималь төгәл итеп тапшырырга омтыла. Бу язучының тормыш детальләрен иң вак сызыкларына кадәр төгәл итеп, конкрет итеп күзәтә алу сәләте турында сөйли.

Г. Кандалый, Г. Тукай басмаларындагы төгәлсезлекләр, хаталар әдипне борчый. Ул төгәлсезлекләр турында әрнеп, аларны төзәтеп, сүзләрнең башка вариантларда куллану мөмкинлеген фаразлап язган күпсанлы мәкаләләре, халык җырларындагы сүзләрнең бүгенге кулланылышын анализлаган язмалары әнә шуны күрсәтә. Язучының тормышка актив карашта торганлыгын, иң вак детальләрнең дә үз урынына дөрес утыруын тоярлык дәрәҗәдә таләпчәнлеген раслый.

Язучының тормыштагы кешеләр сөйләменә ни дәрәҗәдә игътибарлы булуын раслаучы бер фактны мин үзем дә китерә алам. 1986 елның март урталарында без аның белән Казан шәһәренең 10 нчы интернат-мәктәбендә очрашу уздырдык. Ул чакта язучы әлеге повесте өчен Г. Тукай исемендәге премиягә тәкъдим ителгән иде. Укучылар язучының иҗаты турында үз фикерләре белән уртаклашып чыгыш ясадылар. Мөхәммәт абый укучыларның сөйләмен игътибар белән тыңлап утырган икән, унынчы класстан бер егет сөйләгәндә, колакка пышылдап, укучының кайсы районнан икәнлеген сорады, үзе үк әйтеп тә бирде. Миңа бары тик язучы сүзләренең дөреслеген танырга гына калды. Соңыннан язучы урамда булмасын, трамвайда булмасын, кешеләр сөйләменә игътибарлы булуы турында, сөйләменә карап кешенең кайсы төбәктән булуы, холкының үзенчәлекләре хакында күп нәрсә белергә мөмкин икәнлеген әйтеп узды.

Тормышны күзәтү сәләте язучыда никадәр генә актив, әдәби иҗат эшендә аның роле күпме генә зур булмасын, ул әле тормыш тәҗрибәсенең бер өлеше генә. Мәһдиев таланты тәрәзәдән урамга караш ташлап кына да әллә никадәр мавыктыргыч сюжетлар корырга сәләтле булса да, әдәби әсәрләрендә тормыш тәҗрибәсенең биографик өлеше, вакыйга-кичерешләрнең язучы йөрәге аша узганнары, аңда һәм эчке аңда (подсознание) калган тәэсирләр йогынтысы нык сизелә. Мөхәммәт Мәһдиевнең иҗат лабораториясендә биографик материалның мул-лыгы, сикәлтәле, катлаулы тормыш юлын узган шәхеснең кичерешләренең байлыгы, әдип үзе катнашкан вакыйгаларның төрлелеге күзәтелә, иҗат процессында аларның актив катнашуын тоемларга була.

Автобиографик, документаль әсәрләр исемлегенә кертелмәсәләр дә иң беренче әсәрләреннән булган «Без — кырык беренче ел балалары», «Кеше китә — җыры кала» повестьларында ук биографик тормыш материалының әсәр тукымасында яшәвен күрергә, язучының үз тормышыннан алынган вакыйгаларның повестьларда киң кулланылу очракларын табарга була. Бигрәк тә «Без — кырык беренче ел балалары» повесте бу яктан үзенчәлекле. Шул ук юнәлешне «Фронтовиклар» романы һәм башка әсәрләрдә дә күрәбез. Язучы тормышны, язылачак геройларын беркайчан да махсус өйрәнеп, иҗат командировкаларына йөреп әсәрләр язмады диярлек. «Мәңгелек яз» романын, бәлки, күпмедер дәрәҗәдә искәрмәгә кертергә буладыр. Әдәби тәнкыйтьнең әлеге әсәрне уңышсыз әсәрләр исемлегенә кертүе дә, авторның тормышны кичереп түгел, ә өйрәнеп язуыннан килә торгандыр.

Биографик тормыш материалының, авторның үз тәҗрибәсенең әдәби әсәрләргә нигез булып ятуына язучы иҗатыннан мисалларны күпләп китерергә мөмкин. «Фронтовиклар» романына гына тукталып үтик. Язучының биографиясе белән романның төп герое Рушад Сулимов язмышы арасында күп кенә уртаклыклар табарга мөмкин булса да, роман автобиографик әсәр түгел, Рушад образы да авторның күчермәсе дип әйтеп булмый. Ул — җыелма образ. Язучы «Комсомолец Татарии» газетасында Рафаэль Мостафин соравына җавап биргәндә үзе дә шул хакта әйтә. Стильне бөтен тулылыгы белән саклау йөзеннән Мостафин соравын һәм авторның җавабын тәрҗемәсез рус телендә карап үтик.

— «В какой мере роман автобиографичен? Мне приходилось слышать мнение, что главный герой романа Рушад Сулимов — это второе «я» автора. Ведь вы тоже служили во флоте, затем много лет работали учителем в сельской школе.

— И все же говорить об автобиографичности нельзя. Начать с того, что я не был на фронте: когда началась Отечественная война, я был мальчишкой. На флоте я служил в начале 50-х годов, а в школе работал значительно позже описываемых событий. Я хорошо знал бывших фронтовиков, работал с ними в одном коллективе, со многими дружил и всегда восхищался зрелостью их суждений, хозяйской озабоченностью за все, что совершается в мире, высоким чувством ответственности... *(Р. Мустафин — М. Магдеев, «Поколение жизнелюбов», «Комсомолец Татарии», 1974, 15 мая)*.

Әйтелгәннәрдән чыгып, роман автобиографик булмаса да, язучының тормыш тәҗрибәсенең анда зур роль уйнаганлыгына ышана алабыз. Рушад образын тудырганда да автор үз тормышыннан вакыйгаларны киң файдалана. Бу исә образның табигый килеп чыгуына ярдәм итә. «Рушадның беренче тарих дәресен уздырганын хәтерлисезме, «Фронтовиклар»да? Бу — минем флоттан кайткач биргән беренче дәрес» — дип билгеләп уза автор үзе дә. *(М. Мәһдиев, «Иң әйбәт ял — иҗат», «Татарстан яшьләре», 1975 ел, 1 ноябрь)*.

Язучы истәлекләреннән романга кагылышлы бүтән шундый очракларны да таба алабыз. «Ачы тәҗрибә»не ачып укыйк:

«Родларны узганда мин бер хата җибәрдем. Училище коридорында йөргәндә Хәлим ага мине туктатты да өеннән почтасын алып килергә кушты. Мин торып йөгердем, бер хат, берничә газета алып килдем, шакып бүлмәсенә кердем дә, русча ярып, аңа:

— Хәлим Фаттахович, вот принесел, — дидем.

Өлкән укытучы буыла-буыла, йөткерә-йөткерә көлде. Мин ут булып яндым, әмма ул мине тынычландырды:

— Вот син әйбәт белгәнгә күрә ялгыштың, — диде. — Син бит бу җөмләне әйтер алдыннан уйлап куйгансың: кыз бала булса — принесла, ә ни өчен әле ир бала әйтелешендә «принесел» булмасын? Молодец, димәк, син рус телен инде үзләштерә башлагансың... (Бу фактны мин «Фронтовиклар» әсәрендә файдаландым.) (М. Мәһдиев «Ачы тәҗрибә», 51 бит. Казан, Татарстан китап нәшрияты. 1993).

Югарыда искә алынган факт, әлбәттә инде, Рушад образында файдаланыла алмый. Автор аны мәктәп укучысы җибәргән хата итеп куллана. Димәк, язучы шәхси тормышыннан кайбер фактларны әдәби образ тудырганда файдалана икән, ул әле геройның прототибы әдип үзе дигән нәтиҗәгә килергә ярамаганлыгын күрсәтә. Мәһдиев үзе дә «Фронтовиклар» романындагы геройларның барысы да җыелма образлар дигән фикергә басым ясый, шул ук вакытта геройларның тормыштан килеп кергәнлекләрен, тормыштагы прообразларның романнан үзләрен тануларын да яшерми.

Язучының тормыштагы реаль прототиптан әдәби образ ясавы бик үзенчәлекле. Еш кына тормыштагы кешеләр теге яки бу образның тууына этәргеч бирсәләр дә, барлыкка килгән герой үз язмышы, эчке логикасы белән туа, кызыклырак, колоритлырак образга әйләнә. Язучы сүзләреннән тормыш материалы һәм автор фантазиясе арасындагы нисбәтне дә чамаларга була. Әдип җыелма образның сыйфатларын тормыштан бөртекләп җыя, тышкы кыяфәтен тасвирлауга этәргече дә нинди дә булса реаль тормыш кешесе бирә, шуңа да карамастан персонаж авторның фантазиясе белән баетылганнан соң гына табигый итеп эшләнгән геройга әйләнә. Автор фантазиясе геройның эчке дөньясына үтеп керә, тойгыкичерешләрен сурәтли. Роман һәм повестьлардан геройларның хискә һәм моңга бай әллә никадәр эчке монологларын таба алабыз. Бай рухи дөньяга ия булган персонаж, аның күңелендәге хисләрнең табигый тибрәнешләре, уй-фикерләренең

реальлеге — барысы да геройның автор аңында җанлануы, иҗатчы хыялы белән бәетылуы турында сөйли. Мәһдиев иҗатында автор фантазиясе белән тормыш материалы арасыдагы тыгыз бәйләнешне күрергә мөмкин. Язучы фантазиясе тормыштан ераклашкан ниндидер гайре табигый нәрсә түгел. Рус язучысы Константин Фединның «Фантазия — ул күзәтүләр җимеше» дигән сүзләрен дәлилләүче ачык мисал булып тора М. Мәһдиев иҗаты.

Прототиплар турында сүз чыккач, язучының иҗат лабораториясендә аларның күренекле урын тотуларын билгеләп үтү дә урынлы булыр. «Торналар төшкән җирдә», «Бәхилләшү», «Ачы тәҗрибә»нең авторы безгә үз иҗатының чыганакларын, тормыш материалының әдәби әсәрләргә ни рәвешле керүен мавыктыргыч формада ачып бирде. Әлеге әсәрләрне җентекләп өйрәнү, иҗат процессында тормыш тәҗрибәсенең, прототипларның нинди урын алып торуын күзәтергә ярдәм итә. Әйтик, «Торналар төшкән җирдә» повестендагы реаль шәхес Тәлгать Ибраһимов белән танышканнан соң, аның язмышындагы кайбер моментларны без «Фронтовиклар»дагы Гата Сәләхов линиясендә дә таба алабыз. Шул ук әсәрдәге горур, шаккаттырырга ярата торган, ярсу холыклы Зәкәрҗан чалымнарын да Гатада сиземләргә мөмкин. Кернәле «электростанциясе» начальнигы Хәби Фазуллин «Фронтовиклар»дагы Заһир образына шактый «көч» биргән дип нәтиҗә ясарга да җирлек бар. Әлбәттә, әдәби образ инде ул беркайчан да тормыштагы прототипка тәңгәл килеп бетә алмый. Әдәби геройлар арасында прототипка аеруча якын торганнарыннан берсе — «Без — кырык беренче ел балалары» повестендагы рус теле укытучысы Хәлил Фәтхиевич образы. Автор персонажның исемен дә реаль тормыштагы шәхес — Хәлим Фәттахович Искәндәревныкыннан аз гына үзгәртеп алган. Искәндәрев язмышы, аның холкы, рус телен укыту методикасы, дәресләре — барысы да «Без — кырык беренче ел балалары» повестендагы персонажда киң чагылыш тапкан. «Ачы тәҗрибә» китабында язучы бу шәхеската яңадан әйләнеп кайтты. Тарихи шәхес турындагы истәлекләре, фәнни эзләнүләр белән баетып, архив материалларын файдаланып, укучы өчен кыйммәтле материал булырдай итеп бастырып чыгарды.

«Без — кырык беренче ел балалары» — язучының беренче әсәрләреннән. Шуңа күрәдерме язучы анда үз тормышы тәҗрибәсен аеруча киң файдаланган. Повестьның күп кенә прототипларын авторның үз чыганакларыннан ук табарга мөмкин. Кайбер чакта прототиплар көтелмәгән җирдән дә табылып куялар. Хөрмәтле язучыбыз Гариф Ахунов «Йолдызлар калка» исемле автобиографик повестенда безгә менә нәрсәләр сөйли:

«Мөхәммәт Мәһдиев, үзе язучы булгач, башта «Без — кырык беренче ел балалары» дигән талантлы, гаять үзенчәлекле повесть язды. Ә 1993 елны «Ачы тәҗрибә» исемле истәлекләр китабы бастырды. Бу әсәрләрнең икесендә дә тормышның ул замандагы фаҗигалары калку итеп күрсәтелгән. Ул әсәрләрнең икесендә дә минем дә исем бар. Повестьта мин Әлтәфи исемле тотнаксызрак бер персонаж булып керсәм, «Ачы тәҗрибә» дә инде үз исемем белән үк алынган». *(Г. Ахунов, «Йолдызлар калка», Казан утлары, 1995 ел, № 9, 65 бит.)*

Г. Ахунов әдәби эш нечкәлекләрен әйбәт белүче, прототип һәм әдәби образ арасындагы нисбәтне оста тоемлаучы, үз әсәрләрендәге персонажларның прототипларга бай булуы белән аерылып торучы язучы, М. Мәһдиевнең сабакташы буларак, «Без — кырык беренче ел балалары» повестендагы башка геройларның да прообразлары турында күп нәрсә сөйли алыр иде, билгеле. Бу уңайдан, М. Мәһдиев әсәрләренә прототип буларак килеп кергән, янсә мемуарларында телгә алынган шәхесләрнең истәлекләре басылып чыкса, язучы иҗатын һәм шәхесен аңлауда әйтеп бетергесез зур өлеш булыр иде дип билгеләп узасы килә.

Язучы мирасына күз салсак, аның үзенең дә әдәбиятта прототиплар мәсьәләсен әйбәт өйрәнгән галим икәнен дә күрербез. Татар мәдәнияте һәм әдәбияты тарихыннан күп фактларны тапкан, актив эзләнүче галим буларак ул укучыны күп кенә язучыларның әдәби персонажларының прототиплары турындагы мәгълүматлар белән таныштырды. Аның мәкаләләреннән рус язучысы Салтыков-Щедрин һәм татар драматургы Таҗи Гыйззәт әсәрләрендәге геройларның прообразлары, Г. Ибраһимов персонажларының прототиплары турындагы мәгълүматларны табарга була.

Язучының иҗат лабораториясендә эзләнүчәнлек, фактларны җентекләп өйрәнү сыйфаты да мөһим урынны алып тора. Образларның тулылыгы, бөтенлеге, индивидуальлеге турында сөйлибез икән, боларның иҗатчы шәхесенең фактларны тирән өйрәнүе, архивларга кереп, сүзлекләрдән һәм газета-журнал тупләм-

нәрсен актарып эзләнүе нәтиҗәсе икәнен дә истә тотарга тиешбез. Әдип иҗатыннан бер-ике мисал карап үтү генә дә безгә бк күп нәрсәләр бирә алыр иде. «Торналар төшкән җирдә» повестенда Зөлфия турында сөйләгәндә автор героинясының әкият сөйләгәндәге бер җөмләсен хәтерләп калуы турында әйтә, чөнки ул җөмләдә «безнеңчә әйтелмәгән бер фигыль» кулланылган.

«Шул кичтән соң утыз биш еллар узгач, китапханәдә «Совет әдәбияты» журналы саннарын актарып утырганда мин бервакыт сискәнеп киттем, анда М. Ю. Лермонтовның бу әкиятен татарчага тәрҗемә итеп бастырганнар икән. Һәм мин ашыга-ашыга теге җөмләне эзләдем. Бар! Нәкъ шулай!

— Нишләмәк кирәк,— диде Хөршидбәк. (М. Мәһдиев «Торналар төшкән җирдә», Китапта «Бәхилләшү» 1990, 280 бит.)

Бу өзек безгә язучының иҗат лабораториясендәге өч сыйфатны күрергә ярдәм итә. Беренчесе — эзләнүчәнлек, икенчесе — тел фактларына игътибарлылык, өченчесе — хәтер. Татарча җөмләләрне генә түгел, чит телдәге сүзләрнең яңгырашын хәтерләп калу сыйфаты да булган язучыда.

Тормышның бик күп вак детальләрен үзенә сеңдереп барган феноменаль хәтергә ия булган икән бу талант. Язучы үзенең хәтере турында менә нәрсәләр сөйли:

«Минем кешеләргә карата, төсләргә карата, исләргә карата, табигать күренешләренә карата хәтерем бик яхшы. Мин, әйтик, 41 нче елның 22 июне көнне сугыш турында хәбәр килгән вакытта җил кайсы яктан икәнне, болыт нишләгәнен, арыш басуы нишләгәнен хәтерлим һәм беренче тапкыр мобилизациягә хәбәр килгәч, беренче тапкыр сугышка чыгып киткән кешеләрнең атларын, аларның кигән киемнәрен, җырлаган җырлары, көйләрен хәтерлим. Һәм шулай ук сугыш беткән көннең ничек икәне, кемнең нәрсә әйткәне, кайткач, ничек күрешкәне — болар минем бөтенесе дә хәтеремдә...

...Мин шул сугышка кадәрге үзебезнең авылдагы егетләрнең түгәрәк уенга кергәч, кайсы нинди җыр җырлаганын әйтә алам. Кайсы кызның нинди җыр җырлаганын әйтә алам. Әллә нәрсә хәтеремдә шунда». (Язучы белән әңгәмәдән. 1991 ел, 1 август).

Укып карагыз: «Кеше китә — җыры кала» повестендагы ирләрне сугышка озату турындагы эпизодны, «Торналар төшкән җирдә», «Бәхилләшү»дәге күренешләрне, язучы хәтеренең төгәллегенә, әдәби әсәрләр язганда тоткан роленә сокланмый кала алмассыз. Язучы әсәрләрендә кулланылган җыр текстларын да хәтерендә саклавы турында әйтә. Җырларның әсәрләрендә еш кулланылуын да сурәтләнгән чордагы авылның тормышында җыр зур урын алып торуына китереп бәйли.

Язучының иҗат лабораториясен өйрәнүгә этәргечне мин моннан берничә ел элек алган идем. «Совет мәктәбе» журналын актарып утырганда М. Мәһдиевнең «Ни хәлең бар, Фатыйма?» дигән мәкаләсенә тап булдым. Укучыларның сорауларына җавап рәвешендә язылган иде ул мәкалә. Шунда геройлар турында әйтелгән берничә юл мине сагайтты. «Алар әле әсәр эчендә дә авторга бик үк буйсынып бетмәделәр. Мәсәлән, яшь укытучы Хәлимә үзеннән ике тапкыр олы Мостафага авторның теләгеннән башка кияүгә чыкты»,— дигән иде язучы (М. Мәһдиев «Ни хәлең бар, Фатыйма?», «Совет мәктәбе» 1973, № 9). Автор әсәрне ничек теләсә, шулай ясый, дигән фикер безнең укучының күңеленә тирән урнашкан. Шуңадырмы без, укучылар, авторга урынсыз таләпләр куйгалыйбыз, ник инде теге яки бу әсәрне алай тәгәлләдең дип әйтергә яратабыз. Ә монда автор геройның үзенә буйсынмавыннан зарлана. Башта бу фикер сискәндереп, аннан соң язучының бер шуклыгы гынадыр дигән нәтиҗәгә киленсә дә, соңга табарак, башка бик күп классик язучыларның иҗат тәҗрибәсендә мондый хәлнең еш булуы турында мәгълүматлар белән танышкач, Мөхәммәт абыйның арттырмаганлыгы, язучы уенда туган геройның үз табигате, үз рухы, эчке логикасы булганлыгына төшендем. Тик шулай да ничек итеп геройларның шул дәрәҗәдәге мөстәкыйльлеккә ирешә алулары турындагы сорау мине гел борчып торды. 1991 елның 1 нче августында мин Мөхәммәт абый белән Язучылар берлегенең Комлев урамындагы бинасында очрашып, сөйләшеп утырдым. Очрашу алдан планлаштырылган, язучы белән килешенгән иде. Шуңа күрә сорауларны алдан әзерләп килдем. Геройларның буйсынмавы турындагы сорауны да әзерләгән идем. Проза әсәренең ничек языла башлавы турындагы соравыма җавап биргәндә язучы үзеннәнүзе тегесенә дә тукталды. Үз иҗатының бик нечкә бер эчке хасиятен әйтеп бирде. Түбәндә әңгәмәнең бу өзеген мин үзгәртмичә китерүне кирәк саныйм:

— Сез «Татарстан яшьләре»нә интервью биргән булгансыз икән. 1975 нче елда ук инде. Сез әйтәсез: «Мин роман язарга (сүз «Фронтовиклар» романы

турында бара.— Р. Ф.) дип тотынмаган идем, үзеннән-үзе образлар килеп керде. Шулай итеп 500 биткә тулды, машинкада баскач»,— дисез. Сез әсәрне язу алдыннан аның планын төземисез, шулай бит.

— Юк, абсолютно бер план да юк. Яза башлагач, әсәр үзе алып бара. Менә «Ут чәчәге» белән дә шулай булды. «Без — кырык беренче ел балалары» дигәндә дә шулай булды. «Мәскәү татары» дип бер кечкенә генә, өч битлек кенә хикәя язмакчы булган идем, ул мине алып кереп китте.

Менә рус тәнкыйтьчеләреннән, Юрий Борев микән, кемнеңдер бер хезмәтендә «Герои сопротивляются» дигән бер бүлек бар. Геройлар үз юллары белән алып баралар. Бу котылгысыз әйбер. Һәм сюжет та шулай. Менә болай язам, дип башлыйсың, шуннан эчке лабораториясе, эчке кухнясы үзенчә алып кереп китә һәм сине үзенчә мәҗбүр итә. Менә минем шулай булып чыкты, «Торналар төшкән җирдә», «Фронтовиклар» әсәре белән, «Ут чәчәге» белән дә шулай булып чыкты... Һәм башка әсәрләрдә дә. Менә болай дип тотынып карыйсың. Юк, менә әсәр үзе алып кереп китә. Бу — минем өчен котылгысыз нәрсә».

Геройларның көтелмәгән хәрәкәтләре, аңлашылып бетмәгән адымнары турында сөйләгәндә дә язучы кеше тормышындагы вакыйгаларның көтелмәгән борылышларга кереп китүләре, кеше тормышының, биографиясенең аның үзеннән генә тормавы, аңлатып булмый торган нәрсәләрнең булуы белән бәйли.

М. Мәһдиевнең әсәрләре татар әдәбиятына бер-бер артлы яңа ачылган чишмә төсле ургып килеп кергәннәр икән, бу инде аларның язучы күңелендә озак еллар буе өлгергән булулары, әдәби әсәр тусын өчен нинди дә булса бер этәргеч кенә кирәк икәнлеге хакында сөйли. Күрәсең, геройлар, образлар да шулай ук, язучы күңелендә инде бөреләнгәннәр, эчке аңда формалашканнар. Тормышны тирән белгән язучы фантазиясе аларны нәкъ менә кирәкле юнәлештә үстергән, эчке логикасын тапкан. М. Мәһдиевнең әдәби әсәрне кәгазьгә төшерү процессы ул язу процессының соңгы ноктасы гына, моңа кадәрле рухи тәҗрибәдә, эчке лабораториядә өлгергән сюжетның сүзле формага төренүе генә. Моны «әдәби әсәр өстендә ничегрәк эшлисез? Аны кат-кат төзәтәсезме яисә беренче катында ук шулай җиңел туамы?» — дигән сорауга язучының җавабыннан да күрергә була.

«Юк. Бер тапкыр язам мин. Шуннан машинкадан чыккач, бер тапкыр кайбер сүзләрен алыштырам да, бүтән төзәтмим. Бер тапкыр язсам язам. Алай кульязманы төзәтеп, төрле-төрле каралар белән, аны кучереп тә язганым юк. Менә булса булды, булмаса булмады. Бер дыхание белән язып була, бер сулыш белән». *(Язучы белән әңгәмәдән.)*

Языла башлаган әсәр автор күңелендә бертуктаусыз хәрәкәт итә. Кондициягә житү, өлгерү процессы автор кәгазь артында утырмаганда, башка эшләр белән шөгыльләнгәндә дә бара. Инде өлгереп, югары ноктасына җиткән әсәр тыелгысыз агым булып кәгазьгә төшә башлый. Автор үзе моның турында менә нәрсәләр сөйләгән иде:

«Кайбер вакытта түл җыясың. Берничә көннәр буе бернәрсә язмыйсың. Өстәлдә кәгазьләр шул көе ята. Укыйсың, укыйсың... Почта килә, газета килә, журнал килә. Шуларны укыйсың. Мин моңа бер дә борчылмыйм. Өч-дүрт көн, атна буе өстәл янына утырып булмый. Ләкин барыбер эш эшләнә. Бервакыт бөтен газета-журналны бер читкә ташлыйсың да өстәлгә килеп утырасың. Әнә шул атна буе эшләмәгәннең, әйтик, үчен аласың. Куллар талганчы язасың. Ул этеп алып бара, этеп алып бара, просто өлгереп булмый. Кул тала, ручкаларны алыштырасың. Бер-ике-өч көн шулай эшлисең дә яңадан күпмедер дәрәҗәдә энергия, түл җыярга кирәк була». (Язучы белән әңгәмәдән.)

Шушы рәвешле эшләү процессында автор күңелендә туган геройлар җанланалар, укучы күңеленә тәэсир ясардай образлар барлыкка килә. Язучы үзе дә алар тормышы белән яши башлый.

Иҗат процессының иң зур серләреннән берсе — геройга җан өрү, аны тулы канлы итеп тасвирлау өчен йөрәк аша уздырып, образга кереп сурәтләү сәләте. Рус әдәбият белеме, психологиясе аны «вживание» дип атый. Без гади генә итеп «образга керү» дип атарбыз. Безнең халыкта да «йөрәктән чыккан гына, йөрәккә барып җитә» дигән әйтем яши. Геройларны йөрәк аша уздырып, алар тормышы белән яшәп, алар кайгысы белән кайгырып, алар тойганны тоеп сурәтләү сәләте графоманнарга, уртакул язучыларга эләкми. Моңа чын талантлар гына сәләтле.

«Мин моны һич тә укучы күңелен нечкәртер өчен язмыйм. Моны язганда мин елыйм. Минем күз яшьләрем кульязмама тама»,— дип яза «Торналар төшкән

җирдә» повестеның авторы. Ирексездән хәтергә Гетеның «Мина бу ел эчендә «Тассо»ны язу өчен принцессага гашыйк булырга, «Фауст»ны тәгалләү өчен җанымны иблискә сатарга туры киләчәк», дигән сүзләре; героинясының агулануын язганда хәле начарайган француз язучысы Флобер, Горноатакайны кызганып елаучы Бальзак килә. Бу үзенчәлек Мөхәммәт Мәһдиев талантына да хас. Язучы тудырган образларның укучы күңеленә дә якынлыгы, күңелне нечкәртә алу сәләте, тыела алмыйча күлдерә алу куәте дә әнә шуннан килә. Кайчандыр тормыштан тотып алынган деталь, кемнеңдер төсе-бите, кыяфәте, сөйләме язучы остаханәсендә иҗат процессында янадан терелә, җанлана, әдәби сурәткә, портретка, персонаж сөйләменә әйләнә. Иҗат процессының иң югары ноктасы ул образга керү, аны җанландыру. Шушы ноктага күтәрелгән автор геройны реаль тормыштагыдай итеп күрә, аның белән сөйләшә, аның күз яшьләре белән елый, аның кайгысы белән кайгыра ала. Язучы аңында герой никадәр төгәл булып күзалланса, әдәби әсәрдә дә аның портреты шулкадәр төгәлрәк, табигыйрак килеп чыга. Бу Мөхәммәт Мәһдиев иҗатына турыдан-туры кагыла. Сүзләремне раслар өчен янадан язучының үзенә мөрәҗәгать итик. «Геройларыгызны күреп язасызмы?» — дигән соравыма: «Күреп язам. Бөтен кашына, керфегенә, киеменә хәтле күреп язам. Менә күзенә хәтле күреп язам. «Фронтовиклар» да минем Рушад бар икән, мин аны күреп язам, әгәр Гата бар икән, мин аның керфегенә хәтле күреп язам. Шулай ук күрмәгәндә язып булмый. Кайвакытта халтуралар китә, кайвакытта өстәмә бер әйбер кертәсең, иеме, укучы сизеп ала, тәнкыйтьчеләр сизеп ала. Шуны! Бу героең ышандырырлык түгел, диләр. Һәм мин монда бер дә рәнҗемим, алар фальшьны сизәләр. Әдәбиятны чын мәгънәсендә яратып укучы кеше һәрвакытта да фальшьны сизә. Андыйлар миндә бар», — дип җавап биргән иде язучы 1991 елның август аенда.

Укучы күңелен яулап алганчы әдәби әсәр иҗат процессында, автор лабораториясендә катлаулы үсеш юлы үтә. Иҗат процессының башы исә язучының балачагына, гомер юлында кичергән вакыйгаларга, күзәтелгән детальләргә барып тоташа. Әсәр язучының тормыш тәҗрибәсе белән формалаша, үсә, баый, язучы рухы нииндидер бер этәргечтән көч алып язылa башлаганчы кайвакыт шактый сулар ага. Язучы никадәр генә тәҗрибәле булмасын, кайвакыт әсәр язылa башласын өчен нииндидер бер этәргеч кирәк була. Әсәрне яза башлау төрле язучыда төрлечә була. Кайберәүләр нииндидер бер тормыш фактыннан кереп китәдер, кемнәрдер нинди дә булса бер вакыйга белән рухланып иҗат итә башлыйлар, кайсыдыр язучылар социаль заказ тәэсире белән дә яза башларга мөмкин. М. Мәһдиев иҗатының этәргече нәрсәдә соң? Геройларны, сюжетны нәрсә хәрәкәткә китерә? Бу сорауга да язучы үзе генә җавап бирә ала. Шуңа күрә дә аның җавабын укып карыйк.

«Башта идея туа. Нииндидер бер идеяны әйтәсе килә. Мәсәлән, «Фронтовиклар», дигән әсәрдә нинди идеяне әйтәсе килде? Яшь егетләр, чын күңелдән ышанып, Ватанны коткарабыз дип көрәшеп кайтканнар. Һәм без Германияне җиңдек, тормыш яхшырыр, дип ышанып тылда да фронтовикларча көрәш алып баралар. Ә тормыш яхшырмый. Менә егетләр сыналар бераздан. Алардагы наивлык бетә башлый. Мин шушы идеяне үткәрергә теләгән идем. Ул идеяне үткәреп бетермәдем. Егетләр минем һаман шул... патриот булып, әйбәт күңелле булып, күңелләре сынмаган көе калалар әле икесе дә, ике егет тә. Ул вакытта инде мин идеямне үткәрә дә алмыйдыр идем. Әгәр бүген язсам (әңгәмә 1991 елда) мин аларның бераз сынганнарын күрсәтер идем. Чөнки фронтовиклар алдандылар. Алар дошманны җиңеп кайткач, монда эшкә тотынып караганнар иде, күреп торалар: бер төрле кешеләр сугышка бармый калганнар, тегеләйболай махинация ясап баеп ятканнар, ә фронтовиклар шинель белән кайттылар. Эшкә тотынып караганнар иде, тормышны көйли алмадылар. Шуннан алар орден-медаль колодкаларын салып ташлап үзләре дә тормыш җаен җайларга дип кереп киттеләр һәм бик күбесе үзләренең теге Ватан сугышы чорындагы матур уйларын югалттылар. Мин шуларны әйтергә теләгән идем, әйтеп бетерергә мөмкин булмады ул вакытта.

Башта идея туа. Идея тугач, аның геройлары үзләре килеп керәләр. Әйе, бу идеягә туры килә торган кешеләрне син күргәнсең инде тормышта. Алар килеп керәләр, берсе килеп керә, икенчесе килеп керә. Шуларга каршы кешеләр килеп керә. Шушы идеягә каршы торучылар, аяк чалучылар килеп керә. Тормыштан барысы да». *(Язучы белән әңгәмәдән.)*

Язучы иҗатының үзенчәлеген күп очракта әнә шулай тормыш билгели. Әдип хәтта әсәрләренең формасының үзенчәлекле булуын, тоташ бер сюжет сызыгына ия булмаган новеллалардан торуын да үз тормышының катлаулыклары белән

аңлата, тормышның новеллалардан торуын әйтә. «Минем әсәрләремдә төгәл композиция, төгәл сюжет юк икән, димәк, мин үземне үзем язам. Минем тормышымда төгәл композиция, төгәл сюжет булмады беркайчан да»,— дигән иде ул бу турыда сүз чыккач.

Этәргечләр турында сүз тиктомалдан гына башланмады. Чөнки иҗат процессында әдәби әсәр яза башлауга этәргеч күп вакытта зур әһәмияткә ия. Әсәр еш кына шул этәргечтән, беренче җөмләдән башланып китә. Мөхәммәт Мәһдиев иҗатында беренче җөмлә дә бик мөһим.

«Башлап җибәрү, әлбәттә, кыен инде. Ул барлык язучыга да шулай, миңа гына түгел. Ул бит темп алу дигән сүз. Темп, увертюра. Бу, әлбәттә, кыен. Бетерә алмыйча азапланганым юк. Бетерәм. Әйбәт бетерәм. Башлау кыен. Беренче җөмлә кыен. Моны Горький да әйткән, башка язучылар да әйтә: беренче җөмләне табу кыен. Шуны таптыңмы, китте. Колеяга кердең. Әнә шул беренче җөмлә алып бара. Беренче җөмлә, беренче абзаң. Шул алып бара һәм ахырын да шул эшли инде аның. Мин аны шулай дип уйлыйм». *(Язучы белән әңгәмәдән.)*

Ни өчен беренче җөмләгә шулкадәр зур игътибар бирә соң язучы? Моны бер генә нәрсә белән аңлатырга мөмкин: язучының эчке лабораториясендә өлгергән әсәр юл алсын өчен, буаны ерып җибәргән төсле бер сәбәп кирәк. Беренче җөмлә, әсәрнең башламы әнә шул рольне үти. Беренче җөмләнең рухы әсәрнең гомуми рухына юнәлеш бирә. Аннан соң иҗат процессында «илһам» дигән төшенчә дә бар бит әле. Беренче җөмлә, күрәсең, язучыга шул илһам ачкычы ролен үти торгандыр.

Язучының иҗади дөньясы — остаханәсе серләр белән тулы. Аларның ачылмый торганнары һәм мәңге ачылмаячаклары да бар. Өйрәнелергә мөмкин булып та, тикшерелмичә калганнары да бардыр. Кайберсенә язучының үзеннән башка төшенеп тә булмас инде...

Язучы Мөхәммәт Мәһдиевнең тагын бер әһәмиятле хасияте бар. Аның иҗат лабораториясе, шәхесенең төп сыйфатлары әсәрләрендә, мәкаләләрендә зур чагылыш тапкан. Укы, укучы — шатлан, ләззәтлән — татарның бөек улының иҗат серләренә төшен!

# ТАГЫН БЕР ӘДӘБИ АЧЫШ

Тарихтагы җуелмас эзләребезне беренче нәүбәттә язма мирасыбыз тәшкил итә. Бигрәк тә рухи дөнья һәм әдәбиятыбыз тарихына караган кадерле эзләрне... Соңгы 30—40 ел эчендә генә дә байтак әдәби истәлекләрнең барлануы, җыелуы, һәм рухи мираска караган яңадан-яңа сәхифәләрнең бер-бер артлы ачылу фактлары моны артыгы белән раслый. Мисалга Кол Гали, Котб, Мөхәммәдьяр, Шәмсетдин Зәки, Габделҗәббар Кандалый, Мифтахетдин Акмулла һәм тагын башка шагыйрьләрнең әсәрләреннән яңа басмалар дөньяга чыгуын, ә аларның исә археографик эзләнүләр нәтиҗәсендә табылган кульязмалар нигезендә барлыкка килүен күрсәтергә мөмкин. Әйе, соңгы 30—40 ел эчендә археографик белемебезне баету юнәлешендә ирешелгән казанышларыбыз бәхәссез икән.

Мәгълүм булганча, Икенче дөнья сугышыннан соң элекке СССРда татар тарихына караган язма материалларны җыю, өйрәнү эшләре 60 нчы елларда иң әүвәл Казан университетында башланган иде. Утыз елдан артык эшләп килгән һәм хәзер дә дәвам итә торган эзләнүләр нәтиҗәсендә университет китапханәсенең хәзинәлегенә — Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенә — төрле шәрекъ телләрендәге гарәп язулы ун меңнән артык кульязма саклануга тапшырылды. Шушы елларда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты каршындагы мирасханәгә дә меңләгән яңа кульязмалар, иске китаплар керде. Болар хакында моңарчы беркадәр язылган иде инде. Шуңа күрә бүген мин кульязма истәлекләребезне эзләү, җыю һәм өйрәнү буенча соңгы елларда барлыкка килгән яңа үзәк хакында берничә фикер әйтергә теләр идем. Сүз Татарстан җөмһүриятенең Милли китапханәсендә оешкан һәм «аягына» ныклап баса башлаган яңа бүлек — Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге хакында.

Дөресен әйткәндә, моннан биш-алты ел элек, әлеге бүлек оеша башлаган вакытта, шәкертләремнән бер-ике егетнең анда эшкә урнашуын хуплаган хәлдә, бу яңа бүлекнең киләчәге хакында кайбер шөбһәләр дә кичергән идем. Мәсәлән: социаль һәм иҗтимагый авыр шартларда яңа бүлеккә колачларны киң җәеп эшләр өчен мөмкинлекләр булырмы? Яңа истәлекләр җитәрлек күләмдә табылмаса, егетләрнең рухлары сүрелеп калмасмы?

Бәхеткә каршы, минем әлеге шикләнүләрем артык булып чыкты. Милли китапханәнең җитәкчелеге яңа бүлек үссен өчен матди шартларны мөмкин кадәр тудыра баруга иреште; яшь фикердәш һәм сафташларым исә көннән-көн канатланып, дәртләнеп эшләүләрен дәвам иттеләр. Нәтиҗәдә, Милли китапханәдә ачылган яңа бүлекнең хәзинәсендә хәзер ике меңнән артык кульязма һәм алты меңгә якын сирәк басма китап маясы барлыкка килде.

Яңа бүлекнең тиз арада болай тернәкләнеп китүенә китапханәдә тудырылган уңай шартларга, мөгаен, тагын бер сәбәп өстәлүен дә күрсәтергә кирәктер. Ул сәбәп, минемчә, бүлек мөдире Раиф Мәрданов җитәкләгән яшь коллективның, үз тышлыгында гына йомылып калмыйча, университеттагы коллегалары белән актив хезмәттәшлеккә керүе, экспедицион эзләнүләрне кулга-кул тотынып бергә башкарулары, көнчелек, күңел тарлыгы кебек начар сыйфатлардан азат булуыннан гыйбарәт. Яшерен түгел: университет китапханәсендә байлык та күп, тәҗрибә дә зур. Мәсәлән, тарих фәннәре кандидаты доцент Җәүдәт Миңнуллин җитәкли торган Шәрекъ бүлегендә хәзер 15 меңнән артык кульязма берәмлеге саклана, ә университет археографларының эзләнү тәҗрибәләре исә утыз биш еллык...

Милли китапханәдәге яңа бүлек ирешкән казанышларның әһәмиятен анда тупланa башлаган байлыкның саннарына гына кайтарып калдыру да ярамастыр. Табышлар арасында чын ачыш дәрәҗәсенә лаеклары да бар. Шушы раслый торган мисалларның берсен тү-

бәндә тәкъдим итәлә торган публикациядән күрергә мөмкин. Анда сүз моңарчы иҗаты тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән, дөресрәге, барланмаган, укучыларга канәгатьләнерлек күләмдә ирештерелмәгән (бәяләмәсе гел «суфый шагыйрь» дигән тамгалаудан әлләни ерак китмәгән) фикер иясе, шагыйрь Мәүла Колыйның бу көнгә кадәр билгесез кала килгән зур күләмле ике әсәре хакында бара. Төгәлрәк әйткәндә, ике поэмасы хакында. Истәлекләрнең табылу тарихы, кульъязмаларның саклануы сыйфаты буенча авторның кереш мәкаләсендә, кыскача булса да, шактый тулы мәгълүмат бирелгән. Табышның, яңалыкның әһәмияте хакында да дөрес күрсәтелгән. Өстәп шуны гына кечәйтеп әйтәсе килә: ике поэманың өлешчә генә килеп җитүеннән чыгып, табышның әһәмиятен кечерәйтергә нигез юк. Әсәрнең өлешләре ачылу, һичшиксез, аларның тулы текстлары табылуны да тәэмин итәчәк. Чөнки без хәзер Мәүлә Колый дигән шагыйрьнең, элек уйлаганыбызча, бары «хикмәтләр» кебек кыска жанрда иҗат иткән «тар» юнәлешле шагыйрь түгел, бәлки башка жанрларда да эшләгән киң колачлы автор икәнлеген белдек. Өстәвенә, аның зур күләмле әсәрләренең эчтәлеге белән әдәби үзенчәлекләре хакында да мәгълүматыбыз беркадәре артты.

Күрсәтелгән әсәрләрнең өлешчә генә саклану кебек фаҗигале күренешкә таянып, мондый оптимистик нәтиҗә чыгаруга гаҗәпләнмик. Иң элек бер өлеше генә ачылган истәлекләрнең, шул өлешләр хакында мәгълүмат игълан ителгәч, тулырак күчермәләре табылуы татар археографиясендә шактый еш очрый торган күренеш. Мисалга элек фрагментлары, аерым өлешләре генә табылган «Яр-яр» исемле тарихи йола җырының, «Түләк-Сусылу» дастанының беренче публикацияләрдән соң купкә тулырак һәм сыйфатлырак нөсхәләре ачылу фактларын атарга мөмкин. (Бу хакта безнең «Кауры калэм эзеннән» исемле китапның 1994 елда чыккан икенче тулы басмасыннан карарга мөмкин.) Чөнки күпләгән фактлар археографик дөньябызның суы бер дә саекмый торган олуг дәрья икәнлеген туктаусыз раслап килә. Ахыр чиктә Мәүлә Колый каләменә караган өр яңа әсәрләрнең табылу факты да шул хакыйкатьне тагын бер кат исбатлап тора. Шуңа күрә мин, яшь каләмдәшемне бу мөһим табышы белән ихлас котлап, аның киләчәк эзләнүләренә тагын да зуррак уңышлар теләү белән сүземне тәмамлар идем. Ниһаять, Мәүла Колый мирасын төгәлрәк туплау, тирәнрәк өйрәнү, тулырак хәлдә киң катлам укучыларга җиткерү бурычын да алар буыны сыйфатлырак итеп башкарыр дигән өметтә калам.

**Миркасыйм ГОСМАНОВ.**

●

## Гасый җафи Мәүла Колый сүзли, дуслар...

Мәүла Колый — XVII йөзнең икенче яртысында иҗат иткән күренекле татар әдибе. Ул Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакырганый, Кол Гали, Сәйф Сараи, Мөхәммәдъяр, Кол Шәриф кебек фикер ияләренең асыл рухи бакчаларыннан азык алып, үз шигъри дөньясын тудырган олы шагыйрь.

Татар әдәбияты тарихында Мәүла Колый иҗатын өйрәнү моннан 70 еллар элек башланган. Аның әсәрләре табылу турындагы беренче хәбәр Фазыл Туйкә тарафыннан 1926 елның апрель аенда «Кызыл Татарстан» газетасының 81 санында дөнья күрә. Шул вакыттан башлап Мәүла Колый шигырь-хикмәтләренең яңадан-яңа күчермәләре табыла һәм өйрәнелә. Шагыйрьнең иҗатын барлап, аны фәнни өйрәнүгә төрле елларда Габдрахман Сәгъди, Латыйф Җәләй, Хәй Хисмәтуллин, Шакир Абилов кебек әдәбият белгечләре зур өлеш керттеләр. Камил Дәүләтшин Мәүла Колый иҗатын әтрафлы һәм җентекләп өйрәнүгә кандидатлык диссертациясе багышлады.


Моңарчы кат-кат расланганча, Мәүла Колый иҗатының нигезендә суфыйчылык идеологиясе ята. Шул ук вакытта, башка татар суфый әдипләренә дә хас булганча, Мәүла Колый әсәрләрендә дә җирле традицияләр һәм дөньявилык идеяләре чагылыш тапкан. Тулаем алганда, аның иҗат нигезен дә тәшкил иткән суфыйчылыкның ислам дине белән бәйле гаять катлаулы һәм каршылыклы бер тәгълимат икәнлеген истә тотарга кирәк.

Мәүла Колыйның тормыш юлы хакындагы мәгълүматлар бөтенләй билгесез иде диярлек. Шагыйрьнең иҗатына, шул чор документларына, шәҗәрәләргә һәм риваятьләргә нигезләнеп филология фәннәре кандидаты Марсель Әхмәтҗанов Мәүла Колый биографиясен беркадәре ачыклауга иреште. («Совет мәктәбе». 1986 ел. 10 сан.) Яңа мәгълүматларга караганда, Мәүла Колый (кайбер шигырьләрендә «Меллагол кол» рәвешендә дә очрый) исеме белән мәгълүм шагыйрьнең чын исеме Бәйрамгали Колыев (Бимкә суфый) булган икән. Ул XVII йөз урталарында Казан өязендәге Чыты (хәзерге Питрәч районына керә) авылында дөньяга килгән. Казанда мәдрәсәдә укыган. Аның исеме XVII гасыр ахырында хөкүмәт һәм татарлар арасындагы гауга-низагъларга бәйләнешле документларда да телгә алынган. Мәүла Колый (Бәйрәмгали Колыев) җитәкчелегендә Казан ягындагы төрле татар авыллары крестьяннары 1678 елда Биләр шәһәре хәрабәләре янына күчеп урнашканнар. Патша хөкүмәте, әлбәттә, бу хәл белән ризалашмый, һәм 1699 елда Петр Беренче фәрманы белән татарлар ул җирләрдән куылганнар. Мәүла Колый иптәшләре белән Шушма буена, Иске Иштирәк авылына барып урнашкан.

М. Әхмәтҗанов табып ачыклаган дәлилләр буенча Мәүла Колыйның тәрҗемәи хәле шул рәвешчә күзаллана. Бу мәгълүматлар, «Татар поэзиясе антологиясе»нең яңа басмасында да (чыганагы күрсәтелмичә) тулаем урын алган. Антологиядә шагыйрьнең әсәрләренә дә шактый киң урын бирелгән.

Мәүла Колый иҗатының өйрәнелү тарихы тулырак күзаллансын өчен, аның әсәрләре тел һәм иҗтимагый фикер үсешендәге үзенчәлекләре ягыннан да билгеле бер кадәр тикшерелгән булуын әйтеп үтәргә кирәк. Шулай ук аның шактый әсәрләре рус укучысына да тәкъдим ителгән.

Мәүла Колый хикмәтләренең кульязма күчермәләре Казан, С.-Петербург, Уфа шәһәрләрендәге гыйльми оешмаларда саклана. Аның әсәрләренең яңа күчермәләре хәзерге вакытта да татарлар яши торган төбәкләрдә, сирәк булса да, табылып тора. Без биредә укучыларны шундый табышларның соңгысы, шактый берәгәйлесе белән таныштырмакчы булабыз. Аның «берәгәйле»леге — Мәүла Колыйның моңарчы фәнгә бөтенләй мәгълүм булмаган яңа әсәрләренең күчермәләре табылуда. Өстәвенә: аерым хикмәтләр авторы буларак без белгән Мәүла Колыйның биредә поэма жанрында да иҗат иткәнлеге ачыла. Ә бу, үз нәүбәтендә, табышның әһәмиятен бермә-бер арттыра. Ягъни аның мирасына поэма жанры да өстәлә.



*Мәүла Колый әсәрләре язылган кульязма җыентык.*

Әдипнең бу әсәрләре теркәлгән кульязма җыентык шушы юлларның авторы тарафыннан 1990 елның гыйнварында Әгерҗе районының Яңа Аккуҗа авылында Фазлый ага Габдрахмановтан (1908—1995) алынган иде. Ул хәзер Татарстан Милли китапханәсенең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «606т.» шифры белән саклана. Сүз уңаеннан, бу җыентык белән бергә Фазлый бабайдан алынган тагын өч кульязма хакында да кыскача мәгълүмат бирик. Боларның берсе 1765 елда Меңләр авылында Монасыйп бине Мәскәү кулы белән язылган дини риваятьләр, икенчесе XVIII гасыр ахырында күчерелгән дини хикәятләр, ә өченчесе 1902—1903 елларда мәшһүр Иж-Бубый мәдрәсәсендә белем алган татар шәкертенең дәрес конспектларыннан гыйбарәт. Алар хәзерге вакытта Татарстан Милли китапханәсендә сакланалар.

Яңа Аккуҗа авылы, гомумән, татар әдәбияты тарихын кызыклы археографик табышлар белән куандырып тора. Йөзләгән татар авылларын гизгән археограф-галим Марсель Әхмәтҗанов 1978 елда шул ук авылдан Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасының яңа күчермәсе табылуы хакында хәбәр иткән иде. («Идел», 1995, 11 сан.)

Яңа табылган кульязманың үзенә тукталыйк. Җыентык Россия һәм Европа кәгазьләренә язылган, һәр битнең зурлыгы 10×16 см. Ул XX йөз башында Казанда басылган «Һәфтияк шәриф» китабы тышлыгы эченә урнаштырылган. Мәүла Колый әсәрләре җыентыкның ахырында, барлыгы 11 кәгазьдә (62а—72б) өлешчә сакланып калган. Җыентыкка ике әсәр дә гарәп язуының тәгъликъ төре белән теркәлгәннәр. Нигездә, һәр бит саен 13 әр шигъри юл язылып, бер биттәге текстның зурлыгы 7,5×13,5 см мәйданны били. Җыентыкның 1а—61б кәгазьләрендә шәргый мәсьәләләр, догалар, йолдызларга нигезләнгән сүрия-гарәп календаре буенча язмалар, Рамазан аена багышланган шигъри әсәр, сихер-тылсым догалары һ. б. шундыйлар теркәлгән. Кульязма җыентыкның Бәдшәл авылында (44а бит; бу авыл хакында төгәл мәгълүматлар хәзергә табылмады) Мортаза атлы кеше кулы белән 1754 елда (61а бит) язылганлыгы күрсәтелгән. Кульязма җыентыктагы барлык текстлар да коңгырт сары төстәге кара белән бер үк кеше тарафыннан язылганнар. Каләменең һәм имлясының тотрыксызлыгына караганда, шулай ук кайбер башка үзенчәлекләргә нигезләнеп, җыентык әле кулы ныгып җитмәгән шәкерт тарафыннан язылган дигән нәтиҗә ясарга мөмкин. Кульязма җыентыкның саклану дәрәҗәсе уртача диярлек. Күп урыннарда карасы уңган, кәгазе зарарланган.

Югарыда телгә алынган Мәүла Колый әсәрләренә килгәндә, алар кульязмада теркәлгән ике поэмадан гыйбарәт. Кызганыч ки, җыентыкның аерым битләре җуелганлыктан, поэма текстлары да өлешчә генә сакланганнар. Алай да беренчесе сюжет һәм эчтәлек ягыннан шактый тулы, барлыгы 238 шигъри юлдан гыйбарәт (62а — 70б битләр). Башы һәм ахыргы өлешләре тулы, фәкать әсәрнең уртасындарак, кульязмадагы берничә бит җуелу сәбәпле, өзеклек керә. Әсәрнең ахырында (223 юл), «Берекәннәр сыйфатын әйдем сезә...») ягъни, берләшкәннәр, бердәмнәр сыйфаты) дип поэманың исеменә дә ишарә ителә. Аннан соң (70б бит):

«Әй, Ходайа, гасый җафи Мәүла Колый,
Рәхмәтеңлә сән биргел коллык йули...» —

дип, авторның исеме дә конкрет күрсәтелә. Поэманың исемен һәм авторын әсәр ахырында белдерү, авторның үз-үзенә түбәнсенеп «гасый җафи» дип эндәшеп тәмамлавы суфыйчылык әдәбияты өчен хас күренеш. Мондый алымны Колыйның рухи остазлары булган Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакырганый һ. б. суфый шагыйрьләрнең барлык әсәрләрендә дә диярлек күрергә мөмкин. Мәүла Колыйның башка хикмәтләрендә дә ул алым бар. Мәсәлән, остазы Мелла Мамайга багышланган «хикмәт»енең бер күчермәсендә бетем өлеше «Гасый җафи Мәүла Колый сүзли, дуслар», дип тәмамлана.

Икенче әсәрнең башлангыч өлеше генә (70б—72б битләр, барлыгы 67 шигъри юл) сакланган, төп һәм бетем өлешләре юк. Шулай да, әсәрләрнең теле, идея-тематик үзенчәлекләренең якынлыгы җәһәтеннән караганда ике әсәрнең дә бер авторның иҗат җимеше икәнлеге бәхәссез. Хәтта аларның исемнәре дә бер-берсенә аваздаш формада аталганнар. Беренчесе якынча «Берекәннәр сыйфаты» рәвешендә булса, икенчесе «Хәлаль нәфкъә эстәгәнләр сыйфаты» (Хәлаль ризык теләүчеләр сыйфаты»). Ихтимал, мондый «сыйфат»лаулар рәвешендә язылган әсәрләр тагын да булып, алар бер циклны тәшкил иткәндер дигән фикер дә туа. Шулай да, текстлардан күренгәнчә, һәр сыйфат сюжет ягыннан мөстәкыйль бер әсәр рәвешендә гәүдәләнә.

«Береккәннәр сыйфаты» поэмасының кыскача эчтәлеге түбәндәгедән гыйбарәт.

Бер ир белән хатын, үзара киңәш-табыш иткәннән соң фани дөнья мәшәкатьләрен читкә куеп, тыныч урынга китеп, тормышларын гел Хакъ Тәгаләгә, гыйбадәткә, ихластан ахирәт тормышына әзерләнүгә багышларга кәрар кылалар. Бер тауга барып кечкенә генә торак һәм гыйбадәтханә төзиләр, шунда гомер кичерә башлыйлар. Хакъ Тәгалә юлыннан тайпылмыйча, намаз укып, ураза тотып, 60 ел яшәгәч, боларга Иблис вәсвәсә сала. Иблис ирнең гыйбадәт белән генә утыру фикерен чуалта. Хакъка биргән антны бозу булса да, ир белән хатын дөнья күрергә дип чыгып китәләр. Бер шәһәр янындагы чишмә буенда туктталалар. Ире ипи алырга дип шәһәргә юнәлә. Аннан кайтышлый ул бер мәһабәт сарай һәм сарай эчендәге искиткеч гүзәл хан кызын күреп туктала. Икәвенең дә күңелләрендә гыйшык уты кабына. Ир хатынына кайтып хәлне аңлата.

Бу урында берничә бит төшеп калудан текстка өзеклек кергән, шунлыктан кайбер вакыйгалар безгә билгесез хәлдә кала... Әмма ниндидер бер вакыйгалардан соң хан кызы белән ирне «тотып алалар» һәм зинданга ябалар. Кайтмаган ирен эзләп бичара хатын сарайга килә. Ирнең кайда икәнлеген ачыклагач, башын-йөзен ике бөркәнчек белән каплап, ике табак аш (пылау) алып зинданга бара. Зиндан сакчысының күңелен бер табак аш белән яулап алып, зинданда ябылган кешемә ризык ашатыйм дип, эчкә үтә. Анда башындагы бер бөркәнчекне хан кызына яптырып, буш табакны да аңа биреп, чыгарга куша. Кызга: аулак җирдә табакларны ташлагач, сараеңа кайт та тыныч кына йөр, дип өйрәтеп җибәрә. Кызының бу әллә нинди бер ят ир белән тотылуыннан хурланган, ачуыннан ярсыган хан җәлладка тоткыннарны китерергә куша. Зинданчы аларны тиз генә хан катына алып килә. Шактый сүзләр, аңлашу соңында, хатын йөзеннән бөркәнчеген алгач, боларның ир белән хәләль хатыны икәнлеген күреп хан һәм җәллад хәйран калалар. Шул рәвешчә, ханның йөзе «ак» килеш булып кала, ир белән хатын да җәзадан исән-сау котылалар. Өстәвенә, хан аларга күп итеп мал-байлык та бирә. Ир һәм хатын әүвәлгечә гыйбадәт белән тыныч гомер кичерүләрен дәвам итәләр.



*Мәүлә Колыйның «Береккәннәр сыйфаты...» әсәренең тәмамланган һәм «Хәләль нәфкъә...» поэмасының башланган битеннән күчермә.*

Автор поэмасын береккәнлек, бердәмлек аркасында гына бәладән котылып, иминлеккә ирешергә мөмкин дигән фикер белән йомгаклап куя. Шулай итеп, әсәр укучыларны бердәмлеккә өндәп, «берлектә — көч» дигән мотив белән тәмамлана.

Әсәрнең сюжеты мавыктыргыч һәм чишелеше оста корылган. Автор әсәрдәге хәлиткеч роль ̆ хатынга йөкләгән. Аның кыюлыгы һәм акылы белән Мәүла Колый четрекле мәсьәләне уңай хәл итә. Нәтиҗәдә, «бүреләр дә тук, сарыклар да исән» булып кала. Идея-тематик ягына килгәндә, бердәмлек мәсьәләсе кешелек дөньясында һәрвакыт актуаль дигән фикер туа.

Кульъязма җыентыктагы икенче әсәр — «Хәлаль нәфкъә эстәгәнләр сыйфаты» поэмасының аз өлеше генә сакланганлыктан, аның эчтәлегенә аерым тукталу ашыгычлык булыр иде.

Әсәрләр шигъри төзелешләре һәм тел ягыннан Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакырганый, шулай ук Мөхәммәдъяр әсәрләренә бик якын торалар. Аларда гарәп-фарсы алынмалары чагыштырмача аз, борынгы төрки-татар теле формалары, үзенчәлекләре өстенлек итә.

Поэмаларның матбугат өчен әзерләнгән текстлары турында да берничә сүз әйтергә кирәк. Укылышны һәм аңлауны җиңеләйтү өчен текстларның орфографиясендә транскрипция элементлары кулланылды. Җәяләр эчендә бирелгән аерым хәрефләр, иҗекләр, сүзләр, кульъязманы күчерүче тарафыннан ялгыш төшереп калдырылган фаразлардан гыйбарәт. Текстлардагы кайбер имля тотрыксызлыгы (мәсәлән, барып-баруб-барыб, килеб-килүб, ирде-иде, диб-тиб һ. б.) кульъязманың үзендәгечә сакланды.

Әсәрләрне текстологик эшкәртү буенча киңәшләре, аерым сүзләрнең дөрес укылышларын һәм мәгънәләрен ачыклауда ярдәм күрсәтүе өчен академик Миркасыйм ага Госмановка чын күңелдән рәхмәтемне белдерәм.

Мәүла Колыйның яңа табылган бу әсәрләрен киләчәктә анализлап, әтрафлы өйрәнү, әлбәттә, әдәбият һәм тел галимнәре бурычы. Безнең бурыч татар әдәбияты тарихы өчен әһәмиятле булган яңа табышны матбугат аша укучыларга җиткерү һәм галимнәр хөкеменә тапшырудан гыйбарәт. Җыеп әйткәндә, Мәүла Колый каләменә бәйле бу яңа табышларның тагын бер әһәмиятле ягы шунда ки: алар шул әсәрләрнең тулырак күчермәләрен эзләүгә һәм шуның белән бергә шагыйрь мирасының фән өчен моңарчы мәгълүм булмаган яңа сәхифәләрен ачуга этәргеч булып торалар.

**Раиф МӘРДАНОВ,**
Татарстан Милли китапханәсенең
Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире.

# Мәүлә Колый

## Береккәннәр сыйфаты

Кил, нигяр[1] бу дөнйаны куйсак кәрәк,
Ахирәт әсбабене корсак кәрәк.
Кил имди, без бу дөнйадин бизәлем,
Тагъга[2] барып мәсҗид-саумага[3] төзәлем.
Гъәурәт[4] әйде: дыңла сүзем, әй ири,
Андагъ иргә ихлас кәрәк, пакь-ари[5]
Ихлас илә һәр эшни оталмазсән[6].
Кил, торалым ил эчендә тагыйә
Ихлас булса, һәркайда булмаз хата.

[1] Нигяр — гүзәл.
[2] Тагъга — тауга.
[3] Мәсҗид-саумага — гыйбадәтханә.
[4] Гъәурәт — хатын.
[5] Пакь-ари — пакь, ару.
[6] Оталмазсән — оталмассың.

Ире диде: Хакъ йулы хәлүәт[1] улур,
Хәлүәтдә тагъәт[2] кыйлан Хакный булур[3].
Диде гъәурәт: «Китәр ирсәң тагъ сари[4],
Хәлүәт улса адәм йөрмәз ул яри[5].
Дорды[6] Заһид, китделәр ире-хатун
Телләрендә йад итеп Тәңре атын.
Бардылар тагъга йәнә хәлүәт сари
Хайван, адәм күп гизмәз ул тагъ яри.
Ул тагъ үзрә төзделәр мәсҗид-һөҗрә[7]
Тагъәт кыйлу(п) гомерләрен кичерә
Дордылар Хакъ әмрилә, кыйлу(п) эши,
Күңелләрендин чыкды дөнйа тәшвиши[8].
Дорды анлар ул саумагыйда алтмыш йыл,
Рузә, намаз кыйлыб булды Хакъга кол.
Алтмыш йыл имди тәмам булмышында,
Һич хатасыз Хакъга бетүб тормышында
Килде Иблис, монларга итеп вәсвәсә,
Монларның Хакъга барур йулун кисә.
Заһидның фикеренә диде: «Кырлар вар,
Күңелеңездин китсен ул тугъ-у-гобар[9].
Заһид бу фикери күңел(иг)ә алыб
Гъәурәтенә әйде андин сүз салыб:
«Йөр чыкалым, йаланларда йөрәлем,
Рәүзаларда[10] төрлүк[11] кошлар күрәлем,
Күрәлем нәбатларның[12] гөлләрен,
Гашикында зикр кыйлан[13] болбылларын.
Гъәурәт әйде аңа: «Әй, Заһиди!
Хакъ эшендә тормага кыйлдың гъәһди[14],
Гизмәклекдә төрлүк нәрсә күрәсен,
Дөнйаның бер эшенә әүреләсен».
Диде Заһид: «Йөр чыкалым гизмәгә,
Сәйер кыйлыб[15] күңел керен йазмага».
Чыкдылар кыры-йази[16] гизделәр,
Сәйер кыйлыб күңелләр(ен) дөзделәр[17].
Гизә-гизә көнләрс кичә булды,
Намаз дигәр[18] вакъти бер шәһәрә килде.
Туктадылар анда бер чишмә сарә,
Заһид андин нан[19] алмага шәһәрә вара.
Варды Заһид ул шәһәр ичрә[20] керде,

---

[1] Хәлүәт — аулак.
[2] Тәгъәт — гыйбадәт, намаз.
[3] Булур — табар мәгънәсендә.
[4] Тагъ сари — тау ягына.
[5] Ул яри — ул тарафка.
[6] Дорды — торды.
[7] Мәсҗид-һөҗрә — аерым мәчет.
[8] Дөнйа тәшвиши — дөнья мәшәкате.
[9] Тугъ-у-гобар — тугъ сүзе буйсынучанлы, кыршау, алка мәгънәсендә; гобар — томан, караңгылык. Тугъ-у-гобар — монда: буйсынучанлык караңгылыгы (ягъни: томаналык).
[10] Рәүза — гөлбакча, чәчәклек.
[11] Төрлүк — төрле.
[12] Нәбат — үлән, үсемлек.
[13] Гашикында зикр кыйлан — гыйшыкларын сөйләүче, мәхәббәтләрен сайраучы.
[14] Кыйлдың гъәһди — вәгъдә бирдең, ант иттең.
[15] Сәйер кыйлу — йөрү, гизү.
[16] Кыры-йази — йазы — сахра.
[17] Дөзделәр — дөзмәк — төзәтү.
[18] Намаз дигәр — икенче намаз, чираттагы намаз.
[19] Нан — икмәк.
[20] Ичрә — эченә.

Кайтмышында (бер) гали[1] сарайи күрде.
Ул сарай капугыйдыр[2] сим-у-зәрин[3],
Ичрә карап күрде бер маhи руйин[4].
Ул маhи руй ул шәhәрнең шаh кызи,
Хөсне ичрә маh табан[5] ирде үзи.
Күрде Заhид ул кызи, булды әүварә[6],
Карамакдин китмәгә булмаз чара.
Белде: ул кыз гашыйкъ булмыш үзенә,
Ул Заhидның карады кыз йөзенә.
Көн-ай коймуйур[7] (?) Заhид йөзи,
Кыз йәнә гашикъ булуб текде күзи.
Заhидә мән бер нишан[8] бирсәм кәрәк,
Ул нишандин Заhид кичә килсә кәрәк.
Ул бер заман бер айнәйи[9] алды кереб,
Айнәйи ачыб бакты каршы торыб.
Айнә сырты Заhидә, йөзе — үзенә,
Йабды айнәйи, кирү кайтты үзенә.
Йәнә чыкды бер айакка[10] су салыб,
Суыны түкеб, айакын керде алыб.
Йәнә чыкды бер нари әленә[11] алыб,
Кушты нари[12], кисте уртала(й) йарыб.
Кыз керде кире йәнә сарайына,
Алыб чыкды йәнә бер тимән игнә[13].
Сындырыб орды йиргә игнәне:
«Ник торасын, белмәйсен сән», — дигәне.
Кыз керде сарайә, чыкмады ул,
Заhид андин китмәклеккә тотты йул.
Китте Заhид гъәурәтенә кауышты,
Нигә кичү калмышыны сорышты.
Заhид әйде: «Күчә[14] берлә мән барай[15],
Кайтмышымда күрдем бер сарай.
Ул сарайда күрдем караб бер маhи,
Бичара улыб гашикында кылдым аhи».
Гъәурәт әйде: «Аны күрүб ни йолдың,
Ни нишан күргүзде ул, ни белдең?»
Заhид әйде: «күргүзде hәр нишанын,
Нишанында белмәдем ни дигәнен.
Хатун әйде: «Нишанын дигел мәңа,
Сыйфатыны мән әйтеб бирәм сәңа»
Заhид әйде: «Бер айнә алыб чыкды,
Айнәсен мәңа тотыб ачыб бакты.
Йәнә бер айак суы алыб чыкды,
Сәрчәдән[16], килеб аны түкүб китте.
Андин йәнә бер нари чыкды алыб,
Кушды аны, бер-беренә орыр йарыб.
Андин алыб чыкды бер тимән игнә»,
Сындыруб йиргә орды аны йәнә.

---

[1] Гали — биек, бөек.
[2] Капугъ — капка.
[3] Сим-у-зәрин — алтын-көмеш.
[4] Маhи руй — ай кебек нурлы йөз, чибәркәй.
[5] Хөсне ичрә маh табан — гүзәллектә тулган айдай матур.
[6] Әүварә — бер нәрсәгә бирелеп китү.
[7] Коймуйур — (?) балкыйдыр.
[8] Нишан — вәгъдә бүләге.
[9] Айнәйи — көзгене.
[10] Айак — савыт.
[11] Әленә — кулына.
[12] Нар (анар) — гранат.
[13] Тимән игнә (тибән инә) — зур энә.
[14] Күчә — урам.
[15] Барай — бару.
[16] Сәрчәдин — пыяладан, ягъни пыяла савытта.

Ничә баксам чыкмады андин кирү,
Йулуму[1] тотуб киттем сәңа сару.
Белмәдем мән аны ни (эш) кыйл(м)ышын,
Бу эш ичрә күңелендә нә әйтмешен»[2].
Хатун әйде: «Аны белеб нидәсен?
Белсәң, йәнә аңа нә эш къиласын?
Заһид әйде: «Ул маһи алды күңел[3],

. . . . . . . . . . . . . . . .

Нишаныңдин нә димешен сөйләгел!»
Гъәурәт әйде: «Андагъ ирсә, килгел».— димеш...[4]
... Илтүбән[5] анлари зинданә салды.
Заһидны гъәурәте көтте — килмәде[6].
«Көйүкендин чәрам-карар калмады,
Таң намазга килмәкде Заһид мәңа.
Ник килмәде бер бәла булды аңа?»
Заһид хатуны ул багъга[7] барды йөрүб,
Сарайдин инде дайә[8] хатуни күрүб,
Дайә әйде: «Ни кеше хатуны сән?»
Хатун әйде: «Заһидның хатуны мән».
Дайә әйде: «Булды безем йөз кара,
Бу эш ичрә ни кыйлалыйк, ни чара?»
Хатун әйде: «Мән кыйлайын чарасын,
Китәрәйен сезнең йөзнең карасын.
Ни йирдә Заһидлә[9] кыз, әйдең мәңа,
Илтеңез мәни, җәһәд[10] барам аңа».
Хатунә дайә зиндан йирен әйтте,
Ике табак аш алыб хатун китте.
Башына ике дәстарчә[11] йабуб
Шул сагъәт зинданә йитте барыб.
Зинданчыга диде хатун: «Әй, гъәзиз!
Бер сагъәт(кә) мәне зинданә кергүз.
Зинданда кешем бар, аш йидерәйем[12],
Бер табак аш сәңа йийма бирәем».
Зинданчы әйде: «Сүзеңне тыңлаем, хуш».
Таш тик күңел йомшаткан бер табак аш!
Рәүан[13] кереб, тиз кире чыккыл[14] сән йәнә,
Хан белмәсен бу эшн — куркарым йәнә».
Хатун рәүан керде ичрү[15] аш алыб,
Бер дәстарчә башындин алды салыб.
Дәстарчәне ул кызның башына салыб,
Табакны кулына бирде: «Чыккыл алыб!
Зинданчыдин табакны алгыл сораб,
Хәлүәт йиргә чыккач табакны борагъ!»[16]
Рәүан сарайга сән баргыл җәһәт,
Сүз булса, аптырама, күңелең бикүт!»[17]
Кыз чыкты башына дәстарчә салыб,

---

[1] Й у л у м у — юлымны.
[2] Н ә  ә й т м е ш е н — ни әйткәнен.
[3] Бәйтнең икенче юлы юк.
[4] Бу урында текст өзелә, ягъни кулъязмадагы берничә бит төшкән.
[5] И л т ү б ә н — илтеп.
[6] К и л м ә к д е — килмәк иде, килмәкче иде.
[7] Б а г ъ — бакча.
[8] Д а й ә — хезмәтче.
[9] З а һ и д л ә — Заһид илә.
[10] Җ ә һ ә д — тиз.
[11] Д ә с т а р ч ә — яулык, бөркәнчек.
[12] Й и д е р ә й е м — ашатыйм.
[13] Р ә ү а н — тиз, шунда ук.
[14] Ч ы к к ы л — чык.
[15] И ч р ү — эчкә, эчкәрегә.
[16] Б о р а г ъ — ташла.
[17] Б и к ү т — нык бул, тыныч бул.

Китте (рәүан)[1] зинданчыдин табакны алыб[2].
Бер хәлүәттә табакны салыб китте,
Сараена сәламәт барыб йитте.
Хан йәнә мәсҗиддә чаш[3] намазын кылыб,
Къәһр[4] илә ултурды тәхтенә килеб.
Диде: «Йәллат[5], килтүрүң Заһидлә кызни,
Ник бөйлә[6] кара къилды безем йөзни?
Йәллатә хандин бөйлә булгач фәрман,
Зинданә шул ук заман барды рәүан.
Зинданчыйә диде: «Тиз кер ичәрү,
Заһид илә хан кызын килтүр бирү!
Зинданчы Заһидлә хатунны бирде,
Йәллат рәүан монлари алыб барды.
Заһид илә хатун ханны күрделәр,
Хезмәт[7] илә йирә йөзен ордылар.
Хан анда диде: «Әй, бәдбәхет хатун!
Йөз кара иттең, сакламый аталык хакын».
Хатун әйде: «Ни тигде мәндин зарар?
Ни зарар тигсә мәндин, биргел хәбәр».
Хан әйде: «Ул багъда ни къилмыш(сын) сән,
Йөзеңә кара сөртеп килмеш(сен) сән?»
Хатун әйде: «Әй, шаһым, булгыл ата,
Кичәлекдин эшемез булды хата.
Бу гъитаби[8] багъ өчен ирсә мәңа,
Йалбарамын Тәнре хакы өчен сәңа.
Кичә берлә йиттек караңгы булуб,
Шәһәрә кердек бер чишмә якалай йөрүб.
Килә-килә бу багъ ичрә йиттек без,
Йокы гъәләбә къилды[9] — анда йомдык күз.
Армышдин йоклабмыз үздин[10] китеб,
Йоклабмыз уйганмай, таң намаз үтүб.
Йәлла(т) килеб тотты безне йокыдан,
Диде безгә: «Йөреңез, йиреңез зиндан!»
Кичәлекдин эшемез хата булмуш,
Белмәдек без, бу бакча сезнең имеш.
Ул гъәйеб булды бездә кичә өчен,
Гъәйбемез кичер, Тәнре хакы өчен».
Хан әйде: «Канча[11] хәйлә (сән) идәсен,
Бу тәдбирлә[12] ничә ийерәб[13] кидәсен?»
Хатун әйде: «Бези монча[14] идәсен,
Багыгыза кермеш өчен дотасын[15].
Хан диде: «Кем дийә дуругъ[16] сүзи:
«Сән безем кара кылдың йөземези!»
Хатун әйде: «Нә эш булды бу ара,
Нә зарарым тигеб[17] йөз булды кара?»
Хан әйде:«Заһид илә тотулуб

---

[1] Бу сүз кульязмада артык язылган булса кирәк.
[2] Табакны салыб китте — ташлап китте.
[3] Чаш — төш вакыты.
[4] Къәһр — ачу.
[5] Йәллат — җәллад.
[6] Бөйлә — болай.
[7] «Хөрмәт» булырга да мөмкин.
[8] Гъитаб — шелтә, сүгү, ачулану.
[9] Гъәләбә къилды — җиңде.
[10] Үздин — һуштан.
[11] Канча — күпме.
[12] Тәдбирлә — ният белән.
[13] Ийерәб — боргаланып, хәйләләп.
[14] Монча — болай.
[15] Дотасын — тотасың.
[16] Дуругъ — тугъры.
[17] Тигеб — тиеп.

Ошбу йиргә килебсән, кара йөз булуб.
Хатун әйде: «Шәригатьтә мондагъ[1] эш булса,
Үз хәлале берлә тотылуб ханлара килсә...»
Хан әйде: «Ирмәсмүсән[2] минем кызым,
Йук ирсә гъәләтмедүр[3] минем сүзем?»
Хатун әйде: «Мән бу Заһид хәлале[4],
Сәнең кызың ирмәзмән[5], белгел бәли[6]».
Хан әйде: «Йөзеңне ачкыл, күрәйен,
Бу Заһидның хәлале ирсәң беләйен.»
Хатун анда чадырун ачды заман,
Хан күрүб ошбу эшдин калды хәйран.
Хан әйде йәллатә: «Нидер бу халь?»
Йәллатның сүз димәгә калмады мәҗаль[7].
Хан кызына кеше изды[8] белмәгә,
Сарайында бары-йукын күрмәгә.
Сарайында күрделәр ул дәм[9] кызи,
Каралыкдин йуылды ханның йөзи.
Хан йәллатә диде: «Мондагъ мине хәҗил[10] итдең,
Имди сән үз башыңа үзең йитдең».
Хан бойырды — йәллати санын кистеләр,
Һәр саныны дәруазага[11] астылар.
Заһид(д)ин китте йәнә монча михнәт,
Хан Заһидә күб бирде мал — гъәнимәт[12].
Ул шәһәрдин киттеләр йула кереб,
Сумгъәсинә йиттеләр йәнә барыб.
Йәнә алтмыш йыл кыйлдылар гъибадәт,
Көндезүн рузә тотыб, төнлә — тагъәт.
Гомерләре ахыр улды — үттеләр,
Дөнйа-ахирәт морадына йиттеләр.
Берекмәкдин итте анлар монча эш,
Берекнәнләр асан[13] булыр йаз вә кыш.
Гъакиль[14] адәм берекеб берлек кыйла,
Хакъ рәхмәте берлек(к)ә йакын була.
Кил, әй, мөэмин, берекеб кыил һәр эши,
Хакъдин рәхмәт булса[15] кәрәк ул кеши.
Берекнәнләр сыйфатын әйдем сезә,
Берекнән эш асандыр сезә-безә.
Хак рәхмәте берлекдә хасил ула,
Берегеб тагъәт кыилан рәхмәт була.
Безләрә тәүфикъ рузи[16] кыилгыл сәнә,
Колларыңа, Изем[17], сән пошт-пәнаһ[18].
Тәүфикъ теләб йыгъларым сәндин өмид,
Рәхмәтең пәрауан[19] сәнең, кыилма нәүмиз.

---

[1] Мондагъ — мондый.
[2] Ирмәсмүсән — түгелме син.
[3] Гъәләт — ялгыш.
[4] Хәлале — хатыны.
[5] Ирмәзмән — түгелмен.
[6] Бәли — шулай.
[7] Мәҗаль — көч, куәт.
[8] Изды — күндерде, җибәрде.
[9] Дәм — вакыт, чак.
[10] Хәҗил иту — оятлы иту.
[11] Дәруаза — капка, шәһәр капкасы.
[12] Гъәнимәт — бүләк.
[13] Асан — имин, тыныч.
[14] Гъакъиль — акыллы.
[15] Рәхмәт булса — рәхмәт тапса.
[16] Рузи — ризык, өлеш, язмыш.
[17] Изем — Тәңрем.
[18] Пошт-пәнаһ — таяныч, терәк, яклаучы (пошт-арка, терәк; пәнаһ — яклау).
[19] Пәрауан (дөресе: фәрауан) — мул, бай, чиксез.

Тәүфикъ биреб күргүз хакъ йулларыңны,
Рәхмәтлек(к)ә йарлыка колларыңны.
Әй, Ходайа, гасый[1] җафи Мәүла Колый,
Рәхмәтеңлә сән биргел коллык йули.
Рәхмәтеңдин нә өмид кыйлмагани,
Рәхим сән, йарлыкагыл сән ани.
Җөмләләри[2] йарлыкаган сән Кәрим,
Гъәйебләрен йабкычы гъәфү рәхим.

## Хәлаль нәфкъә эстәгәнләр сыйфаты

Бер нурындин йаратты Хакъ Әфрасиаб[3]
Ул үзе бер шаһ иде, халкы гъораб[4].
Мөтәмәкян[5] мәками йире[6] аның,
Бер гъәзиз колы иде бер Ходайның.
Сулары иде бер дәрйа — Уркан Өгүз,
Башында Әфрасиаб, тамагы диңгез.
Башындин тамагына өч айлык йул,
Тамагында бер шәһәрдер, күб-калын ил.
Әфрасиаб шәһәрендә бер фәкыйрь
Тиречелек къилыр ирде кәм-у-хәкъир[7].
Кырык йылча тиречелек кыйлды тәкъи,
Һәр көнгә йарым тәңкә ирде хакъи.
Һәр көнгә йарым тәңкә улур ирде,
Бу көчем хәлаль микә(н) дәйүр[8] ирде.
Бу көчем хәлаль булса күрәйен,
Нә бирүрсә, Хакъга караб торайын.
Ихлас-лә мән чөн бу эшне къилайын,
Көчем кайчан хәлаль булса беләйен.
Йарым тәңкә һәр көндә эшләб алыб,
Бакар ирде аны дәрйага салыб.
Дир ирде: бу тәңкә хәлаль ирсә,
Батмагай[9] бу дәрйага, миңа бирсә.
Кырык йылча салды суга көч итеб,
Һич берсе күренмәде батыб китеб.
Кырык йыл итмешендә тиречелекдин,
Йарым тәңкә алды ул йалчылыкдин.
Дәрйага йәнә һәм салды ани,
Хәлаль ирсәң батмага кумаз сәни.
Батмаз ирсәң сән миңа булдуң хәлаль,
Батыр ирсәң сәнең өчен йук мәлаль[10].
Дәрйага батмаз улды тәңкә йәнә,
Тәңрегә къилды[11] фәкыйрь тәшәккер-сәна.
«Бисмиллаһ» тиб тәңкәне алды рәуан,
Калтасы[12] ичрә тәңкәне кыйлды пинһан[13].
Көнләр ичрә ул шәһәрдә бер хуҗа

---

[1] Гасый — гөнаһлы.
[2] Җөмләләри — барчаларны.
[3] Әфрасиаб — монда шәһәр (Сәмарканд).
[4] Гъораб — фәкыйрь, сәер.
[5] Мөтәмәкян — торган җир, яшәгән урын.
[6] Мәками йир — шул ук мәгънәдә; бу урында тавтология килеп чыга.
[7] Кәм-ү-хәкъир — ким вә фәкыйрь, мескен һәм түбәнсетелгән.
[8] Сүз кульязмада бозылып «дирүр» рәвешендә язылган.
[9] Батмагай — батмас, батмаячак.
[10] Мәлаль — әрнү, кайгыру.
[11] Кыйлды тәшәккер-сәна — рәхмәтләр, мактау сүзләре укыды.
[12] Калта — акча янчыгы.
[13] Пинһан кыйлу — яшеру.

Урну олугъ, дәүләте кимсез, йүчә[1]
Кәруан улуб сәүдәгә китмәк теләр.
Күб халайыкъ моңа йулдаш булдылар.
Уркан Өгүз кимәсенә ултуруб,
Кимәләргә калә[2] комаш тултуруб.
Ул хуҗага килде ул тиречс фәкъир,
Йалбарыб сүзен әйде ким-ү-хәкъир.
Диде: «Котлугъ булсын сәфәр ниятең,
Йүчә къылсун Хакъ Тәгалә дәүләтең.
Мин фәкъиргә күзеңне салырмусән,
Бер сүз дисәм, сән кабул алурмусән?»
Диде хуҗа: «Әй, фәкъир, дигел сүзең!
Сүзеңә бу җан корбан улсун безнең».
«Йарым тәңкә Хакъ хәлаль бирде мәңа,
Ул тәңкәне әманәт бирәм саңа».
Хуҗа диде: «Хуш, фәкъир, дотам сүзең.
Бу тәңкәдин морадың айгыл[3] үзең!
Әманәтне бирдең мәңа, ни алайын,
Мән саңа ни кирәген нә беләйен?
Әйде фәкъир: «Бу тәңкәне сән белгел,
Хакына һәр нә тигәр алыб килгел!»
Ул хуҗа чөн Тәңренең хакын хаклар,
Ул тәңкәне малына кушмай саклар.
Фәкъир мәңа бирде моны әманәт,
Кыйамәт көн булмасын тир[4] йаман ат.
Уркан Өгүз тамагына ирделәр,
Андагы бер олугъ шәһәр күрделәр.
Ханына керде анлар... (?) алыб,
Хан монларә хезмәт итте баш салыб.
Йәнә кәрван өч кичә-көндүз кичеб,
Хан кашында җөмләсене йийеб-эчеб...

---

[1] Йүчә — югары, дәрәҗәле.
[2] Калә — мал, байлык.
[3] Айгыл — әйтеп бир.
[4] Тир — дир, дип.



**Хатыйп Миңнегулов,**
КДУ профессоры.

# НИНДИ ТӨСКӘ КЕРСӘ ДӘ, АСЫЛЫ БЕР...

Алга барырга теләгән халык үткәнне өйрәнә, үзен борчыган сорауларга тарих сәхифәләреннән җаваплар эзли, булып узган вакыйга-хәлләрдән үзенә гыйбрәт ала. Шөкер, без дә әкренләп тарихыбызга борыла башладык, анда үзебез өчен сабак булырдай нәрсәләрне күреп хәйран да калдык. Баксаң, халкыбызның каһарман уллары теләсә нинди шартларда көрәштән туктап калмаганнар икән: хәрәкәт иткәннәр, тарих, заман һәм киләчәк хакында уйланганнар, фараз да кылганнар... Әнә шундый фидакарь затларның берсе — Гаяз Исхакый (1878—1954). Хәзерге укучы инде аның олуг әдип, атаклы публицист, мәшһүр идеолог һәм җәмәгать эшлеклесе икәнлеген белә. Әмма бу белү әле, нигездә, гомуми планда, вывесканы — күрсәтмә тактадагы текстны үзләштерү күләмендә генә. Гаяз Исхакый язганнарның төп эчтәлеге, мәгънәсе, эшчәнлегенең асылы нәрсәдән гыйбарәт,— бу хакта әле киң катлам укучыларның гына түгел, хәтта белгечләрнең дә күзаллаулары шактый сыек. Һич шикләнүсез әйтергә кирәк, Гаяз Исхакый — ул татар тормышының феномены, ягъни гадәттән тыш сирәк очрый торган күренеше. Аны белү ул — мәдәниятебезне, тарихыбызны белүнең, милли үзаңны үстерүнең мөһим чараларыннан, факторларыннан берсе. Шуңа күрә безгә бу фидакарь затның һәр язганын, һәр эш-гамәлен өйрәнү һәм белү, алардан сабак алу — тарихи зарурият һәм рухи ихтыяҗ.

Укучыларга без Г. Исхакыйның «Бугазлар» исемле язмасын тәкъдим итәбез. 1936 елның август аенда язылган бу мәкалә «Яңа милли юл» журналының шул ук елгы сентябрь санында (№ 9 (102). 1—8 б.) дөнья күргән.

Г. Исхакый мөхәррирлегендә 1928—1939 елларда Берлиндә чыккан «Яңа милли юл» хакында инде без ике махсус мәкалә бастырган идек. Журналдагы аерым материаллар (нигездә, баш мөхәррирнең үз язмалары) да, кереш сүз һәм тиешле аңлатмалар белән, укучыларга ирештерелде. Безнең бу мәкалә шул эшнең дәвамы булып тора.

Англия, Франция, Италия, Япония һәм кайбер башка илләр катнашында Лозаннада уздырылган халыкара конгресс үзенең 1923 ел 24 июль килешүе белән Төркияне Босфор һәм Дарданел бугазларына ия булу хокукыннан мәхрүм итте. Ачык диңгез юллары дип игълан кылынган бу бугазлар белән идарә итү халыкара комиссиягә тапшырылды. Әлбәттә, сугыштан, эчке һәм тышкы каршылыклардан хәлсезләнгән Төркия бу хурлыклы карар белән вакытлыча ризалашырга мәҗбүр булды.

Кәмал Пашаның (Ататөрекнең) сыгылмалы, оста сәясәте нәтиҗәсендә, Төркия әкренләп ныгый, үзенең халыкара дәрәҗәсен күтәрә барды. Лозанна килешүен юкка чыгару өчен көрәш хәрәкәте төрекләр арасында киң колач алды. Һиһаять, Төркия таләбе белән 1936 елның 22 июненнән 20 июленә кадәр Швейцариянең Монтре шәһәрендә уздырылган халыкара конгресс Лозанна килешүләрен юкка чыгарырга һәм Дарданел, Босфор бугазлары белән идарә итү эшләрен төрекләрнең үзләренә кайтарып бирергә мәҗбүр булды. Шулай итеп, табигый хаклык, иҗтимагый гаделлек, гәрчә тулысынча булмаса да, тантана итә. Г. Исхакый мәкаләсе әнә шул халыкара вакыйга, төрек кавеменең шатлыклы, куанычлы көннәре уңае белән барлыкка килгән.

«Бугазлар» язмасы кайсы яклары белән игътибарга лаек соң? Шуларның берничәсен генә атап китик.

Мәкалә безгә дөньядагы илләр, милләтләр тормышының үзара бәйләнешле булуын, 20—30 еллардагы халыкара вазгыятьнең нинди хәлдә булуын, Төркиянең эчке хәлләрен һәм тышкы мөнәсәбәтләрен шактый дәрәҗәдә күрсәтеп тора. Рәсәй-Төркия каршылыкларын тарихи планда яктырту — язманың иң кыйммәтле якларыннан берсе.

Башка илләрне һәм халыкларны яулап алу, буйсындыру яисә үзенә бәйле итү — урыс хакимиятенә элек-электән хас сыйфат. Идел-Урал, Себер, Алтай, Ерак Көнчыгыш, Казагыстан, Урта Азия, Кавказ, Кырым, Балтыйк буе...— болар бит берсе дә урыс җирләре түгел, ә башка халыклардан тартып алынган җирләр. Шунысы гаҗәп: бу гайре табигый процесс, әхлаксыз эш-гамәлләр еш кына «ирекле кушылу», «кушылу», «үзләштерү», фәләннәрдән «азат кылу», «цивилизацияле итү», «иминлек урнаштыру», «Ватанның чикләрен ныгыту» һәм матур яңгырашлы башка шундый сүзләр белән аңлатып киленде һәм хәзер дә шулай дәвам итә. Рәсәй—Татарстан шартнамәсенә кул куелуның икенче көнендә, ягъни 16 февральдә «Останкино» каналы буенча «Яңалыклар»ны тапшыручы диктор телевизор караучыларга мондый эчтәлектәге мәгълүмат бирде: Казан ханлыгы була. Ул Рәсәйгә кушыла («присоединилось»). Октябрь инкыйлабына кадәр татарлар империя составында имин генә яшиләр...

Татар мәмләкәтләренең, шул исәптән Казан ханлыгының Мәскәү хакимияте тарафыннан ничек яулап алынуы, татарларның дүрт гасырдан артык колониаль изелү астында нинди «имин»лектә яшәүләре[1] хәзерге вакытта хәтта мәктәп балаларына да мәгълүм була бара. Империя тарафдарлары өчен «бүленмәс һәм бердәм» төшенчәләре, әйтерсең, дөнья яратылганнан бирле килә торган мәңгелек табигый төшенчәләр. Әйтерсең, ят җирләр һәм халыклар Мәскәү хакимиятенә Ходай тәгаләнең үзе тарафыннан бүләк ителгән...

Мәгълүм булганча, Төркия белән мөнәсәбәт — урыс тышкы сәясәтенең иң мөһим өлеше. Әмма биредә тигезлек, хезмәттәшлектән бигрәк, Рәсәй империясенең үз күршесен буйсындыру, ахыр чиктә аны тәмам юк итү максаты өстенлек итә. Петр Беренченең 1725 елгы яшерен «Васыятьнамә»сенә[2] генә мөрәҗәгать итик. Анда мондый юллар бар: «Русия мәмләкәтен дөнья мәмләкәтенә әйләндерер өчен, аның башкаласын Азия һәм Европа хәзинәләренең ачкычы булган «Истанбулга күчерү шарт... Шөбһәсез ки, Истанбулга ия булган патша дөньяда иляһи патша булачак... Һиндстанның ачкычы — Төркиянең башкаласыдыр... Төркия дәүләтен юк итүдән элек Иранның җанын алуны киңәш итмим».

Кайберәүләр Петр Беренченең кан коюга, басып алуга юнәлтелгән бу әхлаксыз «Васыятьнамә»сен Рәсәй сәясәтенең хосусый бер күренеше итеп кенә күрсәтергә омтылалар. Әмма мондый караш өчен һич тә нигез юк. Чөнки Петр патша бу яшерен документны үзенә кадәрге һәм үз чорындагы урыс рәсми сәясәтенә таянып төзегән, хөкемдар Иваннардан килә торган басып алу, буйсындыру сәясәтен гамәлгә ашыруга үзе дә зур өлеш керткән. «Васыятьнамә»нең төп эчтәлеге, гомумән, күпгасырлык Рәсәй империясенең тышкы эш-хәрәкәтләренә шактый туры килә.

Мәкаләдән Г. Исхакыйның Петр васыятен белүе яхшы аңлашыла. Әмма «Бугазлар» язмасы авторы өчен Рәсәйнең колониаль сәясәте болай да ачык.

---

[1] Бу хакта күзаллау тудыру өчен М. Худяковның мәшһүр хезмәтенә («Очерки по истории Казанского ханства»...) һәм Р. Әмирхан, В. Имамовның «Татарларның Ватан сугышы» (Яр Чаллы. КамАЗ, 1993) һәм Вахит Имамовның «Запрятанная история татар» (Наб.-Челны, КамАЗ, 1994) китапларына күз салу да җитә.

[2] Яшерен васыять.— «Казан утлары», 1992, № 1.— 166—168 б.

Чөнки ул бу сәясәтнең ниндилеген газиз халкының язмышында ачык күргән, үз җилкәсендә татыган, аңа каршы көрәше өчен төрмәләргә утыртылып, Архангел якларына сөрелгән, ахыр чиктә, сөекле ватаны — Идел-йортны калдырып, чит мәмләкәтләрдә каңгырып йөрергә мәҗбүр булган. Бөек әдип, вафат булып, җәсәден үзгә илдә калдырса да, рухы, язганнары, башкарган эш-гамәлләре белән әкренләп туган җиренә — Идел-йортка кайта...

Г. Исхакый үз мәкаләсендә Рәсәй империясенең Төркиягә каршы үткәрелгән сәясәтендәге төп баскычларны атап китә. Тарихи тәҗрибәне гомумиләштерү рәвешендә ул болай ди: «Бу васыятьне (ягъни Петр Беренче язмасын.— Х. М.) вөҗүдкә чыгарыр өчен, Русия һәрбер форсатдан файдаланып, бу көнгә кадәр Төркиягә һөҗүм итә килде». **«Русия, теләсә кызыл төсдә, ак төсдә, берләшкән зур бер дәүләт булып калганда тугрыдан-туры Ак** (Урта.— Х. М. ) **диңгезгә чыгар өчен, бугазларын, Истанбулны алыр өчен омтылачакдыр»... «Рус дәүләтенең идарәсенең төрле-төрле төскә әверелүе, мәмләкәтнең бер режимдан икенче режимга күчүе генә берләшкән Русиянең бу милли сәясәтен үзгәртә алмаячакдыр[1]»** (ассызык безнеке.— Х. М.).

Г. Исхакый — гомере буе халыкларның азатлыгы, тигезлеге, иминлеге өчен көрәшкән шәхес. Бу максатка исә империяләрне бетерү, бәйсез милли дәүләтләр төзү, гадел халыкара мөнәсәбәтләр урнаштыру юлы белән генә ирешергә мөмкин. Мәкалә авторы фикеренчә, Рәсәй (СССР) империясе — Төркия өчен генә түгел, ә башка күп кенә халыкларның, шул исәптән татарларның иминлеге, азатлыгы өчен дә киртә. «Русия тарафыннан бугазларның, Истанбулның әминияте (иминлеге — Х. М.), Төркиянең үзенең бу йирләрдәге алты йөз еллык хакимиятенең тулы көенчә дәвам итдерелүе,— дип яза Г. Исхакый,— рус империализмының кырылуы берлә генә тәэмин ителә беләчәкдер. Бу да руслыкның истилясындан (басып алуыннан.— Х. М.) Украина, Кафказ, Кырым кеби Кара диңгез дәүләтләренең кортылып (котылып; корылып.— Х. М.), яңадан үз милли истикъляларыны (бәйсезлекләрене.— Х. М.) кайтарулары берлә, **үз башларына аерым милли дәүләтләр төзеп яшәүләрен тәэмин итү берлә генә мөмкин булачакдыр»** (ассызык безнеке.— Х. М.).

30 нчы елның урталарында язылган «Бугазлар» мәкаләсе күп кенә фикер-күзәтүләре белән бүгенге көнгә дә аваздаш. Һаман да Кара диңгез, Кырым, Кавказ өчен көрәш бара. СССР дәүләтенең варисы Рәсәй һаман да империя булып кала килә, милләтләрнең үзбилгеләнүенә төрле киртәләр корыла, кеше хокуклары бозыла, яңа бәйсезлек алган халыкларның эчке эшләренә тыкшыну дәвам итә...

Г. Исхакый СССР империясе составындагы урыс булмаган халыклар арасында киләчәктә милли хәрәкәтнең көчәячәген һәм ахыр чиктә аларның бәйсезлек алачакларын искәртә. Бөек әдипнең бу фаразы, бик акрынлык һәм кыенлык белән булса да, гамәлгә аша бара. Мәкалә авторының империя көчләре белән сак эш итәргә, аларның вәгъдәләренә алданмаска чакыруы бүген дә актуаль яңгырый.

«Бугазлар» язмасы тарихи чаганак буларак та игътибарга лаек. Халыкара тормышның, сәяси көрәшнең үзәгендә кайнаган Г. Исхакый фикерләре, аның үткән, хәзерге, киләчәк заман турында уйланулары бүгенге тарихчылар, сәясәтчеләр өчен дә менә дигән материал. Чөнки анда сабак, гыйбрәт алырлык нәрсәләр күп. «Бугазлар» мәкаләсенең, безнең уебызча, Төркия галимнәре өчен дә файдасы зур. Чөнки бит аның төп эчтәлеген Төркиягә мөнәсәбәтле вакыйгаләлләр тәшкил итә.

Мәкалә Гаяз Исхакыйның тарихны, халыкара вазгыятьне яхшы белүче, сизгер, үз мәсләге ачык булган зирәк сәясәтче, дипломат икәнлеген янә бер мәртәбә раслый. Аның карашлары бүгенге милли һәм иҗтимагый хәрәкәт өчен аеруча мөһим.

* * *

Журнал укучыларына мәкалә, нигездә, язылыш үзенчәлекләрен саклап, һич кыскартусыз тәкъдим ителә.

---

[1] Мәскәү хакимиятенең Икенче бөтендөнья сугышыннан соң да Төркиядән бугазларны таләп итүен генә хәтергә төшерик.

## Бугазлар

(«Яңа милли юл», 1936, № 9 (102). 1—8 б.)

Төрле-төрле бик күп зур вакыйгаларга бай булган 1936 елның булып үткәннәре арасында Монтрода (Монтре. Швейцариядәге шәһәр.— Х. М.) тупланган бугазлар конгрессы да, шөбһәсез, киләчәктә зур бер урын тотачакдыр.

22 нче июньдә ачылган бу конгре уңышлы эшләрене 20 нче июльдә генә тәмам итеп, үзенең карарларында 1923 нче елда 24 июль тарихында бугазлар хакында Лозан(на) да (Швейцариядәге шәһәр.— Х. М.) кабул ителгән бәйнәлмиләл (халыкара.— Х. М.) карарларны үзгәртде. Лозан могаһәдәсе (шартнамәсе, килешүе.— Х. М.) буенча, кирәк Чәнак калга бугазы (Дарданел), кирәк Истанбул бугазы (Босфор) ачык диңгез юллары итеп игълан ителгән вә болардан үтү-кичүне идарә итү бәйнәлмиләл бер комисионга (комиссиягә.— Х. М.) тапшырылган, Төркия дәүләтенең бугазларны ныгыту, бугазлар тирәсендә гаскәр тоту хакы да бетерелгән иде. Нәзари (күзәтүче, контроль.— Х. М.) уларак, бугазарның саклануы, Лозан могаһәдәмсенә кул куйган Ингилтәрә (Англия.— Х. М.), Франса, Италия, Япуния мәмләкәтләренең хакы вә бурычы итеп кабул ителгән вә бу могаһәдә җәмгыяте әкъвамның (Милләтләр лигасының.— Х. М.) карамагына тапшырылган иде.

Лозан могаһәдәсе буенча, 1358 елдан бирле һичкем берлә уртаклашмаенча төрекләрнең биләп килгән мәмләкәтләренең капкасы булган Дарданелның, Истанбул бугазының ачкычы кулларындан алынган, төрекләрнең каравылчылары, сакчылары бугаздан ераклашдырылган иде. Мөстәкыйль бер дәүләтнең сәламәтлеге өчен бу һичбер төрле итдереп кабул ителерлек эш булмаса да, 14 еллык сугышдан бик арып чыккан яңы Төркия, бу тарихи хакларында каты торырлык көче юклыгын белеп, теләр-теләмәс бу шартларны кабул итәргә вә бу могаһәдәне үзгәртүне киләчәкдәге бер форсатка калдырырга мәҗбүр булган иде. Яңы Төркия эчке эшләрен юлга куеп бетерер-бетермәс, бугазларның ачык калдырылуы Төркиянең истикълялы (бәйсезлеге.— Х. М.) берлә һичбер оешмый торган бер нәрсә икәнен бик ачык күрде. Бик тиз Лозан могаһәдәсенә имза атган (кул куйган.— Х. М.) дәүләтләр арасында бугазларны саклауны Төркиягә кайтару хакында мөрәҗәгатьләр дә булынды. Ләкин төрле сылтаулар табып, дәүләтләр бугазлар хакындагы карарларыны яңадан карарга ашыкмадылар. Бугазларны ачык калдыра килделәр. Төркиягә: «Сезнең дәүләтегезнең сәламәтлеге Җәмгыяте әкъвамның фәләненче маддәләре (статьялары.— Х. М.) берлә тәэмин ителгән фәлән»..,— дип сүзне кайтара килделәр.

Җәмгыяте әкъвамның әгъзалары Италия берлә Хәбәшстан (Абиссиния; Эфиопия.— Х. М.) арасында чыккан сугышда Җәмгыяте әкъвамның көчсезлеге, зәгыйфь Хәбәшстанны куәтле Италиягә каршы химая итәрлек (якларлык.— Х. М.) бәйнәлмиләл куәтнең мәүҗүд (хасыйл.)— Х. М.) булмавы Төркия әфкяре гомумиясене (иҗтимагый фикерен; җәмәгатьчелек карашларын.— Х. М.) галәйанга (кузгатуга; ярсытуга.— Х. М.) китерде. Безнең дә мәмләкәтемезне саклавымыз фәкать үз көчемез берлә генә мөмкин булачак, нә Җәмгыяте әкъвам, нә дә Лозан могаһәдәсенә кул куйган дәүләтләр, бугазлардан диңгез куәте көчле бер дәүләт Мәрмәрәгә, Кара диңгезгә кереп илемезгә һөҗүм итәчәк булса, безгә ярдәмгә килә алмаячаклар икән, шуның өчен бугазларның ачык булуы мәмләкәтемезнең сәламәтлеге өчен зур бер тәһлакә (куркыныч.— Х. М.) икән, боны мөхәкъкак (һичсүзсез, шикләнмичә.— Х. М.) үзгәртергә, бугазларны саклауны үз кулымызга алырга кирәк,— диделәр. Катгый итеп могаһәдәгә имза куйган олуг дәүләтләргә һәм дә Кара диңгез буендагы дәүләтләргә Төркия хөкүмәте яңыдан мөрәҗәгать итде. Бугазлар мәсьәләсен хәл итәр өчен аерым бер конгре (конгресс.— Х. М.) ясауны таләп итде. Италия-Хәбәшстан сугышы Ак диңгездә (Урта диңгездә.— Х. М.) ингилизләрнең боңарча хаким булган вазгыятьләренә зарар китерәчәк бер төс алуы вә Ингилтерә хөкүмәте Ак диңгездәге мовазәнәне (тотрыклылыкны; тигезлекне, балансны.— Х. М.) саклауда үз көченә генә таяна алмаячагын күреп, Ак диңгез буенда мөһим җәгърафый урын тоткан Йунанстан (Греция.— Х. М.) Төркиянең дә шул эшкә катышдырылуыны кирәкле тапды. Төркиянең сәяси әһәмияте, кыйммәте Ингилтерә күзендә күтәрелде; төрекләр бондан файдаланып, Ингилтерәдән бугазлар могаһдәсен үзгәртүгә разыйлыгын алдылар. Франса да Ингилтерә разый булган эшкә каршы килә алмады. Япуния дә Төркиянең бу таләбене тәмамән хаклы табуын белгертде. Кара диңгез буендагы дәүләтләрдән Румания, Болгария, СССР ризалыкларыны белдерделәр.

Кара диңгез буендагы дәүләтләрдән Украина, Кырым, Гөрҗестан (Грузия.— Х. М.) вакытлы рәвештә большевик истиласы (баскынчылыгы.— Х. М.) астында булганга, мөзакәрәгә (сөйләшүләргә.— Х. М.) катыша алмадылар. (3) Италия гына бугазлар хакында сөйләшүнең вакыты түгел дип мөзакәрәгә катышырга разый түгеллеген белдерде. Нәтиҗәдә ун дәүләт йиренә тукыз дәүләтнең вәкилләре катышып, Исвичрәнең (Швейцариянең.— Х. М.) Монтро шәһәрендә 22 июньдә конгре ачылды. 20 нче июльдә бөтен маддәләрдә килешеп, куллар куелып, бугазлар хакында яңы низамнамә (килешү, шартнамә; кагыйдә.— Х. М.) төзелде. Монтро конгрессы могаһәдәсенең бугазлар хакындагы бөтен маддәләренә юк итеп хисап итде. Бугазлар өстендә Төркия хөкүмәтенең һичбер чикләнмәгән хокукыны таныды. Боңарча бугазларны идарә иткән бәйнәлмиләл комисионны (комиссияне.— Х. М.) бетереп, бугазларны идарә итүне Төркиянең үз кулына тапшырды. Төркиянең бугазларны үзе теләгән рәвештә сакларга, ныгытырга, гаскәрене теләгән йирендә тотарга тулы хакы барлыгыны кабул итеп, кул куелган көндә үк бугазлар тирәсенә төрек гаскәренең йирләшүен кануни табды. 15 августдан игътибарән (башлап.— Х. М.) бугазларның бөтен идарәсе Төркиягә күчәчәк ителде.

Сугыш тәһләкәсе (куркынычы.— Х. М.) булганда бугазларны ябу Төркия хөкүмәтенең генә хакы икәнен конгре таныды. Солых вакытында да чит дәүләтләрнең Мәрмәрә диңгезенә, Кара диңгезгә барачак сугыш көймәләренең Төркиянең сәламәтлеге өчен хәтәрле булмауны күздә тотып, Төркиянең хәзерге диңгез көчендән бик күп түбән булу шартлары берлә тәхдид итде (чикләде). Төркия хөкүмәте үзе үк солых вакытында да, сугыш вакытында да сәүдә көймәләренең үтү-чыгуы Төркиянең карамагы астында сәрбәст (ирекле.— Х. М.) булуын таләп иткәнгә, бу маддә һичбер тавышсыз-тынсыз кабул ителде. Фәкать Совет Русиясенең үз диңгез сугыш көймәләренә бугазлар тәмам ачык булуыны таләп итүе генә зур моназарәгә (бәхәскә.— Х. М.) сәбәп булды. Ингилтерә, Япуния вәкилләре боны һичбер тәрле кабул итәргә тарафдарлык күрсәтмәделәр. Ахырдан Совет Русиясенең бугазлардан сугыш көймәләрене үткәрү хакы башка дәүләтләргә 15 мең тон(на)лык исәпләгәндә, 25 мең тон(на)га чыгарылды. Шулай итеп бер ай дәвам иткән бугазлар конгресы тәмам булды. Һәм дә дөнья сугышындан соң Төркиянең бугазлар өстендәге алынган хакы кире үзенә кайтару рәвешендә тәмам булды. Конгрега катышкан тукыз дәүләт вәкилләре дә кул куйдылар, ялгыз Италия гына кул куюдан баш тартды. Могаһәдә кануни халән (законлы тәс.— Х. М.) алды, Төркия хөкүмәте имза атканның соңында ук бугазларга гаскәри куәтене кердте. Фәүкылгадә (гадәттән тыш, чираттан тыш.— Х. М.) җыелышына тупланган Төркия Милләт мәҗлесе Монтро могаһәдәсене тәсдыйк итде (раслады.— Х. М.) вә Төркия хөкүмәте (4) ике бугазны да ныгытырга керешде.

Лозан могаһәдәсендәге бугазлар хакындагы маддәләр Төркиянең диңгез сугыш куәтләренең артмавыны күздә тотып эшләнгән иде. Бөтен тарафдагы диңгезләре шәррән яра ачык булганда Төркия дәүләте, байлыгы, көче җитсә дә, сыгыначак бер урыны булмаганга, зур диңгез сугыш көче тугдыра беләчәк түгел иде. Яңы могаһәдә Төркиянең диңгез сугыш көймәләрен артдыруына, Кара диңгездә дә, Ак диңгездә дә хатири сайларлык диңгез көчле бер дәүләт була белүенә киң мәйдан ачды. Төркиянең харижи (тышкы.— Х. М.) сәясәтендә яңыяңы имкяләр (мөмкинлекләр.— Х. М.) тугдырды. Төркия хөкүмәте шуларны күздә тотып, үзенең илен саклау көчен артдырып өчен, 10 еллык бер план хәзерләп (1936—1946) Милләт мәҗлесендән 67 миллионлык бер тәхсыйсать (программа.— Х. М.) кабул итдергән иде. Август башындагы мәҗлесендә тизлек рәвештә кирәкләр өчен тагын биш миллион лира бирүне Милләт мәҗлесе кабул итде. Хәзерге көндә, бер тарафдан, Төркиянең халкы һәрбер йирдә бугазларның кайтарылу шадлыгы бәйрәмене ясап килә. Икенче тарафдан, хөкүмәт көчле диңгез мәмләкәте булу чараларыны күреп ятадыр. Күптән түгел генә Алманиядан алган дүрт су асты көймәләренең берсе килеп Төркия бәхриясе (диңгез флоты.— Х. М.) тарафындан кабул ителде. Озакламыйча башкалары да берәмберәм киләчәкләр вә Төркиянең флотын, диңгез көчләрене куәтләндерәчәкләр. Икенче тарафдан, Төркиянең дәүләт химаясендәге (карамагындагы.— Х. М.) бер банк(а)сы берлә инглизләрнең дәүләт химаясендәге бер малигрупп (ширкәт?— Х. М.) арасында Төркиядә «Тимер вә корыч» ширкәте төзелде. Боның сәрмаясе (акчасы; башлангыч капиталы.— Х. М.) инглизләр тарафындан бирелеп, вапурлар (пароходлар, суднолар.— Х. М.) төзетү эшләренә керешелде. Бондан соңда Төркиянең диңгез кырыендагы шәһәрләрен ныгыту, портларны юлга салу юлында хәрәкәт ителәчәк дигән хәбәрләр йөреп торадыр. Боларның барысы бергә

җыелганда, яңы бугазлар могаһәдәсе Төркиянең куәте артуына, Ак диңгездә Төркия роленең зураюына, дөньяның тынычлыгын саклауда тоткан урынының ныгуына сәбәп булачакдыр вә Төркиянең бәйнәлмиләл хөрмәтене бөтен дөньяда артдырачакдыр.

Боңа башка Монтро конгресы сугышдан соң булган бик күп конгресларның иң муаффәкыятьлеседер (уңышлысыдыр.— Х. М.). Бугазлар могаһәдәсе — сугышдан соңгы зиһният (фикерләү; концепция.— Х. М.) берлә эшләнгән могаһәдәне беренче мәртәбә көчләнгән дәүләтнең хакын тану нигезендә үзгәртү, төзәтү могаһәдәседер. Төркия берлә сугышкан дәүләтләрдән Ингилтерә (5), Франса арасында сугыш зиһнияте тәмамән беткәнлеген күрсәтә торган дәлилдер. Шуның өчен бу могаһәдәнең Төркия берлә Ингилтерә, Франса, Япуния арасында самими мөнәсәбәтнең артуына сәбәп булачакдыр. Бу дәүләтләр арасында дустлык нигезендә яңы-яңы аңлашуларның вөҗүдкә (барлыкка.— Х. М.) килүенә мәйдан ачачакдыр.

Якын көнләргә кадәр Аурупада Төркиягә каршы сугыш зиһнияте тәмамән бетмәгән кеби бер хәлдә иде. Төркиянең бик күп тәшәббесләре (үтенечләре, мөрәҗәгатьләре.— Х. М.) шул зиһният аркасында кысыр кала иде. Бондан файдаланып Совет Русиясе Төркияне Аурупа агымындан читдә тотарга тырыша вә төрле ялган пропаганда, интригалар берлә аурупалашу дәверене кичерә торган Төркияне Аурупадан мәгънән (мәгънәви.— Х. М.), мадтән (матди.— Х. М.) озаклашдырып килә ала иде. Бу могаһәдә большевикның ялган пропагандасының зәминен (нигезен, җирлеген.— Х. М.) бетерде. Эчке вә тышкы эшләрендә Аурупа зиһниятле төрек милләтенең куәтле Төрек дәүләте булуына киң офык ачды. Ак диңгез тарафындан Төркиянең сәламәтлегене Ак диңгездәге мовазәнә (тотрыклылык; баланс.— Х. М.) берлә баглап, Төркиянең ул тарафы бәйнәлмиләл бер сигорта (химая, саклау, иминлекне тәэмин итү.— Х. М.) астына керде. Калды фәкать Кара диңгез тарафындан Төркиянең сәламәтлеген саклавы гына.

Төркиягә бу тарафдан һөҗүм итүче куәт фәкать руслардыр. 1699 нчы елда беренче мәртәбә бу эшкә тиле Петр башлады. Төрек гаскәрендән җиңелеп кире чигәргә мәҗбүр булса да, Петр бугазларны, Истанбулны алуны васыять итеп калдырды. Бу васыятьне вөҗүдкә чыгарыр өчен, Русия һәрбер форсатдан файдаланып, бу көнгә кадәр Төркиягә һөҗүм итә килде. Берсендә ул Төркиядәге христианларны химая итү, икенчесендә истикъләл (бәйсезлек.— Х. М.) сораган серблар, болгарларны яклап, өченчесендә Йунанстанның (Грециянең.— Х. М.) аерылуына ярдәм итү кеби күренешдә инсани кеби сылтауларга буяшдырса да, асыл максады Петрның васыятен тотып, бугазларны кулда итү булып барадыр. Бу начар уй берлә руслар 1736 да, 1768 дә, 1789 да берсе артындан берсе Төркиягә каршы сугышлар ясадылар. Бу сугышлар берлә Төркияне арытып, Төркиянең мохтар (ирекле, бәйсез.— Х. М.) өлкәсе булган Кырым дәүләтенә, гүя, истикъләл бирдергән төскә куеп, Кырымны әүвәлән Төркиядән сәясәтән (сәяси яктан.— Х. М.) аерып, аннары истиля итәләр (басып алалар.— Х. М.). Кырым ханлыгының бетерелүе, русларның Кара диңгезнең иң мөһим ноктасы булган Севастопольне забыт итүләре (яулап алулары.— Х. М.), Төркиянең Кара диңгез тарафыннан саклану вазгыятене авырайта. Русларга сугыш көймәләрене артдырырга имкян бирәдер. Шул куәткә таянып, (6) Русия бугазларны алуны көннең мәсьәләсе итеп куядыр.

Беренче Александр 1808 дә шул максад берлә Төркиягә каршы сугыш ачадыр. 1828 нче елны Русия хөкүмәте (Беренче Николай) Йунанстанга ярдәм итү сылтавы берлә тагы бер мәртәбә Төркиягә каршы сугыш ачадыр. Ләкин бу юлында да Истанбулга, бугазларга хуҗа булуга муаффәкъ (уңышлы, нәтиҗәле.— Х. М.) була алмыйдыр. 1855 нче елны беренче Николай Истанбулны, бугазларны алыр өчен икенче мәртәбә Төркиягә каршы сугыш ачадыр. Ләкин Төркия тарафыннан инглизләр, француздар да катышып, руслар бик каты җиңелеп калалар. Төрекләр иттифакчыларны (союзниклар.— Х. М.) берлә Кырымга керәләр, Севастопольне алалар. Русия бу җиңелүдән тик калмый. Болгарларга ярдәм сылтавы берлә 1877 дә Төркиягә каршы тагын сугыш ачадыр. Бу юлы рус гаскәре Әдирнәне (Төркиянең Европа өлешендәге шәһәре.— Х. М.) алып, Истанбулның әндәри төбенә (якынына?— Х. М.) — Яшел Күйгә (Аястафануска) кадәр килеп җитәдер. Ая-Суфиянын манарасына тагарга дип зур чиркәү кыңгыравы берлә Истанбулга керергә тырышалар, фәкать Төркиянең соңгы көчләре берлә бик каты Истанбулны саклауларына каршы бер эш дә эшли алмыйдыр. Рус гаскәре арыйдыр, аны хәстәлек басадыр, Аурупа дәүләтләре арага кереп, Болгарстанны төрекләрдән аерып, Берлинда солых ясаталар; рус гаскәре дә иленә кайтып китәдер. 1913 нче елны Русия Франса берлә аңлашып бетеп гаскәри иттифак ясап өлгергәч, бугаз-

ларны, Истанбулны алырга план корадыр. 1918 нче елны тәмам булырлык зур бер гаскәри план берлә якын киләчәкдә шул бугазларны кулда итү, Истанбулны алу сугышына хәзерлек башлыйлар. План хәзерләнеп бетмәс борын, 1914 нче елда беренче августда сугыш башланадыр. Төркия үзен битараф игълан итсә дә, аңарга каршы Русия бары бер сугышчы дәүләт кеби карап киләдер, Төркияне сугышдырыр өчен төрле-төрле хәйләләр эшлидер. Кара диңгезне үз ихтыярында гына кеби тотар өчен, Истанбул бугазы янына сугыш көймәләрен сакларга җибәрәдер. Алар берлә, төрек сугыш көймәләре чыгып йөрмәсен дип, Кара диңгезнең Истанбул бугазы тамагына миналар чәчәдер. Шул миналарны чәчкән чагында 28 октябрьдә Кара диңгездәге төрек сугыш көймәләре берлә бәрелешү ясап, беренче ноябрьдә Төркиягә сугыш игълан итәдер. Иттифакчылары Франса, Ингилтерә тарафындан Истанбулның Русиягә бирелүенә сүз аладыр. Истанбулны басып керер (7) өчен Одессада махсус йөз меңлек гаскәр хәзерлидер. Чәнак калга сугышларына катышыр өчен үзенең Балтыйк флотыннан берничә сугыш пароходын да күндерәдер. Һәм дә Кара диңгездә төрек вапурларының (судноларының.— Х. М.) йөрүе — килүенә зур комачаулык эшләп киләдер. Бу арада Русиядә сугыш башланып, Русия сугыш сафыннан чыккач гына Төркия ул тарафдан бераз киң сулыш аладыр. Русиянең һөҗүм планы, Петр васыятен тутыру тагын бер мәртәбә соңга калдырыладыр.

Совет хөкүмәте, башка эшләр берлә бик каты мәшгуль булганга, әүвәлге елларда Төркияне бу якдан тыныч калдырып торса да, бераз баш-күз алгач да, ул да Кара диңгез флотыны куәтләндерергә керешәдер. Төрле сылтаулар берлә Кара диңгезгә Балтыйкдан сугыш көймәләрен ташыйдыр; ул да бугазларны алуны максад итеп куядыр, Истанбулны кулда итәргә тырышадыр вә киләчәкдә дә тырышачакдыр.

Бер тарафдан Монтро могаһәдәсе берлә Төркиянең Аурупа дәүләтләре берлә багланышы бугазларның бәйнәлмиләл бер тәэминат астына алынуы, икенче җәһәтдән Совет Русиясенең дахили (эчке.— Х. М.) вазгыятенең бик чуалчыклыгы Совет Русиясенең бугазларны алып, Истанбулга хуҗа булуыны, бу көнләрнең вазыйфасы итеп куюдан озакдарак торуга мәҗбүр итәдер. Шуны аңлап Совет Русиясе, гүя, Төркиягә дуст кеби күренеп, хәйлә берлә, интрига берлә Төркиянең мәгънәвиятенә (рухи халәтен.— Х. М.) корып, хаким вазгыятьдә булырга, төрек милләтчелеген оетырга, йоклатырга тырышадыр. Фәкать бу асыл максаддан ваз кичү, Петрның васыятене ташлау түгелдер. **Русия, теләсә кызыл төсдә, ак төсдә, берләшкән зур бер дәүләт булып калганда тугрыдан-тугры Ак диңгезгә чыгар өчен, бугазларны, Истанбулны алыр өчен омтылачакдыр** (ассызык безнеке.— Х. М.) Берләшкән Русиянең (ягъни СССРның.— Х. М.) бу тарафка таба икътисадый, сәяси киңәюенә киртә булып торган Төрек хакимлегене уртадан калдырырга (алдырырга? — Х. М.) бөтен көче-куәте берлә тырышачакдыр. Төркиягә каршы ике йөз ел дәвам итдерелгән бу сәясәт рус империализмының анахаттый (төп, магистраль юнәлеш? — Х. М.) рәвешене алгандыр. Рус дәүләтенең идарәсенең төрле-төрле төскә әверелүе, мәмләкәтнең бер режимдан икенче режимга күчүе генә берләшкән Русиянең бу милли сәясәтен үзгәртә алмаячакдыр. **Русия тарафыннан бугазларның, Истанбулның әминияте** (иминлеге.— Х. М.), **Төркиянең үзенең бу йирләрдәге алты йөз еллык хакимиятенең тулы көенчә дәвам итдерелүе, рус империализмының кырылуы берлә генә тәэмин итәлә беләчәкдер. Бу да руслыкның истилясыннан** (басып алуыннан.— Х. И.) **(8) Украина, Кафкас, Кырым кеби Кара диңгез дәүләтләренең кортылып** (корылып.— Х. М.), **яңыдан үз милли истикъляларыны** (бәйсезлекләрене.— Х. М.) **кайтарулары берлә, үз башларына аерым милли дәүләтләр төзеп яшәүләрен тәэмин итү берлә генә мөмкин булачакдыр** (ассызык безнеке.— Х. М.).

Совет Русиясендәге хәрәкәтләрнең иң куәтлесе, иң җанлысы, руслыкдан сан ягыннан күп, мәдәният ягыннан өстен, вәхшилек ягыннан гына түбән торган гайре рус (рус булмаган.— Х. М.) милләтләрнең истикъляял хәрәкәтләре, үз мөкаддәратьләрен (язмышларын.— Х. М.) үз кулларына алу агымнары икәнен без белеп, күреп торганга, Кара диңгезнең бу милли дәүләтләренең бәгыс бәгъдәлмәүтләре дә (теләкләре, дәгъвалары; традицияләре — Х. М.) табигый рәвешдә мәйданга киләчәкдер. Табигый рәвешдә Төркиядә каршы ике йөз ел дәвам итдерелгән рус империализмы, Кара диңгез сахилендән (ярыннан.— Х. М.) кырылып, ватылып чигенергә мәҗбүр ителәчәкдер. Бондан соң гына бугазлар вә Истанбул да Төркия хакимияте тыныч бер тормышка кавышачакдыр. Бу көн озакда түгелдер. Монтро муаффәкъкыятен (уңышын.— Х. М.) бәйрәм иткән бүгенге төрек дөньясы озакламаенча бугазларның мәңгелек төрек кулында калу бәйрәмен дә итәчәкдер. Бу бәйрәмдә бүген Совет истилясының астында булган

безнең туган илләремез (ягъни Идел-Урал.— Х. М.). Кырым, Кафкасның, иттифакчымыз Украина, Гөрҗестанның кортылу бәйрәменә дә тәсадеф иткәнгә (катнашканга, очрашканга.— Х. М.), бу киләчәк бәйрәмнең нәшъәсе (барлыкка килүе.— Х. М.), таты тагын зурраграк булачак. Чыңгыз дәверендәге кеби милли төрек (төрки.— Х. М.) бәйрәме төсене алачакдыр. Бүген һәр йирдәге мөһаҗирлегемез, туганларымызның Монтро муаффәкыятьләрен бер җан, бер тән кеби бәйрәм иткәндә, бу бәйрәмнең тууына сәбәбче бугазлардагы сиксән мең төрек шәһиденең рухы алдында тез чүгәмез. Аларның олуг команданы, төрек (төрки) илләренең соңгы өлкәсенең истикъляльн алып калуны төреклек каһарманы Гази Мостафа Кәмал Пашага[1] төрек Тәнресендән озын еллар гомер теләп, төреклек хөрмәтләремезне, сәламнәрене сонамыз (җиткерәбез.— Х. М.)

**Гаяз ИСХАКЫЙ.**

*Текстны гарәп графикасыннан тиешле аңлатмалар белән хәзерге язуга күчереп, журналга филология фәннәре докторы Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ әзерләде.*

*20 февраль 1994 ел.*

---

[1] Гази Мостафа (1880—1938) — илнең беренче президенты (ул 1923—1938 елларда мәмләкәт белән идарә итә). 1934 елда Ататөрек кушаматын ала.

---

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

### Демьян Фәтхи

(1906—1943)

Татарстан Язучылар берлеге бинасында Ватан азатлыгы өчен гомерләрен биргән әдипләргә куелган мемориаль такта бар. Анда Демьян Фәтхи дигән шагыйрьнең дә исеме уеп язылган. Якты дөньяда нибары утыз җиде яшь яшәп киткән әдип заманында ялкынланып иҗат иткән, үз заманы кешеләре күңеленә шигърият нурын чәчкән, катлаулы заман карурманнарын адашмый чыгарга булышучыларның берсе булган. Безгә аңардан мирас булып «Тальян» (1929), «Бояр урманында» (1930), «Металл тавышлары» (1931) дигән китаплары, «Алтын тайга трагедиясеннән» исемле поэмасы һәм башка тезмә вә чәчмә әсәрләре калган. Шагыйрьнең сайланма шигырьләре, поэмалары һәм хикәяләре «Һәрвакыт сафта» (1970) исемле җыентыгында урын алган.

Демьян Фәтхи (Касыйм Фәтхетдин улы Фәтхетдинов) 1906 елның 10 октябрендә элекке Самара губернасы (хәзерге — Ульянов өлкәсе, Чардаклы районы) Татар Колмаеры авылында крестьян гаиләсендә туа. Самара (хәзерге Куйбышев) шәһәрендәге Татар-башкорт педагогия техникумында укыган чагында ук шигырьләр яза башлый. 1926 елда Казанга килеп, Татрабфакка укырга керә. Шул елларда беренче җыентыклары нәшер ителә.

Утызынчы ел урталарында яшь шагыйрь Ерак Көнчыгышка китә. Анда сигез елга якын гади эшче, берочтан иҗат эшен дә дәвам итә. Ул алтын рудникларында эшләүче татарлар тормышын, революция җилләре китергән кискен үзгәрешләрне Себер табигате фонында сурәтли. «Алтын тайга трагедиясеннән» (1939—1940) поэмасы шул елларда языла һәм Демьян Фәтхи иҗатында күренекле урын били.

Сугыш алдыннан Демьян Фәтхи Татарстанга кайта, Зеленодол шәһәрендә гади эшче булып эшли. 1941 елда ул фронтка китә, Сталинград янындагы сугышларда катнаша, берничә тапкыр яралана. 1943 елны Кантемирово (Воронеж өлкәсе) янындагы каты сугышлар вакытында солдат-шагыйрь батырларча һәлак була.

Демьян Фәтхи — үзенең кыска гына иҗат гомерендә халкыбызга үз чоры кешеләренең каршылыклы-катлаулы образларын чагылдырган асыл әсәрләр иҗат итеп калдырган әдипләребезнең берсе.

## Индус Сирматов

# БЕР ДӘФТӘР МОҢ...

Бөек шагыйребез Габдулла Тукайның халык җырларын күңелебезнең бер дә тутыкмас һәм күгәрмәс рәүшан көзгеседер дип санавы хакында фәлсәфәгә бирелә башласаң, тиз генә тукталып та булмас кебек. Чөнки җырлар халкыбыз тормышына шулкадәр тирәнтен үтеп кергән; алар аның тарихын да, бүгенгесен дә, киләчәккә өметләрен һәм үткәндәге казанышларын да, заманның бер мизгелендә кешенең ни халәттә булуын да, халыкның тапкырлыгын һәм җорлыгын да — гомумән, тагын күп сыйфат һәм халәтен дә чагылдыра. Һәр халыкның җырлары аша шушы халыкның, кем әйтмешли, үз биографиясен дә өйрәнергә була.

Болар турында күп язылды, күп әйтелде. Әмма әлегә чаклы, барыбер, Тукай кебек өздереп, нәкъ өстенә бастырып берәүнең дә әйтә алганы юк.

Шуңа күрә бу язмамда мин дә халык җырларын бәяләп утыру максатын куймадым. Сүз башкарак ызанда булыр.

Минем кулымда 128 битле дәфтәр. Әлбәттә, кульязма дәфтәр. Монда 1942 елның 7 июненә кадәр латин хәрефләре белән, аннан соң кириллица белән язылып, һәрберсенә исәп саны куеп барылган 1776 дүртьюллык җыр куплетлары тупланган. Дөрес, 168 битлек дәфтәрнең алдагы 40 бите югалган — шуңа күрә хәзер инде без 238 куплетны укый алмыйбыз. Ул югары куплетларда ниләр булгандыр, ә менә исән сакланган 1538 куплетны укып чыккач та күңелгә «бер дәфтәр моң икән бу» дигән уй килде. Әлбәттә, моңны дәфтәрләп үлчәп булмаганын һәркем аңлый. Үзем дә беләм. Әмма кем дә булса бу дәфтәр белән танышса, ул да шундыйрак фикергә килер иде, мөгаен.

Бу юлларны укыгач, «Нинди дәфтәр соң ул, нигә әйтмисең, ник ялындырасың?» дияргә ашыкмагыз. Сабыр әйлән! Хәзер нәкъ шул турыда язарга җыенам.

...Шулай бер мәлне Татарстан телевидениесендә атна саен «Җомга көн кич белән» дип исемләнгән әдәбият-сәнгать альманахы чыгара башладык. Мактану түгел, беренче чыгарылышларыннан ук телевизор караучыларга бик ошап китте бу. Шулай булмаска, һәр очрашуга республиканың күренекле язучыларын, галимнәрен, композиторларын, рәссамнарын, артистларын чакырабыз бит!

Әдәбият-сәнгать турында да, халкыбыз тарихы турында да, әхлак турында да сөйләшәбез һәм телевидение тарихында булмаган хәл — дин мәсьәләләрен дә иркен күтәрәбез. Гадәттә, телевидение тапшыруларының һәрберсе аерым бер аудитория өчен, аерым бер яшьтәге кешеләр өчен булса, «Җомга» очрашуларыннан исә һәркем үзенә ниндидер күләмдә рухи азык ала. Шуңадыр, беренче тапшырудан соң ук редакциягә дистәләп-дистәләп хатлар килә башлады.

Рәхмәт, хезмәтебезгә бәя бирәләр. Тагын да рәхмәт, хатлар арасында бандерольләр дә күренә башлады.

Менә шундый бандерольләрнең берсе 1991 елның гыйнварында Краснодар краеның Каневски станциясеннән (бәлки «станица»дыр) килеп төште.

Җибәрүчесе — азык комбинатында 25 ел лаборант булып эшләгән, хөкүмәт бүләкләренә лаек булган ветеран Гөлмәрьям ханым Җиһангирова. Гөлмәрьям ханымга ихтирам һәм рәхмәт йөзеннән хатының эчтәлегеннән кайбер сөземтәләр белән таныштырам.

Аның ире Хәмзә Сәлимҗан улы Җиһангиров 1921 елда Шөгер районының Чыршылы авылында туган. Икесенең дә иң матур яшь чаклары Бөгелмә як-

ларында үткән. Хәмзә егет вакытыннан ук гармунда бик оста уйнаган, халык җырларын җыеп һәм язып барырга яраткан. Сугыш һәм хезмәт ветераны, күп кенә орден һәм медальләр иясе Хәмзә Сәлимҗан улы вафат булганчыга кадәр алар шулай — берсе гармун уйнап, икенчесе җырлап, 42 ел гомер иткәннәр.

Туган якларына кунакка кайткач, телевизордан «Җомга көн кич белән» альманахының берничә чыгарылышын караганнан соң Гөлмәрьям ханым кадерле истәлеген — Хәмзә агай җыеп язып барган менә шушы җырлар дәфтәрен безгә җибәрергә булган. «Хәмзәнең яшь чагында язган җырларын җырлагыз. Матур җырлары бик күп. Мөмкин булса, рәсемен дә телевизордан күрсәтегез».

Әнә шундый олы бүләк һәм никадәр тыйнак үтенеч! Татар халкының иң күркәм сыйфатларыннан берсе чагыла түгелме?! Нәкъ үзе — җибәргән җырлардагы сыйфатларның берсе.

Инде дәфтәрнең үзенә, моң дәфтәренә кайтыйк. Җырларның язылу көннәре дә куелып барылган бу дәфтәрдә: беренче көн — 1939 елның 24 марты, соңгысы — 1944 елның 30 гыйнвары. Хәмзә агай, әлбәттә, моның белән генә тукталмаган. Чөнки дәфтәрдәге соңгы җөмлә — «продолжение следует». Әмма автор хезмәтенең ахыры белән танышу әлегә миңа насыйп булмады, бәлки булмас та. Шуңа күрә, насыйп булганына канәгатьлек кылып, мең ярымнан артык куплет арасына кереп чумыйк әле.

Дөресен әйткәндә, ничек тиз чумсаң, шулай тиз калкып чыгарга да мөмкин. Чөнки җырларның баштан алып ахырына кадәр барсы да — мәхәббәт җырлары. Хәер, мәхәббәт диңгезенә бер төшеп батсаң, тиз генә чыгармын димә. Мондагы бер дәфтәр моң дигәнем дә — бер диңгез моң икән ләбаса. Мәхәббәт диңгезе исә моңландыра да, сызландыра да бит ул!

Хыяллан, хыяллан, ди күңел. Мәхәббәт хыяллары өчен берәү дә гаепләмәс, дип өстәп куя.

Сузма, сузма, дәфтәргә күч, ди акыл. Акылны тыңлыйк.

Дәфтәрдәге 1538 җыр куплеты арасында бик күпләргә таныш, төрле китапҗыентыкларда басылып чыккан, хәзер дә җырлана торганнары да бар. Моңа чаклы мин укымаган, ишетмәгәннәре дә очрап куя. Бу, әлбәттә, башкалар да белми торгандыр, дигән сүз түгел. Мин үземнән генә чыгып әйтәм. Ә кайберләре бәлки хәзер инде чынлап та онытыла башлагандыр...

Бөдрә йонлы юрга атым,
Бөдрә яллы туры атым.
Күз алдымда тотар идем
Син җаныйның сурәтен.

Кара киям, кара салам,
Кара куренмәм микән.
Утын бирдең, бир суын да —
Азрак сүрелмәм микән.

Иртә торып битем югач,
Барып карыйм көзгегә.
Сипарат сөтләре кебек
Аердылар безне дә.

Күгәрченнәр күп монда,
Ак төслесе юк монда.
Кеше ярлары күп монда
Безнең ярлар юк монда.

Тәрәзә төбем гөлсирин,
Сындырма гөлсиринне.
Башы сынган, тамры корган
Гөлләр иттең син мине.

Ян тәрәзә төпләренә
Гөл сулары түгелгән.
Югалдың син күз алдымнан,
Югалмыйсың күңелдән.

Мәк чәчәге матур диләр,
Юк бит мәк орлыкларым.
Сабыр кешеләр саргаймый,
Юк бит сабырлыкларым.

Нинди матур җырлар! Үзеңнең беренче тапкыр гашыйк булганыңны искә төшер дә, шушы куплетларны җырлап җибәр әле. Биллаһи, 20—30 елга яшәреп китәрсең. Күбрәккә булмаса әле! Йә булмаса, җавапсыз калган мәхәббәт турында уйлаганда:

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре «уел».
Тыңламыйм күке тавышын,
Мин үзем күке быел.

Бу куплетларны укыдым да, гомеремә бәхетле минутлар өстәдем. Әгәр ишеткәнегез булмаса, сезнең дә бәхетле мизгелләрегез артсын!

Моңа чаклы үземә таныш булмаган куплетлар арасында хан заманында җырланган җырлар да бар икән әле. Укып карагыз, сезнең ишеткәнегез бар идеме? Җыры иске булса да, хисегез яңарыр. Чөнки, мәхәббәт ул үзе иске нәрсә булса да, һәрбер йөрәк аны яңарта, дип раслый түгелме соң шагыйрь.

Язган хаттагы сүзләрең
Укыр вакыт күңелем шат итә.
Янә җавап язмыйммы дип
Фикерем көн-төн йад итә.

Бу дәфтәрдә борынгылар рәтендә саналырлык һәм халкыбызга кире кайтарып бирелергә тиешле куплетлар да байтак икән:

Иртән торып тышка чыксам,
Азан әйтә гаеткә,
Бер-ике җыр язып бирәм,
Алмасаң, дус, гаепкә.

Азан турында җыр чыгару түгел, азанның үзен дә ишетми яшәвебезгә 70-80 ел тулуын искә алсак, әлеге җырның «туган елы» үткән гасырга ук барып тоташа, дип раслау ялгыш булмас бит? Җитмәсә, әле стиле дә җәдит мәдрәсәләре шәкертләренең стилен хәтерләтә.

Чинаякта ак энҗеләр,
Ефәк кирәк тезәргә...

Хәзерге заманда энҗене ефәк җепкә түгел, капрон җепкә генә тезү турында сүз бара ала. Ә инде бу гасырның 20—70 елларында ефәк җепләргә тезәрлек энҗеләр, ай-һай, кемдә генә булды икән?! Димәк, җыр чыгарылу вакытын да борынгырак дәверләргә чигерергә туры килә. Һәрхәлдә, җыр соңрак заманда чыгарылган булса да, аның рухында борынгылык аңкып тора.

Ак бияләй эчләрендә
Алмаз йөзек шәүләсе...

Каеш йөгәндә алты чук,
Алтысы да алтын чук...

Алтын алка авыр тарта,
Алты мыскалдан арта...—

дип башлана торган куплетлар да рәхәтләнеп борынгылыкны дәгъвалый ала.

Алтын да гына ияр, мамык мендәр,
Дүрт читендә ука чугы бар;
Күрер өчен сагынып килгән ярны,
Өзелеп сөйсәң, каршы чыгып ал.

Ап-ак, ап-ак кигән калфак,
Яка чылбыр муйнында,
Яка чылбыр кигән кызның
Йоклар идем куйнында.

Бара торгачтын утырдым
Бәдиан төпләренә,
Әнекәем бәхил булсын
Имезгән сөтләренә.

Карчыга ла оча канат кагып,
Канаткайларыннан кан тамып,
Ир балакай, мескен, тормыш итә
Ата-анасыннан яшь калып.

Алып бирим талир тәңкә,
Так толымнарыңа пар итеп,
Ал кулыңа, җаный, сал куеныңа
Гомерлеккә генә яр итеп.

Карамакай дуга, кара юрга,
Кайдан гына алдың бу атны?
Бик сагынып, җанкай, бик саргаеп,
Сиңа гына яздым бу хатны.

Күгәреп лә яткан, әй, тау микән,
Әйләнеп лә яткан яу микән?
Сайрасана, сары сандугачым,
Безнең туган илләр сау микән?

Сыгылып-сыгылып елыйм бәхетем юкка,
Кан тамадыр бәхтем беткәнгә,
Капкан ашым миндә зәһәр була
Гомерләрем бушка үткәнгә.

Болары инде — борынгылыкларына һич шик калдырмый торган җырлар. Кайсыларында көнкүреш элементлары, кайсыларында сөйләм тел нормалары, кайсының стиле шуны раслап тора.

Хәер, мин монда аларның борынгылыгын дәлилләү бурычын куймадым бит әле. Искәртәсе килгәнем — кешелек яшәешенең төрле дәверләрендә халкыбызның рухи халәтен чагылдырган авыз иҗаты әсәрләрен түкми-чәчми җыеп калу зарурлыгы. Ярый ла Хәмзә агайның бер дәфтәре алла ризалыгы белән безнең кулга килеп керде (ул Татарстан фәннәр Академиясе фондына тапшырылачак), ә бит әле бер дәфтәргә дә теркәлмәгән һәм хәзер инде рәтләп җырланмый да торган, онытылуга дучар ителгән җырлар бихисап. Тизрәк шуларны туплап каласы иде.

Дәфтәрне укып чыккач, халык җырларының бер характерлы үзенчәлеге турында Тукай әйтеп калдырган бер фикер искә төште. Бу — куплетның беренче ике юлында нәрсә дә булса турында җырланып, соңгы ике юлы бөтенләй көтелмәгән, колагыңны торгыза торган юллар булуы. Чынлап та: бөтен дәфтәр шундый җырлар белән тулы диярлек. Шулай да арада баштан ахырга кадәр бер фикер дәвам итә торганнары да юк түгел.

Күзләремне, күзләремне
Күзләремне күзлисең.
Минем моңсу күзләремнән
Нинди серләр эзлисең?

Күзләренне, күзләренне,
Күзләреңне күзләдем.
Күзләреңнән серләр алдым,
Син бет шуны белмәдең.

Күзләремә туры карап
Күзләремне күзләмә.
Минем күзем — серле диңгез,
Аннан серләр эзләмә.

Халык җырлары текстында тагын бер үзенчәлекне күзәткәнегез бардыр. Бу — җыр куплетының беренче өлешендәге сүзләрнең тулысынча кабатланып, ә икенче яртысының аерылып торуы. Ә инде киресенчә, ягъни куплетларның баш өлеше башкача булып та, ахырлары бертөрлерәк булганнарын очратканым юк иде. Монда очраттым.

Агыйделдән су алганда
Төшеп китте чиләгем.
Төнлә төшләремдә күреп,
Серләремне сөйләдем.

Алмагачтан алма алып
Савытларга өләштем.
Төнлә төшләремдә күреп,
Синең белән сөйләштем.

Төрле куплетлардагы фикерләрнең яңарак вариантта әнә шулайрак кабатлануы башкаручыларның төрле төбәктән булуыннан, яки бер төбәктән булып та, бер җырчының башкаруын икенчесе ошатып бетермәвеннән, яки аны камилләштерергә теләвеннән килә торгандыр, мөгаен.

Әйе, халык — ирекле, үзенә ничек уңай булса, шулай җырлый. Менә мәсәлән:

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме Мөкаррәмә,
Авыр сүзләр әйткәнмендер,
Дускаем, үпкәләмә.

Һәм аңа охшаш:

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Рәхилә.
Авыр сүзләр әйткәнмендер,
Җаныкаем, бәхиллә.

Янсә икенче пар:

Алсу гөлем, алсу гөлем,
Алсу гөлләрем сиңа,
Алсу гөлем, керсез күңлем
Мәңгегә булсын сиңа.

һәм:

Алсу гөлем, алсу гөлем
Алсу гөлләрем сиңа.
Алсу гөлем, саф күңелем
Бүләк итәрмен сиңа.

Бер җырның ике варианты, дигәннән, халык авыз иҗатында вариантлар тулып кына тора торгандыр, ахырысы. Хәер, гаҗәпләнер урын бармыни! «Йосыф кыйссасы»ның, «Бакырган», «Бәдәвам» китапларының, «Нанас», «Идегәй» дастаннарының да аерым куплетларының вариантлары әледән-әле табылып тора түгелме!

Төрле авылларда төрлечә җырланган җырларны Хәмзә агай үзенчә язып барган икән — аңа Ходай үзе кушкан инде.

Җыр һәм бию ансамбленең яки үзешчән коллективларның репертуарларында әле хәзер дә рәхәтләнеп башкарыла торган «Җырлыйк әле» җырлар тезмәсен генә алыйк. Нигездә, бу җыр уникe куплет белән башкарыла. Шаянрак егетләр-кызлар егермедән арттырып җибәргәннәрен дә ишеткәнем бар. Репертуарларда һәм җыентыкларда, мәсәлән, алтынчы куплет болай бирелә:

Жырлыйк әле, жырлыйк әле,
Жырлыйк әле алтыны,
Жырламас идек алтыны —
Бүген бездә ял көне.

Хәмзә Җиһангиров дәфтәрендә исә күмәклек рухы түгел, ә аерым бер кешенең шәхси кичерешләре чагылдырылган вариант бар:

Жырлыйм әле, жырлыйм әле,
Жырлыйм әле алтыны,
Һаваларда оча инде
Йөрәгемнең ялкыны.

Уникенче куплет белән дә нәкъ шундый хәл. Китапларда:

Жырлыйк әле, жырлыйк әле,
Уникегә тулганчы,
Уникеләргә тулганчы,
Дуслар күңле булганчы.

Хәмзә Җиһангировта:

Жырлыйм әле, жырлыйм әле,
Уникеләр тулганчы,
Их, бер күреп сөйләшергә
Күңелләрем булганчы.

Кайсы вариант уңышлырак, дигән сорауны куясы да юк. Беренчесе — зал тулы концертларда, мәҗлесләрдә, кичке уеннарда күмәкләп башкарырга кулай булса, икенчесе исә (шул ук урыннарда булса да) аерым жырчы-солист башкаруына көйләнгән.

Хәмзә агайның башка куплетлары белән танышканда да мин шундыйрак күренешне күзәттем. Димәк, ул әлеге жырларны шәхсән үз йөрәге, үз күңеле аша үткәргән, аларның халык жыры булуы турында уйлап тормыйча, үзенеке дип тә кабул иткән.

Күпләрегезнең ишеткәне, үзегезнең жырлаганы бардыр, һәрхәлдә, безнең якта менә бу куплетны болай жырлыйлар иде:

Сөйдем инде, сөйдердем дә,
Инде сөймим кемне дә.
Яшьлек юләрлегем белән
Генә сөйдем сине дә.

Хәмзә агай варианты исә менә мондый:

Сөеп икене сайладым,
Хәзер сөймим берне дә,
Бәлки яшьлекләрем белән
Сөйгәнмендер сине дә.

Без яшь чакта галәмәт тә хисләргә бирелеп болай жырлый идек:

Алма битем, нихәл итим,
Каласың бит ятларга.
Ятлар булмас минем кебек
Салыр янган утларга.

Хәмзә агай исә егет чагында башкачарак жырлаган икән.

Жаныкаем, гөлкәем,
Каласың бит ятларга,
Ятлар минем кебек булмас,
Салыр янган утларга.

Әллә яшьтән үк күңелгә сеңеп калганга, әллә башка сәбәптән, безнең як вариантлары уңышлырак, отышлырак, хисләрне тулырак ачып сала төсле. Исән булып, Хәмзә агайдан сорасаң, ул да үзенекен өстенрәк куяр иде дип уйлыйм. Чөнки ул да үзенчә ишеткән, үзенчә жырлаган, дәфтәренә дә үзенчә теркәп куйган.

Безнең халыкта иң күп таралган җырлар Агыйделгә һәм сандугачка бәйле. Моннан берничә ел элек бер-бер артлы нәшер ителгән «Агыйделкәй» һәм «Сандугачым-былбылым» дигән сувенир китаплары да шуны раслый. Ул чагында без барыбыз да һәр куплеты «Агыйдел» һәм «Сандугач» сүзләре белән башланган җырларның шулкадәр күп булуына шаккаткан идек. Бу сүзләр куплет уртасында булганнары әле тагын күпме! Хәзер шикләнәм, әлеге җыентыкларга халык арасында йөри торган «Сандугач» һәм «Агыйдел» сүзләре белән башланган куплетларның да яртысы тупланмагандыр. (Мин моны китапны төзүченең кимчелеге дип санаганнан түгел, әнә шундый җырларның никадәр күп булуына хәйран калуымнан язам). Шулайдыр, шулайдыр. Хәмзә агай дәфтәрендә генә дә әлеге җыентыкларда урын алмаган дистәләрчә (!) куплетлар очраттым. Халык арасында андый дәфтәрләр тагын күпмедер дә, дәфтәрләргә теркәлмәгән җырлар күпмедер!

Агыйделкәйләрнең балыгы уяу,
Акчарлаклар тибеп алалмый.
Сөямен дә генәй, сөям, дигән чакта
Күз яшьләрен тыеп калалмый.

Агыйделнең аръягында
Йөри колхоз куйлары.
Без киткәндә кечкенә иде,
Үскән зифа буйлары.

Агыйделне иңләп-буйлап
Киләләр гармун уйнап.
Җилләр исә, тал бөгелә,
Мин бөгеләм сине уйлап.

Агыйделгә басма салдым
Өч багана, өч киртә.
Чит илләрнең шунсы кыен —
Сагындыра кич-иртә.

Икенче бер җыентыкка «Сандугач» сүзе белән башланган җырлар тупланган булуын һәм Хәмзә агай дәфтәрендә бу җыентыкка керми калган андый җырлар күп булуын әйттем. Аларны укыгач ясалган нәтиҗәләр дә, нигездә Агыйделнекеләр белән туры килгәнгә кабатлап тормыйм. Китапта урын ала алмаган берничә куплет белән генә таныштырам:

Сандугачым сайрасаң да,
Өзәм бер чәчәгенне.
Белсәң иде киләчәктә
Ниләр күрәчәгеңне.

Сандугачлар басып сайрый
Кызыл гөлне яратып.
Төннәр буе мин йөримен
Синең өчен, җан атып.

Сандугачым, сайрар булсаң,
Сәхрәдә тал әзерлә.
Аерылышкан кошлар ничек,
Без дә шулай хәзергә.

Сандугач баласын тоттым,
Урман араларыннан.
Синең хәлләреңне сорыйм
Былбыл балаларыннан. һ. б., һ. б.

Шундый куплетларны укыгач, ничек моңланмыйсың да, вакыт тәэсиреннән саргая башлаган дәфтәргә карап, ничек аны моң дәфтәре дип атамыйсың.

Хәер, гел моңга гына кайтарып калдырсак, бик үк хаклы да булмассың. Чөнки дәфтәрдәге язмалар тагын кайбер нәрсәләргә игътибар итүне сорыйлар икән әле.

Беренчесе — куплетларда заман рухы чагылышы. Аңысына кыскача гына тукталам. Тормышыбызга индустриализация, урбанизация һәм башка төрле «зация»ләр тирәнрәк үтеп керә башлагач, шул шаукымга һәм модага ияреп, 30 нчы елларда татар балаларына әллә ниткән исемнәр кушып бетерүләреннән хәзер рәхәтләнеп көләбезме? Көләбез һәм урынлы көләбез. Бу шаукым халык җырларында да чагылыш тапкан, тарихыбыз шаһиты булып хәзер дә ишетелгәләп куя.

Колхоз басуына барып,
Трактор көйлисеңме?
Сөям, җаныем, ташлама, дип,
Син дөрес сөйлисеңме?

Безнең турда идарәдә
Радио тыңлыйлар,
Сезнең белән бергә булган
Минутлар онтылмыйлар.

Аклы ситса күлмәгемнең
Пояслары бер метр.

Иркәм-бәгърем, дигәннәргә
Серләреңне бирми тор.

Кооперативның ишеген
Яшелгә буйталар,
Таң алдыннан сандугачлар
Син булып уйталар.

Лампочкалар якты яна
Коридор алларында.
Икәү бергә булсак иде
Дошман күз алларында.

Әйе шул, шулай шул: сөю-мәхәббәт белән тракторларны, лампочкаларны, кооператив ишекләрен, пароходларны, автомобильләрне бер казанга салып бол-

гату безнең татар кулыннан гына килә торган эш ул! «Олы абыйга» атап пешергән боткам тәмле булсын дип!

Китәм иркәм, китәм иркәм,
Китәм иркәм Бакуга...

Ансы да дөрес. Татар Бакуга нефть чыгарырга да китте, Донбаска күмер казырга да кузгалды. Березникида химия заводы төзеп тә дан алды... Авыллар кешесез калды. Шөкер, әле истәлеккә җырлары калган икән.

Бу эшләргә каян өйрәндек дисезме? Хәмзә агай ансына да җыр белән җавап бирә:

Аллы-гөлле чәчәк җыям
Тауның итәкләрендә.
Шатланышып без укыйбыз
Совет мәктәпләрендә.

Җилләр чыкса, җил очыра
Агыйделнең комнарын.
Көндәлек эш итеп укыйм
Ленин бабай томнарын.

«Көлмә кешедән, авызың өшегән» диләрме әле. Ярый әле без кешедән көлмибез, үзебездән-үзебез көләбез. Өстенлегебез шунда.

Игътибарны җәлеп иткән нәрсәләрнең икенчесе — халкыбызның сюжетлы җырлары. Монда алар тулы текст белән түгел, ә аерым куплетлар рәвешендә нумерлап бирелгән. Димәк, бер үлчәмдә иҗат ителгән төрле сюжетлы җырларның аерым куплетларын кайбер урыннарда бер көйгә, әйтик, «Урам көенә», «Авыл көенә» һ. б. җырлап йөрү гадәте дә булган. Андый очракларны мин үзем дә хәтерлим.

Шулай булмаса, дәфтәрне язучы сюжетны «ботарлап» тормас иде.

Куплетлар арасында мин «Мәрфуга», «Көймә килә», «Кара урман», «Фирдәвескәй», «Күк күгәрчен», «Рәйхан», «Җаныем-бәгърем», «Нурия», «Күбәләгем-түгәрәгем» кебек һ. б. сюжетлы җырларның аерым өзекләрен һәм вариантларын да очраттым.

Өченче бер нәрсә — авторлар иҗат иткән җырларның халык җырлары белән янәшә йөрүе. Мондыйлар арасында төрле музыкалы спектакльләрдә җырлана торганнары да, җыр итеп махсус иҗат ителгәннәре дә, композиторлар көй язганнары да, халык үзе көй чыгарганнары да бар. Болар, беренчедән, аерым авторларның халык җырына әйләнерлек уңышлы әсәрләр иҗат итүе турында сөйләсә, икенчедән, авторларның үз әсәрләрендә халык авыз иҗатыннан шактый отышлы файдалануларын дәлилли.

Таң алдында уянырмын,
Җилкәңә шәл салырмын.
Таң шикелле иртән кайтыр булсаң,
Каршы чыгып алырмын.

*(М. Җәлил сүзләре, З. Хәбибуллин музыкасы. «Сагыну» җырыннан вариант).*

Алтын минем туган илем,
Көмеш телле гармуным.
Гармун җырлый яшьлегемнең
Бар шатлыгын, бар моңын.

*(Ә. Ерикәй сүзләре, Җ. Фәйзи музыкасы. «Гармун» җырыннан.)*

Дәфтәрне укыганнан соң күңелгә килгән барлык уйларны да кәгазьгә күчерергә теләсәң, әле тагын бик озак дәвам итәргә булыр иде. Мондый язмаларны башлавы җиңел, тукталуы авыр — аерыласы килми. Ләкин укучының түземлелеге белән дә исәпләшергә кирәк. Әйдә, бу язмага сыймый калган хисләрем моң булып үз күңелемдә дәвам итсен. Халкыбызның җыр мирасы — чын-чынлап, мәңге кимемәс моң бит ул!

# Җомга намазы вәгазендә — «Казан утлары»

Җомга намазына җыелган халык ахырдан нинди дә булса темага вәгазь укылганын белә торгандыр инде. Чөнки һәр заманның сәясәте дини кануннар белән нытытылганда гына кешедә дәрт, инану барлыкка килә.

Җае чыккан саен вәгазьдә мин дә «Казан утлары» журналында чыккан әсәрләрне файдаланырга омтылам. Дөрес, иң элек бу хакта авылыбызда мулла вазифаларын алып баручы Исламгали бабай белән киңәшләшәм, шуннан соң бергәләшеп вәгазьнең темасын ачыклыйбыз. Соңгы вакытта без, мәсәлән, язучы Ринат Мөхәммәдиевның быел бишенче-алтынчы саннарда чыккан «Утлы таба өстендә» дигән бүгенге көн романына тукталдык...

Ниһаять, мин — вәгазьче. Укыйм. Үзем күзәтәм: тыңлаучыларымның кайсысына нинди тәэсир ясала?

«...Мөфти һәм аның ярдәмчеләре өстендә Диния нәзарәтенең махсус эмблемалары төшерелгән яшел чапан, башларында затлы чалма-бүрекләр. Капкадан тикшереп үткәрүчеләр булсын, Кремльнең Зур сараена кергәндә булсын, аларга шактый гаҗәпләнеп һәм күрәсең, шикләнеп тә карадылар. Яшерен-батырын түгел, үзем дә Тәлгать Таҗетдинне әлеге киемдә тәү кабат күрдем. Алар үтеп киткәндә һәркемнең гаҗәпсенеп күзәтеп калуы күңелдә яшерен бер горурлык хисе дә уятты әле хәтта... Күрсеннәр, танысыннар — безнекеләр уза иң. Затлы төсләр, зәвыклы киемнәр. Ул буй, төс-кыяфәт дисеңме. Бирсә — бирә бит ул Аллаһы Тәгалә...»

Тыңлаучыларым тураеп, арык күкрәкләрен киергәндәй итсәләр, яшьле күзләрендә — горурлык чаткылары. Ә мин аларга ирек бирәм: пауза ясап алам һәм укуымны дәвам итәм:

«...Киң мәрмәр баскычлар буйлап икенче катка күтәрелдек, патшалар тантана иткән алтын сарай заллары аша уздык. Әллә ничәшәр Георгий тәреләре тагылган җансыз сыннар торып калды. Ә без бер ташкын, яшел җил сыман дип әйтимме, әллә яшел дулкынны хәтерләтепме, алга уздык. Уңга-сулга карау юк. Кая инде ул, аяклар югары, сакал үрә тора, борыннар тәз, карашлар алга, бары тик алга төбәлгән. Ян-якка сибелеп юл ачалар безгә. Мөфтинең кодрәте чиксез...»

Тукталып алам, һәркемнең күз алларына бу мәһабәт күренешне китерүләре өчен ирек куям. Хәйран калуларын белдереп, башлар чайкала, тыңлаганда кыймшанусыз калган куллар, аяклар хәрәкәтләнеп куялар. Тоеп торам: укыганым һәркем күңеленә тирән сеңә бара.

«...Без тоташ бәллүр һәм көзгеләрдән генә гыйбарәт, Кремль сараеның да йөзек кашы булып торган, Екатерина исемен йөрткән залга килеп кердек. Залның нәкъ уртасында торган яшел өстәлнең түрендәге затлы кәнәфигә килеп утырды мөфти.

— Көтәм, — диде һәм сәгатькә карап куйды.

Аның үз-үзен шул дәрәҗәдә горур, иркен тотуы таң калдырды минс. Шушы сарай һәм заллар буенча инде ун-унбиш көн йөрибез югыйсә, ә тартыну һәм мокытлыктан котыла алган юк. Күпме генә үзләштем дисәң дә, юк-юк та баш иелә, гел уйламаган бер җирдә тез чүгеп куя.

Съездда тәнәфес вакыты иде. Дөресрәге, ул инде тәмамланып килә. Ельцинны Президиум бүлмәсенә узган, дидeләр.

Кердем. Әмма янына якын килерлек түгел. Яраннары һәм ярарга тырышып йөрүчеләр урап алган үзен. Югыйсә, теләсә кемне уздырмыйлар монда, журналистларга да юл ябык.

Ельцинның якыннарыннан Виктор Илюшин янына килдем. Йомышымны сөйләдем. Башын гына чайкады.

— Үзең уйлап кара. Ике-өч минуттан съезд дәвам итәчәк. Хәл итәсе мәсьәләләр муеннан. Ул аерыла алмый хәзер.

Үзем дә шулайрак уйлыйм уйлавын. Өмет юк. Әмма мөфти бик тә кызу бит анда. Аңарга ничек аңлатырмын? Башымны калкытып, Ельцинга таба текәлдем шунда».

Тыңлаучыларыма карап алам. Үземнән өстәп куям: «Менә бит Ходай Тәгалә ничек эшкәртә?!»

«Сөйләшеп торган җиреннән, үзен уратып алган кешеләрнең башлары өстеннән ул да, ничектер, мин басып торган тарафка карап куйды. Очраклы рәвештә караш-ларыбыз кисеште».

Үзем тыңлаучыларыбызны күзәтәм, сүз дә кыстырып алам: «Ходай Тәгалә кушканга, билгеле, дим».

«...Һәм, мине сәламләп, кулын күтәрде ул. Мин аңарга таба тартылып куйдым. Үзен уратып торган кешеләрне аралап, күрешергә кулын сузып, миңа таба килде Россия Югары Советы Рәисе».

Аллаһы Тәгаләнең кодрәте белән аларның күрешүләре, мөфти белән сөйләшүлә-ре турында укыганда безнең күңелләр тетрәнеп торды. Урыс патшасының йөрәгендә миһербанлык уянып, изге юлда йөргән мөфтиебезгә, хаҗга баручы өч йөз мөселман-га булышуын теләдек. Хак Тәгалә, Синең ярдәмең, Синең кодрәтең чиксез — нинди генә каршылыклар булса да, юк очкычларны бар иттертә, юк долларларны таптыр-та, киртә коручыларны урыннарыннан «очырттыра» аласың Син!

Тыңлаучыларымның йөзләре якты, күзләрендә — шатлык яшьләре... Бабайлар тәмам әсәрләнгән иделәр.

«Мөфти Тәлгать Таҗетдин җитәкчелегендә ике «ТУ-154» самолеты билгеләнгән вакытта Гарәбстан тарафларына «Шереметьево-2» һава аланыннан күтәрелеп юл тотты. Доллар да табылган иде... Ул заманнар өчен кеше башына мең долларның ни булуын хәзер аңлау да җиңел түгел. Бик зур акча иде ул.

Ә Россия халык депутатлары съездында игълан ителгән тәнәфес ул чакта төгәл унбиш минутка озынгарак сузылды. Моны күпләр абайламый да калды бугай. Дөнья кадәр эш эшләнде».

Әйе, бу «вәгазь» аша да дөнья кадәр бик зур эш эшләнде. Менә Ходайның хикмәте, әсәрнең кодрәте ничек!

Әнвәр НИЗАМЕТДИНОВ,
Башкортостан, Туймазы районы, Югары Бишенде авылы.

## Дуслашып өлгердем

Көннәрдән беркөнне: «Күңелемә рухи азык булырдай берәр газета-журнал-га язылыйм әле», — дип элемтә бүлегенә кергән идем. Каталогтан эзли торгач, «Казан утлары» дигән журналга күзем төште. Үзе саф татар телендә чыга, хакы да бик кыйммәт түгел икән. Тоттым да шул журналга язылдым.

Шулай да күңел бераз шикләнеп куйган иде: «Журнал Казанда басылгач, безгә — Башкортостанга үз вакытында килеп торырмы икән? Әллә бу адымым акчамны җилгә очыру гына булырмы? Заманалары бигрәк буталчык бит...»

Бәхеткә, барысы да киресенчә килеп чыкты. «Казан утлары» өебезгә вакытында Кояштай балкып килеп керә, күңелләребезне җылыта, аңнарыбызны баета, кызык-лы-гыйбрәтле бихисап әсәрләр, яңа авторлар белән таныштыра. Иң мөһиме: анам телендә рәхәтләнеп, тәмам күңел булганчы укыйм. Журналда басылган әсәрләрнең авторларын күрмәсәм дә, хыялымда еш кына алар белән сөйләшәм, серләшәм, фикер алышам...

Кыскасы, «Казан утлары» журналы миңа бик тә ошады. Аның белән үзара якынаеп, дуслашып киттек. Шуңа күрә мин яраткан журналыма киләсе ел өчен дә язылып куйдым. Ихластан әйтәм: аннан башка тормышымның яме юк кебек!..

Шундый бай эчтәлекле, яхшы сыйфатлы журнал чыгаруыгыз өчен чын күңелдән кайнар рәхмәт Сезгә, редколлегия әгъзалары һәм редакция хезмәткәрләре! Киләчә-ктә дә безне яңа роман-повестьлар, хикәя-парчалар, шигырь-поэмалар, рәссам-нарыбызның яңа әсәрләре, язучыларыбызның төсле рәсемнәре белән гел куан-дырып торыгыз, яме?!

Сезгә нык сәламәтлек, тормышыгызның һәр өлкәсендә дә уңышлар теләп:

Кәшфи АХУНҖАНОВ, укытучы.
Башкортостан, Салават шәһәре.

## Әхмәт Юныска — 80 яшь

Кабатланмас үзгә холыклы бу шагыйрьнең биографиясе гади дә, катлаулы да... Әхмәт Юнис улы Юнысов (Әхмәт Юныс) 1916 елның 15 октябрендә Татарстанның Кукмара районындагы Әсән-Елга авылында туа. 1931 елда җидееллык мәктәп тәмамлагач, башлангыч мәктәптә укытучы, аннары мәктәп мөдире булып эшли. 1935—1937 елларда Чиләбе өлкәсендә укыта, Донбасс шахтерлары арасында пропагандист була. Шул чорда эшчеләр тормышына багышланган беренче шигырьләрен яза...

1937 елда Ә. Юныс Казанга кайта һәм Татарстан китап нәшриятында мөхәррир, «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан»), «Яшь сталинчы» («Татарстан яшьләре») газеталарында әдәби хезмәткәр булып эшли. 1939 елда, фин сугышы башлангач, үзе теләп армия сафына баса һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. 1940 елда, хәрби хезмәттән кайткач, Ә. Юныс янәдән «Яшь сталинчы» газетасында эшен дәвам иттерә. Бу елларда яшь шагыйрьнең шигырьләре һәм поэмалары тупланган «Тантана» (1939) һәм «Әсән-Елга» (1941) исемле ике җыентыгы дөнья күрә...

Бөек Ватан сугышы елларында Ә. Юныс башта Апас районының Чури-Бураш МТСы политбүлегендә эшли, аннары, армия сафына алынып, 1942—1943 елларда «Ватан намусы өчен» исемле фронт газетасы редакциясендә хәрби хәбәрче булып хезмәт итә.

1945—1949 елларда Ә. Юныс Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында укый. Диплом алганнан соң, «Яшь сталинчы» газетасы редакциясендә әдәби хезмәткәр, «Пионер» (хәзерге «Ялкын») журналы редакциясендә җаваплы сәркатиб (1951—1954) һәм Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты редакциясе мөдире (1957—1958) вазифаларын башкара.

Әхмәт Юныс — «Без кайтырбыз» (1944), «Кырларга сәяхәт» (1955), «Булдырасың болай син генә» (1963), «Канатлана күңел» (1965), «Туган җирем, сиңа җырым!» (1966), «Бәхет» (1974), «Үземнең язым» (1976) кебек шигъри китаплар авторы. Дөнья күргән шигырьләр-поэмаларында ул үзе яшәгән чорның сулышын, йөрәк тибешен чагылдырырга омтылды. Бер үк вакытта оста тәрҗемәче дә булган каләмдәшебез нәниләр өчен К. Чуковский, С. Маршак, А. Барто әсәрләрен татар телендә яңгыратты.

Ә. Юныс, озакка сузылган каты авырудан соң, 1976 елның июль аенда Казанда вафат булды. Ул 1939 елдан СССР Язучылар союзы әгъзасы иде...

Вафатыннан соң инде ике дистә ел вакыт үтсә дә, Ә. Юнысның якты исеме, башкарган эш-гамәлләре онытылмый. Каләмдәшләре, чордашлары аның, Хәсән Туфанны тоткынлыктан коткару өчен, 1947 елда Мәскәүгә, СССР Югары Советы Рәисе янына баруы турында хәзер дә гаҗәпләнеп сөйлиләр. Бу вакыйга әдәбиятчы галимебез Мәсгуд Гайнетдиновның 1989 елда Татарстан китап нәшриятында басылган «Давылларда, җилләрдә» дигән китабында да тәфсилле яктыртыла.

Якташлары да аның исемен, шушы Әсәнбаш төбәгеннән чыккан Пугачев полковнигы Мәсәгут Гомәрев, халык җырчысы Мәрьям Рахманкулова, күренекле профессорлар Мәхмүт Яхин, Фәйзелхак Газизуллин, техник фәннәр докторы, СССР Дәүләт премиясе лауреаты Фоат Шакиров, әдәбият галиме, язучы, диктор Фоат Галимуллин, Дубылтыда (Латвия) үткәрелгән яшь драматурглар семинарында дүрт дистә каләмдәше арасында беренчелекне яулаган Халисә Ниғъмәтуллина кебек шәхесләр белән бергә, олылап, «Безнең Әхмәт Юныс!» — дип телгә алалар. Бүгенге көндә Кукмараның үзендә һәм шагыйрьнең туган авылында аның исемен йөрткән урамнар бар. Хәзер исә заманында Әхмәт Юныс укыган һәм укыткан мәктәптә, аңа багышлап, музей ачарга да җыеналар... Әнә шулай, үз улын онытмый халык!..

**Шаһинур МОСТАФИН.**

## ГЕНЕРАЛЬ КОНСУЛНЫ КАБУЛ ИТҮ

Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев 4 сентябрьдә Казан Кремлендә Төркия Республикасының мәркәзебездәге генераль консулы Алпхан Шоленны кабул итте. Дусларча әңгәмә барышында А. Шолен әфәнде үз консуллыгының функцияләре, статусы һәм вәкаләтләре турында сөйләде. Төркия Республикасы Президенты С. Дәмирәл әфәндедән Татарстан белән ике яклы сәүдә-икътисадый, фәнни һәм мәдәни элемтәләрне үстерүгә зур әһәмият бирүен әйтте. Җөмһүриятебез Илбашы М. Шәймиев, Төркиянең дәүләт эшлеклесен җылы тәбрикләп, бу вакыйганың зур тарихи әһәмияткә ия булуын күрсәтеп үтте. Әлеге консуллык, Татарстаннан тыш, туган-даш Башкортостан, Чувашстан, Мари Иле, Самара өлкәсенә дә хезмәт күрсәтәчәк.

А. Шолен әфәнде шулай ук, үзенең рәсми вазифасын башкаруга керешкәнче, ТР Премьер-Министры Ф. Мөхәммәтшин һәм Дәүләт Советы Рәисе В. Лихачев белән дә очрашып сөйләште.

## В. ЛИХАЧЕВ ТАИЛАНДТА

16—20 сентябрь көннәрендә Таиландта АСЕАН (АИПО) Парламентара оешмасының Эш комитеты һәм Генераль ассамблеясе утырышы булды. Аның эшендә 15 дәүләт вәкилләре, шул исәптән Россия Федерациясе Федераль җыелышының Федерация Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе В. Лихачев җитәкчелегендәге делегациясе дә катнашты.

Парламентара оешма вәкилләреннән (Индонезия, Малайзия, Филиппин, Сингапур, Вьетнам, Таиланд) Россия делегациясе белән очрашуы вакытында Россия Федерациясе һәм АСЕАН хезмәттәшлегенең торышы, перспективалары турында эшлекле сөйләшү булды. Очрашуда катнашучыларның күпсанлы сорауларына җаваплар биреп, В. Лихачев Президент сайлауларыннан соң Россиядәге эчке сәяси хәл, Чечняда эшләрне җайга салуны цивилизацияле һәм хокукый хәл итүгә якын килү мәсьәләләре, дәүләтнең диннәргә, шул исәптән Ислам диненә мөнәсәбәте турында җентекләп сөйләде, Татарстан Республикасының халыкара элемтәләре тәҗрибәсенә киң тукталды.

## «СӨЕМБИКӘ» БӘЙРӘМ ИТӘ

Халыкара абруй казанган «Сөембикә» журналы 23 сентябрьдә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында үзенең 70 еллыгын бәйрәм итте. Юбилярны котларга илебезнең төрле төбәкләреннән һәм чит илләрдән күп кенә кунаклар килгән иде.

Бәйрәм кичәсендә журналның баш мөхәррире Роза Туфитуллова «Сөембикә»нең («Азат хатын»ның) үткәне һәм бүгенгесе белән таныштырды. ТР Премьер-министры урынбасары И. Хәйруллин юбилярга Татарстан Республикасының Мактау грамотасын тапшырды. Татарстан Дәүләт Советы Рәисенең беренче урынбасары Р. Харисов, Татарстан Мәгълүмат һәм матбугат министры И. Әхмәтҗанов, ТР Мәдәният министры урынбасары М. Низамиев, туган-даш Башкортостаннан килгән кунаклар — «Башкортостан кызы» журналының баш мөхәррире, шагыйрә Г. Юнысова-Иделбаева, «Ак калфак» берләшмәсенең Уфадагы җитәкчесе, шагыйрә һәм прозаик Д. Булгакова, Мәскәүдән Татар зыялылары клубы директоры, язучы Н. Кәримова, Чаллы шәһәре мэры Р. Алтынбаев, Аксубай районы хакимияте башлыгы М. Халитов һ. б. кайнар котладылар, бүләкләр тапшырдылар.

Соңыннан сәнгать осталары концерты булды.

## ЕВРОПАГА СӘЯХӘТ

Милли Мәҗлес һәм «Иттифак» партиясе рәисе Фәүзия Бәйрәмова чечен делегациясе составында «Тынычлык Маршы» белән Төркиядә һәм Данияда булып кайтты. «Тынычлык Маршы»ның максаты — Чечняда сугышны туктату, Чечняның бәйсезлеген тану, сугыш башлаучыларны халыкара трибуналга тарту. «Тынычлык Маршы» Төркиянең күп шәһәрләре буйлап үтте. Анда катнашучылар җирле халык, сәяси фирка җитәкчеләре һәм дәүләт эшлеклеләре, матбугат эшлеклеләре һәм галимнәр белән очрашты. Чечня бәйсезлеге мәсьәләсе буенча Анкара һәм Стамбул шәһәрләрендә зур митинглар үткәрелде, аларда Фәүзия ханым да чыгыш ясады.

Данияда «Тынычлык Маршы»нда катнашучыларны «Кеше хокукларын яклау комитеты»ның Хельсинки группасы каршы алды. Биредә илнең Премьер-министры, Скандинавия илләренең хокук яклаучылары, аерым министрлар, галимнәр һәм матбугат әһелләре, Данияда яшәүче мөселманнар белән дә очрашулар булды. Аларның парламентлары каршына Чечняның бәйсезлеген тану мәсьәләсе куелды.

## ХАЛЫКАРА СЕМИНАР-СИМПОЗИУМДА

26—29 августта Анкара шәһәрендә төрки дөньясы әдәбиятчыларының халыкара

семинар-симпозиумы булды. Аны Ататөрек исемендәге мәдәни мәркәз үткәрде. Семинар-симпозиумда, Төркия, Әзербәйҗан, Үзбәкстан, Казагыстан, Кыргызстан, Уйгурстан галимнәре белән берррәттән, Казан университеты профессоры, «Казан утлары» журналының редколлегия әгъзасы Хатыйп Миңнегулов та катнашты һәм чыгышлар ясады.

Галимнәр корылтаенда 30 томлык төрки дөньясы әдәбиятлар тарихын, энциклопедиясен, антологиясен, терминнар сүзлеген язуның торышы, бу эшне тагын да камилләштерү мәсьәләләре каралды.

## «ОСТАБИКӘ» — ТӨРКИЯДӘ

Чаллы шәһәренең «Остабикә» фольклор ансамбле Төркиядә булып, зур уңыш казанып кайтты. Әлеге илнең Президенты С. Дәмирәл белән очрашу, Э. Гази исемендәге фестивальдә катнашу, «Евразия-Төркия» халыкара телеканалы тапшыруларында чыгыш ясау, тугандаш мөселман җөмһүриятенең күп кенә шәһәрләрендә һәм авылларында концертлар кую, халык белән якыннан аралашу күңелләрдә җуелмас якты хатирәләр калдырды.

Әлеге гастрольләрне Татарстанның Балалар һәм яшьләр эше дәүләт комитеты оештырган иде.

## АРАЛАР ЯКЫНАЯ

Екатеринбургта Татарстан Республикасының даими вәкиллеген ачу тантанасы булды. Анда хөкүмәт һәм шәһәр хакимияте вәкилләре, эре эшкуарлар һәм банкирлар, шулай ук Уралдагы чит ил консуллыкларының җаваплы хезмәткәрләре катнашты. Татарстан делегациясен ТР Дәүләт Советы сәркатибе Н. Әбдрәшитова җитәкләде. Олы кунакларны Свердловск өлкәсе губернаторы Э. Россель кабул итте.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ

Җөмһүриятебез язучылары оешмасының чираттагы идарә утырышында халкыбызның бөек әдибе Гаяз Исхакыйның тууына 120 ел тулу юбилеен 1997 елның февраль аенда олылап үткәрү чаралары каралды.

Шул ук утырышта Татарстанның халык язучысы, проза остасы Фатих ага Хөсни исемендәге бүләк булдыру турында да карар кабул ителде. 5 миллион сум күләмендәге әлеге бүләк һәр елны матбугат битләрендә дөнья күргән һәм татар әдәбиятының күркәм традицияләрен уңышлы дәвам итә алган иң оста, зәвыклы язылган хикәя авторына биреләчәк.

Утырышта оештыру мәсьәләләре дә каралды. Татарстан Республикасының Зур концерт залына директор итеп билгеләнгән Мансур Шиһапов урынына, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары итеп Әхмәт Гадел (Гаязов) расланды.

## ЧИСТАЙДА — ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ КӨННӘРЕ

17—19 сентябрь көннәрендә Чистай районында татар әдәбияты көннәре үткәрелде. ТР Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев җитәкчелегендәге бер төркем язучылар иң элек район һәм шәһәр хакимияте җитәкчеләре белән очраштылар, бередәге атаклы сәгать заводында, музейларда булдылар, район мәдәният сараенда чыгыш ясадылар. Аннары язучылар (алар арасында Татарстанның халык язучысы Ә. Еники, халык шагыйрьләре Ш. Галиев, И. Юзиев, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Р. Фәйзуллин, танылган прозаиклардан К. Тимбикова, Б. Камалов, Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары Ә. Гадел, тәнкыйтьче Ф. Галимуллин, «Идел» журналыннан шагыйрь Р. Зәйдулла, «Салават күпере» журналының баш мөхәррире З. Хөснияр һ. б. бар иде), төркемнәргә бүленеп, районның Каргалы, Мөслим, Гаделша, Дүртөйле авылларында халык белән очраштылар, мәктәпләрдә һәм мәдәният йортларында чыгыш ясадылар.

19 сентябрьдә язучылар бөек әдибебез Гаяз Исхакый туган Яушырмә авылына килеп, аның изге туфрагына баш иделәр. Алар биредә 1997 ел февралендә ачылачак әдәби тарихи музейның тупланып килүче экспонатлары белән таныштылар, мәктәп балалары һәм авыл халкы белән очраштылар.

## БЕРЕНЧЕ ЛАУРЕАТЛАР

Милли балалар әдәбиятын үстерү һәм баетуны күздә тотып, Татарстан Язучылар берлеге бу өлкәдә иҗади уңышларга ирешкән каләм ияләренә ел саен атаклы язучы-патриот Абдулла Алиш исемендәге премия бирергә карар кылган иде. Һиһаять, быел сентябрь аенда беренче лауреатларның исемнәре мәгълүм булды. Алар — күренекле балалар язучысы, проза остасы Ләбибә Ихсанова һәм Татарстанның халык шагыйре Шәүкәт Галиев. Лауреатларга махсус диплом һәм 600 доллар күләмендә акчалата бүләк тапшырылды.

## ГАБДУЛЛА ШӘРӘФИ КИЧӘСЕ

Татарстан язучыларының Г. Тукай исемендәге клубы үзенең быелгы сезонын күренекле язучы-фронтовик Габдулла Шәрәфинең 70 еллык бәйрәм кичәсе белән башлап җибәрде. Юбилярны ТР Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев, Татарстанның халык язучысы Ә. Еники, Татарстанның халык шагыйре Ш. Галиев, прозаиклар Л. Ихсанова, М. Хуҗин, М. Хәбибуллин, М. Маликова, шагыйрьләр Р. Әхмәтҗанов, Р. Әхмәт һ. б. кайнар котлады. Заманында Г. Шәрәфи эшләгән «Сөембикә» журналы коллективы исеменнән әдипне баш мөхәррир урынбасары М. Әмирханов һәм бүлек мөхәррире Р. Камалетдинова тәбрикләде. Якташлары — Биектау районы вәкилләре, «Спутник» акционерлык җәмгыяте җитәкчеләре юбиляр адресына җылы сүзләрен әйттеләр, бүләкләр тапшырдылар.

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт драма академия театрының атаклы артистлары Н. Ихсанова, Р. Тажетдинов тыңлаучыларны язучының аерым хикәяләре белән таныштырдылар. К. Хәйретдинова, Л. Бичарина, З. Хәйретдинов, Г. Шаһиев кебек танылган җырчылар исә кичәдә юбиляр яраткан әсәрләрне башкардылар.

## ЯЗУЧЫ — АКАДЕМИК

Үзәге Санкт-Петербургта булган Россия гуманитар фәннәр Академиясе сафларында Татарстаннан М. Хәсәнов, Т. Галиуллин, Ф. Мусин кебек билгеле татар әдәбиятчылары бар иде инде. Хәзер аларга фән һәм укыту өлкәсендә озак еллар нәтиҗәле эшләп килүче Хатыйп Миңнегулов та кушылды. 17 сентябрьдә аңа Россия гуманитар фәннәр Академиясенең хакыйкый әгъзасы булып сайлануы турындагы таныклык (диплом) тапшырылды.

Филология фәннәре докторы, Казан дәүләт университеты профессоры, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасының Дәүләт бүләге лауреаты, журналыбызның редколлегия әгъзасы һәм даими авторы Хатыйп Йосыф улы Миңнегуловны академик булуы белән ихлас күңелдән котлыйбыз!

## ШАГЫЙРЬ ИСЕМЕНДӘГЕ УРАМ

Вакытсыз арабыздан киткән талантлы, фидакарь шагыйрь — «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире Рәшит Әхмәтҗановның якты исемен мәңгеләштерү буенча якташлары тагын бер изге гамәл кылдылар. Хәзер Баулының элекке Санаторий урамы аның исемен йөртә.

## КОРЪӘН БАСЫЛДЫ

Татарстан Республикасында беренче тапкыр гарәп телендә Корьән дөнья күрде. Җөмһүриятебезнең газета-журналлар нәшрияты мөселманнарның изге китабын 10 мең данәдә бастырды. Алар республикабыз мәчетләренә таратылачак.

## РӘССАМНЫҢ ДҮРТЕНЧЕ КҮРГӘЗМӘСЕ

Казанның М. Горький исемендәге әдәби-мемориаль музеенда Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Шамил Шәйдуллинның нәфис сәнгать әсәрләре күргәзмәсе булып үтте. Әлеге рәссам пейзаж, натюрморт, портрет, графика жанрында уңышлы эшли. Аның күп кенә иҗади хезмәтләре илебездәге төрле музейларда һәм картина галереяларында, шулай ук АКШ, Алмания, Австрия, Төркия һәм Франциянең шәхси коллекцияләрендә саклана.

Мәркәзебездә үткәрелгән дүртенче күргәзмәсендә Ш. Шәйдуллин сәнгать сөючеләрне үзенең соңгы елларда иҗат иткән 50 әсәре белән таныштырды.

## НӘККАШ НӘКЫШЬЛӘРЕ

Татарстан нефтьчеләре башкаласы Әлмәт шәһәрендә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының гыйльми хезмәткәре, күренекле каллиграф-галим, күп кенә шәмаилләр һәм тугралар (шәхси герблар) авторы Нәҗип Нәккаш хезмәтләреннән торган күргәзмә ачылды. Әлеге үзенчәлекле остаһың китапларны һәм журналларны бизәүче график әсәрләренә дә бирәдә урын мулдан бирелгән. Рәссам борынгы каллиграфия сәнгатен торгызу, аңа кабатланмас янадан-яңа бизәкләр — төсмерләр өстәү юнәлешендә армый-талмый эшли. Элгәре аның шәхси күргәзмәсе башкалабызның Г. Тукай музеенда да күрсәтелеп, сәнгать сөючеләр тарафыннан югары бәһаләнгән иде.

## УФА ЯШЬЛӘРЕ — КАЗАН КУНАКЛАРЫ

14—21 сентябрь көннәрендә Уфа шәһәреннән Башкортостанның Милли яшьләр театры артистлары Казан тамашачыларына үзләренең иң яхшы спектакльләрен күрсәттеләр. Алар арасында М. Кәримнең «Салават» трагедиясе, Ә. Атнабаевның «Мәхәббәт турында җыр» драмасы, Ш. Рәхмәтуллинның «Уеннан — уймак» әсәре бар иде. Театрның рус труппасы Лопе де Веганың «Дурочка», А. Чеховның «Чайка» әсәрләрен сәхнәләштергән иде. Театрның директоры Е. Климов, сәнгать җитәкчесе — Башкортостан Республикасының атказанган артисты А. Надерголов һәм башка барлык яшь сәхнә осталары казанлыларның ихлас рәхмәтенә, көчле алкышларына, бихисап чәчәк бәйләмнәренә лаек булдылар.

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** «Сөембикә» — Васил Ханнанов картинасыннан фотокүчермә.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** язучы Рәфкать Кәрами.

# ЯҢА КИТАПЛАР

Айдар ХӘЛИМ. **Гомеремнең ун көне яки Бер җинаять эзеннән.** Тольятти шәһәрендә басылган. 1996. 672 б. *(иллюстрацияләр белән)*. Тиражы — 10 000 данә.




Айдар Хәлим — шагыйрь һәм язучы буларак әдәбият сөючеләргә яхшы ук билгеле булса да, киң даирә укучылар өчен ул, беренче чиратта, кайнар публицист һәм тынгысыз җәмәгать эшлеклесе буларак ныграк мәгълүм. Моннан биш ел элек Литвада рус телендә басылып чыккан «Книга печали, или записки аборигена» китабы бу фикерне ныгытучы саллы дәлил булды һәм ул татар иҗтимагый дөньясында зур резонанс та алды.

«Гомеремнең ун көне...» исә, күләме ягыннан булсын, эчтәлеге ягыннан булсын — татар публицистикасы тарихында моңарчы күрелмәгән вакыйга. Әсәрнең нигезен — авторның Уфа шәһәренең үзәк мәйданында (1990 ел, октябрь) сәяси ачлык игълан итү белән бәйләнешле хәлләр, гомумән, 50 дән узган әдипнең Идел һәм Урал буе республикаларындагы сәяси һәм әдәби хәрәкәткә караган вакыйгалар, шәхесләр турында уйлану-кичерешләре тәшкил итә. Китапның титул битендә мондый юллар бар: «Авторның бу яңа китабы, фельетон жанры белән билгеләнсә дә, көлкетәнкыйтьтән бигрәк, газиз халкының ачы язмышы өчен шагыйрь йөрәге әрнешләре белән сугарылган». Әсәрнең аерым өлешләре 1995 елда журналыбыз битләрендә дөнья күргән иде инде.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЬ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)